ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**ГАЯЗ ИСХАКЫЙ**

# КӨНДӘЛЕКЛӘР

3 китапта

**1 нче китап**

**1919–1920**

Казан
2023

УДК 94 (093.3)
ББК 63.2
И 91

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Редколлегия:**
*К.М. Миңнуллин (җитәкче), Д.Ф. Заһидуллина,
Ә.М. Закирҗанов, Э.М. Галимҗанова, И.Г. Гомәров*

**Фәнни мөхәррир**
*Э.М. Галимҗанова*

**Төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны
әзерләүчеләр:**
*Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова*

**Исхакый Г.**
И 91 Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2023. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-448-1

Китапта татар милләтенең мәнфәгатьләрен яклап, аның бәйсезлеге өчен көрәшкән әдип Гаяз Исхакыйның (1878–1954) Токиодан Парижга кадәрге сәфәрен яктырткан көндәлекләре (1919 –1920) урын алды.

Басма татар әдәбияты, мәдәнияте һәм тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

УДК 94 (093)
ББК 63.2

ISBN 978-5-93091-448-1

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2023
© Д.Ф. Заһидуллина, кереш сүз, 2023
© Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова,
гарәп язуыннан гамәлдәге татар язуына күчерү,
искәрмәләр һәм аңлатмалар әзерләү, 2023

## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Узган гасырның 90 нчы елларында Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә татар әдәбияты классигы, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның (1878–1954) шәхси фонды оеша башлый. 2008 елда язучының юбилее уңаеннан Төркиянең «Аяз – Таһир (Төркестан – Идел-Урал)» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакый мирасының бер өлешен: документлар, хатлар, көндәлекләренең электрон күчермәләрен, ә 2018 елда исә төп нөсхәләрен әлеге мирасханәгә тапшыра.

Бу материаллар арасында иң кыйммәтлесе – аның үз кулы белән язып барган көндәлек дәфтәрләре.

Көндәлекләренең әһәмиятен ассызыклап, Г. Исхакый үзенең васыятьнамәсендә: «…Дәфтәрләремнең кыйммәте – тарихи һәм мәгънәви ягында. Һәм бу дәфтәрләрнең эчтәлеге киләчәктә Идел-Урал төрки-татар мөселманнарының милли хәрәкәтләренең зур әһәмиятен яктыртачак...»[1], – дип язып калдырган. Әлеге көндәлекләрдә Г. Исхакыйның 1919 елның 26 апреленнән 1953 елның 10 ноябренә кадәрге мөһаҗирлектәге хәяты яктыртыла.

Гаяз Исхакый, Россиядән чыгып киткәннән башлап, көндәлек дәфтәрләре алып бара. Солых сәфәренә ул, үзе әйтеп киткәнчә, 1919 елның 24 гыйнварында кузгала. Ул бу хакта: «Бүген 24 нче гыйнвар. Мин үткән елны шул көнне солых сәфәренә чыгып киткән идем. Инде ел тулды», – дип яза *(1920, 24 гыйнвар)*.

Көндәлекләр ике өлештән тора. Беренчесе – 1919 елдан 1932 елга хәтле, Төркиягә кадәрге чорны эченә алган 23 дәфтәр. Аларның 21 е 1919 елдан 1921 елга кадәр язылган. 1921 елдан

---

[1] *Исхаков М.Г.* Әсәрләр: 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф.Г. Фәйзуллина]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 410.

1928 елга хәтле көндәлек язу эше тукталып торган. 1928–1932 еллардагы хатирәләр 2 дәфтәргә тупланган. Шул еллардан соңгы көндәлек дәфтәрләре югалган булса кирәк. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында көндәлекләрнең бер өлеше юкка чыгуы хакында ул васыятьнамәсендә дә әйтә. Г. Исхакый 1943 елдан көндәлекләр алып баруны яңа исәптән башлый һәм «Истанбулдагы хатирә дәфтәрләрем» дип атый. Төркия чорына караганнары – 19 дәфтәр.

Әлеге китапта Г. Исхакыйның Төркиягә кадәрге чорда язылган көндәлекләренең 2–17 нче (барлыгы 16) дәфтәрләре тәкъдим ителде. Кызганыч, көндәлекләрнең 1 нче дәфтәре сакланмаган.

Язмалар төрле күләмдәге дәфтәрләргә кара белән гарәп графикасында язылган. Кайбер очракларда, сүзләрнең укылышын дөрес бирү максатыннан булса кирәк, аерым сүзләр яки атамалар латин хәрефләре белән яки кириллицада бирелгәннәр.

Китапка текст кыскартуларсыз, дәфтәрләргә бүленеше дә чыганактагыча үзгәртелмичә (кайбер сүзләр, җөмләләр бүленгән хәлдә) урнаштырылды.

Көндәлекләр төрле шартларда язылганга күрә, кульязманы уку шактый авыр. Шул сәбәпле кайбер укылмый калган сүзләр шакмак җәяләр эчендә өч нокта [...] белән күрсәтелде. Җөмләләрдә кайбер сүзләр төшеп калу, сүзләргә кушымчалар ялганып бетмәү очраклары да еш очрый. Андый урыннарда шакмак җәяләр эчендә җөмләләр тулыландырылды. Тыныш билгеләре хәзерге пунктуация кагыйдәләренә туры китереп куелды.

Укучыларга текстны үзләштерүне җиңеләйтү максатыннан, алынма сүзләргә, аңлашылмаган гыйбарәләргә сүзлекләр тәкъдим ителде. Шәхесләр һәм географик атамаларга, кайбер тарихи вакыйгаларга искәрмә һәм аңлатмалар астөшермәләрдә йолдызчыклар (*) белән урнаштырылды.

Китапның кушымта өлешендә Гаяз Исхакыйга һәм шул еллардагы вакыйгаларга бәйле фотосурәтләр бирелде.

ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре тарафыннан «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» җыентыгының

Г. Исхакыйга багышланган 5 нче чыгарылышында (2018), көндәлекләр белән таныштыру максатыннан, беренче тапкыр 2–6 нчы дәфтәрләр, шактый гына кыскартулар белән, укучыларга тәкъдим ителгән иде. Биредә әлеге дәфтәрләр дә кульязма чыганактан яңадан тулыландырылып эшләнделәр.

Текстлар Институтның текстология бүлеге хезмәткәрләре Ә.Х. Алиева (7, 8, 9, 10, 11 нче дәфтәр), Ф.Г. Фәйзуллина (2, 3, 5, 6, 16, 17 нче дәфтәр) һәм Г.М. Ханнановалар (4, 12, 13, 14, 15 нче дәфтәр) тарафыннан әзерләнде.

Әлеге көндәлекләрнең дөньяга чыгуы Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлек чорындагы тормышы һәм эшчәнлегенең томанлы сәхифәләрен киңрәк ачып, киләчәктә көрәшче-әдип белән бәйле төрле вакыйга һәм фактларны киңрәк яктыртырга, иҗатын һәм эшчәнлеген эзлекле рәвештә дөрес бәяләргә ярдәм итәр дигән өметтә калабыз.

# «ШУЛ ӨМИДСЕЗ ИСТИКЪБАЛЬ АЛДЫНДА РУХЫМЫЗДАГЫ ПАКЬЛЕКНЕ САКЛЫЙ АЛЫРМЫЗМЫ?»

«Гаяз Исхакый көндәлекләре» исеме үзе үк татар мәдәнияте белән таныш укучыда зур кызыксыну уята торгандыр. Чөнки бөтен дөньяга танылган мәшһүр татарлар арасында да тормыш юлындагы борылышлар теләсә нинди детектив романнарның коллизияләреннән дә текәрәк булган, Галиҗәнаб язмыш шулкадәр биеклекләргә күтәргән һәм билгесезлекләргә ташлаган, әмма үзе сайлаган мәсләгенә – татар халкының милли үзаңын үстерүгә һәм алгарышына – тугры кала алган Исхакыйга тиң сәясәтчене, фикер иясен, әдәби иҗат әһелен аерып күрсәтү җиңел түгел. Аңа, өйрәнчек әсәрләре мәйданга чыгуга, бик хаклы рәвештә, «татар дөньяви әдәбиятының беренче классик әдибе» дигән бәя бирелгән – ул бүген дә шулай кабул ителә. Исхакыйга татар милләтенең көрәш шигарен – «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!» лозунгын яңгырату һәм шуның тирәсенә кавемдәшләрен туплау насыйп булган! Аңа дөньяның иң атаклы мөнбәрләреннән, татар халкының мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклап, ялкынлы чыгышлар ясарга язган! Татар халкының, Татарстанның бүгенге уңышларында аның акыл-гыйлем, каләмэшчәнлек өлеше зур булу беләүдә дә шик уятмый.

Шул ук вакытта Исхакый – яп-яшь килеш татар авылыннан Россия киңлекләренә чыккан, төрмәләргә ябылган һәм сөргеннәргә сөрелгән, дөньяның бөек акыл ияләре белән фикердәш булган, чит җирләрдә «милләтем» дип даулаган, гомеренең яртысын диярлек мөһаҗирлектә үткәргән, әмма юлының хак булуына шикләнмәгән көрәшче шәхес тә.

Аның романнарга тиң тормыш юлында «ак таплар» күп булган кебек, гаять киң карашлы, үткен фикерле, үзенә һәм башкаларга таләпчән, кыю һәм көчле холыклы асылы, тормыш позициясе белгечләрдә дә еш кына сораулар уята.

Әлеге сорауларның бер өлешенә җавап – әдип үзе мөмкинлек булганда көн саен язып барган көндәлекләрдә, әлбәттә. Укучы кулына тәкъдим ителә торган шушы басма – «Гаяз Исхакый көндәлекләре»нең 1 нче китабы. Әлеге китапка әдипнең 1919 елның 26 апреленнән 1920 елның 10 мартына кадәр аралыкта күргәннәре-кичергәннәрен туплаган 16 көндәлек дәфтәре керде. Алар бербөтен сюжетка, уртак чишелешкә ия кебек тоела, чөнки «өметсез истикъбаль», ягъни киләчәк билгесез бер вакытта Европага барып, татар халкының хәлен дөнья сәясәте мәйданында яңгырату бурычын үтәргә омтылу, тырышу-тырмашу, тартышу тарихы кебек укылалар. 2 нче көндәлек дәфтәре 1919 елның апрелендә Япониянең Токио шәһәрендә башланып китә. Токиода, Йокоһамада, Харбинда ярты елга якын Франция, Германия, Англия, Америка, Швеция, Голландия һ.б. консуллыклар аша Европага китәргә рөхсәт-виза, Милли Идарәдән документлар һәм юлдашлар көтеп торган Исхакый ахырда чех солдатлары белән диңгез аша Прагага барып җитә, шуннан, дөнья гизеп, Парижга килеп ирешә.

Аерым бер кеше күргән-кичергәннәрне тасвирлаудан тыш, әдәби иҗатны һәм тарихи барышны, көндәлек тормышны һәм шәхси караш-фикерләрне бер үремтәдә укучы игътибарына тәкъдим итә торган уникаль текстлар буларак көндәлекләр мәдәният тарихында да аерым бер югары урын тоталар. Чөнки аларда «бүген үзем күргән» картина-сурәт һәм фактлар теркәлеше, вакыйгаларның шәхси кичерешләр дулкынында күрсәтелүе чынбарлыкны тергезә һәм аны ихласлык белән сугара. Гаяз Исхакый көндәлекләре дә тарихи барышны, вазгыятьне ачыктан-ачык, ышандырырлык итеп аңлатуы белән кыйммәтле.

Көндәлекләрнең бу өлеше татар халкы язмышында борылыш вакытына туры килгән 1917 елдан соңгы вакыйгаларны күз алдына куя, шәрехли. Аларда сүз барган хәлләрне аңлар өчен, күпмедер күләмдә тарихи аңлатма биреп китү дә сорала.

Беренчесе – Милләт Мәҗлесе оешу[1]. 1917 ел инкыйлаблары дәверенә килеп кергәч, Россиядә хакимият үз көчен югалткан бер вакытта татар зыялылары, үз халкының бердәмлеген саклау

---

[1] Кара: https://tatarica.org/tat/razdely/istoriya/novejshee-vremya/znachimye-sobytiya/millt-mlese Онлайн-энциклопедия Tatarica

һәм XX йөз башында башланган милли-мәдәни үсешен дәвам итү өчен, махсус чаралар эшләү һәм аларны тормышка ашыру кирәклеген аңлыйлар. Шундыйлардан, II Бөтенроссия мөселман корылтае (1917 елның 21 июле – 2 августы, Казан), Эчке Россия һәм Себер мөселманнары эшчәнлеге белән идарә итү, кавемдәшләренә иҗтимагый-сәяси вазгыятьне аңлату һәм аларның фикерен уртак бер юлга юнәлтү максатыннан, Милләт Мәҗлесе җыю турында карар кабул итә. Ул 1917 елның 20 ноябрендә Уфа шәһәрендә оеша. Рәисе – С. Максуди, рәис урынбасары – И. Әхтәмов, сәркатибе итеп Г. Фәхретдинов сайлана.

Мәҗлес барышында милләтнең киләчәктә бердәмлегенең ике моделен алга сөргән ике фракция бүленеп чыга: төркичеләр – Эчке Россия һәм Себер төркиләренең милли-мәдәни мохтарияте яклылар (бертуган Максудилар, Г. Исхакый, З. Кадыйри, Г. Терегулов һ.б. – барысы 50 ләп кеше); туфракчылар – Идел-Урал Штаты формасындагы автономия яклылар (И. Алкин, С. Атнагулов, Һ. Атласов, Г. Баттал һ.б. – барысы 37 кеше). Татарларның бер урында тупланып түгел, ил буйлап сибелеп яшәвен истә тотып, беренче төркем аларны милләт, тел, дин, уртак карашлар нигезендә берләштерү идеясен алга сөрә. Икенче төркем бу бердәмлекне билгеле бер территориягә беркетүне мөһим дип саный. Аларның һәр икесе, татарлык асылын саклап, халыкны үстерү турында сүз алып бара.

Милләт Мәҗлесе Совет хөкүмәтен рәсми танымый, аның утырышларында, милли-мәдәни мохтарият законнарын эшләү белән беррәттән, советлар режимына мөнәсәбәт, диннең дәүләттән аерымлануы, Идел-Урал территориаль автономиясе оештыру, аның хөкүмәте урнашыр өчен урын сайлау кебек мәсьәләләр дә карала.

Икенчесе – Милләт Мәҗлесенең Югары башкарма органы – Милли Идарә[1]. Ул 1918 елның гыйнварында Милләт Мәҗлесе депутатлары тарафыннан сайлана, 3 юнәлеш: Малия (финанс), Мәгариф һәм Диния министрлыклары булдырып, Уфа шәһәрендә эшкә керешә.

---

[1] Кара: https://tatarica.org/tat/razdely/istoriya/novejshee-vremya/znachimye-sobytiya/millt-mlese Онлайн-энциклопедия Tatarica

Әмма Совет хакимияте һәм милли хәрәкәт җитәкчеләре арасындагы мөнәсәбәт кискенләшә башлагач, 1918 елның башында күп кенә депутатлар большевиклар кулында булмаган җирләргә күченә башлыйлар. Милләт Мәҗлесе һәм аның Идарәсе исә, большевиклар басымына үзләре генә каршы торырга көчләре җитмәсен аңлап, милләтнең бердәмлеге өчен борчылып, татар халкының мәнфәгатьләрен Европаның иң абруйлы сәяси мәйданнарында – Версаль солых конференциясендә яки Париж тынычлык конференциясендә яңгыратырга кирәк дигән карар кабул итә. Шул вакытта Европа илләре һәм Америка Кушма Штатлары татарларны яклап чыгар, Советлар каршында аларның хокукларын исәпкә алу кирәклекне кискен итеп куяр дигән ышаныч Г. Исхакыйны да бу эшкә алынырга рухландыра.

Милли Идарә әгъзаларының бер өлеше белән Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә килгән Г. Исхакый монда «Маяк» исемле газета чыгара башлый, бер үк вакытта Европа парламентларына барып ярдәм сорау өчен әзерлек эшләренә керешә.

1918 елның 28 февраленә каршы төндә Мәҗлеснең кайбер җитәкчеләре кулга алына, 21 апрельдә Милли Идарә таратыла, 25 апрельдә бу юнәлештәге оешмалар ябыла. Исхакый исә, Япония аша Европага барып, үзенә йөкләтелгән олы миссияне башкарып чыгар өчен, юлга кузгала. Көндәлекләр әдипнең Кызылъярдан 1919 елның 24 гыйнварында чыгып киткәнлеген хәбәр итә. Гомумән алганда, әлеге дәфтәрләрдә Исхакый биографиясенә кагылышлы бик күп даталар ачыкланганны аерып әйтергә кирәк.

Бу елларның иң караңгы, канлы сәхифәләре Гражданнар сугышы белән бәйле була. Ул 1918 елның 17 маенда Чехословак корпусының баш күтәрүеннән соң башлана, 1922 елның 25 октябренә кадәр дәвам итә. Советлар, Ак гаскәрләр, милли хәрәкәтләр арасында барган аяусыз көрәш большевикларның җиңүе белән тәгәлләнә. Исхакый Япониягә чыгып киткән вакытта, илдә шушы сугыш бара. Татар зыялыларының, халык язмышын кайгырткан милләтпәрвәрләрнең дә язмыш кайсысын кайсы якка ташлый: кемдер мобилизациягә эләгә, кемдер чит илгә кача, кемдер кулга алына... Элемтәләр булмау, кавемдәшләреннән һәм Милли Идарәдән хәбәрләрне айлар буе көтеп тору шуның белән аңлатыла.

Шулай итеп, «Гаяз Исхакый көндәлекләре»нең 1 нче китабы кешеләрдәге «киләчәкнең өметсезлеге» халәтендә татар халкын якларга дип озын һәм авыр юлга чыккан әдипнең күргәнкичергәннәрен тергезә. Үз чиратында анда илдә барган хәлләр, татар җәмәгать эшлеклеләренең фикер-карашлары, зыялылар арасындагы мөнәсәбәтләр, әдипнең үз тормыш позициясе бик ачык чагылыш таба.

Әйтик, 9 августта – Мәскәүдән качып киткәненә бер ел тулган көнне – ул үткәннәрен искә төшерә. Мәскәүдә үзенә революцион трибуналда хөкем чыгарырга әзерләнгәннәрен, качып, Казан аша Самарага, аннары Уфага килүен, Милли Идарә эшләрендә катнашуын, Милли Идарә белән Кызылъярга күченүен сөйләп уза. Европага эләгү максаты белән, Харбинга юл алуын, аннары Япониягә юнәлүен әйтә.

Япониядә аерым бер шәхесләр – сәясәтчеләр, журналистлар белән очрашулар вакытында сөйләшүләрне шактый тулы, сүзгә-сүз диярлек кабатлап, әдип аларда үзенең иҗтимагый-сәяси карашларын да яктырта. Әйтик, 5 майда маркиз Окума белән очрашу вакытында Исхакый әңгәмәдәшенә нинди максат белән Европага юнәлүен аңлатып үтә: «Русиянең әхвале хәзер бәйнәлмиләл *(халыкара)* бер хәл алды. Русия халкы үзеннән-үзе үз мәсьәләсене хәл итәчәк түгел. Русиянең идарәсе, Русиядәге милләтләрнең хокуклары Европада хәл ителәчәк, шуның өчен утыз миллионлы төрек кавеменең теләген ишеттерер өчен, беренче уларак, сезгә килдек. Сезне кардәш дип, кайгымызны сөйләргә килдек, аннан Европага китәчәкмез. Максатымыз – киләчәктәге Русиянең төзелешендә безнең тавышымызны ишеттерү, милли гаямезне *(омтылышыбызны)* вөҗүдкә чыгару. Милли гаямез бу: Төркестан, Казакъстан, Кырым, Кавказ, Идел буе өчен аерым-аерым штатлар ясау һәм дә шулар арасында мәдәни берлекне тәэмин итү. Без – бер милләт. Исемемез – төрек милләте. Кабиләләремез аерым булса да, тарихымыз, телемез, әдәбиятымыз бер. Русиядә безнең зур урынымыз бар, шуңарга муафикъ хокукымыз булырга тиеш». Бу өзектән Исхакыйны айлар буе кысынкылыкта яшәргә мәҗбүр иткән идеяне аерып чыгару авыр түгел.

Әдип Японииядә күп кенә рәсми әңгәмәләрдә катнаша, аларда япон һәм төрки-татарларның бергә булганда гына үз милли асылларын саклап кала алачагы, җәмгыятьләрендәге икътисади-мәдәни үсешне тәэмин итәчәге көндәлекләр буена аерым язмаларда искәртелеп килә *(8 май язмасы)*.

Болар арасында Исхакыйның шәхси сәяси позициясен аңлатканнары да бар. Әйтик, 12 май язмасында Милли Идарә белән эсерлар кул астындагы Себергә чыгып киткән Исхакыйның Колчак хөкүмәте сәясәте белән килешмәве, аннан татар халкына, башка милләтләргә файда булмас дип каравы дәлилләнә.

Көндәлекләр Японииядәге көнитешне: гаиләләрдәге тормыш, музейлар, китапханәләр, мәктәпләр һәм югары уку йортларын, театрларны, көндәлек һәм бәйрәм вакыйгаларын – татар дөньясы белән чагыштырып, сөйләп бара. Японииядәге аерым бер мәдәни күренешләр әдиптә аларны татарларда да булдыру фикерен дә уяталар.

Шул ук вакытта Исхакыйның татар дөньясына кагылышлы күзәтүләре дә кызыклы. Әйтик, 22 май көнне әдип «Хочи Шимбун» идарәсендә татар хатын-кызлары турында интервью бирә. Исхакый татар хатын-кызының хөр фикерле, укымышлы, эшчән, үз хокуклары өчен көрәшә торган образын сурәтли. Әйтик, «Хатын-кыз арасында үз хәятын үзе тәэмин итә торганнары бармы, булса, нинди эшләрдә булыналар?» дигән сорауга ул: «Бар һәм дә күп. Хатыннарның иң зур эше – хәзердә мөгаллимәлек. Аннан соң бик күп хатыннар читек-кәвеш каеп, калфак, кәләпүш эшләп, хәятларын тәэмин итәләр. Соңгы елда хатыннарымыздан докторлар, адвокатлар да бар, зур мәктәпләрдә мөгаллимәләр бик күбәйде, елдан-ел күбәя бара», – дип җавап бирә. Ирләр белән тигез хокуклылык турындагы сорауга да уңай җавап биреп, мисалга Мөхлиса Бубиның казыя итеп сайлануын китерә, зур горурлык белән: «Хәзерге көндә казый хатын бөтен ислам галәмендә фәкать бездә генә бардыр», – дип өсти. «Татар хатынының иң зур хосусияте нәрсә?» дигәндә, язучы аның иренә терәк һәм таяныч була алуын искәртә: «Иреннән аерылмавы һәм дә иренең кайгысыны-шатлыгын һәрвакыт бер итүе. Ире Себергә китсә, татар хатыны Себергә китә, ире чит мәмләкәткә чыкса, анда китә. Монын

аркасында гаилә мохафаза ителә *(сакланып кала),* татар гонсыры әрәм булып әләф-тәләф булмый». Шул рәвешле, әдип япон җәмгыяте алдында татар хатын-кызының гаилә сакчысы, милләт сакчысы, аның якты киләчәген тәэмин итүче булуы турындагы югары бәясен тагын бер кат ассызыклап уза.

Көндәлекләрдә табигать, тормыш сурәтләре күз алдына килеп баса, язучының оста каләме һәр мизгелне укучы күңеленә китереп бәйли. Бер яктан, ул үзен олы җиһанның матурлыгын күзәтүче итеп тоя («Хәятның һәр тәмле, татлы манзаралары алдында сәерче булам торам», *22 май*). Шунда ук үкенеч һәм канәгатьсезлек күренеп китә: «Хәятның матур дулкынларыннан читтә калдым».

Әдипне «Дөрес юл белән бараммы?», «Эшләремнең нәтиҗәсе булырмы?» кебек сораулар борчыганы көндәлекләр буйлап аерым җеп булып сузыла. Әйтик, 25 май көнне бер хатын-кыз япон рәссамы каберен зиярәт иткәндә үзенең визит карточкасын калдырып, ул күңеленә килгән мондый уйлары белән уртаклаша: «Без бит – икемез дә Олуг Асиянең үзенең кадерен үзе белми торган балаларына үзенең кыйммәтле якларын күрсәтергә тырышучы, үзенең хәятының матурлыкларын күз алдына китереп, асияленең үзенә үзенең ышануын уятырга теләгән җүләрләре. Син инде үлгән, мин әле йөрим, ләкин син бер эз калдыргансың, мин дә бер эз калдырачакмын. Бик ихтимал, синең рәссамлыкта ясаган Асиялек эзеңне күзен акайтып, европалы хәят артыннан чаба торган япон гәнеҗе *(яше)* таптап киткәндер. Китмәгән булса китәчәктер. Минем милли хәятымызда калдырырга теләгән эземне дә, бәлки, руслык кары, русларга тәкълид *(ияру)* басып киткәндер йә китәчәктер. Ләкин без үз вазифамызда булырга тиеш...» Шул рәвешле, үз халкының якты киләчәге өчен тартышуының ахыргы максатына ирешү-ирешмәү хакында икеләнүләр вакытында да Исхакый үз эшчәнлеген язмыш тарафыннан йөкләнгән вазифаны башкару дип кабул иткәнлеге күренә.

Әлбәттә, Исхакыйга күңелсезләнерлек, төшенкелеккә бирелерлек сәбәпләрнең бик күп булуы да көндәлекләрдә аермачык. Һәр көнне җитмәүчелек белән яшәү, илдән хәбәрләр алмау, зур өметләр баглап килгән япон зыялыларының һәм рәсмиләренең дә,

Япониядәге Европа һәм Америка илчелекләренең дә бернинди ярдәм күрсәтергә теләмәве шундыйлардан. Бер яктан, ул үзенең халкының өметсез хәлен уйлап сызлана: «Без, Русия мөселманнары, елдан артык дәвам итә торган канлы, эчке сугышта миллиард сумлык мал, мөлкәтемезне югалттык. Меңнәр-меңнәр балаларымызны корбан иттек. Олуг иҗтиһад, гайрәт берлән аякка бастырып килә торган милли мәдәниятемезне дошман аягы астында издердек, таптаттык. Хәзер ни бер милли мөәссәсәмез *(оешмабыз)* бар, ни бер милли саглам *(нык)* агымымыз бар, ни бер җәрәхәтләнмәенчә калган милли әгъзамыз бар? Сәүдә бетте. Иген чәчү, мал асрау бетте. Уку-укыту тукталды. Иҗат, матбугат кар астында калды. Халык өмидсезләнде, юлдан язды, куркакланды, зәгыйфьләнде. Зыялысы хулиганланды, имансызланды» *(29 июнь)*.

Икенче яктан, күп кенә күңелсезлекләрнең шушы сәбәпкә, аз санлы халык вәкиле булуга барып тоташканын аңлап чарасызлана: «Без, җәмәгать эшендә йөри торган кешеләр, һәр көндә кебек шундый шанымызга муафикъ булмаган мыскыллар күрәмез, аңарга каршы һичбер төрле җавап бирә алмыймыз, чөнки безнең алар берлән тартыша торган коралларымыз юк. Безнең Европага тәэсир итәрлек матбугатымыз юк. Безнең Европаның малиясенә тәэсир ясарлык икътисади җәмгыятьләремез, куәтләремез юк. Милләтнең йөзенә ыргытылган һәртөрле мыскылларга җавап бирерлек артымызда оешкан бер җан, бер шәй хәленә килгән милләтемез юк» *(25 июнь)*.

Шул ук вакытта халыктагы якты киләчәккә ышанычның – зыялылар, шул исәптән, үзе тудырган өмет булуы да кабатланып килә: «Ләкин фикер, идея безнеке һәм дә аларны эшләткән, аларны йөгерткән, аларның тирләрен агыздырткан нәрсә – мәгънәви көч, без биргән көч, без тудырган көч, аларның милләтләренә мәхәббәтләре, аларның безгә иманнары, ышанулары» *(23 июнь)*.

Күрәсең, шушы фикер Исхакыйга көч биреп тора: күпме генә каршылыклар булмасын, алар Фуад Туктаров белән бергәләп Европага китү уеннан кайтмыйлар. 3 октябрь көнне, «Karachi maru» исемле чех пароходына утырып, Европага китеп баралар. Кытай, Корея, Сингапур, Цейлон утраулары, Көньяк-көнчыгыш Африка, Согуд Гарәбстаны, Италия, Австрия аша, утлар-сулар,

давыллар-ачыгуларны кичеп, Европага килеп җитәләр. Бу сәяхәткә Исхакый Һайнек Схазел исемле чех кешесе булып кузгала.

Әмма Европа да колач җәеп каршы алмый. 3 ай Прагада билгесезлектә, өметсезлектә яшәгәннән соң, сәяхәтчеләр 10 мартта Парижга барып керәләр.

Исхакый бу китүнең илдән бөтенләй аерылу булуын белми әле. Ике айга якын су юлы белән гизеп, чех җиренә аяк баскач та, ул болай дип язып куя: «Хәзер без Прагага барамыз. Аннан Франсәгә чыгарга иҗтиһад итәчәкмез. Аннан өйгә» *(26 ноябрь).*

1919 елны йомгаклаган 31 декабрь көнне тагын бер кат шуны искәртә: «Быел Яңа елны Прагада үткәрдем, киләсе елга үз илемдә үткәрергә язгандырмы, юктырмы – бер Алла белә. 19 нчы ел минем өчен мәхәббәтсез ел булды. 20 нчесе инде бәхетле булсын иде. Эшләр юлга китеп, өсткә алган милли вазифаны үтәп, үз хәятымызга кайтып, эшкә тотынасы иде инде».

Үзе өчен символик дата булган, Милли Идарә Уфадан качкан 12 октябрь көнне, бу хәлнең бер еллыгын билгеләп, Исхакый вакыйгаларга анализ ясый, бәя бирә. Ул Милли Идарәнең Себердә оешып эшләп китә алмавын монда милли рух булмау, зыялылар азлык белән аңлата. Үзләренең хәзерге халәтенә күчеп, «Милләтнең мәгънәвисе безне, үзенең бәйнәлмиләл *(халыкара)* сәхнәгә чыга торган вәкилләрен, вәкил иттереп җибәрерлек булмады. Милләт оешкан. Милли көче – тарихи зур вазифаны үтәүдә үзенең вәкилләрен милләтнең шәэненә *(дәрәҗәсенә)* мөнасиб иттереп сакларлык дәрәҗәдә генә, минем теләнеп җыйган акчамны җибәртерлек дәрәҗәдә оешкан хәлгә килә алмады. Ул интрига урыны, хулиганлык урыны булды. Без хәзер, үземезгә йөкләнгән вазифаны үтимез дигән булып, Европага чыгып барамыз. Андагы мәнфәгатемезгә каршы аз гына булса да бер эш эшли алырмызмы, әллә юкмы – бер Алла белә».

Инде сүнгән өметне Исхакыйның ялгыз булмавы, башка зыялыларның да милләт файдасына тырышуы кабызып җибәрә. Шундыйлардан, 1920 елның 12 гыйнварында С. Максуди Парижда башкарган олы хезмәт көндәлеккә килеп керә: «Садри солых конференциясенә безнең милли теләкләремез хакында меморандум язып биргән».

Гомумән алганда, көндәлекләрдә Гаяз Исхакый шәхесе, холык-фигыле шактый тулы дәрәҗәдә күз алдына килеп баса. Иң беренче чиратта аның гомерен милләтенә хезмәткә багышлаганлыгы, бары тик шушы максатка хезмәт итү юлын гына дөрес санавы аермачык күренә. Кызыксынучан, аралашучан кеше буларак, ул 2–3 сәгатькә туктап торган урыннарда да китап кибетләре, китапханәләр, уку йортлары, мәчетләр, газета-журнал идарәләре эзли, һәр урында – кешеләрнең тормышы белән кызыксына, үз халкы турында сөйләргә омтыла, татар дөньясы белән чагыштыра, татар тормышын камилләштерү, яңарту идеяләре белән яна. Ул – милләтпәрвәр, милләт хадиме.

Көндәлекләрдә Исхакыйның дөньядагы сәясәтне, төрле илләрнең көчен һәм мәнфәгатьләрен тирәннән аңлавы, анализлавы күренә. Күрәсең, аның тарафыннан ясалган иҗтимагый-сәяси адымнар дөнья геосәяси картасын яхшы күзаллап, бар яклап уйлап гамәлгә куелалар.

Шәхси сыйфатларыннан, фикерен курыкмыйча, кемнәрнедер үпкәләтермен дип уйлап тормыйча, турысын ярып сала торган булганлыгы күп кенә мисалларда күзгә ташлана. Әйтик, Кызылъярдагы Кече Милләт Мәҗлесе, Г. Исхакый инде Харбинга чыгып киткәннән соң, тагын бер тапкыр Европага вәкилләр җибәрү мәсьәләсен карап, тагын 3 кешене сайлап куйгач, әдип ачулы телеграмма суга. Көндәлекләрдәге үз ихтыяҗларын кайгырткан татар морзалары, сәүдәгәрләре, аксак ишаннары адресына әйтелгән бәяләмәләр генә түгел, бәлки Ф. Туктаровның «Синең, Солтанбәкнең кирәге юк, дигән телеграммаң Милли Идарәдә бик зур шау-шуга сәбәп булган һәм дә үзеңә телеграмма да биргән» дигән сүзләре дә *(13 июнь)* шуны раслый.

Бер үк вакытта әдип нечкә күңелле, зәвыклы, матурлыкка сизгер чын рәссам булып калкулана. Моннан тыш, анда интуиция зур булганлыгы, вакыйгаларны алдан белдергән төшләр күрүе, аларга ышануы сизелеп бара. («Бүген төштә Садрины күрдем. (...) Ихтимал, аның хакында бер-бер хәбәр килә торгандыр» (*13 июнь* һ.б.).

Көндәлекләр әдәби әсәр кебек укылалар. Язучы матур сурәтләргә, детальләргә игътибар бирә. Еш кына фразеологизмнар

куллана. Әйтик, «Чабата кайтарып тормаенча килгән булса, әллә кайчан эш беткән була иде» (*9 июнь*).

«Гаяз Исхакый көндәлекләре» белән танышкач, әлеге текстларның тагын бер бик зур өстенлеге күзгә ташлана: алар вакыйгаларга читтән, ерактан торып, инде уйлаганнар алга килгәч түгел, бәлки шушы «тарихны тудыру» барышында карарга юл ача, әйтерсең лә укучы да, Исхакый белән бергәләп, Токио һәм Йокоһамада йөри, диңгезләр гизә, Альп тауларын кичә, татар иҗтимагый хәрәкәтенең үткәненә, 1920 еллардагы хәленә карый, киләчәге өчен борчыла. Көндәлекләр авторы XXI гасыр кешесе булган татар укучысын 100 ел элек кичерелгән милли ваемнарга алып керә, аларны татар халкының бүгенге гамьнәренә китереп тоташтыра. Киләчәк өметсез булып тоелган бер дәвердә дә рухи пакьлекләрен һәм ышанычларын җуймаган, халкын саклау өчен төрледән-төрле юллар эзләгән зыялыларның үрнәге – аларның рухи батырлыкларына мәдхия булып яңгырый.

*Д.Ф. Заһидуллина,*
*ТР ФА академигы*

# 2 нче дәфтәр*

## 1919 ел, апрель-май

*26 сында*

Бүген иртәдән үк музейлар карарга, сәнаигълык[1] выставкасы карарга китәмез. Иң әүвәл японнарның музыка мәктәпләренә керәмез. Бакча уртасында агачтан бина ителгән[2] зур-зур өйләр – һәммәсе дә бик биек, һәммәсе дә бик якын. Эчләре бик тәмиз[3], пакь, һавасы күп. Аерым-аерым бүлмәләрдә берәү-икәү япон кызлары пианинода, скрипкада уйнап яталар. Сыйныфларның кайберсендә көйләргә өйрәнәләр, кайберсендә музыка, нота язу хакында дәрес алалар. Укучыларның иң күп кыйсеме – кызлар. Монда без, беренче мәртәбә уларак, кершән ягынмаган кызлар күрәмез. Беренче мәртәбә, имчәкне үстермәс өчен, күкрәкне бик каты буып, арка ягыны бик ямьсез иттереп, горбун чыгарып куя торган кушаксыз[4] кызларга очрап, беренче мәртәбә аякларына агач башмак кимәгән япон кызларын күрәмез. Төсләр, буйлар да моңынчы күрмәгәнемезгә башка. Матур булмасалар да, җирәнгечләр түгел. Гади генә, ямьсез генә, тупас кына авыл мөфтисенең кызлары. Безнең алда да бөтен мәктәп шәкертләре (җыенысы 250 икән, күбе кызлар, аз кыйсеме егетләр) зур бер залда бергәләшеп йырлыйлар. Мөгаллимнәре – немец, бик оста иттереп, тамак берлә йырлый торган япон балаларын Европа ысулынча йырларга өйрәткән. Зур гына сәхнәнең өстенә тезелеп утыралар. Кызлар бер-ике тарафта, егетләр караучыга каршы якта, бергә йырларга тотыналар. Араларында бик матур кыз тавышлары, бик көчле ир тавышлары бар. Һәммәсе немец мөгаллименең күзенә, ишарәсенә генә карап утыралар. Бер көйне

---

* Беренчесе сакланмау сәбәпле, китап икенче дәфтәрдән башлана.

[1] Сәнаигълык – сәнгать.

[2] Бина ителгән – төзелгән.

[3] Тәмиз – чиста.

[4] Кушаксыз – киң билбаусыз.

йырлыйлар, икенче көйне йырлыйлар, бик матур хиссият уяталар. Без, мәктәпнең төрле тарафларыны карап, рәхмәт әйтеп чыгып китәмез. Мәктәптә укучылар һәммәсе японнар булса да, мөгаллимнәрнең күбесе немецлар икән. Һәм дә тәгаллем[1] лисаны[2] немецча икән.

Аннан туп-тугры сәнаигы нәфисә выставкасына китәмез. Зур залда дүрт-биш йөз таблолар тагылган. Иң күбесе – табигать манзаралары, икенче дәрәҗәдә – кошлар-хайваннар. Өченче дәрәҗәдә – адәм рәсемнәре, гомумән караганда, бөтен рәсемнәрдә әллә нинди буяу җитми. Рәсемнәр бер караганда бик оригинальный күренсәләр дә, икенче караганда бер йире тулмаган кебек хис итеЛә, эшләп йитмәгән хиссиятене калдыра. Әллә нәрсәсе тонык, әллә нәрсәсе җитмәгән, әллә нәрсәсе ким. Үзе тәмамән рәсем, үзе тулы түгел. Япониянең чәчәге чәчәкнең иң зур бер хасияте булган истән мәхрүм булган кебек, мондагы рәсемнәр дә рухтан, җаннан мәхрүмнәр. Хосусан, адәм сурәтләренең һичбер җаны юк. Бите тонык, күзе япон, ирене үлгән. Табигать манзаралары матурлар, тулыраклар, ләкин аларда да буяулар бертөслерәк, аларда да әллә нинди җитлекмәү бар, алардан җанлылык, йылы исеп тормый. Иң оста эшләнгән рәсемнәр, шөбһәсез, кошлар рәсеме вә, гомумән, хайваннар рәсеме. Боларны япон рәссамнәре фәүкыльгадә[3] бер мәхәббәт берлән эшләгәннәр, бик нечкә иттереп аңлап, аларны җанландырып утырткannар. Йөри-йөри берничә бүлмәләрне үтеп киткәндә, бер картның рәсемен күрәмез. Бу җанлы ук булмаса да, хәрәкәтле, үлгән түгел. Йөзләре, озын кашлары, сирәк сакаллары бик күп нәрсә сөйли. Йөри-йөри тагы моңардан да остарак эшләнгән бер картның рәсеменә очрыймыз. Монысы, хакыйкатән[4], Европа мәгънәсендә рәсем. Бабайның бөтен әхвале рухиясе кәгазьгә килгән дә алга баскан. Выставканың бер кыйсемен бетереп, икенчесенә керәмез. Анда тагы берничә җанлы, рухлы, сөйли торган кеше рәсемнәренә очрыймыз. Гомумән караганда, япон

[1] Тәгаллем – өйрәнү, белем алу.
[2] Лисаны – теле.
[3] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[4] Хакыйкатән – чыннан да.

рәссамнәре буяуны истигъмальдә[1] үзләренә бер юл кулланалар икән. Рәссамлыкта иң авыр булган осталык, адәм баласының бөтен әхвале рухиясене ингыйкяс иттерә торган[2] йөз, күзне тасвир итү әле аларга мөяссәр булмаган[3] икән. Әле япон рәссамы бөтен кайгыны, бөтен шатлыкны, бөтен тәэсиратны бергә җыеп, йөзгә бирер дәрәҗәгә кадәр үсмәгән икән. Мадам ки[4] юлына кергәннәр, мадам ки шулкадәр уртача осталар йитешкән, әлбәттә, зур осталар да, талантлар, даһилар да йитешкәндер. Аннан соң без тарихи музәханәгә[5] китәмез. Андый тарихи музәханәләрне мин бик күп күргәнем бар. Мондагы нәрсәләр әһел өчен бик кадерле, тарих голямасы өчен бик зур кыйммәткә маликтер[6]. Безнең кебек сәясәтчеләр өчен музейлардан булган бер музей. Әлбәттә, монда Шәрык булганга, бөтен нәрсәләр – Шәрык мәгъмүлаты[7]. Әлбәттә, боларның да барысы да Шәрыкта, Кытайда, Японда бик күптән бирле мәдәнияттә барлыгына аяклы дәлилләр. Ләкин аерым-аерым искитәрлек нәрсәләрне без күрмимез яисә күрә белмимез. Сүз арасында гына әйтеп китим: иске япон савыт-сабалары арасында бик матур комганнар бар. Болар нәрсә, дип сорагач, су савыты, дип җавап бирәләр. Димәк, комган безгә гарәпләрдән килгән бер нәрсә түгел, үземезнең өемездә электән булган. Музәханәнең искиткеч бер йире булса, ул да бинасының пөхтәлеге, яктылыгы. Аннан да чыгамыз. Падишаһлык көтебханәсенә керәмез. Көтебханә бик зур түгел. Петербург көтебханәсенә караганда күп кечкенә, ләкин алай да ярамаслык түгел. Махсус рөхсәт берлән без китаплар саклана торган бүлмәләргә керәмез. Алты катлы бинаны берәм-берәм карап чыгамыз. Көтебханәнең бинасы һәйбәт иттереп эшләнгән. Эчендә хосусый биш йөз меңләп җилд[8] китап бар икән. Иске кытайча, кореяча китаплар да бик күп икән. Иске төрек китаплары юк, гарәп-фарсы әсәрләре юк, дип белешәмез, фәкать бер данә

[1] Истигъмальдә – куллануда.
[2] Ингыйкяс иттерә торган – чагылдыра торган.
[3] Мөяссәр булмаган – мөмкин булмаган.
[4] Мадам ки – шулай да.
[5] Музәханәгә – музейга.
[6] Маликтер – иядер.
[7] Мәгъмүлат – эшләп җитештерелгән нәрсәләр.
[8] Җилд – том.

«Мөгаллиме сани»* дигән китапка гына очрыймыз. Монда әле тюркология фәне бер дә куелмаган булырга кирәк. Үзләренең әйтүенә караганда, китапларының илле мең җилде генә әҗнәби[1] Европа телендә булса да, күзгә күренүгә караганда, бик күбесе инглизчә булырга охшый. Йөри-йөри арып беткәч, бер бакчага кереп, бераз тамак ялгап чыгамыз да тагы китәмез. Хайванат[2] музәханәсе бар икән, шуны эзләп табамыз. Гади хайванат музәханәсе, ләкин ни өчендер төя[3] берлә маймыл бик күп. Шуңарга башка[4] искитәрлек нәрсә юк. Япониянең ярты хәяты балык берлә низагга үтсә дә, ни өчендер аквариумнары бик зәгыйфь.

Сәгать тугызда киткән кешеләр фәүкыльгадә арып, биш ярымда гына номерга кайтамыз. Башлар япон музыкасының көйләре, япон рәссамнарының таблолары, тарихи мең төрле нәрсәләр, әллә ничә төрле телдә китаплар, дөньяның бөтен кыйсемендәге хайваннарның сурәтләре [берлән] тулып беткәнгә, бик зур ару хис итәмез. Көн никадәр иртә булса [да], яңадан чыгарлык көч хис итә алмыймыз. Бу көнне шуның берлән тәмамлыймыз.

*27 сендә*

Бүген – якшәмбе көн, урамнарда халык бик аз. Магазиннарның күбесе ябык. Урамнар рәтләп әрчелмәгән. Японнар бәйрәм итәләр. Якшәмбе көнне бәйрәм итәләр. Без Русиянең эчендә, христиан галәменең уртасында, үземезнең бәйрәмемезне саклар өчен, христиан бәйрәмен олугламас өчен, озын еллардан бирле Русия хөкүмәте, Русия халкы берлән талашып, кычкырышып киләмез. Японнар – мөстәкыйль дәүләтле, күбесе японнар, үзләреннән-үзләре христиан бәйрәме – якшәмбе көнне бәйрәм итәләр. Дәүләт мөәссәсәләре[5] ябык, мәктәпләр укымый, завод-

* «Мөгаллиме сани» – «Икенче укытучы». Монда Һ. Максудиның 1902 елда өлкән сыйныфлар өчен гарәпчә укырга-язарга өйрәткән әлифбасы турында сүз бара.

[1] Әҗнәби – чит.

[2] Хайванат – хайваннар.

[3] Төя – дөя.

[4] Шуңарга башка – «шулардан башка» мәгънәсендә.

[5] Мөәссәсәләре – оешмалары.

фабрикалар эшләми. Христианлык тәэсире никадәр зур. Буш көннән истифадә итәр өчен, бәхрия нәзарәте[1] янындагы музәханәгә китәмез. Зур сарай кебек мөкәммәл[2] бинаның өч каты рус-япон сугышында алынган ганимәт маллары[3] берлә тулган. Сугыш көймәсеме дисең, коралмы дисең? Диварларда – диңгез сугышларының рәсемнәре. Менә Русиянең Шәрыкка таба атлавына беренче зарбә[4] булган Сутим сугышының* манзаралары. Менә аның башы, менә аның иң каты вакыты, менә япон флотының галибәсе[5]. Шыгрым тулган япон балалары, көлә-көлә йөриләр. Көлә-көлә, берсе-берсе берлә хиссиятләрен бүлешәләр. Диварлар сугышта батырлык күрсәткән офицер-солдатларның рәсемнәре берлән туп-тулы. Шкафлар руслардан алынган көймәләрнең сыныклары берлән шыгрым тулы. Музәханәнең йортына да иске туплар тезелгән. Барысы да Русиядән алынган. Барысы да – Русиянең 904 нче елгы ахмаклыгының аяклы дәлилләре**.

Озын иттереп карап бетергәч, вакытымыз барлыгыны белеп, боларның нәзарәтендәге музәханәгә китәмез. Монда яңа нәрсә күп юк, хәзер дә күрелә торган нәрсәләр. Сәфәрнең төрле кораллары – җәяүледән башлап автомобильгә кадәр, начар киемнән башлап бүгенге көнге дүрт-биш мең кеше сыйдыра торган пароходка кадәр – һәммәсенең моделе бар. Монда да пакьлек, пөхтәлек, тәмизлек[6].

---

[1] Бәхрия нәзарәте – диңгез министрлыгы.

[2] Мөкәммәл – камилләшкән.

[3] Ганимәт маллары – сугышта кулга төшерелгән дошман малы.

[4] Зарбә – сугу.

* Сутим сугышы – Цусима сугышы – Япон диңгезендәге Цусима утравында 1905 елның 14–15 маенда вице-адмирал З.П. Рождественский җитәкчелегендәге Россия Тын океан флотының 2 нче эскадрасы адмирал Хэйхатиро Того җитәкчелегендәге Япония Император флоты тарафыннан җиңелүгә дучар була.

[5] Галибәсе – өстенлеге, җиңүе.

** Русиянең 904 нче елгы ахмаклыгының аяклы дәлилләре. – Монда 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышы күз алдында тотыла. Бу бәрелеш, Маньчжурия һәм Корея өстеннән контроль урнаштыру өчен, геополитик көндәшлек аркасында башлана. Сугыш Россиянең җиңелүе белән тәмамлана. Нәтиҗәдә, Россия үзенең хәрби диңгез порты булган Порт-Артурны һәм Сахалинны японнарга бирергә мәҗбүр була.

[6] Тәмизлек – чисталык.

*28 ендә*

Бүген без иртәдән үк мәктәпләргә башлыймыз. Безне, беренче уларак, ибтидаи[1], игъдади[2], гали[3] дәрәҗәләргә бүленгән хосусый бер мәктәпкә җибәрәләр. Мәктәп Токионың читендәрәк, зур бер бакча эчендә, биналар аерым-аерым салынган. Күп өйләр аерым-аерым торалар. Мәктәп биналарының күбесе агачтан. Һәммәсе дә бик киң, зур иттереп эшләтелгән. Сыйныфлар зур, биек, якты. Тәрәзәләр киң һәм зур. Сыйныфлар, мәктәп эче бик пакь, тәмиз. Без барганда тәнәфес вакыты. Йортта беренче сыйныф балалары уйнап йөриләр. Хәлфәләре яннарында. Икегә бүленгәннәр дә икесенә дә ике бик зур туплар биргәннәр, бер гөруһысының тубы кызыл, бер гөруһының – ак. Малайларның да башларына кигән киемнәре бер бүлекнеке ак, берсенеке – кызыл. Уен шуннан гыйбарәт: мәйданның уртасында ике малай байраклар күтәреп торалар, ул байрак агач саплары берлә җиргә кадалганнар. Малайлар икешәрләп тупны (берәмләп тәгәрәтергә көчләре җитми) тәгәрәтеп, бер мәгълүм даирәне әйләндерәләр дә үз сафларыннан икенче икегә йибәрәләр, алар тагы үз кизүләрен үтәләр дә өченчеләргә бирәләр. Шулвакытта туп ычкынып китә, малайлар куып җитә алмый яисә тотам дип сузылгач егыла. Шуны дикъкать берлә җитәкли торган кырыклап бала шарк килә. Кайсы гөруһның балалары һәммәсе тубын элегрәк тәгәрәтеп китсәләр, шул бүлек узган була. Звонок була. Мәктәп эченә керәмез. Сыйныф урындыклары һәр балага аерым эшләнелгән. Балалар һаман уен хәлендә: берсе сөйли, бере көлә, берсе сикерә. Мөгаллимнәр тик торалар, һич тыймыйлар. Менә мөгаллим бүрекләрен салырга куша, һәммәсе, бердән салып, парталарындагы тартмаларга куялар. Мөгаллим хәзер рәсемнәр өләшәчәген игълан итә, бик зур тавыш берлән үзләренең шатлыкларыны изһар итәләр[4]. Шуннан соң зур кулда мөгаллимнәре берлә бергә алынган рәсемнәр өләшәләр. Беренче кергән елны балаларны мөгаллимнәре берлә бергә рәсемгә төшерәләр икән, үзләренә бирәләр икән һәм дә, тәмам иткәч,

[1] Ибтидаи – башлангыч.

[2] Игъдади – урта.

[3] Гали – югары, олы.

[4] Изһар итәләр – күрсәтәләр.

шуны икешәрлиләр икән, шуның берлә мәктәпнең тәрбиясенең сәмәрәсене[1] баланың күз алдына утыртып куялар. Бу сыйныф әле балалар бакчасыннан аз аерыла, уку бик аз, балалар бик яшь, җиде-сигездә, әле берсе дә китап укый белми. Икенче сыйныфка керәмез, анда кыйраәт[2] бик авыр гына өстерәп маташалар. Өченче сыйныфта һәм дә кыйраәт, анда инде балалар тәмамән укый белә башлаганнар. Тотлыкмаенча мәхрәҗләре[3] берлән укыйлар. Япон әлифбасы бик авыр булганга, тәмамән сәвадлы[4] булыр өчен, өч ел укырга мәҗбүрият бар икән. Өченчедән, дүртенче сыйныфка керәмез. Анда бер малай укыганын хикәя итеп сөйләп тора. Балалар бик ихлас берлән тыңлыйлар, бәгъзы йирендә кычкырып көләләр, бәгъзы йирендә йөзләренә хәсрәт чыга, битләре-йөзләре дикъкатькә баткан. Бишенчедә хисап эшлиләр, ләкин цифрлары японча булганга, бер-бер нәрсә аңлый алмыймыз. Японнар гарәп цифрын кабул итмәгәннәр икән. Алтынчы сыйныфта җәгърафия укыталар. Шуның берлән ибтидаи мәктәп тәмам була. Моны бетергән балалар шул хосусый мәктәпкә яисә хөкүмәтнең игъдадисына керә алалар. Анда укулар биш ел. Без берәм-берәм гимназияне карап чыгамыз. Укытулары – рус гимназиясендәге фәннәр, фәкать инглиз теле артык. Аны бу мәктәптә тәмамән укырлык-сөйләрлек, әдәбиятыннан файда итәрлек ясап чыгаралар икән. Гимназиянең физика бүлмәсене, нәбатат[5], хайванат бүлмәләрен аерым-аерым карыймыз. Һәммәсе бик бай иттереп эшләнелгән, һәммәсе бик пакь, тәмиз. Аннан соң гали кыйсеменә – университет ягына чыгамыз. Монда безне төркем-төркем студентлар каршы алалар. Һәммәсе үзенең хезмәтен тәкъдим итә. Элек безне көтебханә бүлмәсенә алып керәләр, зур бер бина. Ысулы мигъмариясе[6] бик матур: өч катлы манаралап салынган. Аның уку бүлмәсене, китап саклана торган йирләрене – һәммәсен карыймыз. Илле мең җилддән артык китап бар икән. Шул бинаны бер япон, үзе салдырып, мәктәпкә

[1] Сәмәрәсене – нәтиҗәсен.
[2] Кыйраәт – уку.
[3] Мәхрәҗләре – артикуляцион базалары.
[4] Сәвадлы – укый-яза белерлек.
[5] Нәбатат – үсемлекләр.
[6] Ысулы мигъмариясе – төзү-архитектура стиле.

вакыф иткән икән. Манараларның берсенә чыгамыз. Ни күземез берлән күрик: мәктәпне чолгаган зур бакчаның бер тарафында, җәйрәп, диңгез ята. Күбәләк кебек очып, җилкәннәрдә кабыклар чаба. Соңра һаваланып кына, төтенне җибәримме-юкмы дигән кебек, зур диңгез пароходы кереп килә. Без бу манзараны озак тамаша кыламыз. Аннан соң университетның дәресханәләрене карарга китәмез. Университет кыйсемендә хокук, тыйб[1], әдәбият, тарих, сәясәт, икътисад исемнәрендә биш факультә[2] бүленә икән. Мәҗмуг[3] студенты дүрт мең чамасында икән. Әҗнәбиләрдән[4] ике йөзләп чинлы, унбишләп кореялы гына бар икән. Дәресханәләре бигүк шәпләр түгел. Болар инде шактый искергәннәр. Лаборатория, физика бүлмәсе, хайванат-нәбатат бүлмәләре бик тулы. Карап бетереп, йөртүче мөгаллимнәргә, студентларга рәхмәт укып, китәргә чыгамыз. Университетның мөдире безне көтеп тора, диләр. Профессорлар каршына китәмез. Анда утызлап профессор, күрешәмез, сөйләшәмез. Без[нең] мәктәпләремездән, безнең гыйльми хәрәкәтемездән сорыйлар[5]. Чәй тәкъдим итәләр. Сыйланып, рәхмәтләр укып, чыгып китәмез. Бу мәктәп моннан алтмыш ел элек бер мөгаллимнең дәрде берлә хосусый өйдә генә башланган. Шуннан бирле тәрәккый итә-итә, Японияненең иң зур гыйлем йортына әйләнгән. Хәзер бөтен сыйныфларында җиде мең шәкерте бар. Дөнья кадәр биналары бар, матбагасы бар, үзенең газетасы бар. Гали кыйсемендә генә алтмышлап профессоры бар. Укучылардан елына утызар гына иен[6] алып укытса да, елына өч йөз мең иен мәсариф[7] тота икән. Бу мәктәпкә караганда, моның тәрәккый тарихын күздән кичергәндә, бик тирән уйларга китәсең. Ник безнең Шиһаб хәзрәтнең мәдрәсәсе* бүгенге көндә

---

[1] Тыйб – медицина.
[2] Дөресе: факультет.
[3] Мәҗмуг – барлык.
[4] Әҗнәбиләрдән – чит ил кешеләреннән.
[5] Сорыйлар – сорашалар.
[6] Иен – йена – Япониядәге акча берәмлеге.
[7] Мәсариф – чыгымнар.
* Шиһаб хәзрәтнең мәдрәсәсе – Казанда 1870 елда Ш. Мәрҗани тарафыннан нигез салынган һәм аның исеме белән аталган «Мәрҗания» мәдрәсәсе.

шул гыйлем йорты дәрәҗәсен алмаган да, ник «Мөхәммәдия»* шуның юлына басмаган, ник «Хөсәения»** шул эзгә кереп китмәгән дә, агач башмаклы японнарның алтмыш ел элек башлаган ибтидаи мәктәпләре, җиде мең шәкертләре Европада урын тота торган гыйлем йортына әверелгән? Бу сөальләр тугрысында уйларга ярый.

Безгә тагы япон ысулы мигъмариясендә бер бинаны күрсәтергә булсалар да, вакыт соңга күрә, өйгә кайтып китәмез. Кызлар мәктәбен дә күрәсемез килсә дә, алар да ябылганга, анысын да икенче көнгә калдырырга мәҗбүр буламыз.

*29 ында*

Бүген көн иртәдән үк тулы башлана. Иң әүвәл иртә торуга, безгә япон газетасы кертәләр. Бу газетада безнең үземезнең дә рәсемнәремезне төшергән дә тәрҗемә хәлемезне язган. Япончадан тәрҗемә иттереп карыймыз. Гади газета. Мөхбирләре ялганлаган кадәр генә ялганлаган. Биргән мәгълүматы милли ноктаи назардан караганда файдалы.

Икенче вакыйга. Йокоһамада (Токиодан утыз-кырык чакрымда Токионың порты) зур бер янгын булган. Өч мең дә ничә йөз өй янып беткән. Егерме мең халык урамга актарылган. Илле миллион иенлык мал-мөлкәт харап булган, ягъни Истанбул янгыннарына охшаган бернәрсә булган. Токио, Йокоһамада, шәһәр эчендә бик күп сонгый[1] каналлар йөртелгән. Диңгез суы килгән чакта, шул каналларның һәммәсе су берлән тула да, диңгез чыккан чакта, шул каналдагы бөтен пычракларны һәммәсен юып китә. Шуннан берничә сәгать каналлар сусыз кебек калалар. Менә янгын диңгез суының типкән вакытына очрамаенча – суның киткән чагына тугры килгән дә утны сүндерер өчен су җитмәгән. Биш-алты сәгатьтә агач өйләр берсе арты берсе көлгә әверелгәннәр. Ягъни, тәмамән Истанбулча булган. Өч ягыннан

* «Мөхәммәдия» – Г. Баруди тарафыннан нигез салынган һәм 1882 елда Казанда ачылган мәдрәсә.

** «Хөсәения» – 1889 елда Оренбургта бертуган Әхмәт (1837–1906), Мәхмүт (1839–1910) һәм Гани (Гани бай, 1839/1940–1902) Хөсәеновлар ачкан мәдрәсә.

[1] Сонгый – ясалма.

диңгез берлән уралган Истанбул[да] меңәр-меңәр өй янып беткән кебек, диңгез буена сузылып утырган Йокоһама да шулай булган. Боларның икесендә сәбәп – битарафлык. Ләкин шулкадәр эш сөя торган японнарга бу мөсаһәлә[1] әллә ничек килешеп бетми.

Өченче вакыйга. Безгә иртүк Токиода француз теле мөгаллиме булып бик озак хезмәт иткән бер мөселман көрд хатыны берлә зиярәткә килде. Хатын япон кызы булса да, ислам кабул иткән, үзе кәлям гарәпчәсене[2] бик шәп сөйли. Мисырда бер ел калган. Бик күңелле бер хатын. Гадәтләре берлән европалашкан: башында – эшләпә, аякта – ботинка. Аркасында горбуны юк. Фазылбәк үзе фарсыча-гарәпчә оста сөйли. Мисырда да, Сүриядә дә гарәпчә укыган. Төрекчәсе бик зәгыйфь, французча бик яхшы беләә, егерме ел Франсәдә калган, инглизчә дә сөйли. Япониядә 14 елдан бирле яши. Күп таныш-белеше бар, японча да сөйли. Ләкин ни өчендер үзенең мәгълүматыннан, үзенең тәҗрибәсеннән халыкны истифадә иттерү[3] юлына куя алмаган. Үзенчә гозләткә[4] бирелгән. Тик тора. Хәзерге сүзләренә караганда, бик мөселман кебек күренә, бәлки хакыйкатьтә шулайдыр. Ләкин без Европа тәгълиме[5] күргән кешеләрдән лөзүменнән артык мөселманлык күрсәк, шөбһәгә төшә башлыймыз, самимиятенә иманымыз кими. Хасиятләнеше мөселманлыгы кебек ясалма бернәрсә түгелме дигән карарга киләмез. Моңарда ул хис уянмады. Картая башлагач, христиан галәмендә бик күп торып, чит дөньяга хезмәткә яшьлек гамәлен бик күп еллар әрәм итеп, шуңарга каршы һаман начар мөгамәлә күргәнгә каршы гакселхәрәкәт[6] кенә кебек тоелды. Адашкан кешенең үз илен сагынуы, үз йортын сөюе кебек кенә хис калдырды. Бәлки, бу фикерләр тугрыдыр да, бәлки, түгелдер. Чөнки бер-ике күрүдән кешене белү бик авыр. Һәр нә исә[7], бу кешенең рухында зур бер фаҗига бар.

---

[1] Мөсаһәлә – игътибарсызлык.

[2] Кәлям гарәпчәсене – гарәпчә сөйләмне, м о н д а: гарәп телендә.

[3] Халыкны истифадә иттерү – халыкка файда китерү.

[4] Гозләткә – ялгызлыкка.

[5] Тәгълиме – белеме.

[6] Гакселхәрәкәт – каршы юл тоту.

[7] Һәр нә исә – нәрсә булса да.

Аннан соң рәсми иттереп эшне юлга куяр өчен, Америка сәфарәтханәсенә[1] китәмез. Сәфирнең[2] үзен күрер өчен, карточкаларымызны бирәмез. Сәркатип чыга, сәфир бәк хәзер генә чыгып киткән. Мөһимрәк мәсьәләләрдә ул үзе кабул итә, шуңарга күрә сезнең килү хакында мин аңарга сөйләрмен дә, иртәгә вакыт ягын әйтер, диде. Без шуны муафикъ күреп, чыгып киттек. Барачак мәмләкәтемез Франсә булганга, аның сәфиренә киттек. Ләкин вакыт соң булганга, безне сәфирнең мөстәшары[3] гына кабул итте. Мәсьәләне аңлаттык, кулдан килгән ярдәмне итәрмен, ләкин үзем генә катгый җавап бирә алмыйм. Сәфир берлә сөйләшеп җавап бирермез, диде. Аштан соң безне «Һоши Шимбун»* газетасының мөхәррире идарәләренә чакырды. Артымыздан кеше килгән. Китәмез. Безне редакторларыннан берәү каршы ала, идарәнең кабул [итү] бүлмәсенә алып керәләр. Берничә мөхәррир килеп күрешәләр. Безне зур өстәл янына утыртып, чәй тәкъдим итәләр. Чәй башлангач та, газетаның мөәссисләреннән[4] бер әфәнде килеп керә. Картрак кеше. Граф Окуманың** каршында тиҗарәт[5] министры булган кеше. Хәзер матбугат берлә генә мәшгуль. Хөкүмәткә оппозициядә Япониянең исляхында роль уйнаган картлардан. Кыяфәтләре, битләре берлән башкорт старшинасына бик ошый, ләкин зур яшендә, әллә никадәр тәҗрибә-гыйлем, гайрәт сакланганы күренеп тора. Шуннан соң мөхәррирләрдән берәү редакция исеменнән, безгә карап, инглизчә алдан хәзерләнгән бер адресны укый. Безгә

---

[1] Сәфарәтханәсенә – илчелегенә.

[2] Сәфирнең – илченең.

[3] Мөстәшары – ярдәмчесе.

* «Һоши Шимбун» – Бирелә сүз «Хочи Шимбун» («Hochi Shimbun») газетасы турында бара. Әлеге газетаның хуҗасы Окума Сигэнобу булган. Г. Исхакый үзенең көндәлекләрендә әлеге газетаның язылышын төрле җирдә төрлечә бирә: «Һоши Шимбун» (هوشى شيمبون), «Һоҗи Шимбун» (هوجى شيمبون) һәм «Хоҗи Шимбун» (حوجى شيمبون). Уйлавымызча, Г. Исхакый, тел белмәү сәбәпле, япон сүзләрен һәм атамаларны ничек ишетсә, шулай язган.

[4] Мөәссисләреннән – оештыручыларыннан.

** Граф Окума – Окума Сигэнобу (1838–1922), Япониянең дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтчесе, дипломат.

[5] Тиҗарәт – сәүдә.

кардәшлек изһар итү[1] һәм дә элекке тарихта зур урын тоткан Чыңгыз ханның* балаларының бабаларының мирасына наил[2] булуларына ышанудан гыйбарәт. Аңарга каршы мин татарча җавап бирәм, мәгънәсе моннан гыйбарәт: безне хәзер тарих уңайсыз бер вазгыятькә куйды. Мәсәлән, мәдәниятемез, тарихымыз хатирәдә. Муәффәкъ[3] җәгъръафиямез буенча руслар берлә бәгланганга, мәсьәләләремезне аерым хәл итә алмыймыз. Ләкин руслар үзләре хәзер башкорт булдылар, мәмләкәт мәсьәләсен үзләре хәл итә алмаячаклар. Русия мәсьәләсе бәйнәлмиләл[4] бер мәсьәлә булды һәм булачак. Шуңарга күрә без, мәгънәви ярдәм сорап, сезгә, япон милләтенә беренче килдек, кардәшлекне искә төшереп, беренче сәламне сезгә бирдек. Сез безгә, иншалла, кардәшлек ярдәме итәрсез. Мин үзем әһле каләм булганга, сезгә, каләм иптәшләрем, безгә илтифатыңыз өчен, безнең эшемезгә ярдәмгә кул сузуыңыз өчен, татар-төрек матбугаты исеменнән рәхмәт укыйм. Шуннан соң төрле сөальләр башланды. Иң әүвәл безнең тора торган йиремезне сорадылар. Харита[5] буенча кайдалыкны күрсәттек. Монда кулымызда үземезнең хаританың булмавы зур зарар иде. Томскида шуны эшләтергә тотынган идем, кешесе булмады. Тупраклы мохтарият һәйәтенең[6] шул хакта бернәрсәсе дә Милли Идарәгә** килмәгән. Алар йә булмаган, йә

---

[1] Изһар итү – күрсәтү.

* Чыңгыз хан – (1155 яки 1162 еллар тирәсе – 25 нче август, 1227), Монголия һәм бөтен Урта Евразия кабиләләрен һәм халыкларын берләштереп, дөнья тарихындагы иң зур империя төзүче иң атаклы беренче патша (император).

[2] Наил – ирешкән.

[3] Муәффәкъ – ирешкән.

[4] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[5] Харита – географик карта.

[6] Һәйәтенең – комиссиясенең.

** Милли Идарә – Эчке Россия һәм Себер төрки-татар милли-мәдәни мохтариятенең югары башкарма идарәсе.1918 елның гыйнварында Милләт Мәҗлесе карары белән оештырыла. Уфа шәһәрендә эшли. Рәисе – С. Максуди, рәис урынбасары – И. Әхтәмов. Шул ук елның 21 апрелендә Милли Идарә эшчәнлеге (Диния нәзарәтеннән тыш, аңа сәясәткә кысылмау шарты белән, эшчәнлеген дәвам итәргә рөхсәт бирелә) Совет хакимияте тарафыннан тыела. Себердә Совет хакимияте урнаштырылганчы, Милли Идарә әгъзалары үз эшчәнлекләрен Кызылъяр шәһәрендә дәвам итәләр. С. Максуди киткәннән соң, рәис вазифаларын И. Әхтәмов башкара.

булса да, Милли Идарәгә килмәгән. Аннан соң гореф-гадәтемез, хәятымыз хакында озын-озын сөальләр бирделәр, без канәгатьләндерерлек җаваплар бирдек. Ләкин ахырга таба боларның Русия хәлене бер дә белмәүләре мәгълүм булды. Шуннан Русиядә хәзер ни барлыкны, Русиядәге тартышның барышын, безнең урынымызны күрсәттек. Шулай итеп, ике сәгать сөальләшеп утырдык. Шулвакытта тагы рәсемемезне чыгардылар. Шуннан соң матбагаларын карарга чыктык. Биналары бер чатны әйләндереп алган. Газета ширкәт ысулына бина ителгән[1] икән. Шәрикләренең[2] саны ике мең дә биш йөзгә җиткән. Араларында граф Окуманың зур кешеләре бар, матбагасы бик зур, мөрәттибләр[3] бүлмәсенә керәмез. Шыгрым тулган мөрәттибләр хәреф җыеп торалар, ләкин хәреф тартмалары (кассалары) безнеке төсле түгел, кыеграк койма кебек сөялгән тартмаларга хәрефләр утыртып куелган. Бер-берсенең алдындагы кассасының биеклеге ике аршын, озынлыгы дүрт-биш аршын. Япон хәреф галәмәтләре ике мең данәгә җитә икән, шуңарга күрә хәреф җыю бик авыр икән һәм дә акрын эшләнә икән. Бездә, мәсәлән, урта мөрәттиб газета юлын сәгатенә 25, 30 юлны җыйганда, боларның мөрәттибләре биш-алты юл да җыя алмый икән. Аннан машина кыйсемен күрәмез. Анда сигез ротационный машиналар[4] дөбердәп эшләп ята. Күрше бүлмәсендә хәрефләр куялар. Тагы бер бүлмәдә фотограф эшләп ята. Безгә үземезнең хәзер генә алган рәсемнәремезне күрсәтәләр. Бу газета Токионың оста бер газеталарыннан саналса да, өч йөз мең нөсхә басыла, үзе, иртәнле-кичле булып, ике мәртәбә нәшер ителә икән. Аннан йортларына чыгамыз. Анда автомобильләр, арбалар газетаны таратырга хәзер торалар. Без редакцияне, корректорлар бүлмәсен, конторасын, телеграфханәсене (үзенә махсус), һәммәсене үтәмез, һәммәсен күздән кичерәмез. Җыенында сигез йөзләп кеше хезмәт итә икән. Мөрәттибләрнең вазифалары[5] 26 иеннан

---

[1] Бина ителгән – оештырылган.
[2] Шәрикләренең – катнашучыларының.
[3] Мөрәттибләр – хәреф җыючылар.
[4] Ротационный машина – типографик басма җайланмасы.
[5] Вазифалары – хезмәт хаклары.

йөзгә кадәр икән. Бик зур рәхмәт укып, күрешеп, аерылышамыз. Бүген өйдән беркая да бармыймыз. Кичне өйдә генә үткәрәмез.

*30 [нчы] апрель*

Бүген ике сәфарәтханәдән телефон көтеп ятамыз. Телефон өйләгә кадәр дә юк, өйләдән соң да юк. Без моңарга бераз гаҗәпкә каламыз. Шундый зур мөәссәсәләр вәгъдәләрендә торырга тиешләр иде. Ахырдан бүген Япониянең вәли гаһеденең[1] балигъ булу мөнәсәбәте берлә хөкүмәтнең бәйрәме икән. Шул мөнәсәбәт берлән парад та булган. Ихтимал, зыяфәт[2] тә булгандыр да вакыт та булмагандыр. Рус-япон җәмгыятеннән телефон, иртәгә бәйрәм булганга, мәктәпләр ябык, дип хәбәр бирәләр, димәк, безнең көнемез буш. Шуннан файдаланыр өчен, көрд Фазылбәккә барамыз, дип, мәктүб җибәрәмез. Көн ягмурлы, һава юеш, минем ягмур пальтом да юк, зонтик та юк, башка пальто да юк. Шуңарга күрә көнемне дә өйдә үткәрәм.

Күңеллерәк бер мәсьәлә булса, акча курсының бераз рәтләнүе. Гомәр әфәнде* кич мең сумга йөз дә биш иен алып кайтты. Өч кенә көн элек мең сумга фәкать җитмеш кенә иен бирәләр иде. Икенчесе, минем ашказаным бер төрле юлга куела башлады, һаман әле әүвәлге хәленә килмәсә дә, баш авыртулар бетте.

Петропавелдан һич хәбәр юк, Харбиннан һич хәбәр юк. Берничә хат яздык, җавап һаман юк, почта озак йөри. Цензор озак тота.

*1 нче май*

Бүген японнарның сугышта үлгән каһарманнар көне дигән бәйрәмнәре. Махсус гыйбадәтханәдә гыйбадәт укылып, гаскәри парадлар була икән, ләкин көн ягмурлы, һава матур түгел. Шуңарга күрә мәктәпләр укымый, мөәссәсәләре эшләми, без беркая да бара алмыймыз. Вакыт буш булганга күрә, Фазылбәккә кунакка барамыз. Ул Йокоһаманың читендә, бер авылда тора икән. Диңгез буе, бик матур йир. Аңарда кунак буламыз. Хәя-

---

[1] Вәли гаһеденең – патша варисының.

[2] Зыяфәт – кунак итү.

* Гомәр әфәнде – Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883–1938), хокук белгече, сәясәтче һәм журналист.

ты – япон хәяты. Хатыны – япон кызы. Безне сыйлыйлар, хөрмәтлиләр, шунда Давыд исемле Бумбай* мөселманнарыннан сәүдәгәр берлән танышамыз. Ләкин ул гарәпчә дә, фарсыча да, төрекчә дә белмәгән[гә], инглизчә генә, тәрҗеман аша гына сөйләшәмез. Гади бер мөселман, башка бернәрсә юк. Көн буе кунак булып, кичен өйгә кайтамыз.

*2 нче май*

Беренче эшемез Франсә сәфарәтенә[1] барып әйтү. Безгә телефон кагарга[2] вәгъдә бирсәләр – телефон булмады, шуңарга күрә без икенче кат киттек. Баргач, бездән гафу үтенделәр һәм дә Парижга сезнең хакта сәфир бәк телеграмма бирде, шуның җавабы алынмаганга күрә, сезне чакырмаган идек. Җавап тиз булыр, диделәр. Бу безне сөендерде, димәк, безнең эшемез рәсми юлга куелды һәм дә сәфарәтханә үзе телеграф берлән хәбәрләшүне өстенә алгач, эшкә әһәмият бирелде. Без сөйләшеп кайтамыз. Америка сәфарәтханәсенә баруны соңгарак калдырамыз.

Өйгә кайтуымызга, безне газета мөхбирләре көтеп тора, аларның бетмәгән сөальләренә җаваплар бирәмез. Ләкин сөальләр бик күп вакытта бик мәгънәсез булганга, аптырап та каламыз. Мәсәлән, бүген татарлар «Алла»ны ничек таныйлар, дип сөаль бирделәр. Моңарга ни дип җавап бирергә кирәк. Алламыз бардыр, бердер. Артта да юктыр, алда да юктыр, зур да түгелдер, кечкенә дә түгелдер. Күзле түгел, күзсез дә түгелдер, һәрнәрсә күрәдер, һәрнәрсә ишетәдер, ләкин колагы юктыр әсасындагы мәгънәдә җавап бирергәме? Бу кадәресене һәр газета язучы белергә тиеш. Әллә «Алла» мәгънәсенең фәлсәфәсен исламның вөҗүде улып, галәме мәүҗүдат[3] хакындагы фәлсәфәсене аңлатыргамы? Мәгънәсе хакында, әлбәттә, бер-ике сөаль берлән канәгатьләндерергә җавап та биреп тә булмый. Моның мөхбирләргә кирәге дә юк. Бу – тарихы идеал, бу – тарихы фәлсәфә сөальләре. Яисә татарлар иртә берлән сәгать ничәдә йокыдан

---

* Бумбай – Һиндстандагы Бомбей шәһәре. 1995 елдан аның исеме Мумбай дип үзгәртелә.

[1] Сәфарәтенә – сәфарәтханәсенә.

[2] Кагарга – шалтыратырга.

[3] Галәме мәүҗүдат – чынбарлык галәме.

тора, дип сорыйлар. Менә моңарга җавап тап. Ничә дисәк, ялган булмас. Яисә татарлар иртә берлән ни ашый, дип сорыйлар. Пәрәмәч ашый, диикме?

Безнең хакта күп нәрсәләр яза торган бер газетаның ике мөхәррирен ашка алып керәмез. Берсе безне бик беләсе килә, бик ихласлы. Үзе бик самими күренә. Көлгәндә, тәмамән безнеңчә, самими иттереп, эченнән көлә. (Без японнардан эчтән көлгән кешене беренче очратамыз.) Озын сөйләшәмез. Әллә никадәр сөальләргә җавап бирәмез. Яшьләремезне кат-кат сорыйлар. Монда яшь мәсьәләсе мөһим мәсьәләме икән әллә, газета язганда, һәрвакыт безнең яшьләремезне язмый калдырмыйлар. Очрашканда, һаман сорыйлар. Ләкин Гомәр әфәнденең 36 да булуына ышанмыйлар. Чәче коелып беткән, ул карттыр, дип куялар. Эштән соң безгә бер карточка бирәләр. Карточкада русча язылган рус исемнәре тагылган булса да, ул безгә Сеулда* очраган япон офицеры булып чыга. Ул безне зияраткә[1] килгән. Аның берлән озын иттереп сөйләшәмез. Ул русча белгәнгә, аңлашу җиңел була. Безгә монда хәрби даирәләр берлән күрешергә тәүсыя итә[2], берничә кешене күрсәтә. Мәсьәләнең астыннан-өстеннән күп мөзакәрәләргә[3] кереп китәмез. Икенче бер көнне тагы килергә вәгъдә биреп китә.

*3 нче май*

Без бүген иртүк дарелмөгаллиматны[4] һәм дә хатыннар гимназиясен карарга китәмез. Зур бер мәктәп бинасы. Уртасы бакча берлән тулган. Сыйныфлар өчен биналары урам буен уратып алган. Үзендә гимназиясе, үзендә ибтидаи[5] мәктәбе, үзендә балалар бакчасы, үзендә музыка сыйныфы, үзендә гимнастика сыйныфы, үзендә гали дарелмөгаллимат. Сыйныфтан сыйныфка керәмез. Һәммәсе пакь, тәмиз, һавасы күп. Анда-монда укучы кызлар тулган, күбесе яшьли кызлар яисә ханымнар. Төсләрендә һичбер

---

* Сеул – Корея Республикасының башкаласы.

[1] Зияраткә – күрергә.

[2] Тәүсыя итә – киңәш итә.

[3] Мөзакәрәләргә – фикер алышуларга.

[4] Дарелмөгаллиматны – хатын-кызлардан укытучылар әзерли торган уку йортын.

[5] Ибтидаи – башлангыч.

төрле япон хатыннарында булган акшарга буяну юк – һәммәсе әдәпле, инсафлы. Очраганда, бик түбән иелеп сәлам бирәләр. Күз уйнатулар һич юк. Аякларында – ботинкалар. Аркаларында теге ямьсез нәрсә юк. Безне хәйранга калдырган нәрсәнең иң зуры: боларның физика, нәбатат[1], хайванат бүлмәләренең мал-мөлке һәм дә электрик-механик бүлмәләренең байлыгы. Монда өйрәтү тәмамән күзгә күрсәтү ысулына куелган. Сыйныфларда укып утыралар. Лабораториядә гамәлият ясап яталар. Кыйраәтханәсендә[2] моталәгага[3] чумганнар. Бер бүлмәгә керәмез, монда мөгаллим булачак ханымнар кием-салым тегәргә өйрәнеп яталар. Икенчесенә керәмез. Анда чигешкә өйрәтеп торалар. Өченчесенә керәмез. Анда эш остасы абыстай кызларга кишерләр турап, балыклар кискәләп, аш пешерергә өйрәтә. Ашханәләренә керәмез. Егерме-утыз туташ ак алъяпмалардан аш хәзерләп маташалар. Ашау бүлмәсенә керәмез. Монда озын өстәлгә һәрбер кемнең алдына бер тарелка балык, бер савыт соус куелган. Һәр табынга зур бер табак берлән пешкән дөге китерелеп куелган. Икмәк-фәлән һич юк. Гимнастика бүлмәсенә керәмез. Зур-зур туташлар махсус киемнәрдән сикереп, йөгереп, югары атылып, уйнап яталар. Мәктәп йорты шау килә. Анда әллә ничә йөз вак кына балалар мөтәфәрди[4] бер йирдә туптан уйный, бер йирдә агачка, баганага менеп маташа. Бер почмакта шакмаклардан өй ясап уйныйлар, бер йирдә балчыктан кирпечләр, кошлар оештыралар. Бер бүлмәдә алларына алган зур дәфтәрләрдәге балыкларны, кошларны төрлесен төрле буяуга буяп торалар. Һәр йирдә фәгалиять[5], һәр йирдә хәят. Зур бер дәресханәгә керәмез. Бер-ике йөз кыз утырганнар да бик зур дикъкать берлә тыңлыйлар. Профессор акрын гына, вәкарь берлән генә әллә нәрсә сөйли. Мөдәррисләр, мөгаллимнәр, профессорлар берлән сөйләшәмез. Мәктәп хөкүмәт мәсарифенә[6] бина ителгән инде, кырык ел дәвам итә. Үзе дүрт сыйныфлы. Монда дарелмөгаллимат яисә гимназия тәмам иткән

---

[1] Нәбатат – үсемлекләр.

[2] Кыйраәтханәсендә – уку залында.

[3] Моталәгага – укуга.

[4] Мөтәфәрди – аулак.

[5] Фәгалиять – эшлеклелек.

[6] Мәсарифенә – чыгымнарына.

кызларны алалар, уку-укыту бушлай, күбрәк керүчеләр мөгаллимнәрнең балалары була. Янында пансионы да бар. Читтән килгәннәр шунда торалар, ләкин ашау-эчүләре үзләреннән. Күпмегә төшә, мәктәп шулкадәр ала. Хәзер хәят бик кыйммәтләнгән, шуңарга күрә кызларга, ашар-эчәр өчен, аена җитмешәр иен түләргә туры килә, ди. Тормышлары безнеңчә, ятак бүлмәсе безнең мәдрәсәләр кебек – идәнгә камыш намазлык җәелгән. Аның өстенә мәдрәсәдәге кебек тәбәнәк өстәлләр тезелгән. Шәкерт шунда тезен бөкләп утырып дәрес укый. Кич берлән астына көрпә җәеп, идәнгә ятып йоклый. Тәһарәтханәләр бик зур, әллә ничә йирдә казан, әллә ничә йирдә зур агач су савытлары. Кызлар шуларга кереп коеналар. Дәресләр бөтен Европа мәктәпләрендәге кебек, шуның өчен ике төрле тел укытыла, берсе – инглизчә, берсе – немецча. Мәктәпнең яхшы куелганына бер яктан сөенеп, үземездә шундый мәктәп юклыгына көенеп чыгып китәмез. Хәзер без тагы кызлар мәктәбенә барамыз. Ләкин бусы демократиянең фәкыйре өчен. Бу мәктәп – һөнәр мәктәбе. Монда, аена өч иен алып, тегәргә, чигәргә, кисәргә, үрергә, бәйләргә, чәчәк ясарга өйрәтәләр. Сыйныф бүлмәләре шыгрым тулган, мәктәптә мең дә биш йөз кыз укый. Һәммә сыйныфта мөгаллимнәр. Берсендә тегәләр, берсендә бик күп киергеләр киереп, идәнгә утырганнар да чигәләр. Берсендә озын өстәлләргә кискән чүпрәк-чапракны салганнар да үтүклиләр, берсендә алларына мангаллар куйганнар да шуларда кечкенә генә тимер коралларны кыздырып торып, шуның берсе берлән сонгый[1] чәчәкне язалар[2], берсе берлән йомшартып, үзләндереп, чәчәкнең сабын бөгәләр. Бер бүлмәдә кош сурәтләрен, урман, ялан манзараларына каратып чигәләр. Шундагы кошларга, хайваннарга җан өрәләр. Мондагы иҗтиһад[3], мондагы тырышлыкны күргәндә, бу халыкның алтмыш ел эчендә шулкадәр зур адым атлавының мәгънәсен дә аңлыйсың, сәбәбен дә беләсең. Монда хатыннар эш кешесе иттереп чыгарылалар. Монда хатыннарга уенчык, курчак, ирләренең хәятын төрлеләндерүче дип карау кермәгән. Монда алар да – ирләре берлән бергә эшләүчеләр, тудыручылар яки ясаучылар.

[1] Сонгый – ясалма.
[2] Язалар – турайталар, ачалар, җәяләр.
[3] Иҗтиһад – тырышлык.

*4 нче май*

Без, көнемез буш булганга (якшәмбе көн), Токионың читтәге бер җәйлек йиренә китәмез. Токиодан илле чакрымлы йирдә, диңгез буенда. Поезд икенче класста, бер сум да тугыз тиен (японча) ала. Үзе бер сәгать тә унҗиде минут бара икән. Җәйлекнең исеме Камакура, диңгез ярында, монда бик күп комлык (пляж), шуңарга күрә монда диңгез коенуы бик шәп була икән. Диңгез буйлап зур авыл утырган. Биегрәк йирләргә бик матур дачалар бина иткәннәр. Бик зур парк диңгезгә карап ята. Үзенең әтрафындагы матур урыннарына электрик трамвай йөри, бик күп матур урыннарны карап беткәч, диңгез якасына салынган бер отельгә кереп, чәй эчәмез. Зур бер отель, халык шыгрым тулган, һәммәсе дә коенырга, кәеф алырга килгән. Европалыларның иң күбесе – америкалылар. Аннан каласы – русиялеләр. Ләкин америкалылар дигәннең дә иң күбе Америка яһүде, русияле дигәннең бөтенләе рус яһүде. Монда, гомумән, яһүднең күплегенә хәйран калмаслык түгел. Болар һәр никадәр төрле-төрле исемнәрдә – америкалы, франсәле, англияле, русияле дип йөриләр дә, милләт ягыннан һәммәсе яһүдләр. Безнең отельнең халкын милләткә бүлгәндә, иң зур күпчелек яһүдләрдә булачак. Кайдан Япониядә тынычлык булганын белеп җиткән, кайдан акча җыеп өлгергән, кайдан килеп җиткән? Чәйдән соң номер карыймыз. Дача урынында булса да, номерның бәһасе бассейн берлән Токиодагыча тугыз-ун иен, хәзерге рус акчасы берлән йөз сум. Ләкин бүлмәләре бик чиста. Манзара бик киң. Әтраф бик матур. Әле коену башланмагангамы, буш номерлар күп. Кичкә таба һава бераз юешләнеп китә. Ягмур башланганда монда бик юеш була торгандыр, дип, бүлмәләр алудан ваз кичәмез. Тиздән монда ягмур ява башлады. Кич берлә өйгә кайтсак, безгә Харбиннан мәктүб бар. Яңа хәбәр юк. Саулык-сәламәтлек. Ләкин акча мәсьәләсе һаман рәтләнмәгән һәм дә Петропавелдан һаман хәбәр алынмаган. Бүген шулай үтә.

*5 нче май*

Бүген иртүк безгә бик күп еллар Япониянең баш министры булып торган, әле быел кыш көне генә истифа итеп[1],

[1] Истифа итеп – отставкага китеп.

Харага* урынын биргән маркиз Окумага зиярәткә барамыз. Безне маркизның янындагы сәркатипләре, үзенең университетындагы профессорлары (хосусый университеты бар) каршы ала. Килеп кергәч тә, ике ягыннан тотып, маркиз Окуманы чыгаралар. Япониянең ихтилялы[1] вакытында, алтмышынчы елларда, маркиз Окума революционер булып, сугышып, аягын сындырган, шуннан бирле аның аягы аксак калган. Зур, таза бер карт. Киң маңгайлы, ачык күзле, зур башлы. Өстенә японча җилән кигән, бай авыл ахуннарына охшаган. Күрешәмез дә утырышамыз. Маркиз: «Мин күптән бирле татар милләтенең вәкилләрен күрергә зар булып тора идем, сез килгәнен ишеткәч тә күрәсем килде, бик шатмын», – ди. Без дә кардәш кыламыз да, шундый олуг кешеләрнең булуы, халык өчен шулкадәр хезмәт иткән кеше күрергә мөяссәр[2] булуымыз өчен, шатлыгымызны изһар итәмез[3]. Шуннан соң безнең туп-тугры итеп сөйләү башлана. Маркиз безнең килүнең сәбәбеннән хәбәре булса да, бездән дә сорый, ачык иттереп бәян итәмез, бик дикъкать берлән тыңлый. Шуннан соң үзенең фикерен сөйли. Фикере шуннан гыйбарәт: «Төрек[4] кавемнәре дөньяның тарихында бик зур роль уйнаганнар. Истанбул, Мәскәү аларның кулында булган. Төрек кавеме – гаҗәеп бер кавем, баһадир кавем, сүзе тугры, үзе хакны сөя. Ләкин ни өчендер соңгы елларда эшләре түбән китте. Сез үзеңезнең ханлыгыңызны югалттыңыз. Төркестан истикъляльн[5] югалтты, госманлы төрекләре авыр бер дәвер кичерәләр. Моның сәбәбе нәрсә дип уйлыйсыз?» – ди. Мин: «Без, төрек кавемнәре, Европага таба киткәндә, бик эчкә кергәнмез. Үземезнең илемездән, бердән, Төркестан үземезнең вә кардәшләремез монголлар вә сездән ераклашканмыз. Шуның өчен без анда дошманга караганда зәгыйфьләнгәнмез. Икен-

---

* Хара – Хара Такаси (1856–1921), Япониянең дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. 1918–1921 елларда премьер-министр булып тора. Бу вазифага ул Сигэнобу Окумадан соң түгел, ә 1916–1918 елларда Япониянең премьер-министры булган Масатакэ Тэраутидан соң килә.

[1] Ихтилялы – фетнәсе.

[2] Мөяссәр – җайлы.

[3] Изһар итәмез – белдерәбез.

[4] Төрек – «төрки» мәгънәсендә.

[5] Истикъляльн – бәйсезлеген.

чедән, без, бер яктан, Европаны җиңүче бер халык бер булып кергән кебек, икенче яктан, Европага икенче дин кертүче, ислам таратучы булып танылганмыз. Шуңарга күрә үземезгә каршы бөтен христиан дөньясыны дошман ясаганмыз. Безгә каршы дүрт-биш гасыр әһле салиб мөхарәбәләре[1] дәвам иткән, шуларның һичберсендә дә мәгълүб булмасак[2] та, гонсырымыз[3] азалган[4], санымыз кимегән. Шуннан соң без русларга каршы, госманлы төрекләре Европага каршы мәгълүб булганмыз. Максадымыз нәрсә?

Русиянең әхвале хәзер бәйнәлмиләл[5] бер хәл алды. Русия халкы үзеннән-үзе үз мәсьәләсене хәл итәчәк түгел. Русиянең идарәсе, Русиядәге милләтләрнең хокуклары Европада хәл ителәчәк, шуның өчен, утыз миллионлы төрек кавеменең теләгән ишеттерер өчен, беренче уларак, сезгә килдек. Сезне кардәш дип, кайгымызны сөйләргә килдек, аннан Европага китәчәкмез. Максатымыз – киләчәктәге Русиянең төзелешендә безнең тавышымызны ишеттерү, милли гаямезне[6] вөҗүдкә чыгару. Милли гаямез бу: Төркестан, Казакъстан, Кырым, Кавказ, Идел буе өчен аерым-аерым штатлар ясау һәм дә шулар арасында мәдәни берлекне тәэмин итү. Без – бер милләт. Исемемез – төрек милләте. Кабиләләремез аерым булса да, тарихымыз, телемез, әдәбиятымыз бер. Русиядә безнең зур урынымыз бар, шуңарга муафикъ хокукымыз булырга тиеш». Шул мәсьәлә хакында озын-озак сөйләшәмез. Утыра-утыра сәгать ярым утырып каламыз. Маркиз фәүкыльгадә[7], гакыллы һәм дә бик күп мәгълүматлы, безнең тарихтан, безнең халәттән – һәммәсеннән хәбәре бар. Ахырдан бергә рәсем чыгартырга чакыралар. Маркизны уртага утыртып, рәсем чыгартамыз. Киткән вакытта: «Бөтен кулымнан килгәнне эшләргә әзер. Без, әлбәттә, ярдәмдә булынырмыз, ләкин мин хәзер сәяси кеше түгел, гыйльми кеше. Безнең

---

[1] Әһле салиб мөхарәбәләре – тәре йөртүчеләр сугышлары.
[2] Мәгълүб булмасак да – җиңелмәсәк тә.
[3] Гонсырымыз – токымыбыз.
[4] Азалган – азайган.
[5] Бәйнәлмиләл – халыкара.
[6] Гаямезне – төп теләгебезне.
[7] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

мәктәпләремез сезнең балаларыңызга ачыла. Мәдәният җәһәтеннән якынлашсак, иншаллаһ, җиңәрбез, дәүләт яңадан туар», – ди. Бик самими күрешә, рәхмәтләр укып чыгып китәмез.

Маркиз Окума – Япониянең бәхетле картларыннан. Ул үзе иштирак итешеп[1], Япониядә революция ясашкан. Шуннан соң, даими уларак, кырык-кырык биш ел милләтенең хезмәтендә булынган. Берничә мәртәбә төрле нәзарәтләрдә министр булып, ахыргы вакытларда иң мәсъүлиятьле[2] эшләрдәге хезмәтләр аңарга йөкләтелгән. Рус-япон сугышыннан соң, Русия берлән Япония арасындагы солых мөзакәрәләренә[3] ул рәис итеп күндерелгән һәм дә рус-япон могаһәдәсенә[4] ул кул куйган. Шуннан соң озын вакытлар баш министр булып торган. Хәзер дә зур бер партиянең башы Хара кабинеты төште исә, маркиз Окума кабинет төзеячәк, диләр. Үзе халкына гыйлем берлән дә хезмәт юлына кергән, үз акчасына зур бер дарелфөнүн[5] бина иткән[6], шунда бөтен факультетларны вөҗүдкә китергән[7]. Хәзерге көндә аның дарелфөнүнендә укучы шәкертләрнең саны гына алты меңгә якын, диделәр. Маркиз Окума үзе эшләгән эшләренең йимеше йитешкәнен үзе күргән, ул үзенең милләтенең зур бер милләт булуын күзе берлән күргән, үзенең милләтенең олуг дәүләт булуын үзе күргән, шуның олуглыгының соңыннан үзе файдаланган.

Бүген өйләдән соң күптән күрешергә йөргән миллионер Асаның япон стилендә бина ителгән өен барып карыймыз. Өй, хакыйкатән[8], бик нечкә иттереп эшләнгән. Бөтен стиле, тарзы мигъмариясе[9] иске японча, бүлмәләренең диварлары япон рәссамнары тарафыннан Япониянең тарихи манзаралары рәсем ителгән. Түшәмнәр күпертеп чигелгән рәсемнәр берлән зиннәт-

[1] Иштирак итешеп – катнашып.
[2] Мәсъүлиятьле – җаваплы.
[3] Солых мөзакәрәләренә – килешү җыелышларына.
[4] Могаһәдәсенә – килешүенә.
[5] Дарелфөнүн – университет.
[6] Бина иткән – төзегән.
[7] Вөҗүдкә китергән – булдырган.
[8] Хакыйкатән – чынлыкта.
[9] Тарзы мигъмариясе – архитектура ысулы.

ләнгән. Диварга, дивар буйларына бик күп япон асаре гатикасы[1] йирләштерелгән. Беренче катта зур бер зал Европа ысулында. Икенче катта тагы зал, япон ысулында өй баскычы кебек киң иттерелеп салынган. Икенче каты беренчесенә караганда арт-ка табарак чыгып тора, икенчесенә караганда өченчесе артка табарак чыккан, дүртенчесе каты зур кыялыкка барып төртелгән. Иң югары манарасыннан бик киң манзара ачыла. Бер якта, уч астында – диңгез, икенче якта – Токио. Бу кеше зур пароход ширкәтенең хуҗасы икән. Сугыш вакытында бик зур файда иткән дә, шулай итеп сәнаигы нәфисәне[2] бергә җыйган. Өйнең алды бик зур бакча. Үзе тау итәгендә утырганга, тауның кыялары ачык зур ташлар берлән зиннәтләнеп, бик мәһабәтле тора. Бер ягыннан сонгый шарлавык ясаган. Аннан су бик каты агып, дәһшәтле бер тавыш биреп тора. Уң ягына күл ясаган. Күлгә каршы бер таш өстенә үзенең һәйкәлен куйдырган. Әле үзе исән булса да, бу һәйкәлне үз акчасына үзе эшләтеп куйдыруны мәслихәт тапкан. Монда андый эшләр гаеп саналмый булырга кирәк. Гомумән, Япония халкының әхвале рухиясендә[3] эшләгән кешеләрнең исемнәрен мәңгеләштерү бик зур урын тота булырга кирәк. Монда һәр урамда, һәр бакчада, һәр зур мөәссәсә алдында һәйкәлләре куелган, барысы да – соңгы утыз-кырык ел эчендәге милли каһарманнар. Хәтта исән кешеләргә дә һәйкәлләр бар.

Бүген безгә теге Сеулда очрашкан япон тагы ашка килде. Хәрби даирәләрдән берничә кешеләргә тәкъдим кәгазьләре язып китергән. Үзе Русиядә шактый торганга, Русияне белә, Европа хәятын алышкан. Япониянең садә[4] хәятыннан бик үк разый түгел кебек күренә. Сүзләре, фикерләре, кыланышлары берлән «Аурупадыр, әфәнде» дип, авыз суы түгә торган төрек бәгенә бик охшаган. Бу кешене без әле Япониядә беренче мәртәбә күрәмез.

*Бишенче май.* Бүген бөтен Япониядә бер милли бәйрәм – малайлар бәйрәме. Бүген бөтен Япон халкы шул малайлар бәйрәмен итә. Һәр йирдә, сазан балыгы төсле иттереп, материядән

[1] Асаре гатикасы – борынгы әйберләре.
[2] Сәнаигы нәфисәне – матур сәнгатьне.
[3] Әхвале рухиясендә – рухи халәтендә.
[4] Садә – гади.

эшләтелгән флаглар асылган. Бакчаларда төркем-төркем кечкенә малайлар, зур кәгазь фонарьлар күтәреп, берәр йыр йырлап йөриләр. Хөкүмәт мөәссәсәләре ябылмый икән, кешеләр сату итә. Ләкин урамда яңарак киенгән ир малайлар бик күп. Сазан балыгы байрагы күтәрүнең мәгънәсе моннан гыйбарәт икән: япон халкы атау халкы булганга, алар күптән диңгез берлән күп эш итәләр. Аларның хәятларында балык бик зур урын тота. Балыклар арасында иң батыры сазан икән. Ирләрдә иң зур сыйфат – батырлык. Шуңарга күрә бөтен япон халкы, ир балаларымыз сазан кебек батыр булсын, дип, сазаннан байрак күтәрәләр. Искечә әйткәндә, сазанга табыналар. Монда кызлар бәйрәме дә була икән. Анысы сентябрь аенда, ди. Анда да махсус байраклар була, ди.

*6 нчы май*

Без бүген Америка сәфарәтханәсенә һәм дә Англия сәфарәтханәсенә бармакчы буламыз. Ләкин иртәдән үк безне бер япон зиярәт итә. Гаҗәбе шул: бу япон төрекчә сөйләшә, исеме Кочи, фамилиясе Окубо*. Төрекчә тәмамән аңлата ала. Үзе игъдади[1] мәктәбендә алман теле мөгаллиме икән. Китаплар аша оста гына төрекчә өйрәнгән. Монда яши торган бер әрмән һәм дә бер төрек ярдәм иткәннәр. Хәзер тәмамән үзенең теләгән төрекчә аңлата. Үзе дарелфөнүн бетергән. Махсус төрек тарихы берлән мәшгуль була, һәм дә японнар арасында тюркологияне бер фән иттереп кую филология җәһәтендә күп тәдкыйкатьтә[2] булынган. Япон теле берлән төрек арасында бик күп мөштәрәк[3] сүзләр тапкан. Мәсәлән, безнең «су» японча «сый» икән, безнеңчә «кара» аларча «коры» икән. «Да» сарыф[4] хәбәре аларда да бар икән. Мәсәлән, мин Казанда яшим дигәнне алар да Казан«да» ди икән. Казан«га» барам дигәндәге аларда «йә» була икән Казан«йә».

---

* Кочи Окубо – япон тюркологы. Озак еллар Маньчжуриядә, төрки-татар эмигрантлары арасында яшәве билгеле.

[1] Игъдади – урта.

[2] Тәдкыйкатьтә – тикшеренүләрдә.

[3] Мөштәрәк – уртак.

[4] Сарыф – морфология.

# 3 нче дәфтәр

## 1919

*(6 май – 17 май)*

Безнеңчә «бар» – мәүҗүд дигән сүз – аларча «ар» икән. Моңарга башка[1] ул бик күп сүзләрдә мөштәрәк тәләффызлар[2], мөштәрәк төпләр тапкан. Аның берлә сөйләшү бик күңелле була. Берничә сәгать бергә утырамыз. Монда японча укырга килгән Мөнир әфәнде Ибраһим* хакында бик начар фикердә, тәрбиясез егеттер, безгә күп зарар иткән, дип сөйли. Тәүфикъ исемле бер төрек егете булган икән, аның хакында бик яхшы фикердә. Фазыл хакында сорыймыз. Теләр-теләмәс кенә җавап бирә. Ахырдан мин аның берлән дуст түгел, безнең аның берлән низагымыз чыкты, монда Вафа исемендә бер татар баласы бар иде, шуның тәрбиясе хакында низаг чыкты. Ул баланы Ибраһим алып килгән иде, ул үзе качып китте дә без тәрбиясенә башладык. Хосусан, Токиодагы әрмәни зур ярдәмдә булынды. Малайны мәктәпкә бирдек, ләкин Фазыл, малайны алыр өчен, күп хәйләләр корды. Ахырдан малайны үзенә алды һәм дә мәктәптән чыгарды. Хәзер ул малайны күрсәтмәенчә тота, диде. Ул малай хакында без инде берничә кешедән ишетәмез, үземез берничә мәртәбә Фазылга, малайны күрсәт, дисәк дә, һаман күрсәтмәде. Арада бер сер булырга кирәк. Бу япон – әдәпсез кеше. Шуның өчен мәктәптән чыгарылды, ди. Теге татар баласы, мескен, шунда юкка әрәм булып ята, күрәсең.

Ул киткәч, без, кызуланып җыенып, сәфарәтханәгә китәмез. Иң әүвәл Америка сәфарәтханәсенә барамыз. Анда секретарь, безне күргәч тә: «Сезгә сәфир бәк җомга көн вакыт тәгаен иткән иде, шуны номерыңызга әйткән идем, ник килмәдегез?» – ди. Безгә номерда әйтмәгәннәр, бу бик күңелсез булды. Инде тагы белешим, дип китте. Килеп: «Хәзер сәфир бәк кабул итә алмый. Берничә көнгә мәшгуль. Теләсәңез, сәфарәтнең башка әгъзасы

---

[1] Моңарга башка – «моңардан башка» мәгънәсендә.

[2] Тәләффызлар – әйтелешләр.

* Мөнир әфәнде Ибраһим – биредә сүз Япониянең җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) Васэда университетында укыган улы Мөнир Ибраһимов турында бара булса кирәк.

кабул итә, аңарга фикерләреңезне сөйләңез», – ди. Без разый булamыз. Безне, бер бүлмәгә алып кереп, бер яшь кенә әфәнде берлән таныштыра. Фикерне-максатны сөйлимез, бик ихлас берлән тыңлый, бик күп сөальләр бирә. Әхвале икътисади, җәгърафемез хакында изахлар[1] сорый, бер-ике минут сөйләшкәннең соңында бер мәсьәлә хакында сәфир бәк берлән киңәшләшеп алыйм әле, бәлки ул сезне үзе кабул итәр, дип, чыгып китә. Кайткач, аягүрә генә, сәфир хәзер кабул итә алмый, аның сәяси мәүкыйгы[2] мондый мәсьәләләр хакында сөйләшергә мөсагыйд[3] түгел. Аурупага бару булды шул: Йокоһамада консул аша телеграмма биреп, рөхсәт сорыйсыз, кеше башына җавап өчен йөзәр иен акча куясыз, ди. Без, бу мәгълүматка ихтыяҗымыз юклыгын белдереп, безгә Америка – рәсман милләтләр иттифакы дигән сәфарнең хамисе[4] кебек күренгәнгә, сезгә шул милләтнең вәкиле дип мөрәҗәгать иткән идек. Сезнең хакта газеталарда язылган хәбәрләр дөрест түгел икән. Сезнең дә сәясәт, Европа дәүләтләре кебек, вак милләтләргә аяк чалу юлына куелган икән. Яңлыш адрес берлән мөрәҗәгатемез өчен гафуларымызны үтенәмез.

Егет кызарып кала, без дә кәефсезләнеп чыгып китәмез. Фәкать Америка сәфарәтханәсенең бу мөгамәләсенә бераз гаҗәпкә каламыз. Аннан туп-тугры инглиз сәфарәтханәсенә китәмез. Анда безне бик тиз бер инглиз кабул итә. Кыска гына максудымызны аңлатамыз. Зур күзле, зур тешле, ашарга хәзерләнеп тора торган кебек кыяфәтле бер инглиз бик дикъкать берлә тыңлый. Кулга-аяк азык эләкте, авызыма җим төште, дигән кебек, авызларын тәмлеләндереп, селәгәйләрен агызып куя, шуннан соң бер-ике көннән сезне чакырамыз, озынрак сөйләшәмез, дип, адресны язып ала. Без моннан күп разый булмасак та, беркадәр канәгатьләнеп чыгамыз.

Өйләдән соң Нияз әфәнде*, акча алыштыру өчен, Йокоһамага бара. Токиода алыштыручы юк. Кичкә таба эт булып арып,

[1] Изахлар – аңлатмалар.
[2] Мәүкыйгы – урыны.
[3] Мөсагыйд – рөхсәт.
[4] Сәфарнең хамисе – сәфәрләрнең яклаучысы.
* Нияз әфәнде – Нияз Максуди, Троицк каласында мәдрәсә мөдире. 1914 елда Нью-Йорк университетының тәгълим-тәрбия факультетында укыган.

кәефсезләнеп кайтып килә. Акчаны алыштыра алмаган. Рус акчасының егермелек, кырыклык керенкалардан* мөрәккәб[1] мең сумга – утыз иен. Себер хөкүмәтенең меңлегенә дүрт сумнан игътибар итеп – кырык иен. Яшел меңлекләргә алты сумнан игътибарән – алтмыш иен. Николаевский** биш йөзлекләргә мең сумга тугыз сум бирәләр. Бу эш безнең кәефне бик боза. Безнең җыйган акчаларның иң зур кыйсеме Себер акчалары иде. Аларның бер кыйсемен Омскида, Красноярда, Харбинда*** алыштырдым, ләкин алай да кулда сиксән мең сум Себер акчасы калды. Калганнары меңәрлек керенкаларда. Аларын николаевскийга алыштырырга өлгерә алмадык, чөнки курс һаман кыйммәт торды. Харбин сәүдәгәрләре һәм дә Милли Идарәнең әгъзасы Латыйф әфәнде Яушевлар**** очсызрак алыштырып булыр дип вәгъдә бирделәр. Безнең бәхетсезлеккә каршы, алар да алыштыра алмадылар. Курс та һаман николаевскийга менгәннән менә. Харбинда иенга алыштырырга мөмкин булса да, аны да эшли алмадык, чөнки без килгәч, иенның курсы күтәрелә башлады. Элгәре 7,50 булды, аннан сигезгә чыкты. Сәүдәгәрләр һаман мәслихәт күрмәделәр, төшәчәк, диделәр. Ниһаять, без киткәндә, унга-унбергә менде. Сәүдәгәрләр, мотлакан төшәчәк дигәнгә, без

---

* Керенка – Вакытлы хөкүмәт тарафыннан оештырылып, 1917 елның 18 нче сентябреннән башлап 1918–1919 елларда РСФСР Халык банкы тарафыннан чыгарылган кәгазь акча берәмлеге. Халык телендә бу акчаларны, элекке министр – Вакытлы хөкүмәт председателе А.Ф. Керенский фамилиясенә бәйләп, «керенка» дип йөртәләр. Аның бәясе реаль алтын белән ныгытылмаган булганга, мондый акчалар законсыз рәвештә урындагы типографияләрдә дә күпләп басылып тарала. Чөнки су билгеләре генә булган ак кәгазьдә басылган банкнотларда бернинди саклык билгеләре дә, хәтта нумерация дә күрсәтелмәгән, печате һәм каракош рәсеменең тажы да булмый. Шуңа да бу акчалар халыкта ышаныч уятмый һәм ул үз кыйммәтен югалтып, азакка таба арзанаеп, беркемгә дә кирәкмәс акча берәмлегенә әйләнә. Шулай да 1922 елның 1 нче октябренә кадәр әйләнештә йөрүен дәвам итә.

[1] Мөрәккәб – җыелган.

** Николаевский – Россиядә Николай Икенче патшалык иткән елларда (1894–1917) басылган акчалар күздә тотыла.

*** Харбин – Кытайның төньяк-көнчыгышында урнашкан иң зур шәһәрләрнең берсе.

**** Латыйф әфәнде Яушев – Мөхәммәдлатыйф Мөхәммәдшәриф улы Яушев (1873–1922), татар сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе.

кулымыздагы бер мең иенны күтәреп, Япониягә киттек. Без киткәч, акча курсы тагы төште. Шуңарга күрә без мең иенымызны бик кысып, сум күтәрелгәнче җиткерү нияте берлән сакладык. Һәрнәрсәнең бит чиге бар. Безнең акча да үзенең чигенә җитте. Без акчасыз калдык. Үземез берлән берәр мал алып килгән булсак та, эш ул кадәр булмас иде. Ләкин Харбин сәүдәгәрләре товар алып баруны мәслихәт күрмәделәр дә без акча күтәреп килдек. Инде ул акчаларны иенга алыштырырга кирәк, чөнки монда һәр мөгамәлә иенга. Аңарга банклар алыштырмый, фәкать яһүд спекулянтлары гына шул эш берлән мәшгуль. Солых Мәҗлесенең рус акчасын бөтен дөньяда кабул итмәскә дигән карары безнең акчаның курсын Япон вә Кытай базарының кәефенә баглады да куйды. Аларга рус сумы никадәр төшсә, шулкадәр файдалы булганга, әлбәттә, төшерә генә баралар. Шуның өчен минем ихтыярымдагы йөз туксан мең сумлап акчаның бик зур кыйсеме чүпкә әйләнеп калу ихтималы бик зур. Әгәр ул бәлагә очрасак, әлбәттә, Европага да чыга алмаячакмыз, монда да бер эш эшли алмаячакмыз. Минем үземнең рус акчасына иманым бик зәгыйфь булганда һәрбер шәһәрдә сәүдәгәрләр берлән киңәшләшә килдем, ләкин һичбер шәһәрдә дә безгә акчаны малга әверергә яисә алтынга әверергә киңәш бирмәделәр. Иркутскида алтын сатып алып була иде, ләкин аны алып бару бик авыр, юлда тотсалар, атып үтерәләр, диделәр. Хәтта безгә үземез берлә бергә акча алып барырга да кушмадылар. Без акчамызны да калдырып килдек һәм дә банк аша перевод эшләттек. Харбинга килгәч тә, берникадәр мал алып булыр иде, ләкин акча күп булмаганга, мондагы сәүдәгәрләр берлән киңәшләшеп, илле мең сумына товар алырга һәм дә Америкада саттырырга булдык. Калганын акчалата алыштырырга булдык. Ләкин сәүдәгәр халкы акча эшен бездән күп белә дип ышанганга, иенга да алыштырмадык, алтын да алмадык. Килгәч үк ваклап, николаевскийга алыштырырга кушсак та, аны да Харбин сәүдәгәрләре эшләп бетерә алмадылар. Латыйф әфәнде Яушев та бер дә хезмәт күрсәтә алмады. Шуңарга күрә акча мәсьәләмез бик мөшкелгә әверелде. Вәхаләнки[1] Петропавелда мин бик күп акча җыйганны белү берлән, бу

[1] Вәхаләнки – чынлыкта.

акча бик күп булды, моңардан мөмкин кадәр күбрәк кеше файдалансын дигән кебек, эшнең әһәмиятен аңламаенча, өч кеше тагы сайлаганнар һәм дә Әхмәдбәк* берлән Садри әфәндегә** шулар арасына керергә кушканнар. Димәк, җыенымыз җыелып җитсә, шул акчага карап, алты кеше Европага чыгып китәчәк. Бу акча хәзерге курс берлән хисаплаганда (барысы өч йөз утыз мең булырга тиеш) егерме ике мең, күп булса, егерме өч мең булырга тиеш. Алты кешегә бүлгәндә, өчәр мең дә биш йөз иен төшә. Шул акчага болар Европага барырга кирәк, Европада торырга кирәк, анда милли мәсьәләне мәхкәмәгә куйдырырга кирәк, анда дүртбиш ай калырга кирәк, аннан кайтырга кирәк, бу мөмкинме? Хәзерге Европа хәятында бер вәкил аена мең иеннан ким тора алмый. Бару-килү тагы биниһая кыйммәт, шулай булгач, бу эш бөтенләй вәкил җибәрү эшен сүтеп ташлау дигән сүз була. Тагы ни өчен анда улкадәр алты, тел белми торган, кеше кирәк. Солтанбәк Мәмлиевнең*** анда нинди кыйммәте була? Ибнеямин Әхтәмов**** анда ни эш эшли ала? Фуад Туктаров***** без эшли алмаган нинди эшне башкара ала? Болар һәммәсе дә ахмаклык, оятсызлык, имансызлык. Эш таба алмаган имансыз мирзаларның ашап ятарга кызыгулары. Инде алар кайчан киләчәкләр? Кайвакыт чыгачаклар? Алла белә. Менә мин шуларны көтеп, Япониядә сумны печатьсез алтын иенга алыштырып ятарга кирәк. Киләчәк шулкадәр караңгы булганга, күңел күтәрелми, акча шул дәрәҗәдә түбән булганга, бик күп эшләр акчага бәйләнып кала. Хәерле булсын. Инде ике атналык ашауга бирмәдек.

---

* Әхмәдбәк – Әхмәтбәк Тимербулат улы Цаликов (1882–1928), мөселман халыкларының милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе. Г. Исхакыйның көрәштәше. XX йөз башы татар матбугатында Әхмәт мирза Салихов исеме белән дә мәгълүм.

** Садри әфәнде – Садретдин Низаметдин улы Максуди (1878–1957), дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, хокук белгече.

*** Солтанбәк Мәмлиев – Петроград Эшче-солдат депутатлар советының әгъзасы.

**** Ибнеямин Әхтәмов – Ибнеямин (Биньямин) Әбүсогуд улы Әхтәмов (1877–1941), хокук белгече, милли сәясәт эшлеклесе.

***** Фуад Туктаров – Мәхмүтфуад Фәсах улы Туктаров (1880–1938), сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист, публицист.

Дәрәҗә төшмәсә ярар иде. Инде иртәгә япон вәли гаһеденең[1] балигъ булу көне, аны карайа[2] чыгамыз. Бу көнгә тәмам 7 сендә, 8 ендә, 9 ында монда зур бәйрәмнәр. 7 сендә Япониянең вәли гаһеденең балигъ булу, унсигез тулу бәйрәме булды. Моңарга японнар бик нык хәзерләнделәр, бөтен урамнарын зиннәтләп бетерделәр. Хосусан, күбесе ал да гөл булды.

Зур урамдагы ике күпернең ике ягына да камышлардан бик пөхтә иттереп, баганалар рәвешендә дүрт почмаклы колонналар эшләделәр. Аларны тышкы яктан яшел нарат чыбыклары берлән ураттылар. Алар ерактан ук ямь-яшел булдылар. Югарысына дүрт якка карый торган тәрәзә ясадылар, башына кызыл кояш сурәтле ак йирлектә байрак астылар. Шулай итеп, бу күперләр теремок капкалары хәлен алды. Сарай алдына шундый капканың тагы зурысын ясадылар. Бу капкаларның һәммәсенә дә «Чук[3] яшә» дигән сүзләр яздылар, урамнарның бөтен ягыннан баганалар утыртып чыктылар, аларның өстләрен бездәге капка башларыннан аз гына тарайтып, такта берлән капладылар. Шулар койманың бөтен агачларын бер буе кызыл, бер буе ак материя берлән чолгап алдылар. Төпләренә, бик пөхтә иттереп, капка төсендә рәткә берәр чәчәк берлән алкалап чыктылар. Шул киртәләргә, бик еш иттереп, кәгазь фонариклар элеп чыктылар. Биналарга, магазиннар, өйләргә бик күп зур һәм кечкенә флаглар берлән бизәкләделәр. Программа моннан гыйбарәт: вәли гаһед иң элек үз сараеннан атасы-анасы сараена барачак, аларны зиярәт итәчәк. Анда чыгып, бер мәйданлыкта гаскәргә рәсми кичә ясалачак. Аннан соң [...]парк дигән йирдә мәгъбәдханәгә[4] барып, гыйбадәт кылачак, аннан соң тәбрикләр кабул итәчәк, аннан сараена кайтачак. Без боларның һәммәсене күрергә дип хәзерләнеп торсак та, вәли гаһеднең сарайга баруы, рәсми кичә ясавы иртә берлән сәгать җидедә үк беткәнгә, аны күрә алмадык. Гыйбадәт итә торган урыны бик ерак булганга, анда да китә алмадык, фәкать сәгать дүртләрдә вәли гаһед сараена кайткан вакытка юлына чыктык. Урам тулы халык, бер яктан гаскәр тезелеп тора. Икенче як буш.

[1] Вәли гаһеденең – варисының.
[2] Карайа – карарга.
[3] Чук – озак.
[4] Мәгъбәдханәгә – гыйбадәтханәгә.

Менә туп атылды. Халык: «Сарайдан чыкты», – диде. Озак үтмәде, атка атланып, полис[1] түрәсе үтте. Еракта гаскәргә әмер булды, солдатлар сәлам турысында мылтыкларын күтәрделәр. Ерактан гына музыка ишетелә башлады. Әллә нинди укалы киемнәрдә атларга атланган бер егермеләп гаскәр уртача гына чабып үттеләр. Алар артыннан тагы бер егермеләп үтте, алар артыннан ачык каретада карт бер түрә үтте. Аның артыннан тагы егермеләп самурай, тагы бер арба, анда тагы карт генераллар, анда тагы утызлап самурай, тагы арба, монысында вәли гаһед утырган. Аңарга каршы карт кына бер кеше утырган. Анысын тәрбиячесе, диделәр. Арттан тагы егерме-утыз атлы. Тагы арбада бер шәйләр[2]. Халык башларын алды, музыка якынлашты. Кычкыру, кул чабу һич юк. Вәли гаһед тә халыкка таба бер ишарә дә кылмады. Шулай итеп, бер-ике минутта үттеләр. Музыка безнең ал ягымызда уйный башлады. Безнең алдагы гаскәрләр мылтыкларын төшерделәр, шуның берлән тәмам. Шунысын оныткан икәнмен: падишаһлар үткән чакта, тәрәзәдән карау-фәлән һич ярамый икән. Иске заманда микадолар*, гомумән, халыкка күренеп йөрми дә икән. Алар япон халкының игътикады[3] буенча, рухани да, рәис [тә] булганга, адәм баласына ошый торган күп эшләрне эшләми икән. Инде Япониянең исляхатыннан[4] соң ул гадәтләр күп үзгәргән. Кич берлән бөтен урам утка батты. Фонарьның, лампаның һич иге-чиге юк. Утка бу кадәр юмартлыкны һичбер карап бетерер хәл юк. Мәсәлән, дүрт катлы почмакдагы бер өй[нең] дүрт диварларын да электрика лампалары бизәкләп бетергән. Бөтен лампаның саны берничә меңнәргә җитә торгандыр. Кайбер вагоннар көндез чәчәкләргә өртелгәннәр иде. Кич берлә һәрбер чәчәк астында бер электрик лампасы килеп чыкты. Вагон йөргәндә төрле төскә иңгән ут тавы хәрәкәт итә кебек хис ителә. Күпер башларында зур прожекторлар дөньяны ялтырата, урам почмакларында төрле төстәге лампалардан оештырып ясалган фонарьлар тегермән канаты кебек әйләнеп ята.

---

[1] Дөресе: полиция.

[2] Шәйләр – әйберләр.

* Микадо – Япониядә хан титулы.

[3] Игътикады – ышануы.

[4] Исляхатыннан – реформасыннан.

Урамда халык. Хатыннар, ирләр, балалар, ирләр, хатыннар, балалар. Һәммәсе японча киенгән, бик аз истисна[1] берлән, һәммәсенең дә аягында агач башмаклар, һәммәсе шат күңелле. Ләкин көннәр коры булганга, тузан бик күп. Сигезенче майда шул бәйрәм дәвам итә. Ләкин тугызында Токио шәһәренең тәхтепай[2] булуына илле ел тулганга тагы зур бәйрәм булачак. Шәһәр урамы, паркларда зур чатырлар корып, хәзерлек күреп ята. Җидесе шуның берлән тәмам. Ләкин кич берлән кайтып, танзан суы (японнарның мәгъдән суы[3], безнең нарзан кебегрәк) эчеп утырганда, безнең берлә ике рус егете килеп танышты. Берсе – Дашик фамилиясендә. Русларның мәшһүр алпавытларыннан. 13 нче елларда Кассо берлә скандаллары да булган иде. Сарай даирәсенең зур түрәләренең углы. Үзе гвардия офицеры икән. Хәзер бер япон магазинында приказчик. Рухы бик күтәренке түгел.

Бүген безнең отельдә бал бар. Токиодагы бөтен Европалы хатыннар, егетләр, кызлар җыелып бииләр. Ләкин бу егетнең биисе бик килсә дә, киеме юкка, безнең берлән утыра. Дөнья бу, өйрәтә. Унөченче елларда кадерле малай булганда, бу, безне белсә дә, күрмәмешкә салынып китәчәк иде. 15 нче, 16 нчы елларда гвардия офицеры булганда очраса, бәлки «молчать» дип кычкырачак иде. Икенчесе, мондагы рус сәфарәтханәсенең икенче драгоманы, немец фамилияле, немец нәселеннән булырга кирәк. Бусы татарча укый белә һәм дә яза белә. Сөйли белмим, ди, ләкин сүз арасында күп җөмләләрне татарча әйтә. Бу егет Петроградта әлсинәи-шәркыя[4] мәктәбен тәмам иткән икән һәм дә Петроградта гимназиядә укыганда Йосыф Әхмәров дигән Казан егете берлә бергә булып, аңардан татарча өйрәнгән икән. Японча белә икән. Немецчасы ана теле, французчасы вә һакәза[5]. Япон хәятыннан бик күп нәрсә белә, бик күңелле егет. Гакыллы, уңган. Киеме дә бар, танцевать дә итә белә. Бүген шуның берлән тәмам.

---

[1] Истисна – чыгарма.
[2] Тәхтепай – башкала.
[3] Мәгъдән суы – минерал суы.
[4] Әлсинәи-шәркыя – көнчыгыш телләре.
[5] Вә һакәза – һәм башкалар.

***8 ендә*** бәйрәм дәвам итә. Ләкин безгә артык кызыгы юк күрдек. Инде беренче эш иттереп Йокоһамага икәүләп акча алыштырырга китәмез. Йокоһама – үзенә аерым шәһәр. Бу – Токиодан утыз биш чакрымнарда, ләкин ике арада электрик поезды йөреп торганга, бер шәһәр кебек, бер сум утыз тиенгә барып килеп була. Поезд да шул ике араны илле минутта йөри.

Йокоһамада порт, Йокоһамада әйберләр күбрәк, шуңарга күрә акча алыштыру анда гына мөмкин, ләкин акчаның курсасы[1] бик начар булганга һәм дә рус халкының кадере бер дә булмаганга, без ояла-ояла гына йөримез. Алыштыручыларның иң күбе кытайлар, аннан кала Русия яһүдләре. Болар бөтен эшне үз кулларында тотканга, бик үк алданмас өчен, элгәре япон банкасына[2] керәмез, акчалар алыштыра дигән өстәленә килеп сорыймыз, ләкин рус акчасыны сатамыз димәенчә, аламыз дип сорыймыз. Банкада без рус акчасыны алмыймыз да, сатмыймыз да дип җавап бирәләр.

Кытайларга керәмез. Алар сөйләшмиләр дә, «не надо» гына, ди. Русско-азиатский банкага керәмез, без алмыймыз, ди. Соң алай булгач, ник аңарга русский дигән сүзне такканнар. Теләртеләмәс яһүдләргә мөрәҗәгать итәмез. Алар ала. Аларның алмаган нәрсәсе, сатмаган малы юк, фәкать бәһасендә генә килеш. Себернең дә ала, керенка да ала, николаевскийны да ала. Бәһаләре очсыз түгел. Вак керенкаларга йөз сумына – өч иен. Себер хөкүмәтенекенә йөз сумына – өч иен ярым, керенканың 250 меңнәренә йөз сумына – алты иен. Николаевский йөзлек, биш йөзлеккә – тугыз иен. Туксанга кадәр бер сумлык рус акчасына бер иен дүрт-биш цент (тиен) биргәннәр. Йөримезйөримез, һич арзан. Ахырдан еларга йитешеп, ахырдан николаевскийларны йөзе – ун иенга, яшел меңнәрне йөзен алты иен утыз центка алыштырамыз. Бездә алмасалар, нишлисең соң? Ул соң Русиядә бер туктамаенча саналып тора торган кәгазьләргә каршы алтын мокабил иттереп[3] чыгарган акчасын Япониягә бирәсең. Әгәр Русиядән товар китереп булса иде, товар алыр өчен, әлбәттә, алыштырырлар иде. Ләкин Себер юлы тәмам

[1] Дөресе: курсы.
[2] Дөресе: банкына.
[3] Мокабил иттереп – алмашка.

бетәр хәлдә булганга, товар да китереп булмый. Шулай итеп, без бер уч кәгазь күтәреп, ач калу ихтималымыз бар.

Аннан кайтуга, безне зыяфәткә[1] көтеп торалар. Японнарның әһле гыйлем, әһле каләм, тиҗарәт[2] галәменең сәфирләре безгә японча бер ресторанда зыяфәт бирәләр. Чәй эчеп, шунда китәмез. Элгәре поезд берлән, аннан трамвай берлән, аннан ары тагы трамвай берлән, аннан ары җәяүләп барып, зур бер суның якасына килеп җитәмез. Шунда зур бер ресторанга керәмез. Безне көтеп торалар икән. Япон кызлары бик иелеп-бөгелеп каршы алалар (хезмәтчеләр хокукында ашханәләрдә кызлар) аякларымызны салып, камыш намазлыклы бүлмәләрдән үтеп, озын коридорлар кичеп, югарыга менәмез. Анда безгә махсус бүлмә хәзерләнгән, миндәрләр салганнар. Кич суыкча булгангамы, кечкенә генә хәтфәләр куйганнар. Без аякларымызны бөкләп утырамыз, японнар тезләнеп, безнең болай утыра белүемезгә гаҗәпләнәләр. Бездә дә шулай икәнне сөйлимез. Шуннан соң кунаклар берлә күрешәмез. Берсе – Америкада һәм Берлинда дарелфөнүн бетергән бер хокук галиме. Хәзер бер яктан мөдәррис, икенче яктан төҗҗар[3]. Берсе – зур-зур акционерное обществоның башы, Америка, Русия, Кытай берлә зур сәүдә итүче. Берсе – бер газетаның мөхәррире, башкалары рус-япон мохитендә күргән һәм дә «Хоҗи Шимбун»* газетасы мөхәррирләре. Һәммәмезгә аерым-аерым подносларда берәр матур япон кызы чәй китерәләр. Чәйләре – сары чәй. Шикәрсез, безгә, өйрәнмәгән кешегә, тәмле түгел. Аны бераз эчәмез, шуннан сүзләр башлана. Америка, Берлиннан кайткан кеше инглизчә, немецча яхшы сөйли.

Башкалар берлән сөйләшергә русча белә торган бер япон тылмачлык итә. Безнең хәл хакында сорашалар. Профессор гыйльми якларга, мәдәни хәяткә әһәмият бирә. Мәдрәсә күпме, мәктәп күпме, әдәбият зурмы, матбугат баймы? Сәүдәгәр сату -эшенә әһәмият бирә. Нинди маллар чыга, кай шәһәрләрдә зур

---

[1] Зыяфәткә – чәй табынына.

[2] Тиҗарәт – сәүдә.

[3] Төҗҗар – сәүдәгәрләр.

* «Хоҗи Шимбун» – «Хочи Шимбун». Бу турыда 27 нче биттәге искәрмәне кара.

сәүдәгәрләр бар? Алар берлә ничек эш итеп була? Без монда японнарның сәүдә мөнәсәбәтләренә кергәнлекләрен бик белгәч, үземезнең Харбин, Владивостоктагы сәүдәгәрләргә хатлар язып, монда килә алмыйсызмы, зур эш эшләргә мөмкин, дип чакырдык. Ләкин безнең сәүдәгәрләр бик акрын хәрәкәт итә торган кешеләр булганга, килә алмадылар. Һәммәсенә дә бик күп изахатлар[1] бирәмез. Шуннан соң ашлар бирелә башлый. Төрек ашларына бераз охшаган, ләкин соуслары бик көчле һәм дә әчеле нәрсә бик күп. Сөзеп, балыкларын гына ашыйм, шулпалары тәмле түгел. Шуннан соң бер хатын гитара кебек нәрсә күтәреп керә. Аның янында тагы берсе бар. Икесе дә картрак кыналар. Шунда төрле буяулар, аллы-гөлле киемнәрдә ике япон кызы (гейшалар) керәләр дә элгәре тезләнәләр, аннан безгә карап сәҗдә кылалар. Әлбәттә, болар сәҗдә кылганнан гына без Алла булып китмимез, алар безгә сәҗдә кылганнан гына безнең җарияләргә әверелмиләр. Ләкин без ни кушсак, шуны эшләргә хәзерлекләрен белдерәләр. Безгә, хәзер бию башлана, диләр. Теге абыстайның берсе кылдан бал көрәге кебек ясалган нәрсә берлә, чиртеп-чиртеп, гитарасында уйный башлый. Икенчесе арнауд[2] каһвәханәсендәге йырчылар кебек тамак эченнән алып йырлый башлый. Кызлар биергә керешәләр. Ләкин бию гади бию түгел. Теге абыстай йыр берлән бер хикәяне сөйли. Гитарадагысы хикәядә әхвальдәге әхвале рухияне әйтә. Болар шундагы кылынышларны уйнап күрсәтәләр. Сүз берлән, хәрәкәт берлән, селкенү берлән. Аякларның гына түгел, кулның, йөзнең, битнең – бөтен әгъзаларның биюе берлән вакыйганың мәгънәсен әйтеп бирәләр. Биюләре бик матур, нәзек, нечкә генә. Хикәяләре бик мәгънәле булырга кирәк. Бик моңлы, кайгылы. Менә тәмам. Тагы гейшалар тезләнәләр, тагы безгә сәҗдә итәләр. Без рәхмәт укыймыз, кул чабамыз. Бер аш тагы ашыймыз. Тагы өч гейша керәләр, тагы тезләнәләр, тагы сәҗдә итәләр. Болары бик яшьләр. Берсе бала гына – 12, 13 яшьләрендәдер. Тагы музыка башлана, тагы теге абыстай йырларга тотына. Тагы гейшалар, оялып, биергә тотыналар, болар тагы оста бииләр, тагы матур

---

[1] Изахатлар – аңлатулар.

[2] Арнауд – Албан.

хәрәкәтләр тудыралар, тагы матуррак фигуралар ясыйлар. Шулай итеп мәҗлес дәвам итә. Без япон музыкасының безнең музыкамызга охшаганны – япон моңы берлән безнең моңымыз арасында бик зур якынлык барлыкны сөйлимез. Бездән татарча йырларга үтенәләр. Гомәр әфәнде* «Ашказар»[1] көен йырлый, гаять хушланып китә, икенче мәртәбә үтенәләр. Икенче йырлаганда, шундагы бер япон кушылып йырлый. Шуннан соң бер мөхәррир иске япон хикәясеннән Чыңгыз ханның маҗараларын шигырьләр берлән йырлый. (Япон легендасы буенча, Чыңгыз хан – япон, имеш. Моның хакында махсус хикәяләре бар, башка урында язармын.) Гомәр әфәнде шул көйгә кушыла. Бәгъзы бер йырларында гына тавышның дулкынлануы икенче тарафка борыла. Кан якынлыгы хакында бик күп сүзләр сөйләшеп, сәгать унбергә кадәр утырамыз. Ашаган-эчкән чакта согындыру ысулы бар икән. Үзенең касәсенә салып, су алып бирү зур кадер-ихтирамнан санала икән. Безне дә согындыралар, без дә согындырамыз. Мәҗлес ябылырга вакыт җиткәч, хөрмәтләре өчен мин бер хотбә сөйлим һәм дә төрек милләте берлән япон милләтенең дустлашуы өчен мәмнүнияттә булынам. Аурупалы америкалылар хәзер сезнең берлән бергә мөттәфикъ[2] төсле күренсәләр дә, [...] чыккан. Сезне үзләре берлә мөсави[3] күргәннән килгән эш түгелдер, фәкать сезнең куәтеңез, көчеңездән курыкканнан килгәннән нәрсә генә. Шуңарга күрә безнең төрек галәменең дөньяда дустлары булмаган кебек, сезнең дә дустларыгыз юк. Әхвальнең китеше буенча, без аурупалыларның шул дошманлыкларына корбан булдык. Сез әле вазгыятеңезне саклый аласыз, ләкин безгә килгән тәһлекә[4] сезгә дә мөмкиндер. Шуның өчен бу ике милләт бер-берсе берлә дуст булырга һәм дә берсенең берсе хокукын мөхафәзә итәргә[5] тиешләр. Азияле әкъвам[6] бүгенге көндә Аурупаның аяк астында. Аның

* Гомәр әфәнде – Гомәр Терегулов турында сүз бара.
[1] «Ашказар» – татар халык җыры.
[2] Мөттәфикъ – фикердәш.
[3] Мөсави – бердәй.
[4] Тәһлекә – куркыныч.
[5] Мөхафәзә итәргә – сакларга.
[6] Әкъвам – халык.

мөкаддиматы[1] аурупалы американлыларның кәефләренә баглы, фәкать сезгә үзеңезнең хокукыңызны мөхафәзәгә моктәдирсез[2]. Ләкин бөтен Азия әкъвамы шул золымны, Аурупа, Американың золымын аңлый, моңардан чыгарга юл эзли. Бу юл табылачак. Фәкать шул вакытта сезнең япон милләтенең безнең берлән, җәберләнгән милләтләр берлән бергә булуыңыз лязим. Азия – азиялеләрнеке дигән сәфәрнең зур байрагын сез күтәрергә тиеш. Минемчә, без шул фикердә дип җавап бирәмез. Бүген кич тәмам була.

*9 нчы май*

Бүген – Токионың тәхтепай булуына илле ел тулу бәйрәме. Шәһәр зур бәйрәм итә. Микадо[3], сараеннан чыгып, әллә нинди бер гыйбадәтханәгә барачак. Мәктәп балалары урамнарда байраклар күтәреп йөреячәк. Самурайлар үзләренең иске гадәтләре буенча рәсми кәмит ясаячаклар. Мәгълүм ки, Япониянең халкы өч сыйныфка бүленмеш. Берсе – кенәзләр, падишаһлар, микадо сәлямәсе[4]. Икенчесе – самурайлар, безнеңчә әйтсәк, мирзалар, бәкләр. Өченче сыйныф – халык. Милләтнең идарәсе, гаскәрнең идарәсе әнә шул самурайлар кулында булган. Аларның үзләренең зур оешмалары булган, үзләренең аерым гадәтләре булган, үзләренең аерым хокуклары, аерым вазифалары булган. Бу яктан караганда, болар төрекләрнең янычарларына бераз охшаганнар. Алтмышынчы елларда шул самурайлар, ихтиляль[5] чыгарып, мәмләкәтнең идарәсен үзгәрткәннәр. Микадоларны руханилар тәрбиясеннән алып, дөньяви тәрбиягә әһәмият биргәннәр һәм дә микадолыкны дөньяви бер падишаһлык хәленә китергәннәр вә сарайны руханиларның тәэсиреннән чыгарыр өчен, Киото[6] шәһәреннән күчереп, Токиога китергәннәр. Шуның өчен бу сыйныф халык Япониянең элгәреге идарәсендә генә түгел, Япониянең асыл лөгатендә дә, Япониянең хәятының Европалы ысулына

[1] Мөкаддиматы – м о н д а : язмышы.
[2] Мөхафәзәгә моктәдирсез – сакларга көчегез җитәдер.
[3] Микадо – хан титулы.
[4] Сәляләсе – нәселе.
[5] Ихтиляль – фетнә.
[6] Киото – Япония шәһәре.

күчүендә зур роль уйнаганнар. Ләкин шуннан соң самурайлар, бер сыйныф уларак, куәтләрен гаиб иткәннәр[1], Японияне тугры юлга чыгарып, идарә эшендәге [...]дән ваз кичкәннәр. Менә шул Токионың пайтәхет булуының илле ел, самурайларның шул милли галәбәләренең[2] дә илле ел булганга, алар да бәйрәм итәләр. Һәммә полклары аерым-аерым байраклар берлән паркка баралар. Микадо үзе дә беренче самурай булганга, ул да бара. Киемнәре үзләренә аерым. Байраклары хәзерге байракка бер дә охшамый, читтән караганда озын саплылар, пумалалар гына, ләкин янына барганда болар һәммәсе дә ат кылыннан ясаган. Мәгълүм ки, иске төрекләрнең байраклары ат койрыгы булган. Шул койрыкны озын агачка тагып, шуны күтәрә торган булганнар. Төрле кабиләләрнең төрле төстә булса, ат кыллылыгында һәммәсе дә мөштәрәк булганнар. Чынгызның байрагы җиде ат койрыгыннан ясалган булган. Менә самурайларның да хәзерге көндә пумала төсле күренгән нәрсәләр шулар. Димәк, бу безнең төрек кабиләләрендә генә түгел, монгол кабиләләрендә мөштәрәк булган (хәзерге көндә Төркестанда шундый ат кылы эләктергән таякларны зиярәт өстләренә куялар). Үзләренең гыйбадәт кебек нәрсәләре бик кызык, ләкин янымыздагы япон һичбер төрле аңлата алмаганга, язу бик авыр. Болар, бер яктан караганда, Төркиядәге мәүләвиләр* биюе кебегрәк нәрсә. Моны озын иттереп, тәфсилле иттереп күрә алмыймыз.

Урамда халык бик күп. Һава бик җилле, бик тузанлы, барырга бик ерак, трамвайлар йөрми. Автомобиль алырга мөмкин, ләкин ул да бүген бик кыйммәт. Безнең акчаның курсы бүген бигрәк очсыз. Шуңарга күрә ярты-йорты мәгълүмат берлән генә каламыз. Микадоның киемен дә күрә алмыймыз. Ул әллә кай вакыт үтеп өлгергән. Мәктәп балаларының кичүләре күңелле, һәммәсендә байраклар, һәммәсендә бәйрәм киемнәре. Ләкин музыка юк, йырлау юк. Гомумән, шул зур бәйрәмнәрдә иң күзгә ташланган нәрсә – музыканың булмавы, булса да, бик азлыгы. Шулай итеп, өч көнлек бәйрәм үтеп китә.

[1] Гаиб иткәннәр – югалтканнар.
[2] Галәбәләренең – җиңүләренең.
* Мәүләвиләр – Җәләлетдин Руми мәзһәбенә иярүчеләр.

***11 ендә*** – якшәмбе көн. Бүген япония[ле]ләр атналык бәйрәмне итәләр. Мөәссәсәләр[1] ябык. Без, барон Микатоны күрер өчен, рус-япон җәмгыятенә барамыз. Анда аны күрә алмаенча, дүшәмбе көнгә вәгъдә алып кайтамыз. Японнарның еллары, айлары, көннәре Аурупа ысулынча түгел, аларда унике ел – бер дәвер, унике ай – бер ел, унике көн – бер атна. Елларның исемнәре безнең иске төрек ел исемнәренә бик охшаган:

Беренче ел – тычкан елы, 2 нче – сыер елы, 3 нче ел – барс елы, 4 нче ел – куян (таушан) елы, 5 нче ел – дракон елан (аждаһа) елы, 6 нчы ел – елан елы, 7 нче ел – елкы елы, 8 нче – куй елы, 9 нчы – маймыл елы, 10 нчы – тавык елы, 11 нче – эт елы, 12 нче – кабан дуңгызы елы. Айларның хисабы цифр берлә генә йөри: беренче, икенче, өченче, дүртенче. Көннәр дә ел рәвешендә һәм еллар исемендә йөриләр. Шуңарга күрә аларда айны атналарга бүлү булмаган. Ел японнарча ай берлән сайланылган. Язу да сәнәи шәмсиядә[2], сәнәи камәриядә[3] йөргән. Соңгы елларда Америкага тәкълидән[4] якшәмбе көн бәйрәм итә башлаганнар.

Бүген көн әһәмиятсез генә үтә. Милли Идарәдән хәбәр юк. Бүген төшемдә Хәсәнне* күңелсезрәк күрдем. Бер-бер зарар булмаган булса ярар иде инде.

Акча курсы начар, Франсәдән дә җавап килми. Тагы шул көннәрдә Нияз әфәнде** дә китәчәк булганга, без бөтенләй кулсызаяксыз каламыз. Мин инглиз укыр өчен мөгаллим эзләсәм дә, таба алганым юк.

*12 нче май*

Бүген безнең эшләр бик күп, берсе – бүген безне инглиз сәфарәтеннән мәктүб язып чакырдылар, икенчесе – бүген безгә барон Микато вәгъдә куйды, өченчесе – Гомәр әфәнде*** Йокоһамага акча курсын белергә китте. Нияз әфәнде тиз китәчәк

---

[1] Мөәссәсәләр – оешмалар.

[2] Сәнәи шәмсиядә – кояш елы.

[3] Сәнәи камәриядә – ай елы.

[4] Тәкълидән – ияреп.

* Хәсән – Г. Исхакыйның бертуган энесе Әхмәтхәсән Исхаков булса кирәк.

** Нияз әфәнде – Нияз Максуди, Троицк каласында мәдрәсә мөдире. 1914 елда Нью-Йорк университетының тәгълим-тәрбия факультетында укыган.

*** Гомәр әфәнде – Гомәр Терегулов турында сүз бара.

булганга, без беренче эш иттереп, тагы автомобиль алып, Франсә сәфарәтханәсенә барамыз, анда тагы яңа хәбәр юк, җавап көтәмез, килергә тиеш иде. Килде исә җавап бирәмез, диләр. Аннан саубуллашып чыгып китәмез, туп-тугры барон Микато берлән күрешергә китәмез. Ул да безне көтеп тора икән. Мәсьәләне аңлатамыз. Безнең Аурупага чыгуымызга японнар ярдәмдә булсын иде димез һәм дә япон пароходларында урын табу[ны] җиңеләйтсәгез иде дип үтенәмез. Барон: «Пароход мәсьәләсе зур түгел, тегесе хакында уйлашыйм әле, тиз генә җавап биреп булмый, мин сәясәт дөньясыннан түгел, кулдан ни килә, шуны эшләрмен», – ди. Аннан да эшне бетереп кайтамыз. Гомәр әфәнде дә кайткан, шатлыклы хәбәр бар. Бүген рус акчасының курсы сумына бер тиен күтәреләчәк, ягъни рус акчасының сумы җиде тиенгә хисап ителеп алына башлаган, без, һәрвакыт начар хәбәр ишетергә өйрәнгән кешеләр, моңарга да сөенәмез.

Аштан соң, чакырылган мәктүбне алып, инглиз сәфарәтханәсенә китәмез. Анда безне сәфарәтнең мөстәшаре[1] кабул итә. Аңарга мәсьәләне аңлатамыз. Беренче мәсьәләдә Русиядә сез руслар гына баш дип белмәңез, анда без дә, утыз миллион төрек халкы бар, безнең дә мәнфәгатемез бар. Без дә Русиядә тынычлык телимез, ләкин үземезнең мохтариятемезне мөхафәзә[2] шарты берлән. Безнең теләкләремез – Төркестан, Казакъстан, Кырым, Кавказ, Идел буена мохтарият алудыр. Моны билфигыль[3] алган да идек, ләкин большевиклар җимерделәр. Хәзер большевик берлән сугышып ятамыз, икенче яктан Колчак хөкүмәте дә безнең мохтариятләремезгә каршы килә, аның берлән дә тартышамыз. Шуның өчен Русиядә бер-бер хөкүмәтне тану дигән мәсьәлә туса, безнең шул хокукларымыз ихтирам итү шарт ителсен иде. Икенчедән, без – солых һәйәте[4] әгъзалары. Русиянең хәле Европада хәл ителәчәк булганга, Европага чыкмакчы булып килдек. Европага китү хәзер бик авыр икән, шул юлда ярдәм итүеңезне үтенәмез. Сәфарәт кешесе бик күп сөальләр бирде. Җаваплар бирдек, безнең хәят хакында гына түгел, Русия

[1] Сәфарәтнең мөстәшаре – илчелек киңәшчесе.
[2] Мөхафәзә – саклау.
[3] Билфигыль – чынлыкта.
[4] Һәйәте – комиссиясе.

хакында да мәгълүматы бик зәгыйфь икән. Безнең мәүкыйгы җәгърафемезне[1] бик яхшы иттереп, Идел буе, Кавказ, Төркестан дип әйтеп бирсәк [тә], сез диңгез мәмләкәтеннәнме дип, әллә ничә сорады. Ахырдан рус сәфарәтханәсендә булындыңызмы, диде. Хәер[2], булынмадык, лөзүме дә юк, чөнки ул сәфарәтнең һанги[3] хөкүмәтнең сәфарәте икәне безгә мәгълүм түгел, дидек. Сез дә безнең берәр кешемез берлән күрештеңезме, диде. Хәер, күрешә алмадык, чөнки ул эш мәгълүм булса, Колчак хөкүмәтенең казаклары атып үтерү ихтималы бик якын иде, дидек. Шуннан соң без сезнең хакыйкатән шул кешеләр икәнеңезгә иманымыз тулы булса, сезгә визаны тиз ясар идек, хәзер хөкүмәттән рөхсәтсез ясап булмый, шуңарга күрә телеграф берлә җавап сорыймыз, диделәр. Шуннан мин, бу – хосусый кешеләр өчен эшләнә торган юл, без – милләт вәкилләре, безгә мөгамәлә башка булырга тиеш иде, дидем. Сезнең мандатларыңыз бармы, диделәр. Бар, дидем. Ләкин һаман шул иске сүзләрендә калдылар. Шуннан мин, сезнең Русияне белүчеләреңездән профессор Ярис Тани һәм дә Һарольд Вильямс* яхшы белә, дидем. Шуннан соң мәктүбләр берлән җавап бирергә булдылар. Без күрешеп чыгып киттек.

Нияз әфәнде бүген китә алмады, билет булмады. Ул иртәгә иртүк китәчәк. Мин кич буе Милли Идарәгә мәгърузә[4] яздым һәм дә Харбинга, Иркутскига, Томскига мәктүбләр яздым. Бүген бераз төрекчә белә торган бер японнан инглизчә дәрес алырга башладым. Ләкин япон булганга, үзенең тәләффызы[5] начар, «р» хәрефен бер дә тәләффыз итә алмый. Шуңарга күрә канәгатьләнмәдем. Хәерле булсын.

*13 нче май*

Бүген Нияз әфәнде иртүк китте. Без үз башымызга калдык. Бераз авыррак булыр инде. Фазылбәк килеп, безгә үзенең дәрес

---

[1] Мәүкыйгы җәгърафемезне – географик урыныбызны.
[2] Хәер – м о н д а : «юк» мәгънәсендә.
[3] Һанги – кайсы.
* Гарольд Вильямс (1876–1928), Британия журналисты, тел белгече.
[4] Мәгърузә – доклад, проект.
[5] Тәләффызы – сүзне әйтүе.

бирүгә теләвен тәкъдим итте һәм дә Йокоһамага күчәргә кирәк иде дип тәүсыядә булынды[1]. Без үземез дә Йокоһамага күчү уенда торамыз, ләкин сәфарәтханәләр берлә монда безнең эшләр багланган.

Гомәр әфәнде аштан соң, Йокоһамага барып, бүлмә эзләп кайтты. Таба алмаган, ләкин булачак кебек күренгән. Анда китүдән беренче максат – хәятны очсызландыру. Монда бик һәйбәт булса да, монда шактый бәһале, мин ашау-эчү берлән ун иен түлим, Гомәр әфәнде тугызны. Бу акча да хәзер безгә күп төсле күренә, чөнки акча аз, шуңарга да күз теккән кешеләр бик күп. Нишлисең соң, халык шундый булгач.

Беренче мәртәбә чит дәүләтләргә вәкил күндергәндә фәкыйрь, рәзил[2] булмаслык иттереп, эш кубар дәрәҗәгә җитмәгәнмез. Бу отельдә әлегә кадәр Америка фирмаларының приказчиклары торалар, көнләп кенә түгел, айлап, еллап торалар, тора алалар. Без – олуг бер милләтнең олуг йомыш берлән җибәрелгән вәкилләре – көненә ике-өч сум файда итәр өчен, читкә чыгарга мәҗбүрмез. Бүген дә рус акчасының курсы кичәгечә, ягъни йөз сумына бер иен күтәрелгән. Көн шулай үтә.

*14 нче май*

Бүген һичбер яңа эш булмады. Фазылдан гына безне иртәгә чакырып мәктүб алдык. Бүлмәләр тапкан. Ләкин миңа әле күчәргә муафикъ түгел, эшләр бераз бар. Монда кеше күрү дә уңай. Бүген Харбиннан беренче май рус газеталарын алдык, бик кичегеп килә, цензор тота булырга кирәк.

Кич берлән йөрергә чыккан идем, кызык бер вакыйгага очрадым. Бер кеше зур урамдагы телефон баганасының иң югарысына чыккан да, әллә ниләр сөйли. Урамга дүрт-биш йөз кадәр халык җыелган. Теге кулын бутый, йырлый, әллә ниләр сөйли. Түбәндәге халык шарык килеп көлә. Халык янына бик күп городовой җыелды, ләкин халыкка һичбер сүз әйтми. Урамга халык тулганнан-тула бара. Трамвайга йөрергә бик авыр. Трамвай бик акрынлап үтә, автомобильләр чират көтә. Халык һаман җыела. Теге җүләр һаман кылана, ул сөйли, йырлый, көлә. Түбән-

[1] Тәүсыядә булынды – киңәш бирде.
[2] Рәзил – түбән, начар.

нән аңарга кул да чабалар. Менә бер эшче кыяфәтендәге кеше баскыч берлән тегенең янына менә, төшәргә чакыра булырга кирәк, ике арада моназарә[1] китә, халык һаман шаркылдый. Ахырдан теге чакырырга менгән кеше берни эшли алмый төшеп китә. Теге җүләр тагы шәбәя, ул, азан әйтергә хәзерләнгән кебек, аягүрә баса, куллары берлән бутана, әлләниләр көлдерә. Аны чакырырга икенче кеше менә. Аңардан көлеп, төшереп җибәрә. Ахырдан үзе җиләнен рәтләп, билбавын рәтләргә тотына, җил берлән чабулары ачыла, үзенең штаны да юк икән. Халык тагы шаркылдый. Шуннан бик җитди кыяфәт алып, бик тиз тимерчыбыктан тимерчыбыкка маймыл кебек эләгеп, тырмашып төшеп тә китә. Ләкин төшү берлән, үзен халык чормап ала. Полиция каядыр алып китә. Иң гаҗәбе шул – шул җүләрнең кылануына ун-унбиш минут халык та түзеп тора, полиция дә бер эш тә эшләми. Кем булгандыр, мәгълүм булмады: яисә исеректер, яисә бер җүләрдер. Ләкин, кем булса да, унбиш минут буенча шул урамны рәхәтләндерде.

*15 нче май*

Бүген мин бик каты авырып уяндым. Тәрәзәне ачык калдырып яткан идем дә, төн суык булган, ахырда суык тигән. Кәеф бик начар булганга, иртүк торып, аласы әйберләрне алырга базарга чыктым. Минем һичбер төрле пальтом юк. Сатып алырга акча кызганыч. Әлегә кадәр анда-монда зуррак йиргә барганда, Нияз пальтосын киеп бара идем. Инде ул да китте, шуның өчен пальто алырга мәҗбүр булдым һәм дә яңа пальто алдым.

Өйләдән соң Йокоһамага киттек. Фазылбәк, безгә бүлмә таптым дип, хат язган иде. Ләкин бүлмәләр бик начар, акчамыз бик аз булса да, анда барып тору бөтенләй базарны төшерәчәк булганга алмадык. Гомәр әфәнде яңадан бүлмә карарга калды. Бүген Иркутскига газеталар һәм дә хат җибәрдем. Һавалар суыкча, көннәр ягмурлы. Юешлек күп. Без килгәннән бирле монда бездәге җәй кебек эссе көн бер генә булды.

Бер йирдән дә хәбәр юк.

[1] Моназарә – бәхәс.

*16 [нчы] май*

Бүген иң күңелсез вакыйга монда жандармский правлениенең бер чиновнигының визиты булды. Япониягә барырга уйлаганга, монда бик кысынкылык икәнен сөйләгәннәр иде. Ләкин без һичбер төрле яшерен эшемез булмаганга, бернәрсәдән курыкмаган идек. Монда килгәч тә, шул юлда дәвам иттек. Бөтен теләкләремезне ачыктан-ачык сөйләдек, ачыктан-ачык яздырдык. Ачыктан-ачык үземез мәгърузәмезне[1] кешеләргә бирдек.

Шуның өчен безнең арттан алай тикшереп йөрерлек эш булмаска тиеш иде. Ләкин без килеп, бер-ике көн торгач та, безне полиция чиновнигы зиярәт итте. Әллә нинди мәгънәсез-тозсыз сөальләр бирде, һәммәсен язды. Аннан тагы бер-ике-өч көннән килеп, тагы әллә ниләр сорады. Үземезнең бәгъзы кәгазьләремезне күрсәттек, газеталар укырга куштык. Аннан соң тагы бер проводник алып килде. Анысында сез үзеңезгә хөкүмәт төземәкче буласыз икән, фәлән дип сөальләр бирде. Без, әүвәл синең эшең түгел, без монда эш берлән килгән кеше, үзеңә кирәген генә сора, дип кырт кистек тә киттек. Аннан берәр атнадан тагы килде. Әллә нинди тозсыз-татсыз сөальләр бирә башлады. Мин бик каты кискәч, мин сезгә яхшылык итәр өчен генә йөрим. Менә китәргә телисез икән. Пароход белешергә куштылар. Сезгә ике урын кирәкме, өчме, фәлән, дип сүз башлады. Алай булса, ярый-фәлән, дип әйткәч, тагы үз эшенә керәште. Кырыгынчы мәртәбә сезгә ничә яшь, ник килдеңез, ни эш бетерәсез? Мин тагы ачуландым. Шуның берлән көрсенеп чыгып китте. Бүген иртә берлән жандармский правлениенең тылмачы дип, берсе килде, русча начар гына сөйли. Элгәре паспортны сорады, ахырдан бик күп сөальләр бирде. Кайсысына җавап бирдем, кайсысына бирмәдем. Тагы ник монда килдек мәсьәләсенә җиткәч, озын иттереп ник килгәнне, үземнең махсус йомышым берлән түгел, милләт йомышы берлән килгәнне сөйләдем. Бик ачу килгән булганга, озын иттереп үземнең хәлне аңлаттым. Хәйләкәр генә күзле, әллә нинди ябыша торган сөальләр берлән мине большевик түгелме дип, имтихан итүче җәфа аптырап калды. Кәгазенә язган бик күп сөальләр булса да, каләмен, кә-

[1] Мәгърузәмезне – проектыбызны.

газен тыгып куйды. Шуннан бер япон кебек безнең халыкның тормышыннан сөальләр бирә башлады. Сезгә безнең берлән бер икътисади бер иттифакъ ясарга кирәк иде, диде. Японнарның һәммәсенең теләкләре шул: икътисади бер иттифак ясау. Ләкин аннан үзләре генә файдаланырга уйлыйлар, башка халыкның мәнфәгатен аңлавын һич хәтерләренә дә китермиләр. Башка милләтләр берлә эш итәргә өйрәнмәгән, мәнфәгатьләрнең берлеге әсасына эш күрүне әллә аңламыйлар. Үзләренә килгән европалы, американы һәрвакыт үзләренә хәзер итеп кенә торганга булырга тиеш. Яхшы ният берлән килгән кешегә һич ышанмыйлар. Гомумән дә, яхшылыкка ышанмыйлар булырга кирәк. Япониядә хәят низагысы бик каты булганга, һәрнәрсәгә каршы мәгълүм кадәр акчалата бәһа тәгаен ителгәнгә, болар өчен, зур гаяләр[1]-идеяләр өчен хезмәтне болар аңламый кебек тоелалар.

Һәр нә исә[2], Русиядә I Николай* заманасыннан да ямьсез иттереп эшне кую, килгән кешенең берсен большевик дип утыртып куеп, Габделхәмид** идарәсендәге кебек артыннан кеше йөртүләр шулкадәр мәмләкәт мәйданга китергән, шулкадәр кыска вакытта шул дәрәҗәдә мәдәни яктан үскән японнар өчен гафу итмәслек гаептер. Һәрбер аңлы кеше, үз-үзенә ихтирамы булган кеше алдында үзләренең мәдәни дәрәҗәләрен бик түбән төшерә торган мәгънәсезлектә бүген һичбер яңа мәсьәлә булмады. Шул визит кына эчне пошырды. Ахырдан уйлый-уйлый, монда ашын ашап ята торган Русия сәфарәтханәсенең доносы гына түгелме дигән шөбһәгә төштек. Ни булса да, күңелле түгел... Хәерле булсын.

Гомәр Йокоһамадан номер табып кайтты. Иртәгә күчәчәк, мин ялгыз калам.

*17 [нче] май*

Бүген иртүк көн төш сөйләү берлән башланды. Без инде күптән хәбәр алмаганга, Петропавелда ни бар, ни юк, безнең

---

[1] Гаяләр – теләкләр.

[2] Һәр нә исә – нәрсә булса да.

* I Николай – Россия императоры Николай I Павлович Романов (1796–1855). 1825–1855 елларда идарә иткән.

** Габделхәмид – Габделхәмид II (1842–1918), 1876–1908 елларда идарә иткән Госман империясе солтаны.

берләи барырга сайланган кешеләр кайда, кайчан киләләр икәне мәгълүм булмаганга, шул сөальләрнең һәммәсенә җавапны төш берләи генә эзлимез. Моннан берничә көн элек безгә дип җигелеп куелган тройкага Солтанбәк утырырга теләгәнен һәм утыра алмаганын күреп, Солтанбәкнең килә алмавына юраган идек. Бүген Фуадның* килүен күрдек, шундагы тәфсыйлләтеннән аның да килә алмавына юрадык. Хәзер Себер гаскәре Казанга җитеп килгәнгә, Фуадның ул кадәр тырышып сайланган эшеннән кире кайтуы бик ихтимал. Ул бу эшләрне берсен дә ышанганнан, иман берләи файда була дип эшләми, фәкать кешедән калмас өчен генә эшли. Әгәр шулай булып чыкса, безне юкка ике ай көттерүләр бушлай һавага оча. Һәр нә исә, инде күптән шул эшне ача торган берәр хәбәр булырга тиеш. Икенче эш – Гомәр бүген Йокоһамага күчеп китте. Эч пошканнан бер эш булсын әле, аз булса да үзгәреш булсын дип күчү инде, ни булып чыгар. Файда итәрме, зарармы? Номеры мондагыга караганда очсызрак.

Бүген мин төрекчә белә торган япон берләи японнарның милли концертларына бардым. Концерт Америка миссионерларының залында булды. Зал бик зур түгел, алай да халык тулы түгел иде. Тыңлаучыларның йөзгә туксаны хатыннар, кичке концертларда ирләр күбрәк булучан икән. Хатыннарның бөкрәеп беткән карчыклардан башлап, имчәк баласына кадәр һәр сыйныфы бүген бар. Халык урта сыйныф булырга кирәк. Байча киенгән хатыннар бик аз. Пәрдә ачыла. Залдан сәке кебек күтәреп эшләткән сәхнәдә халыкка каршы биш кеше утырган. Икесенең кулында – озын буйлы өч кыллы гитара кебек бер уен коралы. Өчесе алдына Истанбул мәсҗедләрендә, мәдрәсәләрендә китап куяр өчен алдына куйган, югары башы күтәрелеп тора торган көрсиләр, аларның артына тезләнеп утырган кешеләр рөкүгъга[1] киткән кебек башларын бөккәннәр. Берсенең дә башы күренми. Менә акыртын гына музыка башлана, сирәк-сирәк чиртеп куя бер музыкант. Үзеннән әллә нинди тавышлар чыгара. Менә башын бөгеп, моракабәгә[2] киткәннәрнең берсе башын акрын гына күтәрә. Авызын озын гына йомып тора да, акрын гына ачып, тамак эчен-

* Фуад – Фуад Туктаров турында сүз бара.

[1] Рөкүгъга – иелеп торуга.

[2] Моракабә – уйга чуму.

нән хәрефләрне чыгарып, бер нәрсә көйләргә тотына. Тавышы бик авырлык берлән чыга. Йөзе кызара, тамырлары бүртә, үзе йыртылырлык була. Бер кычкырыбрак җибәрә, бер эчкә таба тавышын ашый. Безгә бер дә тәме булмаса да, бик мәшәкатьләнә. Менә акрын гына анның күршесе башын моракабәдән күтәрә, ул йырлап китә. Беренчесе туктый. Ул икенче төрлерәк

## 4 нче дәфтәр

### 1919 ел

*(Май-июнь)*

тавыш берлән бераз көчәнгәннең соңында, өченчесе башын калкыта. Аннан өчәүләп тотыналар, төрле тавышлар чыгаралар. Кычкыралар, эчкә тавышны тарталар, бик маташалар. Надан шәкерт сабак укыган кебек арыйлар. Ләкин миңа дыдык кешенең[1] ашыгып сөйләргә теләгәне кебек хис калдыра. Бер яктан, ачуны китерә, икенче яктан, шул зур ук карт кешеләрнең шулай зәхмәт чигүләрен кызганасың. Тәмам. Халык кул чаба, бу бер тарихи әкиятне йыр берлән әйтү икән, күңелле, имеш. Пәрдә ябыла, тагы ачыла. Бу юлы өч-дүрт кеше «Юләр яз» дигән музыка парчасын уйнап чыгалар. Беренче башлап уйнаганнары – бию көе, күңелле генә, җиңел генә, безнең «Әтнә көе»нә бик охшаган. Монысында музыйкый як[2] куәтлерәк, урталары да бер җырдан гына гыйбарәт түгел, бер вәзене бар, ахыры тагы күтәренке кылларда шатлыклы, кәефле бию тавышлары берлә бетә. Монысы соңгырак заманның көе икән. Шуннан соң тагы пәрдә ябылып, пәрдә ачылган. Бер хатын, ике ир чыгып тезләнәләр. Хатын – уртада, кулында – өч кыллы гитара. Хатынның бер ягыннан бер ир курай тоткан, икенче ягыннан бер сукыр берничә кыллы озынча иттереп эшләгән цитра кебек нәрсәне йиргә сузып салган (буе ике аршын кадәре бар). Менә бер яктан уйный башлыйлар, икенчедән, үзләре йырлыйлар. Боларның уен коралларыннан да, үзләреннән дә өчесеннән өч төрле тавыш чыгып,

[1] Дыдык кешенең – тотлыга торган кешенең.
[2] Музыйкый як – музыка ягы.

бергә кушылганда бик матур булып китә. Озын бер көй уйныйлар, йырлыйлар, безнең «Агыйдел буйлары»* дигән көйне хәтерләтә. Кайбер йирләре тәмам безнең көй төсле булып, кайбер йирләре бөтенләй «чәһәршәмбегә» борыла[1]. Бусында музыкалык күп, моны мин дә рәхәтләнеп тыңлыйм, бу көй миндә әллә кай йирләремә тәэсир итә. Хосусан, курайчының борып йибәрүләре тәмам башкорт дәртләрен күз алдына китерә (курае камыштан). Халык бик каты кул чавып[2] озата.

Аннан соң бер мәгънәсез нәрсәне бик озын чыелдаталар, аннан соң бию. Ләкин бию гади бию түгел: гакылдан язган бер хатынның биюе. Хикәя шуннан гыйбарәт: бер хатынның бердәнбер углын караклар урлап, Токиога коллыкка сатканнар. Хатын шуның кайгысыннан гакылдан язган, ләкин үзе, йөрәге сизеп, Токиога таба килә. Токиога килеп җиткәч, алдында зур су. Аны чыгарга күпер юк. Көймәчене эзли. Көймәче иптәшләре берлән уйнап-көлеп, биеп утыра. Хатынның көймәчегә түләргә акчасы юк, көймәче: «Бер биесәң, бушлай чыгарам һәм дә угылыңны күрсәтәм», – ди. Хатын бии, биюе бик зур хис калдыра. Ләкин, бертөрле палар[3] бик күп мәртәбә тәкрарланганга, карауччыны ялыктыра. Шуның берлән сәгать 1 ½ дә башланган концерт дүрт ярымда бетә. Уйнаган вакытта тыңлаучыларның барысы да диярлек кулларындагы баскан кәгазьгә карап баралар, һәммәсе бик дикъкать берлән тыңлый. Тавышлану-нитү һич юк. Гомумән, музыкалары бик ибтидаи хиссият калдыра. Бер дә тәрәккый итмәгән булырга тиеш. Номерлары бик озын – тавышның әйләнүе бик бертөсле. Йырлаучыларның тавышлары бер дә матур түгел, концертта европалы бер дә юк иде. Бүген чәйне, кичке ашны ялгыз ашадым-эчтем. Хат-хәбәр юк.

*18 [нче] май*

Бүген бераз хасталанып тордым. Баш авырта, кәеф юк. Бер яктан, мигъдә[4] начар, икенче яктан, әхваль шәп түгел, өченче

---

* «Агыйдел буйлары» – татар халык җыры.

[1] «Чәһәршәмбегә» борыла – монда: бөтенләй читкә китә, безнең көйгә ошамый.

[2] Дөресе: чабып.

[3] Палар – бию хәрәкәтләре.

[4] Мигъдә – ашказаны.

яктан, киләчәк бик караңгы. Шуларның барысын бергә җыйгач, иргә кешегә[1] түшәккә ятарлык кәефсезлек була. Иртәдән, сәгать алтыдан ук уянып, йоклый алмасам да, торып, юынып укырга керештем. Әле чәйгә чыгарга бик иртә. Аннан соң, ваннага кереп, аннан соң гына чәйгә чыктым. Өйләгә кадәр көн шулай сүрән генә үтте. Өйләдән соң Гомәр әфәндегә Йокоһамага киттек. Номеры күңелле генә икән. Ашату-эчертү уртача гына, ди. Ашның иң күбесе ботка икән. Номерның хуҗасы, рус халкы ботка ашарга ярата дип ишеткән дә, ботка иң очсыз аш булганга, русларга ботка пешерергә тотынган. Гомәр әфәнденең бүлмәсеннән чыгып китеп, яңа бер номер таптык. Бик матур урында: тау башында, манзарасы диңгезгә [карый], бәһасе дә кыйммәт түгел. Гомәр шунда күчәргә булды, мин дә язылып кайттым. Мин дә бу Токиодан бик туйдым. Хәзер кич берлән бик арып торам, шуның өчен иртәрәк ятарга уйлыйм.

*19 [нчы] май*

Бүген Нияз әфәндедән телеграмма килергә кирәк иде, ни өчендер юк. Иртә берлән тагы бер жандарм кереп, хәл-әхвальне сорап чыкты. Рус-япон җәмгыятендә һаман әле безнең тәрҗемәне бетермәгәннәр, болай кичектерүләре касдән[2], әллә үзләре шулкадәр вәгъдәсезме? Пароход хакында һәм дә виза хакында да бер эш дә эшләмәгәннәр. Аларга ышаныч шактый кимеде. Бүген озак уйлап торып, японнарның башка бер мөәссәсәләренә барып визит ясадым. Зур илтифат берлән каршы алдылар, берәр сәгать сөйләштек, бөтен әхваль хакында сораштылар, минем мондалыкны элгәре дә белгәннәр, сүз арасында мәгълүм булды. Тагы берәр мәртәбә чакырырга булдылар.

Хариҗия нәзарәтенә[3] барыр өчен вәгъдә алырга куштым. Чәршәмбе көн китәрмез төсле тора. Франсәдән[4] хәбәр юк. Бик озынга калыр, ахрысы. Сәламәтлегем шәп түгел. Мигъдә начар, баш авырта.

---

[1] Дөресе: ир кешегә.
[2] Касдән – юри.
[3] Хариҗия нәзарәтенә – тышкы эшләр министрлыгына.
[4] Дөресе: Франциядән.

*20 [нче] май*

Бүген берничә мәртәбә, барон Микатоны күрер өчен, рус-япон җәмгыятенә бардым, тугры китерә алмадым. Аңардан шул виза мәсьәләсендә ярдәм сорар идем. Мәктүб-фәлән булмады. Өйләдән соң акча алыштырырга Йокоһамага киттем. Меңенә йөз дә җиде иен илле цент алдым. Гомәр* бүлмәсенә күчкән. Нинди буласы мәгълүм түгел, ләкин һавасы һәйбәт. Кич берлән кайттым, Харбиннан телеграмма бар иде. Фуадлардан** һич хәбәр юк диелгән, безнең акчаның бер кыйсеменә товар алганнар. Инде аны сата алмаенча йөдәмәсәк ярар иде. Бүген бер журнал китереп бирделәр, исеме «Мәшрике әгъзам»[1], Асия милләтләрен берләштерер өчен тәэссис ителгән[2] икән. Нашире – «Асия кай»*** җәмгыяте. Бу җәмгыятьтә японнар, чиннар, кореялылар мәшгульләр. Төрекләр, татарлар иштирак итә икән, ләкин соңгы вакытта җәмгыять һичбер төрле җанлылык галәмәте күрсәтмәгән. Шул җәмгыятькә визит берлән барырга торамыз. Рәшид казый**** заманасында башланган эш булырга кирәк. Теге мәкаләмезне бүген японча тәрҗемә итеп бетереп бирделәр.

*21 [нче] май*

Көтү дәвам итә. Иртүк японнарның тагы зур бер сәяси мөәссәсәләреннән телефон берлә чакырдылар. Җомга көнгә вәгъдә бирдем. Рус җәмгыятеннән һәм телефон бирделәр. Безнең йомышларны үтәп маташалар икән. Бүген өйләдән соң хариҗия нәзарәтенә барырга уйлап тора идем, тәрҗеман бик соң килде, нәзарәт ябылып калды. Хәзер безнең план бу: виза алу өчен,

---

* Гомәр – Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883–1938), юрист, меньшевик, Милли Мәҗлес депутаты.

** Фуад – Мәхмүтфуад Фәсах улы Туктаров (1880–1938), юрист, журналист, Бөтенроссия Учредительное собрание әгъзасы.

[1] «Мәшрике әгъзам» – «Бөек Көнчыгыш».

[2] Тәэссис ителгән – оештырылган.

*** «Асия кай» – бередә сүз 1909 елны Япониядә оешкан Азия халыклары союзы «Азия Гикай» («Азиянең уяну җәмгыяте») турында бара.

**** Рәшид казый – Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов (1857–1944), дин галиме, иҗтимагый һәм сәясәт эшлеклесе, язучы, публицист һәм журналист, нашир. 1892–1895 елларда Оренбург мөселман Диния нәзарәте казые. Шуңа бәйле рәвештә халык арасында «Рәшид казый» дип таныла.

барон Окумадан* ярдәм сорарга, ул да бер эш дә эшләмәсә, тагы берничә сәфарәткә мөрәҗәгать итеп, ярдәм үтенергә. Нияздан кыска гына ачык хат алдым. Чанчуньнан яза. Өч көндә кайтып җиткән. Керенка бөтенләй акчалыктан чыккан, ди. Хәерле булсын, безнеке юк иде. Һавалар бик бозылды, ике көннән бирле бездәге көз ягмуры кебек вак ягмур ява. Һава бик юеш. Ягмур мәүсиме[1] башланды булырга кирәк. Әхвале рухия шәп түгел. Өсткә йөкләтелгән вазифаны үтеп буламы-юкмы, бер Алла гына белә. Бүгенге газетада, 15 нче июньдә Бельгия-Голландия хөдүде[2] ачылуы язылган, бәлки шунда китеп булыр. Тел булмауның хәтәре бик зур, тәрҗеман берлә һәрнәрсәне сөйләп булмый. Телле булсам, әлбәттә, хәзергегә караганда күбрәк эшләп булыр иде. Нияз әфәнде андый бару-килүгә шактый саран булды. Аннан соң, безнең эшне бераз кечкенәрәк иттереп тә куймадымы икән? Шундый шөбһәләр бар. Русиядә эшләр бертөрле бара кебек. Себер гаскәре Казанга якынлашып килә. Безнең авылда инде күптән фронт булып, сугыш ачылды, бөтен кардәш-кабиләне эштән чыгармаган булсалар ярар иде инде.

*22 [нче] май*

Бүген көн ягмурлы. Һава бик юеш, шуңарга күрә иртүк баш авыртып уянам. Көн буе китап укып вакыт үткәрдем. Бүген Гомәр әфәнде дә, теге төрекчә белә торган япон да киләчәкләр иде. Алар килгәч тә, «Һожи Шимбун»** идарәсенә киттек. Маркиз Окуманы тагы бер мәртәбә күрергә сорадык. Ләкин безнең бөтен әхваль берлә бик таныш булды дигән мөхәррир (Танабе Бошишко) безне җибәрмәде, тагы идарәгә алып керде, чәй китерделәр һәм дә бер мөхәррирә хатын кереп күреште. Сөйләшә башлагач, мөхәррир безнең татар хатынының хәле берлә танышырга теләгене әйтте. Без мәгалмәмнүният[3] җавап бирергә булдык. Шуннан

---

* Окума – маркиз Окума Сигэнобу (1838–1922), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, дипломат, икътисадчы, Япониянең 8 нче һәм 17 нче премьер-министры, Васэда университетына нигез салучы.

[1] Мәүсиме – сезоны.

[2] Хөдүде – чиге.

** «Һожи Шимбун» – «Хочи Шимбун». Бу турыда 27 нче биттәге искәрмәне кара.

[3] Мәгалмәмнүният – шатланып.

соң бик урынлы һәм дә хатын-кызча күп кенә сөальләр бирде. Берничә сөале берьяктан кызыклы күренмәсә дә, минемчә, бик урынлы иде. Ул: «Татарларда нинди хатын матур санала?» Мин: «Буе уртача, сыны зифа. Биле нечкә, кара сачe озын һәм калын. Йөз кара туткыллы. Күз зур, каш кара! Керфек озын. Бит уртасында кечкенә генә чокырлы. Авыз кечкенә, тешләр вак һәм ак», – дидем. «Татар хатыны ничек кияүгә чыга? Кияү сайлауда үзенең хакы бармы, әллә ата-анасы гына эшне тәмамлыймы?» Мин хатын-кызның хәрәкәте хакында сөйләдем һәм дә шул хокук өчен булган тартышуларны аңлаттым да, «Хәзерге көндә кыз үзе сайлый инде, җәберләр юк», – дидем. «Татар хатынының тәрбиясе ничек? » Мин: «Хәзерге көндә мәктәп тәрбиясе күрмәгән яшь хатын-кыз юк диярлек. Һәммәсе укый-яза белә, ибтидаи мәктәпне бетергәннәр кул эше беләләр. Йорт идарәсенә өйрәнгәннәр, йортын сөяләр. Өйне ташлап, урамда йөрмиләр. Өйне пөхтә, пакь, тәмиз[1] тоталар. Әхлаксызлык бик аз». «Татар хатынында качу һаман да бармы? » Мин: «Хәзер инде карт хатыннарда гына бар». «Татар хатыны баласын үзе тәрбия итәме, татар баласы ана сүзе берлә үсәме?» Мин: «Мотлакан[2], ана сүзе берлән үсә. Баланы татар хатыны бик сөя, кадерләп үстерә». «Татар гаиләсенең баласы күпме була?» Мин: «Уртачалап алты чамасында, бик күп балалы гаиләләр дә күп очрый». «Татар гаиләсендә ир бала күп торамы, кыз баламы?» Мин: «Ир бала». «Хатын-кыз арасында үз хәятын үзе тәэмин итә торганнары бармы, булса, нинди эшләрдә булыналар?» Мин: «Бар һәм дә күп. Хатыннарның иң зур эше хәзердә мөгаллимәлек. Аннан соң бик күп хатыннар читек-кәвеш каеп, калфак, кәләпүш эшләп, хәятларын тәэмин итәләр. Соңгы елда хатыннарымыздан докторлар, адвокатлар да бар, зур мәктәпләрдә мөгаллимәләр бик күбәйде, елдан-ел күбәя бара». «Татар хатыны хокукта мөсавиме[3]?» Мин: «Хәзер мөсави. Мәскәүдә булган съездда хатыннарның мөсавәте[4] хакында милләт тарафыннан карар кабул ителде. Һәм дә шул съездда Диния нәзарәтемезгә әгъза итеп бер хатын

[1] Тәмиз – чиста.
[2] Мотлакан – шиксез.
[3] Мөсавиме – бертигезме.
[4] Мөсавате – тигезлеге.

сайланды*. Хәзерге көндә казый хатын бөтен ислам галәмендә фәкать бездә генә бардыр». «Татар хатынының иң зур хосусияте нәрсә?» Мин: «Иреннән аерылмавы һәм дә иренең кайгысыны-шатлыгын һәрвакыт бер итүе. Ире Себергә китсә, татар хатыны Себергә китә, ире чит мәмләкәткә чыкса, анда китә. Моның аркасында гаилә мөхафәзә ителә[1], татар гонсыры[2] әрәм булып әләф-тәләф булмый[3]».

Мөхәррирә рәхмәт укыды һәм дә шулар хакында газетада мәкалә язарга булды. Үзе «Һоҗи Шимбун» газетасының «хатын-кыз» дөньясын алып баручы гали тәрбияле бер ханым икән.

Аннан соң без миңа чанта (чемодан) алырга чыктык. Ләкин бик бәһале кебек күренде. Җитмеш, җитмеш биш, сиксән иеннар акча кызганып, ала алмадым. Йокоһамада очсызрак кебек иде. Кич берлә безнең «Империал» отельдә танса булды. Бик күп кунак. Токио, Йокоһамадагы Европа халкының бик күбесе килгән. Теге япон кунак та. Танса[4] башлана. Танса – Америка тансасы. Гаҗәп бер танса. Һичбер төрле хәрәкәтләрдә, кыланышларда матурлык юк, һичбер күзне көлдерә торган кеше бизәкләре ясау юк. Ир берлә хатын берсенә-берсе бик янәшә килеп кыймылдашалар да, бик каты ышкынышалар. Ышкына-ышкына бераз йөриләр дә, картрак хатыннарның яшьрәк кешеләр берлә биегәндә кылынган кыяфәтләре, аларның фәна фиддансага[5] кадәр җитүләре җирәнгеч хис калдыра, чиркандыра. Якынлык хисен мыскыл итә. Тансалар берсе артыннан берсе дәвам итә, ләкин һәммәсендә дә мәркәзе сикъләт[6] музыкальныйлыкта

* Мәскәүдә булган съездда ... нәзарәтемезгә бер хатын сайланды – 1917 елның 1–11 нче май көннәрендә Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае (съезды) үткәрелә. Анда хатын-кызның иректле, ирләр белән тигез хокукка ия булырга тиешлеге мәсьәләсе дә карала. Шунда, ислам тарихында беренче мәртәбә буларак, мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы һәм казый итеп хатын-кыз – Мөхлисә Габделгалләм кызы Буби (Нигъмәтуллина, 1869–1937) сайлана.

[1] Мөхафәзә ителә – сакланып кала.

[2] Гонсыры – элементы.

[3] Әләф-тәләф булмый – юкка чыкмый.

[4] Дөресе: танец.

[5] Фәна фиддансага – биюдән ләззәткә.

[6] Мәркәзе сикъләт – монда: хикмәт.

түгел, фәкать тәнне-тәнгә ышкышуда. Гамәлият сөя торган америкалы тансада вакытын бушка әрәм итми, анда да реальный мәнфәгать чыгара. Русларда бу кадәр тупас хайвани тансалар булмый. Американың тимер юлы сетьләре[1], фабрикасы да бик күп нәрсә чыгара торгандыр, тегермән машинасы да бик күп он тарта торгандыр, һәммәсенә мөттәсигъ[2]. Ләкин Америкада нәфасәт, нечкәлек кебек хисси нәрсәләр юк булырга тиеш. Һәрнәрсә торгаший аршины берлән, гирь берлән, доллар берлән үлчәнә. Җирәнгеч. Ни өчендер бүген күңелем «Әрәмнәр» исемендәме, башка исемдәме берничә хикәядән мөрәккәб[3] мәҗмуга язарга күңелем төште. Мәҗмугада берничә хикәя улачак, һәммәсендә дә милләтнең балаларының әрәм булганнарының хәле тасвир ителәчәк. Мәсәлән, милләт өчен әрәм булган Париждагы җәгърафия галиме; анчак милләт өчен исраф булган Равил Сыртланов*; милләт өчен әрәмгә киткән, руска чыккан бер кыз; милләт өчен гаиб булган, рус хатынына өйләнеп югалган бер егет.

Хәзер танса бетте. Сәгать унике, ләкин йырлау-бию тавышы ишетелгәч, мин коридорга чыктым. Коридорда карт кына бер инглиз марҗасы берлә бер япон хатыны биеп маташалар. Мескеннәргә танса бүлмәсендә биешергә пар булмаган да, хәзер шуның калдыгыннан яланып маташалар. Дөнья тигез түгел шул. Мин үзем нишлим? Хәятның һәр тәмле, татлы манзаралары алдында сәерче[4] булам торам. Хәятның матур дулкынларыннан читтә калдым. Япончага тәрҗемә ителгән мәкалә бик начар эшләнгән икән. Бик күп төзәтергә кирәк, ди. Хат-хәбәр, газета-фәлән юк. Шатлыклы бер генә хәбәр бар. Солых Мәҗлесендә Истанбулны төрекләргә калдырырга карар биргәннәр. Һиндстан, Әфганстан, Мисырдагы хәрәкәтләр тәэсир иткән, имеш.

---

[1] Сетьләре – челтәре.

[2] Мөттәсигъ – таралган.

[3] Мөрәккәб – җыелган.

* Равил Сыртланов – биредә сүз генерал-майор Равил Шаһихәйдәр улы Сыртланов (1877–1916) турында бара булса кирәк.

[4] Сәерче – күзәтүче.

*23 [нче] май*

Бүген сәгать биштә безне Япониянең зур бер мөәссәсәсенең[1] шактый зур мәсьүл[2] кешеләре кунакка чакырдылар. Мәҗлесе кечкенә иде. Танышу-аңлашу мәҗлесе иде. Сәгать биштән ун ярымга кадәр бергә булдык. Ашадык, эчтек, бөтен әхваль хакында сөйләштек. Монда килгәннән бирле японнар арасында безнең хәлне бу кадәр яхшы белгән кешеләргә очраганым юк иде. Боларның икесе дә безнең Татарстанда булган. Берсе әле күптән түгел генә Чиләбедән кайткан. Бик күп өмидле сүзләр сөйләнде. Монда безгә шактый зур эшләр эшләргә мөмкинлеге күренде. Тәфсилле язарга муафикъ күрмим. Көн шуның берлән тәмам булды. Ләкин үз ноктаи назарымнан Токиодагы көннәремнең иң тулысы булып үтте.

*24 [нче] май*

Бүген һава бик матур. Көн бик күңелле. Уку-йөрүгә башка[3] бер эш тә эшләнелмәде. Фәкать баш назыйр[4] һәм дә хариҗия назыйры[5] берлән күрешү хакында вәгъдә генә алынды. Көне, сәгате әле тәгаен ителмәгән. Мин үзем бу Токиода торудан бик туйдым, быктым[6]. Тизрәк, ичмасам, Йокоһамага күчәсе иде. Акчаның курсы һаман шулай. Милли Идарәдән хат-хәбәр юк, Франсәдән вә һакәза[7].

*25 [нче] май*

Бүген көн якшәмбе, монда бәйрәм итәләр. Японнар да үзләрен европалы дип уйласыннар дип, якшәмбене бәйрәм итәләр. Өйләдән соң японнарның зур бер зиярәтләренә бардык. Зиярәт бик пөхтә. Тирәсендә ихата юк, фәкать эче урам-урам итеп бүленгән дә, кечкенә-кечкенә зиярәтчекләргә аерылып, тирәсе тотылган. Һәрбер бүлем эчендә бер гаилә, бер фамилиянең зиярәте. Бик күбесендә зур бер таш куелган. Шуңарга кем үлгәне язы-

[1] Мөәссәсәсенең – оешмасының.
[2] Мәсьүл – җаваплы.
[3] Уку-йөрүгә башка – укудан, йөрүдән башка.
[4] Баш назыйр – премьер-министр.
[5] Хариҗия назыйре – тышкы эшләр министры.
[6] Быктым – туйдым, гарык булдым.
[7] Вә һакәза – һәм башкалар.

ла барган. Таш янында һәрбер зиярәттә ике агач савыт. Болары кардәш-кабилә йә дуст-иш килгәндә чәчәк куяр өчен икән. Бер тарафта кечкенә генә баганада – бездәге газета-хат салыр өчен эшләнгән кебек ясалган кечкенә ящиклар. Аларның бер карточка салырга тишекләре бар. Бусы килгән кешегә карточкасын салыр өчен икән. Бәгъзы бер зиярәт йортларында ике яклап таш баганалардан фонарьлар ясаганнар. Гаиләдә үлек булса, йә бер махсус гыйбадәт булса, шулар ягыла икән. Зиярәтләрнең бик күбесе янында яңа, тазә[1] чәчәкләр куелган. Күбесенең өстенә сулар сибелгән. Бу арада чәчәк күтәреп килә торган бик күп хатыннар, ирләр, балаларга очрыймыз. Кабер ташларының искеләренең шәкеле[2] табигый ташлар. Күбесе таудан ничек чыкса, шул көенчә бастырып куелган. Соңгы еллардагы каберләрдә дүрт кырлы, безнең ташлар кебек. Агач бик күп, һәммәсе бик зур кадерләп үстерелгән. Артык ботаклары киселгән, яфраклары тигезләнгән. Сәрви[3] кебек, нарат-чыршы кебек, каен кебек зур агачлар юк. Юлларында һичбер чүп-чар юк. Зиярәт ямь-яшел, каберләр өсте чәчәккә баткан. Японнар зиярәтне бик сөяләр булырга кирәк һәм дә бик еш зиярәткә килә булырга кирәк. Шул ук зиярәттә без японча язылган ташлар өстенә салиб[4] куелган каберләргә очрыймыз, болар – христиан-японнар. Япониядә диндә хөррият булганга, монда зиярәтләр дә аерылмаган икән. Ләкин бу мәнфи[5], начар тәэсир калдыра, чөнки милләтләрдә иң нык саклана торган гадәт, йола – үлү-күмү гадәте, йоласы. Монда милләтләр бер буйдан гадәтләрен, йолаларын саклыйлар, үзләренә чит милләтнең гадәтен, йоласын кертмиләр. Японнар читләргә тәкълиддә[6] шулкадәр йомшаклар булырга кирәк ки, болар иң мөкаддәс булган зиярәтләрендә [дә] чит гадәттән мөхафәзә итә алмаганнар[7]. Тагы шуны онытмаска кирәк: япон халкының игътикадынча[8] үлү – бетү түгел, фәкать башка рәвешкә керү генә. Шулай була

[1] Тазә – монда: әле генә өзелгән.
[2] Шәкеле – тышкы күренеше.
[3] Сәрви – кипарис.
[4] Салиб – хач (тәре).
[5] Мәнфи – күңел кайтаргыч.
[6] Тәкълиддә – иярүдә.
[7] Мөхафәзә итә алмаганнар – саклана алмаганнар.
[8] Игътикадынча – ышануы буенча.

торып да, шулкадәр мөсаһәлә[1] боларның бик җиңеллек берлән Европа мәдәниятенә, Европа диненә, Европа гадәтенә батачакларын күрсәтәдер. Ләкин монда христианлык тәдриҗи рәвешдә[2] тәрбия берлән бирелә. Мәктәп, матбугат, музыка аша керә. Бер зур зиярәт янына туктыймыз. Аның зур таш артына озын гына такталарга бик күп сүзләр язылып, уелып куелган. Бу – бер рәссамә[3] япон хатынының кабере. Ул язган такталарда – дустлары, сөйгәннәренең биргән адреслары. Уң якта – визитный карта өчен ящик. Мин дә карточкамны алдым да шул ящиккә салдым. Без бит икемез дә – Олуг Асиянең ахмак балалары. Без бит икемез дә – Олуг Асиянең үзенең кадерен үзе белми торган балаларына, үзенең кыйммәтле якларын күрсәтергә тырышучы, үзенең хәятының матурлыкларын күз алдына китереп, асияленең үзенә үзенең[4] ышануын уятырга теләгән җүләрләре. Син инде үлгән, мин әле йөрим, ләкин син бер эз калдыргансың, мин дә бер эз калдырачакмын. Бик ихтимал, синең рәссамлыкта ясаган Асиялек эзенең[5] күзен акайтып, европалы хәят артыннан чаба торган япон гәнеҗе[6] таптап киткәндер. Китмәгән булса, китәчәктер. Минем милли хәятымызда калдырырга теләгән эземне дә, бәлки, руслык «кары», русларга тәкълид[7] басып киткәндер йә китәчәктер. Ләкин без үз вазифамызда булырга тиеш, син шул вазифа кебек, йә син дә инде үлгәнсең, мин шуның артыннан монда килдем. Зиярәт янында ике яклап бик күп кабер ташы һәм кабер чәчәге кисентеләренә очрыймыз. Көн кич. Күрше казармада, быргы чалып[8], солдатларны өйләренә җыялар. Без дә өйгә китәмез. Хәерле кичләр!

*26 [нчы] май*

Бүген иртүк, автомобиль алып, Франсә һәм инглиз сәфарәтханәләренә китәмез. Франсәдән җавап һаман килмәгән. Англичаннар безнең хакта мәгълүмат алыр өчен, Русиядәге

---

[1] Мөсаһәлә – җиңел генә карау.
[2] Тәдриҗи рәвешдә – акрынлап-акрынлап.
[3] Рәссамә – хатын-кыз рәссам.
[4] Дөресе: үз-үзенә.
[5] Текстта шулай, «эзеңне» булырга тиеш.
[6] Гәнеҗе – яше (егет, кыз).
[7] Тәкълид – иярү.
[8] Быргы чалып – быргы кычкыртып.

инглизләрнең фәүкыльгадә[1] комиссарлары Слайтонга телеграф берлән мөрәҗәгать иткәннәр, шуннан җавап алмаенча бер эш эшли алмыймыз, диләр. Без үземез Русиядә вакытта шул эшне бетереп килмәгәнмез. Омскида вакытта минем керергә зур ниятем булды, фәкать шундагы куркак кешеләр: «Эш бозылмасын-фәлән, Колчак* белмәсен», – дип, тискәрегә димләделәр. Аннан соң миңа бик күңелсез акча җыю вазифасы йөкләтелгәнгә, әллә никадәр гайрәт шуңарга китте. Киңәш итәргә кеше булмады. Фуадка шул хакта телеграмма биргән идем, ләкин ул үзенең көчен иң күбесен интригага, бозарга сарыф итәргә өйрәнгәнгә, әлбәттә, эшләмәгән. Харбинда Гомәр, куркып, башны әйләндереп, һаман шул минем планнарымны сүтә килде. Аннан соң без, монда чыгу ул кадәр авыр булмас, дип уйлаган идек. Японнарның да бераз ярдәмнәренә ышанган идек, боларның берсе дә килеп чыкмады, хәерле булсын инде. Хәзер теләр-теләмәс көтәргә мәҗбүрмез. Өйләдән соң, Гомәр берлән киңәшләшеп, Харбинга һәм дә Владивостокка китүче татар егете артыннан, анда бәгъзы берәр эш эшләргә кушып, озын мәктүбләр язам. Бәлки, бер нәрсә чыгар. Нияз әфәндедән һаман мәктүб юк. Бу арада газета дә килми башлады, Милли Идарәдән дә хат юк. Кич берлән японнарның иске театрларына барамыз. Аяктан ботинкаларны чыгарып, оекчан көенчә керәмез. Театрның бинасы бик зур. Үзе агачтан эшләтелгән булса да, стиле матур. Ишектән керүгә, диварга сөяп куйган бик күп сонгый[2] букетлар каршы ала. Болар – артистларга бирелгән бүләкләр. Идәндә җефәк арканнар берлән бәйләгән бүләк сандыклары тезелгән. Эчкә керәмез. Театр дүрт почмаклы иттереп эшләтелгән. Каршы якта сәхнә. Ләкин сәхнә эчкә кереп тормый, бәлки уртага таба чыгып тора. Уртага камыш намазлык җәйгәннәр дә, аны ике кеше сыярлык дүрт почмаклы шакмакларга тәбәнәк кенә киртә берлән бүлгәннәр. Ул шакмакларның идәненә кечкенә мендәрләр салганнар. Сәерчеләр[3] шу-

---

[1] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

* Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус хәрби сәясәт эшлеклесе, галим-океанограф, Гражданнар сугышы вакытында Аклар хәрәкәте җитәкчесе.

[2] Сонгый – ясалма.

[3] Сәерчеләр – тамашачылар.

ларга кереп утырган. Зуррак кешеләр икешәр-өчәр, бала-чагалар дүртәр утыралар. Һәрбер шакмак эчендә бер гаилә. Ул үзенең шакмагында мохтар[1] түгел, камыш намазлыклы мохтар. Яртысы, иң тугрысы, идән сәхнәдән ерагайган саен, өсткә таба күтәрелә барган сәхнәнең сул-уң як канатлары тәмам күтәртеп үк эшләтелгән. Партерыннан соң тагы бер кат бар. Аннан соң тагы бер кат. Без сәгать җиделәрдә барганга, яхшы урын юк. Алай да безне идәндәге бер шакмакка утырталар, астымызга мендәр салалар, алдымызга кечкенә генә мангал бирәләр. Бер чәйнек берлән япон чәе, кечкенә генә савытларда ике төрле япон татлысы, япон хәлвәсе китерәләр. Театр дәвам итә. Фәкыйрь бер гаиләнең ярлылык фаҗигасе. Әллә нинди сүзләр, бер нәрсә түгел. Уйнаулары һаман бертөсле. Артта чылтыр-чылтыр итеп думбыра суккалыйлар. Әллә нидә бер нечкә, җиңел тавыш берлән бер бала сузып-сузып бер нәрсә сөйли, күренмәенчә әллә кем, әллә нәрсә йырлый. Артистка ролен уйный торган зур иләмсез япон яшел тавыш берлән сөйләп, бертуктамаенча егълый. Уеннарында осталык-фәләнлек бер дә күренми. Ләкин халык бик ярата булырга кирәк. Хатыннар бер туктамаенча егълап утыралар. Мин күршеләремә карыйм. Бер якта – ирле-хатынлы бер гаилә: унике-унөчле[2] кызлары, тугыз-унлы угыллары алдына утырган – карап утыралар. Өч-дүрт яшьлек бер балалары атасының итәгенә яткан да, йоклап тора. Хатыны, кулына ике чыбык тотып, дөгене бер алып каба да, бер сәхнәгә карый. Бер карый да, бер алып каба. Әфәндесе[3] тагы ике чыбык тоткан да, бер дөгедән, бер серкәләгән яшелчәләр капкалап, сәхнәдән күзен алмый. Уң як күршемдә карт кына бер хатын кечкенә генә касә берлән чәй эчә. Ике-өч яшьлек бала үз шакмакларында уйнап йөри. Яшь кенә бер хатын әфлисуннар әрчеп-әрчеп ашап утыра. Театрда бала бик күп булса да, тавыш юк, халык тын, һәммәсе тезләнеп, аягын бөкләп, рәхәтләнеп утырганнар. Бик күбесендәге чалбар – анадан туган чалбарлар булганга, ялангач, безнең кебек тезе бөгелүдән һич курыкмыйлар. Ләкин уен вакытында һаман йөреп торалар. Берсе чыга, берсе керә. Бер официант чәй китерә.

[1] Мохтар – ирекле.
[2] Дөресе: унике-унөч яшьләрдәге.
[3] Әфәндесе – ире.

Бер сатучы мивә[1] китерә. Бер ашчы дөгеләр-яшелчәләр күтәреп үтеп китә. Менә тәмам. Пәрдә төште, иң тугрысы, безнең авыл өйләрендәге кебек пәрдә тартылды. Халык бераз хәрәкәткә килде, торды, чыкты, без дә чыктык. Югарыгы катларны гиздек. Бөтен коридор кеше берлән тулган. Җыен чүп-чар, шара-бараны саталар да торалар. Кем ала, ник ала – Алла белсен! Югарыда ике буфет, берсе аяк бөкләп утырырга, берсе урындыкка. Анда ашап-эчеп утыралар. Тар коридорда тыгыла-кысыла хатыннар йөриләр. Менә агач чүкеч берлән агачка сугалар. Бу – пәрдә ачылуга галәмәт. (Финляндиянең Сеймында да «Дикъкать» дигән әмерне рәисе агач чүкеч берлән агач сугып белдерә.) Урынымызга утырамыз. Пәрдә күтәрелә. Декорация бик матур: диңгез, көймәләр, җилкәннәр, дулкыннар бик һәйбәт эшләтелгән. Япониянең катыргасы[2]. Ләкин бу юлы да уен бик бертөсле, бер вакыйга бик озын сузыла. Бер мәртәбә егълап бетергәнче, эш өчен ун мәртәбә егълатыла. Яңа пәрдә ачылды. Монысы иске бер әкият: шайтаннар, пәриләр, самурайлар, гейшалар. Һәммәсе бик күңелле генә, ләкин хатын ролен ирләр уйнаганга, бик чиркен бер хис калдыра. Без китәргә буламыз. Җыенына[3] ике кешегә җиде иен алалар. Шактый бәһале[4]. Һәммә урын бер бәһадән икән, ләкин үзләре өчен бәһале түгел. Бердән, ул иен аларга һаман элгәреге иен. Икенчедән, алар иртәнге сәгать уннан килеп, кичке сәгать унбергә кадәр утыралар икән. Болар бөтен гаиләсе берлән иртәдән үк килеп, шунда ашап, эчеп, шунда көн буе үткәрәләр икән. Иң тугрысы, болар айга бер, ике айга бер театр эченә хозурга чыгалар икән. Бәлки, бу театрлар тагы тәрәккый итә төшәр. Ләкин бу әле балаганнан зур аермалы түгел.

*27 нче май*

Бүген һичбер телгә алырлык эш булмады. Иртәдән хаста булып уяндым, көн буе кәефсез үткәрдем. Йокоһамага барып, ике мең сум акча алыштырдым. Сумына унберәр цент бирделәр.

---

[1] Мивә – җиләк-җимеш.

[2] Катыргасы – көймә төре (галера).

[3] Җыенына – сеансына.

[4] Бәһале – кыйммәт.

*28 нче май*

Бүген, иртүк торып, Швеция һәм дә Голландия сәфарәтханәләренә киттем. Максатым – ничек булса да алардан виза алу. Шведлар бик дустча[1] кабул итәләр. Үземезнең хәлне сөйлим. Ләкин: «Нишлик – бер эш эшләп булмый. Эш безнең кулда түгел. Һичбер төрле ярдәм итә алмыймыз, чөнки диңгез инглизләр, американлылар, французлар кулында, алар кош та очырмыйлар. Без бер эш эшли алсак, мәгалмәмнүният[2] эшләр идек. Голландия бер-бер ярдәм итә алмасмы?» – диләр. Бу әфәнде берлән күрешеп чыгып китәмез. Моның дустча мөгамәләсенең сәбәпләрен эзлим. Иң зур сәбәбе – безне яхшы беләләр. Чөнки боларның вәкилләре Салибе Әхмәр[3] җәмгыятьләрендә Германия, Төркия әсирләренә ярдәм иткәндә, һәр йирдә татарларның ярдәм җәмгыятьләренә очрадылар, һәр йирдә татарларның инсанияткяранә[4] мөгамәләләрен күрделәр, татарларның мәдәни бер милләт икәннәрен белделәр, шуның өчен бу әфәнде миңа, вәхши халыкларның бер кешесе дип карамаенча, бер милләтнең вәкиле дип карады. Әүвәлдә күңеле боек күңелне шул аз нәрсә дә ачты. Вакыты берлән башка ахмакларга да кем икәнемезне танытырмыз әле.

Голландия сәфарәтханәсенә киттек. Анда да мәсьәлә шул: «Рәхәтләнеп виза бирер идек, ләкин эш безнең кулда түгел. Хәзер сугыш вакытына нисбәтән ун мәртәбә кысынкылыклы. Һәммәсенә хөкүмәттән җавап алырга, җавап өч айсыз килми. Андагы җаваплар һәммәсе дә Англия, Франциянең катышуы берлән генә эшләнелә». Монда да өмид юк, инде ике генә юл калды. Берсе – маркиз Окумадан үтенү, икенчесе – көтү.

Окума берлән күрешер өчен, шимбә көнгә вәгъдә алдык. Кич берлән бакчада симфонический концерт булды, шунда бардым. Япон халкы бик күп җыелып килгән. Европа музыкасына дәртле кешеләр күбәйгән икән. Шактый гына уйнадылар, безгә – бик күптән рәтле музыка ишетмәгән кешегә – яхшы тәэсир итте. Көндез миңа теге япон мәктәбендә укый торган татар малаен тавып[5]

[1] Дустча – дустанә.
[2] Мәгалмәмнүният – шатланып.
[3] Салибе Әхмәр – Кызыл Хач.
[4] Инсанияткяранә – кешелекле.
[5] Д ө р е с е: табып.

китерделәр. Унсигез яшьлек бер егет булса да, бик зәгыйфь, ябык, сабак та укымый икән. Эш күңелсез, Фазыл һичбер төрле тәрбия итә алмый булырга кирәк. Шуның тәрбиясе хакында күп нәрсәләр уйладым. Японча бик яхшы сөйли, укый, яза. Укып бетерсә, шактый бер егет булып, берәр милли хезмәткә ярар иде, мөгаллим булыр иде, японнар берлә мөнәсәбәткә ярар иде. Шул хакта Харбинга озын хат яздым, укытырга акча тапсалар, бик шәп булыр иде. Милли Идарәдә чит мәмләкәтләрдә укытыр өчен стипендияләр бар иде, ләкин акчасы йитми. Ни булса да, бер эш эшләрмен әле. Бүген берәр хәбәр килер төсле, төш күргән идем. Бернәрсә дә булмады.

*29 [нчы] май*

Тик кенә үтте. Харбиннан хат-хәбәр, телеграмма юк. Фәкать Париждан кайтып килүче бер рус генералы берлән генә танышып сөйләштем. Максатым анда безнең халыктан берәр кешенең булу-булмавын белү иде, белеп булмады. Фәкать бик күп милләтләрнең вәкиле берлә Париж тулы, ди. Бер үземезнең кешеләрдән берәрсе булса, телеграмма бирәчәк идек, булмады, тагы көтәргә калды. Иртәгә маркиз Окумага барамыз, аннан да бернәрсә чыгар төсле түгел. Әллә Кытайга барыйкмы, дип тә уйлыйм. Өч-дүрт көн эчендә берәр карарга киләчәкмез, тик көтү бик туйдырды.

*30 нчы май*

Бүген язарлык бернәрсә дә булмады. Яңлышмасам, бүген Рамазан башы булырга кирәк.

*31 нче май*

Иртүк, сәгать сигездә, Гомәр килде һәм дә безгә тәрҗеман булачак, төрекчә белә торган япон килде. Сәгать тугызда безгә маркиз Окумада вакыт тәгаен ителгән иде. Шунда киттек. Бераз көтәргә тугры килде, биш-ун минуттан соң маркиз үзенең сәркатипләре берлән чыкты, сөйләшү башланды. Саулык-сәламәтлек сорашканнан соң, татар тарихына сүз китте, аннан күчеп, Төркиянең хәленә җитте: «Төрекләрнең хәле шәп түгел, европалылар җәберлиләр. Истанбулны да төрекләрдән алмакчы булалар, бу ислам галәменә ничек тәэсир итәчәк?» – диде. Мин: «Ислам

галәме Европаның бу хәрәкәтен әһле салиб[1] мөхарәбәләренең[2] икенче төсе дип карыйлар. Европаның шул золымына һичбер төрле разый булачаклар түгел. Мисырдагы, Һиндстандагы, Әфганстандагы гыйсъяннарның сәбәбе шул. Әгәр Истанбул мәсьәләсе төрекләрнең файдасына хәл ителмәсә, бик зур гыйсъяннар дәвам итәчәк, Европа дөньясы берлән ислам галәме арасында тагы үтә алмаслык упкыннар туачак. Инсаният ноктаи назарыннан[3] бу фәүкыльгадә зарарлы булачак», – дидем. Шуннан тагы башка мәсьәләләр хакында сөйләшкәннең соңында үземезнең максатымызга килдек. «Безгә Европага чыгарга рөхсәт алышырга син – Мангул углы Окума – безгә, татар балаларына, ярдәм ит», – дидек. Ләкин Окума әллә нинди хикәяләр сөйләде, кечкенә генә шул ярдәмен итмәде. Без: «Рәхмәт, ләкин бездә сезгә, японнарга, зур ышаныч бар иде. Монда кечкенә хезмәтләрне генә түгел, зурларны да итәчәк, дип уйлыйлар иде. Сезнең хакта шундый хата фикердә булуымыз өчен гафуыңызны үтенәмез», – дидек. Һәм дә торып күрешеп чыктык. Ләкин безнең берлән барган япон бик мөтәәссир[4] булган кебек кылынды[5]. Тугры идеме, юкмы – анысын белеп булмый. Алай да, аш ашагач кәеф бик тиз ачылды. Америка сәфиренә[6] бер мәктүб язган идем, шуны төрекчә белә торган японнан инглизчәгә тәрҗемә иттергән идем, ләкин башка кешедән укытып карагач, бик начар булып чыкты, һичбер нәрсә аңламаган. Шуңарга күрә аны җибәрмәдем. Яңаны яздырырга нә русчадан инглизчәгә, нә төрекчәдән французчага, инглизчәгә тәрҗемәче юк.

*1 нче июнь*

Бүген иртә берлән сәгать тугызларда йир селкенде. Монда ул йир селкенүе шактый еш була икән, ләкин мин моның кебек булганын беренче мәртәбә хис иттем. Селкенү ярты минутлар дәвам итте. Диңгез пароходында, дулкында көймә чайкалган

---

[1] Әһле салиб – урта гасырда барган тәре сугышында катнашучылар.
[2] Мөхарәбәләренең – сугышларының.
[3] Ноктаи назарыннан – күзлегеннән.
[4] Мөтәәссир – тәэсирләнгән.
[5] Кылынды – кыланды.
[6] Сәфиренә – илчесенә.

кебек булды. Һичбер төрле миндә курку хисе уятмады. Зур бер тәэсир калдырмады. Күп кешенең бүлмәләрендә шкафлар ачылган. Графиндагы су бик хәрәкәткә килгән, асылган лампалар таган атылганнар. Кичкә таба Асакуса[1] дигән мәхәлләләренә бардык. Монда зур бер гыйбадәтханә бар һәм дә бик зур бер халык өчен хозурлану урыннары бар. Халыкның иң зур кыйсеме простой булганга, япон хәятын шактый яхшы күреп була. Иң әүвәл гыйбадәтханә[гә] киттек. Гыйбадәтханәнең алдында зур бер капка. Капка бик биек иттереп, Чин тарзы мигъмариясендә[2] эшләтелгән. Уртада – зур капка, ике якта – ике кечкенәрәк капкалар. Капка бөтен урамның иңен алып эшләтелгән. Зур капканың югарысында – зур Будда сурәте, кечкенә капкаларның өстендә дә – кечкенә Будда сурәтләре. Өчесенең алдына, алка кебек иттереп, зур кәгазь фонарьлар асылган. Шул капка янында гыйбадәт башлыйлар. Капкадан үткәч, күз алдында – зур гыйбадәтханә. Аңарга керер өчен, ун-унбиш баскычлы өй алдына менәргә кирәк. Фәкать баскычтан алда, зур яслә кебек, бер улак куелган. Моның төбендә ярыклары бик күп, килгән бер кеше шул улакка бакыр акча ыргыта да кулын, без дога кылган кебек, тота да башын иебрәк авыз эченнән бер нәрсә укый. Ләкин бу гыйбадәтханә ябык булганда гына шулай икән. Бүген гыйбадәтханә ачык иде, шуның өчен гыйбадәт кылачак кешеләр туры ук баскычлардан менеп китәләр. Актык баскыч берлән ишек арасында биш аршын чамасы киңлегендә балкон кебек йир бар. Шуның бөтен түшәменә бик зур кәгазь фонарьлар (алтмыш-җитмеш чиләк су сыя торган мичкәләр кадәре) асып чыкканнар. Бер йиренә кыңгырау кебек бернәрсә тагылган. Аның янынннан идәнгә кадәр бер билбау кебек йеп сузылып төшкән. Гыйбадәт итәргә теләүче килә дә шул йепне кыңгырауга суга. Кыңгыраудан зәгыйфь кенә бер тавыш чыга. Моның берлән Аллага гыйбадәткә килгәнен белгертә. Японнар хисаплы халык булганга, Аллаһы Тәгалә килгәнне белмәенчә калып, биргән ике тиен әрәм булмаудан, әлбәттә, куркалар. Кыңгырау шалтырагач, Аллаһы Тәгалә колагын бу тарафка боргач, ул башын бөгә төшеп, ике

[1] Асакуса – Токио шәһәрендәге бер квартал.
[2] Чин тарзы мигъмариясендә – Кытай архитектурасы стилендә.

кулын безнең догадагы кебек итебрәк күтәрә дә йә үз эченнән, яисә кычкырып дога укый. Ләкин ачык булганга, анда туктамаенча, эчкә үк кереп китәләр. Без дә кердек, зур ишеккә каршы йирдә, гыйбадәтханәнең түрендәрәк, челтәр берлән эче бүленгән, аның урта бер йирендә бер биек сәке эшләтелгән, шуның өстендә баскычлы-баскычлы өстәл куелган, шул өстәл өстенә, дәрәҗәсенә күрә, Буддалар тезелгән, алларында ут яна, шуларга якын гына беренче баскычка имам әфәнде менеп тезләнгән. Аның артына түбәндәге идәнгә шәкертләр-мөридләр тезелгән, алар кычкыра-кычкыра мантраны укыйлар. Челтәрнең бу ягында халык күбесе үзе мыгырдый, сул якта бик күп халык җыелган, анда без дә барамыз. Һәр кеше кечкенә генә акча бирәләр дә бер кәгазь алалар. Аны укый-укый чыгалар. Бу бер фалханә икән, өч тиенгә синең язмышың язылган кәгазь чыга икән. Без дә, барып, кәсеп өстәленең янына барып кизү саклыймыз, кизү җиткәч, өчәр тиенне бирәмез. Бер шәкерт ала да эчтә аягын тезләнеп утырган икенчесенә бирә. Ул зур бер агач савытка әллә нәрсә төягән дә, шуны астын өсткә әйләндереп, бер нәрсә карый да (сыйфыр[1] булырга кирәк) бик күп вак бүлемләргә бүленгән шкафлардан ачып, кеше саен бер кәгазь бирә. Миңа биргән кәгазендә: «Көтә торган кешең тиз килмәс. Хәзер сәфәргә чыкма, бераз көт. Күңелеңдә тапкан ташның асыл ташмы, әллә ялганмы, дигән нәсия[2] бар. Эшеңнең ахыры хәер булачак», – дигән. Фалчылар һәммә йирдә бер кебек: чегән хатыны да шуны сөйли. Хәер, әманәт тә шундый гам[3] сүзләр берлән юл күрсәтә. Йолдызнамә дә, Будда [да] ышаныңыз, ди дә, дөньяның алдаулары һәр йирдә бер төсле. Аннан икенче ягына китәмез, монда бөтилекләр, сөйдергечләр, аллалар саталар. Мин унсигез тиенгә японнарның өч аллаларын, өч тиенгә бер сөйдергеч алдым. Аннан да чыгамыз. Ишек янында берничә кат мендәр өстенә бер агач Будда сурәте куелган, шуның янында бик күп кешеләр бар. Һәммәсе тегенең бер йирен кулы берлән сыйпый да, шул кулы берлән тәнен ышкый. Бу сәламәтлек бирә торган санәм[4] икән.

---

[1] Сыйфыр – сан, цифр.
[2] Нәсия – монда: йөк.
[3] Гам – гомуми.
[4] Санәм – пот.

Кулың авыртасы[1], кулын сыйпыйсың да, шуның шәрафәтен кулга сылыйсың. Аягың сызласа – аягын, күзе авыртасы – күзен, колагы авыртасы – колагын вә һакәза[2]. Сылау-сыйпау шулкадәр күп булган булырга кирәк, агачтан яса[л]ган Будданың инде борыннары, күзләр, битләре тәмам ышкылып беткән, фәкать шоп-шома бер агач булып калган. Әле кулын сыйпаганга, әле аягын ышкыганга, берничә мендәргә авыл хәлфәсе кебек менеп утырган мескен Будда бер туктамаенча биеп тора. Аннан чыгамыз, халык арасына керәмез. Урам шыгрым тулы. Бүген якшәмбе булганга бәйрәм. Бер почмакта унбиш тиен туплап, бер гастигә[3] керәмез. Ул безнең Петроградның Народный Домы кебек нәрсә икән, үзендә театры, үзендә гасти, үзендә тарихи музәханәсе, үзендә хайван музәханәсе, иске япон әсатыйрыннан[4] бик күп манзаралар кешеләр төсле иттереп ясатылып куелган. Япон хикәяләренең манзаралары, чучеллардан эшләтелгән япон гаиләсендәге төрле манзаралар, мәсәлән, гейша берлән кәефсафа сөрү, ир берлән хатынның орышуы, баласыз карт берлән картчыкның армуд[5] эченнән бала тууы, сумарай[6] баласын сарайга китереп, аның сачын сарай хатыннары тарафыннан алынуы (иске гадәт буенча) вә башкалар, башкалар. Болар һәммәсе күңелле, халык өчен бик аңлаешлы. Чит кешегә Япониянең хәятын бик аңлата.

Хат-хәбәр юк. Насыйп булса, иртәгә инде Йокоһамага китәм. Бүген Франсәдән кайта торган генералдан тагы озынрак кем бар, кем юклыгы хакында сораштым, без белгән кеше, мәгаттәссеф[7], бик аз, безнең кавказлылар да, кырымлылар да юк. Хәбәр, кем белсен, нидер. Бер телеграмма бирмәкче идек.

*2 нче июнь*

Бүген Токиодан Йокоһамага күчтем. Иртәгә үземә аерым бүлмә булачак, бүген Гомәрдә кунам. Монда һава бик шәп, хәят

---

[1] Авыртасы – авырта исә. Монда: авыртса.

[2] Вә һакәза – һәм башкалар.

[3] Гастигә – гостиницага.

[4] Әсатыйрыннан – легендаларыннан.

[5] Армуд – груша.

[6] Сумарай – самурай.

[7] Мәгаттәссеф – кызганыч.

очсызрак та. Аннан соң, бәлки, ашказаныма да бераз файдалы булыр. Югыйсә мигъдә[1] бик начар. Хат-хәбәр юк. Харбинга телеграмма бирдек. Йокоһамага күчәр алдыннан, Токионың дарелфөнүнендә тарих мөгаллиме мөстәшрикъ[2] профессор Куракити Сираторига* зиярәт берлән бардык. Профессор японнардан беренче мөстәшрикъ. Ул унберенче елны Гамбургда булган мөстәшрикъләр съездына Япониядән вәкил булып барган. Бик күп рус, алман, мажар мөстәшрикъләрен белә, бик күп танышларымыз гамм[3] булып чыга. Бераз русча сөйли, бераз төрекчә сөйли, ләкин икесендә дә яхшы аңлыйм, ди. Хәзерге көндә төрек тарихын япончага язып ята икән. Миннән безнең мөәррихләрне[4] сорады. Мин Шиһабеддин әл-Мәрҗани**, Зәки Вәлиди***, Һади Атласи****, Бари Батталларны***** күрсәттем. Миннән шуларның әсәрләрен җибәрергә үтенде, вәгъдә бирдем. Шуннан мәсьәлә Азия мәдәнияте, Азия кавемнәренең тарихына, аларның истикъбаленә[5] күчте. Бик озын шул хакларда мөзакәрәләрдә булындык[6]. «Мин сәясәт кешесе түгел, ләкин гыйлем, фән ягыннан Асия милләтләрен бер юлга кертәсем килә, хосусан, сезнең

---

[1] Мигъдә – ашказаны.

[2] Мөстәшрикъ – көнчыгыш телләре белгече.

* Куракити Сиратори – Сиратори Куракити (1856–1942), япон тарихчысы, философия докторы, Токио император университеты профессоры. Япониядә тарих һәм шәрык телләрен өйрәнүне фәнни нигезгә куючыларның берсе. Сиратори күп телләр белгән. Аның филология өлкәсендә дә кызыклы, тирән мәгълүматлы фәнни хезмәтләре бар. Россия һәм Көнбатыш шәркыятьчеләренә ул бигрәк тә борынгы монгол телләре группасына караган сюнну һәм дунху тармагының телен өйрәнеп язган тикшеренүләре, хезмәтләре аркылы таныш.

[3] Гамм – уртак.

[4] Мөәррих – тарихчы.

** Шиһабеддин әл-Мәрҗани – Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818–1889), татар мәгърифәтчесе, тарихчы, дин галиме, этнограф, көнчыгыш белгече.

*** Зәки Вәлиди – Әхмәтзәки Әхмәтшаһ улы Вәлидов (1890–1979), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, Башкортстан автономиясенә нигез салучы.

**** Һади Атласи – Һади (Мөхәммәдһади) Мифтахетдин улы Атласов (1876–1938), җәмәгать эшлеклесе, тарихчы-тюрколог, педагог.

***** Бари Баттал – Габделбари Баттал-Таймас (1883–1969), мәгърифәтче, тарихчы, журналист.

[5] Истикъбаль – киләчәк.

[6] Мөзакәрәләрдә булындык – фикер алыштык.

төрекләр берлән японнар кардәш милләтләр, аларның мәдәниләре кулга кул тотынып барырга кирәк, һәм дә тарихта бер юлга таба борылырга кирәк», – ди. Шуннан соң японнарның безне танымауларына күчәмез: «Һичбер японнар төрек халкын белмиләр, аңламыйлар. Менә монда без (минем танышым Окубуга күрсәтеп) икәү генә», – ди. Мин: «Сезнең вазифаңыз – мәктәп шәкертләренә аңлату, дәрестә тәэсир итү, китаплар язу», – дим. Ул: «Кулдан килгәнне эшлимез», – ди. Сүземез музыкага күчә. Аның хакында шактый күп фикерләшәмез, аннан безнең сәяси әхвалемезгә күчәмез. Аннан Япониянең хәзерге хәленә керәмез. Мин японнардагы Американың һәрбер эшенә мөкиббән китүен тәнкыйть итәм. Һәм дә: «Япония истикъбале Америкада түгел, Асиядә», – дим. Ул да мөсәлләм була[1].

Сәгать ярымнар сөйләшеп утырганның соңында күрешеп китәмез. Профессор кыяфәте берлән әһле гыйлемнәнлеге күренеп тора. Шактый зур бер дәрәҗәдә тора икән. Бай гына булырга тиеш. Үзе хәзерге көндә япон вәли гаһеденең[2] тарих мөгаллиме икән.

*3 нче июнь*

Бүген иртә торгач, миңа тиз генә бүлмә булмаячагы мәгълүм булды. Шуңарга күрә миңа Гомәр бүлмәсендә калырга тугры киләчәк. Бу эш, әлбәттә, бик күңелле түгел. Мин иркенләбрәк инглизчә укырмын, дип уйлаган идем. Өйләдән соң Йокоһаманың тышына чыктым. Монда хәзер арпа җиткән икән. Бер йирдә урганнар да инде һәм дә сугып торалар иде. Уруларының ничекләгән күрмәдем, сугуларын күрдем. Элгәре башагын гына өзеп алалар икән дә аннары шунда бер агач берлән кыйныйлар икән. Арпа аз булганга, әлбәттә, мөмкин, ләкин, бик мәшәкатьле, ысулы бик иске. Бер болында печән чабалар иде. Кайберләре безнеке кебек чалгы берлән чабалар, кайберләре сач кистерә торган машина системасында ясалган озын саплы машиналар берлән уралар. Машинаны сабыннан төртеп баргач, машина сач машинасы кебек урып бара икән. Хат-хәбәр юк.

---

[1] Мөсәлләм була – фикергә кушыла, ризалаша.
[2] Вәли гаһеденең – тәхет варисының.

*4 нче июнь*

Бүген инглизчә укырга башладым. Өйләдән соң ягмур ява башлады, һаман ява, туктар төсле күренми. Ягмур мәүсиме[1] башланды бугай.

*5 нче июнь*

Бүген төрекчә белә торган японны көттек, ул «Империал» отельдән хаклар белешәчәк иде. Килде, һичбер хат-хәбәр юк. Көн буе ягмур ява, һава шулкадәр ротубәтле[2], бөтен киемнәр юешләнә. Диңгез бөтенләй күренми, каршы яктагы урам да бик начар күренә. Бу юешлек үзен дәвам итә, безгә, өйрәнмәгән кешеләргә, бик начар тәэсир итү ихтималы бар. Бүген үк буыннар авыр туп, әллә ни баскан кебек тора. Көтә-көтә, хәбәр алмаенча, тәмам эштән чыкмасак ярый инде.

## 5 нче дәфтәр

### 1919 ел, июнь, июль

*6 нчы июнь*

Бүген телгә алырлык бернәрсә юк. Бер йирдән хәбәр юк. Без һаман көтәмез. Эш эт эчәгесе кебек сузылды. Бүген үземнең шәхси хәятым өчен бераз күңел күтәрерлек эш булса, ул да мигъдәм бераз юлга салынган кебек була башлады. Мондагы һава яхшы тәэсир ясады булырга кирәк. Ягмур бүген яумады, көн бик эссе.

*7 нче июнь*

Көн бик эссе, өйдә утырып торганда тир агып тора, хәл-хәбәр юк.

*8 нче июнь*

Һичбер хат-хәбәр юк. Берни булганы юк.

[1] Мәүсиме – сезоны.
[2] Ротубәтле – дымлы.

*9 нчы июнь*

Бүген безгә Харбиннан мәктүб килде. Хат 22 нче майда язылган. Милли Идарәдән унынчы майда Фуад шул көндә чыга, дип, телеграмма бар, ди. Һәм дә Фуадлар Омскида чит мәмләкәт вәкилләре берлән маташып йөриләр икән, ди. Инде ул телеграммага да бер ай үтте, димәк, һаман килә алмаганнар. Чабата кайтарып тормаенча килгән булса, әллә кайчан эш беткән була иде. Хәерле булсын. Бүген олуг дәүләтләрнең сәфирләренә мөрәҗәгать итәргә булдык һәм дә шул хакта бер нәрсә яздым. Бер-ике көннән мөрәҗәгать итәчәкмез. Колчак хөкүмәтен тану хакында газеталар бик нык яза башлаганга, шул хакдагы үз фикеремезне әйтеп каласымыз килә.

*10 [нчы] июнь*

Бүген безнең рус хөдүденнән[1] кичүемезгә ике ай тулды. Юл уңган булса, инде без Парижда булачак идек.

Монда үгезнеке өзелгәнне көтеп ятамыз*. Хат-хәбәр юк, көн ягмурлы.

*11 [нче] июнь*

Бүген кырга чыктым. Кыр бик матур, арпа өлгергән. Аны урып маташалар. Ләкин монда арпага бер бәла бар икән. Чыпчык оча икән. Шуңарга күрә арпа йирләренә бик күп куркынычлар[2] утырткannar, бер кеше куып та тора. Монда ашлык аз булганга, ач чыпчык бик тиз ачып бетерә[3], күрәсең.

Карабогдай чәчәк аткан һәм дә капчыклана башлаган. Башында умарта кортлары йөри, ләкин бал исе еракtan бер дә килми. Иснәп карадым, бераз бал исе бар икән. Иң күп чәчелгән нәрсә төрле яшелчә: торма, бәрәңге, шалкан, суган. Суганның кыягы монда бик эре һәм дә көпшәләнеп үсә. Ике кеше суган түтәлләренең арасыннан тупракны күтәреп, суганнарның төпләренә

---

[1] Хөдүденнән – чигеннән.

* Үгезнеке өзелгәнне көтеп яту – конкрет максатка ирешү юлында нәтиҗә уңай якка хәл ителәчәге билгесез булган очракта әйтелә торган халык әйтеме.

[2] Куркынычлар – карачкылар.

[3] Ачып бетерә – «башакларны ачып бетерә» мәгънәсендә.

өяләр. Аның кыякларының бик күбесен туфрак астында калдыралар, суган зур булсын өчендер инде. Һәрбер йир, дөресте [...], янында, почмакда, берәр савытта, әллә нинди сасы су тора, берәр почмагында тирес череп ята. Шулар берлән түтәлне тиреслиләр булырга кирәк. Ашлыклар бик кечкенә-кечкенә бүлекләрдә. Бик зур кисәге квадрат, йөз сажин булмас. Ике кеше урырга килгәннәр. Ураклары безнеке төсле түгел. Берәр сөям* озынлыгында чалгы сыйфатлы бер пычак. Шуны балта сабы буе бер сапка чалгы рәвешендә утырткannар. Арпаның саламын кулы берлән тота да шуның берлән төбеннән үк кисә, аннан өемгә салып китә. Машина-фәләнгә монда урын да юк, ашлык да юк. Гомумән, монда бөтен эш бик авырлык берлән, бик иске корал берлән эшләнә. Японнарның шулкадәр эшләрне эшләүләренең сәбәбе кешенең күплегендә генә. Монда кешенең исәбе-хисабы юк. Ул ат хезмәтен дә итә, ишәк эшен дә эшли. Автомобильлек вазифасын да үти.

Кич берлән безгә Иван дигән әрмән берлән Вафа дигән татар егете ашка килделәр. Ул әрмән безнең төрек таләбәләренә[1] бик күп ярдәм иткәнгә, аны ашка чакырдык. Мескеннең бик кәефе килде. Үзеңнең яхшылыгыңны тәкъдир итүчене хис итү бик зур шатлык бит. Ул татар егетен бер мәктәпкә йирләштерергә булдык.

Хат-хәбәр юк. Төшләр юрап кына торамыз. Төшкә караганда, тиздән юл күренә дә бит, белмим, ни булыр. Бүген большевиклар тагы Уфаны алдылар дигән хәбәр чыкты. Мескен безнең халык бер ел эчендә биш мәртәбә ике якның гаскәре, иң тугрысы, ике якның хулиганы тарафыннан тапталды, изелде. Алла сабырлык бирсен. Акча курсы тагы төште. Бүген бер сум җиде тиен ярымга хисаплана. Дүрт-биш көн элек тугыз тиен ярымга менгән иде.

Кичкә таба тагы ягмур башланды, бик каты күк күкрәде, яшен яшьнәде. Берсендә бик каты шартлады һәм дә бердән электрик лампалары сүнде. Без электрик стансаны яшен сукты дип уйладык. Ләкин берәр минуттан яңадан утлар кабынды. Кар вә ягмур эчендә боз да бар иде.

---

* Сөям – аршынның чирегенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге (якынча 17 см).

[1] Таләбәләренә – укучыларына.

*12 [нче] июнь*

Бүген иртүк Харбиннан телеграмма алдык. Аннан килүче Агишевлар* берлән җибәрдем, диелгән. Җибәрелгән нәрсәләр, әлбәттә, мәктүбләр, аннан соң, ихтимал, безнең өчен алынган товарлардыр. Һәр нә исә, бер-ике көннән ачык мәгълүм булачак. Фәкать телеграмманың Чанчуньнан** җибәрелүе безне тагы шөбһәгә төшерде. Әллә Харбинда безнең хакында бер-бер тикшерү башландымы, әллә Фуадлар Бүкәйханов*** берлән бергә кулга алынганнар да, безнең хакта да шундый юлларга керделәрме? Бүген көн буе шул мәсьәләләр хакында төрле-төрле фаразлар берлән көнне кичердек. Озак түгел, бер-ике көннән Агишев киләчәк, фәкать кайсы Агишев? Заһидулламы****, әллә Габдулламы? Икесе булса ярый.

Көндез ягмурлы булса, кичкә таба көн ачылды, фәкать һава суыгайды. Көз көне төсен алды.

*13 нче июнь*

Көн тик кенә үтте. Харбиннан бүген килеп җитүне әле көтмимез. Кич суык булганга, бераз суык тигән, баш авырта. Кичкә таба акча курсын белешер өчен, Йокоһамага төшәмез (без тау өстендә торамыз). Курсы бик төшенке – җиде сум егерме биш тиеннәр. Аннан кайтуымызга, безне Габдулла әфәнде Агишев көтеп тора. Ул бик күп мәктүбләр алып килгән, берсе Фуадтан. Харбинда безнең хатлар алынган, алар буенча гамәл кылып торалар. Ләкин Фуадлардан һаман хат-хәбәр юк. Кайчан киләләр, әллә бер дә килмиләрме, һичбер мәгълүмат юк. Фуадның мәктүбе 13 апрельдә, ягъни моннан тәмам ике ай элек. Ул хатта Фуад: «Без хәзер Омскида ятамыз. Бүген Франсә вәкиле граф де Мартельгә***** эшләрне рәсмиләштерү өчен барырга тиеш идек.

---

* Агишевлар – бертуган Заһидулла һәм Габдулла, Кытайда яшәүче төрек-татар милли хәрәкәтендә катнашкан актив җәмәгать эшлеклеләре, сәүдәгәрләр.

** Чанчунь – Кытайдагы шәһәр.

*** Бүкәйханов – Галихан Бүкәйханов (1866–1937), казакъ җәмәгать эшлеклесе, публицист, мөгаллим.

**** Заһидулла – Заһидулла Агишев (1881–1970), җәмәгать эшлеклесе, Ерак Шәрык төрек-татар милли хәрәкәтендә актив катнаша, сәүдәгәр.

***** Граф де Мартель – Дамьен де Мартель (1878–1940), сәясәтче һәм дипломат. 1918–1920 елларда Франциянең Себердәге дипломатик вәкиле.

Ибнеямин әфәнденең* әллә нигә кәефе булмады да бармады. Шуның өчен бүген китә алмыймыз. Шулай да егерменче апрельдән калмамыз. Солтанбәк** тә монда. Без икәү хәзер вәкил булып сайланамыз. Янымызда 15 мең сум акча бар. Синең, Солтанбәкнең кирәге юк, дигән телеграммаң Милли Идарәдә бик зур шау-шуга сәбәп булган һәм дә үзеңә телеграмма да биргән», – дигән. (Теге, без киткәч Агишевларга килгән телеграмма.) Шуннан башка хәбәр юк. Ләкин хәзер инде Фуад куйган мөддәтләр[1] дүрт-биш мәртәбә кимегән. Һаман Фуадлардан хәбәр юк. Әллә инде бөтенләй килмәскә булдылар? Әллә инде хөкүмәт бертөрле манигъ булды да, үзләрен ябып куйдылар? Әллә Солтанбәк бара алмагач, Фуадка акча бирмәделәрме? Әллә теге яктан большевик аша бездән китәргә уйладылармы? Һичберсе мәгълүм түгел.

Инде тагы Харбиннан телеграмма берлән сораганнар, җавап кайчан киләчәге мәгълүм түгел. Әмрулла әфәнденең***, Нияз әфәнде****, Гыйнаять***** хәзрәтнең мәктүбләрендә зур яңа эш юк. Әмрулла әфәнде безгә дип алган малны җибәрү хакында язган. Габдулла безгә кырык тугыз мең сумлык мал алып килгән. Шулай итеп иенга алыштыру уңайрак булмасмы дип уйлыймыз. Ләкин Харбин, Владивостокта чит мәмләкәтләрнең консулларын күрү хакындагы фикеремез[не] фәгалияткә[2] чыгара алмаслар төсле күренә. Аллага тапшырдык. Милли Идарә Уфага күчкән, имеш. Инде Уфаны большевиклар алды, димәк, тагы мәсьәлә чуалды.

*14 нче июнь*

Яңа бер хәбәр юк. Теге татар егете Вафа гына килде. Бер мәктәп тапкан һәм дә бүлмә булган, аңарга торыр-укыр өчен утыз

---

* Ибнеямин әфәнде – Ибнеямин (Биньямин) Әбүсогуд улы Әхтәмов (1877–1941), хокук белгече, милли сәясәт эшлеклесе.

** Солтанбәк – Солтанбәк Мәмлиев, Петроград Эшче-солдат депутатлар советының әгъзасы.

[1] Мөддәтләр – вакыт аралыклары.

*** Әмрулла Аги – Харбинда мәхәллә җитәкчесе.

**** Нияз әфәнде – Нияз Максуди, Троицк каласында мәдрәсә мөдире. 1914 елда Нью-Йорк университетының тәгълим-тәрбия факультетында укыган.

***** Гыйнаять – Гыйнаятулла Салиәхмәт (1889–1926) – Харбин мәчете имамы һәм мөдәррисе.

[2] Фәгалияткә – монда: гамәлгә.

иен биреп җибәрдем. Харбинга имамга шуны тәэмин итү хакында язган идем, әле җавап юк. Шуңарга күрә, үземезгә расходны күтәрергә тугры килү ихтималы бар.

*15 нче июнь*

Бүген Токиога бардык. Габдулла әфәнде безнең малларны япон сәүдәгәрләренә күрсәтәчәк иде. Ләкин алар килмәгәннәр. Ахрысы, сатып булмас. Көн буе анда торып, сишәмбе көн сәфарәтләргә барырга булып, вәгъдәләшеп кайттык. Фуадны сорап һәм дә инглиз вәкиленә керергә кушып, Омскига телеграмма бирдек.

*16 нчы июнь*

Көн тик кенә үтте. Акча курсы бик төшенке. Бүген йөз сумга алты иен гына бирәләр. Габдулла әфәнде безнең малларны сата алмаган. Ахрысы, Америкага җибәрергә тугры килер. Хәерле булсын.

*17 нче июнь*

Бүген иртүк Токиога килдек. Анда бару берлән, без, Габдулла әфәнде берлән икәүләп, Франсә-Англия сәфарәтханәләренә киттек. Франсә сәфарәтханәсе һаман җавап алмаган. Без моңарга бик гаҗәпләнүемезне белгерттек. Ике ай мөддәт эчендә сәфарәтханә үзенең мөрәҗәгатенә җавап алмый. Әллә телеграмма бирдек дип ялганлаганнар, әллә чынлап да җавап юк. Һәр көнне аерым шәхесләр Франциягә китеп тора. Ник сез безгә бирмисез? Без – бер милләтнең вәкилләре. Безнең гаскәремез сезнең мөхафәзә өчен аз кан түкмәде. Бүгенге көндә Франсәдә рус гаскәре эчендә меңнән артык татар солдаты бар. Франсә тупрагында гына үлгән татар солдатының саны ике меңгә җитә. Шулкадәр татар солдаты Франсә өчен кан түгәргә барганда, безгә, милләтнең вәкилләренә, милләтнең дәртен, уен аңлатыр өчен, Франсәгә барырга ярамый. Моны безнең халык ни дип аңлаячак? Без катгый итеп безнең хокукымызны аяк астына таптамавыңызны үтенәмез. Сәфарәтнең мөстәшары[1], бераз кызарып, бераз оялып: «Мин бүген үк сезнең мәсьәләңезне сәфиргә сөйлим, берәр катгый хәрәкәт итәрмез. Документлар хәзерме?» – диде. Һәр документларымыз хәзер, дидек. Тиздән җавап бирергә булып калды. Тизе никадәр

[1] Мөстәшары – киңәшчесе.

булыр. Хезмәт ни рәвештә булыр, Алла белә. Аннан Ингелтерә[1] сәфарәтханәсенә киттек. Анда бераз көттеребрәк кабул иттеләр. Бу – инглизләрнең «сине сөймим» дигән сүзләре, ләкин без, халкымыз тарафыннан җибәрелгән вәкилләр, инглиз малайларының андый тупаслыгына гына, әлбәттә, илтифат итмимез. Һәм итмәскә тиешмез. Биш минуттан соң сәфарәтханәнең сәркатибе чыкты. Күреште, утырыштык. Безгә виза бармы? Сезгә бит Франсәгә барырга кирәк. Франсәдән алыңыз, фәлән-төгәл, озын фәлсәфә китте. Мин, туп-тугры иттереп: «[...] җавап бармы?» – дидем. – Бар, – ул: «Гаяз Исхакыйны белмим», – дигән. Без сезгә [...] безне белә дигәнемез юк. Сез аңарга үзегез мөрәҗәгать иткәнсез, без – милләтемезнең вәкилләре, шуның Милләт Мәҗлесе тарафыннан сайланган кешеләре, кулымызда менә дәлилләремез, сезнең түрәләреңезнең русчаны белмәвенә без гаепле түгел. Безгә Солых Мәҗлесенә барырга лязим, шуны ни юл берлә булса да, сезнең манигъ булмаңыз[2] тиеш. Гаяз Исхакый соң кем дип, минем кемлегеме тагы бер мәртәбә сөйләдек. Кулымыздагы документларны күрсәттек. Без Милләт Мәҗлесемез тарафыннан сайланылган өч зат идек. Беремезне большевиклар үтерде, беремез гаиб булды. Урта мин калдым. Милли вазифаны үтәр өчен, шулкадәр мәшәкать берлән килдем. Монда сез юк сүзләр берлән кирәкмәгән киртәләр саласыз. Матбугат сездә генә түгел, бездә дә бар. Без милләтемезгә ни дип шул мәсьәләне аңлатачакмыз? Сезнең шулкадәр безнең хокукымызны игътибарга алмавыңызны ни дип тәфсир итәчәкмез? Инглиз түрәсе тагы бер мәртәбә безнең сөйләгән сүзләремезне язды, тагы безгә бер мәртәбә Владивостокка телеграмма биреп сорарга һәм дә Лондонга телеграмма бирергә вәгъдә бирде. Вәгъдәсене ни кадәр тотырыр, Алла беләдер. Ләкин без үз вазифамызны эшләми хәлемез юк.

Бүген Парижга Чайковский* һәм Һарольд Вильямс** исеменә телеграмма биреп, безгә ярдәм итәргә үтендек. Монда инде

---

[1] Ингелтерә – Англия.

[2] Манигъ булмаңыз – каршы булмавыгыз, киртә куймавыгыз.

* Чайковский – Николай Васильевич Чайковский (1850–1926), рус сәясәт эшлеклесе.

** Һарольд Вильямс – Гарольд Вильямс (1876–1928), Британия журналисты, тел белгече.

японнар әллә никадәр телеграмманы тотып, эштән чыгарырлар. Телеграммага йөз кырык иен чыкты, ягъни ике мең сум көмеш дигән сүз. Хәерле булсын. Тагы берничә адымнар атлаячакмыз. Бер дә булмаса, хаҗи сыйфаты берлән китү юлына керәчәкмез. Ләкин үз вазифамызны үтәми калмаячакмыз.

*18 [нче] июнь*

Берни булмады. Хат-хәбәр юк. Һава матур гына булды. Иртәгә, Америка газеталарында бастырыр өчен, бер мәкалә җибәрәчәк идек. Инглизчәгә тәрҗемәсе өлгермәде. Инде икенче пароход берлән җибәрергә лязим булачак. Малларны сатып булмый, ахрысы, акча мәсьәләсе мөшкел.

*19 нчы июнь*

Бүген иртүк Англия сәфарәтханәсеннән озын бер мәктүб алдык. Мәктүб – безнең соңгы мөрәҗәгатемезгә җавап. Мәктүбдә безнең виза соравымызга җавабын бу рәвешле бирә: Омскидан алган хәбәремез буенча, безнең Омскидагы вәкилемез Гаяз Исхакыйны белми. Омскида татарларның коммунистларына да Гаяз Исхакый мәгълүм түгел. Сезнең теләкләрне Лондонга телеграмма бирер өчен, бик күп расход чыгачак, шуңарга күрә сәфарәтханә ул расходны үз исеменнән тота алмый. Әгәр телеграмма бирүне теләсәңез, биш йөз иен, ягъни (җиде мең сум) акча китереп биреңез дә, шул хисаптан телеграмма җибәрермез. Рус сәфарәтханәсеннән алган мәгълүматымыз да сезнең файдаңызга түгел, диелә. Димәк, безнең эшемезгә каршы, әллә үземезнең начар организованный булуга башка рус карагруһлары да аяк чалалар. Мондагы сәфарәтханәнең әгъзаларының күбесе – Николай заманасында куелып калган карагруһлар. Сәфир черносотна әгъзасы группасыныкы. Болар, безнең бөтен хәрәкәтемезгә каршы булганга, әлбәттә, нинди юл берлән булса да, зарар итәргә тырышачаклар. Безнең моңарга каршы торырлык бер куәтемез дә юк. Артымызда халәтемез организован түгел. Милли мәсьәләләремез куелмаган, Милли Идарә эше башында – имансыз әрәмтамак мирзалар. Боларда мәсьүлият[1] хисе булмаганга, эшнең эш булып чыгуына ярдәм итү кайда, зарар гына итәләр. Инде менә

[1] Мәсьүлият – җаваплылык.

ике ай торып үтте, Милли Идарәдән унлап телеграммага бер җавап алганымыз юк. 24 нче гыйнварда чыгып киткәннән бирле бер мәктүб, бер язу кисәге алганымыз юк. Эш шул дәрәҗәдә булганда, ничек иттереп шулкадәр зур эш эшли алырга кирәк? Ничек иттереп, өсткә йөкләтелгән милли бурычны үтәргә кирәк? Күп уйлаганның соңында инглиз сәфарәтханәсенә биш йөз иенны садака бирүдән ваз кичтек. Безнең төрек-татар милләте инглиз мәнфәгате өчен ачылган шул канлы сугышында миллионнан артык углын гаскәр иттереп җибәреп, миллиардларча сумда акча сарыф итте. Йөз мең җан корбан итте. Шулар аркасында инде инглизләр немецларны җиңде. Инглизләрнең, әлбәттә, хәзер дә тулмаган йирләре дә бардыр. Акча кирәктә бар, ләкин без инде милләт акчасыннан шул сумманы инглиз сәфарәтенә һәдия итә алмыймыз. Бездән шулкадәр җитәр. Шул йөзәр мең кардәшләремезнең каны берлән инглизләр алдында милләтнең вәкиленә виза бирер дәрәҗәдә хөрмәт, кадер казанмаган булсак иде.

Ул биш йөз иен берлән ул игътибарны сатып ала алмабыз. Бу мәктүбне без инглизләрнең катгый рәд[1] җаваблары дип каршы алдык һәм шулай да инде калды Франсә сәфарәтеннән җавап көтәргә, бәлки алардан бертөрле күңелле хәбәр килер. Без инде Франсәгә телеграмма биргәнгә һәм дә Омскига телеграмма биргәнгә шактый вакыт кичте. Берәр атна эчендә икесеннән дә җавап килер дә, шул мәсьәлә ачылыр дип уйлыймыз. Аннан да рәд җавабы килсә, мәсьәлә фәүкыльгадә мөшкелләнә[2]. Ләкин әле иман һаман бетми. Ул вакыт мин, Пекинга барып, һәм дә Владивостокка барып, яңадан бер хәрәкәт ясап караячакмын. Аллага тапшырдык инде.

Иртәгә Никко* дигән, японнарның иске гыйбадәт йирләренә барып килмәкче буламыз. Окубо** килгән иде, японча биргән мәкаләмезне һаман бастыра алмаган әле, ахрысы. Бөтен шпионнар укып бетермәгәндер. Японнарга тәмамән ышаныч бетте. Омскида татар комитәсе[нең] Гаяз Исхакый мәгълүм түгел дигән сүз нәрсә? Бу – бер инглиз ялганы, әллә хакыйкатән, Милли

[1] Рәд – кире кагу.

[2] Фәүкыльгадә мөшкелләнә – чиктән тыш авырлаша.

* Никко – Япониядәге шәһәр.

** Окубо – Окубо Кочи – Комазава университеты профессоры.

Идарәнең бер имансыз мирзасы шундый милли җинаять ясаганмы? Һәр нә исә[1], бу кәгазьдән соң минем беренче вазгыятем бик начарлана. Аллага тапшырдык.

*20 нче июнь*

Бүген безнең товарны сата алу-алмау беленергә кирәк. Габдулла әфәнде* иртәдән шул малын күрсәтеп, сатулашып йөри булырга кирәк, чөнки Никкога барырга дигән вакытта ул килә алмады. Димәк, без Никкога бүген бара алмыймыз. Әгәр товар яхшы сатылса, Никкога баруның әһәмияте ул кадәр зур түгел, кичә шулай итеп вәгъдәләшкәнгә, аның иртә килеп җитмәве шуны күрсәтте. Без зур өмид берлән мал сатуны көтәмез, безнең малларга Харбинда төлкегә 35 иен биргәннәр. Монда артыграк алмакчы буламыз, әгәр шулай уйлаганча сатылса, безгә иен хәзерге базарга караганда шактый очсыз киләчәк, ягъни базарда унике сум булганда, безгә җиде сумга киләчәк. Бу безнең эшне бик җиңеләйтәчәк. Сәгать 12 ләрдә тагы бер мәктүб. Монысы Франсә сәфарәтханәсеннән, кыска гына, ләкин мәгънәсе бик зур. Шул әхваль эчендә шул документлар берлән генә сәфир бәк виза бирә алмыймыз, дигән. Париждан җавап һаман юк, кайчан киләчәге дә мәгълүм түгел. Омскидан хәбәр юк. Димәк, безгә хәзерге әхваль эчендә рәд килде, димәк, безгә виза бирмәячәкләрен әдәб төсендә аңлаттылар. Инде нишләргә, анысы хакында әле бер карарга килеп җиткәнемез юк. Иң тугры юл шул – мәсьәләне Милли Идарәгә аңлатып, аннан Омскида, Франсә, инглиз вәкилләренә мөрәҗәгать итү иде, ләкин без Милли Идарәдән ике айдан бирле һичбер төрле хәл-хәбәр ала алмыймыз. Алар хәзер Петропавловскидамы, әллә Уфага китеп, юлда әвәрә булдылармы? Һич мәгълүмат юк Фуадтан вә һакәза[2]. Шуңарга күрә аларга ышанып, бер хәрәкәт тә ясарга хәл юк. Алай булса, Харбинга хат язып, шул хәлне Милли Идарәгә белдерергә кушкан идек. Мондый зур эштә бер кешенең иҗтиһады берлән генә, әлбәттә, берни чыкмый. Бөтен мөәссәсә[3] бер кеше кебек хәрәкәт итәргә кирәк.

[1] Һәр нә исә – нәрсә булса да.

* Габдулла әфәнде – Габдулла Агиш, Харбин сәүдәгәре.

[2] Вә һакәза – һәм башкалар.

[3] Мөәссәсә – оешма.

Безнең Милли Идарә бу эштә әлегә кадәр хәзергә башка бер эш эшли алмады. Беренче адым итеп, Франсә сәфарәтханәсенә яңадан барып, Омскидан граф де Мартельдан телеграмм берлән безнең хакта җавап соратырга, икенчесе, Франсә сәфарәтханәсеннән Парижга яңадан телеграмма бирүне үтенергә, әгәр алар да акча сораса, боларына инде бирергә дә, шуннан соң шуларга җавапны һәм дә Омскидан киләчәк хәбәрне бераз көтәргә. Шул арада Франсә, Англия, Америка сәфарәтләренә яңадан мәктүб берлән виза бирүне сорап мөрәҗәгать итәргә. Боларның берсеннән дә без теләгән җавап чыкмаса, мин яңадан Владивостокка кайтып китәм дә, андагы вәкилләр берлән тагы бер мәртәбә сөйләшеп карыйм. Аннан да берни чыкмаса, үземезнең теләгемезне газеталарда игълан итәмез дә, милләтемезнең хокукын, шул тәгъриз[1] хакында протест игълан итәмез. Кулымызда башка юл юк.

Өйләдән соң Габдулла әфәнде килде, малны күрсәткән, ләкин бик очсыз бирәләр, ди. Харбинда 35 иен биргән төлкеләргә 27 иен гына биргәннәр. Сатсаң, бик очсыз, сатмасаң, иен бик кирәк. Ахырдан 32 ләргә булса, сатарга карар иттек. Булмаса, Америкага җибәрәмез. Ләкин аннан әйләнгәнче бик күп вакыт үтәчәк. Мондагы ихтыяҗны канәгать итеп, иен алу берлән үтәргә мәҗбүр булачакмыз. Кәеф бер дә юк.

Эч поша. Бераз күңел ачылмасмы дип, Токиога Габдулла әфәндегә ашка барамыз. Анда бүген бал бар һәм дә француз хөрмәтилә зыяфәт бар икән. Француз офицерлары, француз исеменнән йөри торган яһүди марҗалар бииләр, сикерәләр, көлешә-уйнашалар, бәйрәм итәләр. Безнең агай-эненең каны берлән немецчаны арткannар[2]. Туй ясыйлар. Без шул эшнең иң зур гамәлләре җыенында. Солых Мәҗлесенә бару өчен генә дә виза да ала алмыймыз. Бу эшләр бик зур дәрес булырга тиеш. Татар-төрек баласына кешеләр өчен өмәгә йөрүнең ни дәрәҗә кадерсез икәнен күрсәтә торган тарихи сабак булырга тиеш һәм булачак та, иншаллаһ. Халкымызга шул оятсызлык, шул золымны аңлатачакмыз да.

---

[1] Тәгъриз – ризасызлык.

[2] Артканнар – м о н д а : арттырганнар.

*21 [нче] июнь*

Бүген икенче бер сәүдәгәргә малымызны күрсәтергә идек. Габдулла әфәнде көн буе шуның берлән мәшгуль булды, ләкин бернәрсә дә чыкмады. Берсе дә алмады. Инде мал Америкага җибәреләчәк. Анда ул август башларында барып керәчәк, сатылуына кадәр дә шактый вакыт үтәчәк. Шуңарга күрә аның акчага әверелүе бик озынга сузылачак. Бәһасе күпмегә китәчәк, анысы һәм мәгълүм түгел.

Бүген бик эссе булды. Мин кичкә таба диңгез хәмамы[1] эзләп киттем. Йокоһаманың тирәсендә барып таптым һәм дә беренче мәртәбә Тихий океанда (бәхре мохитләрдә) коенып кайттым.

Бүген японнарның бер ахмак атналары үтте. Японнар, Америкага тәкълид[2] булырга кирәк, 15 нче июньнән алып 21 нчегә кадәр сузылган атнаны, зәңгәр салиб[3] төсе биреп, иминият атнасы дип атадылар. Һәм дә бөтен тимер юллар, вагоннар, урамнарын зәңгәр тире берлән тутырдылар. Кешеләргә зәңгәр тире кисәкләре саттылар. Рикшалар[ның] арбаларына зәңгәр тире ябыштырган. Бөтен Япониянең хәяты зәңгәр тире химаясенә бирелгән. Һәр йирдә бу атнада бер-берегезгә зарар итмәңез, имин булыңыз, имин булыңыз дип язылган. Бу ахмаклык атнасы, бер яктан караганда, әлбәттә, көлке. Икенче яктан караганда, японнарның тәкълидтә никадәр сабырсыз икәнлекләрен күрсәтә торган күңелсез бер эш.

Бүгенге көндә христианнардан әллә никадәр зарар итә торган японнар, имеш, христианлыкның дин галәмәтләренең химаясенә керәләр дә иминият атнасы ясыйлар. Аннан соң алай итеп кенә иминият атнасы, мәхәббәт атнасы, уен атнасы ясап уйнаулар ул Европа, Америка кебек бөтен дөньяны талый-талый баеп бетеп, бәйрәм ясарга аптырап торган халыкка гына килешә. Халкының йөзгә туксан сигезе штансыз йөргән японга Америкага ошыйм дип кылану – маймыллык кына. Япон әфкяре гомумиясе[4] моны яратмаган, имеш. Шунысы гаҗәп: атнаның беренче көнендә кинематограф җимерелеп, миллионлап кеше җәрәхәтләнгән. Икен-

---

[1] Диңгез хәмамы – диңгез ярында махсус су керү урыны, пляж.

[2] Тәкълид – ияреп.

[3] Салиб – тәре.

[4] Әфкяре гомумиясе – җәмәгатьчелек фикере.

че көнендә зур бер янгын булган. Өченче көнендә зур бер кеше үтерү җинаяте булган. Хаслы[1] һәрбер көнендә башка атналарга караганда җинаять, бәхетсезлек, иминсезлек күбрәк булган.

Хат-хәбәр юк.

*22 нче июнь*

Бүген иртәдән үк һава бик ягмурлы һәм дә җилле. Җил шулкадәр каты, бөтен өй селкенә. Без тәрәзәне ача алмыймыз. Вак кына ягмур өзелмәенчә яуса да, һава бик бөркү, хәтта эссе дә.

Өйләдән соң безнең тәрҗеман керә, аның берлә сөйләшеп утырганда, безгә яңа бер юл күрсәтә, ул – Мексикага китү. Аннан Европага чыгу җиңел булачак. Анда китәргә мин ярдәм итешә алам, ди. Без аңарга ачыграк белешергә кушамыз. Үземез шул фикернең татбигын[2] уйларга тотынамыз. Бу юл – шактый озын юл. Иң әүвәл Мексикага чыгарга пароходта егерме ике көн барырга кирәк, аннан Европага кадәр ике атналап барырга кирәк. Бу – бер. Икенчедән, Франсәгә керергә, анда да виза алу җиңел булмаячак, ләкин ничек тә ул Европага шактый якын булганга, мондагыга караганда юл якынлана төшәчәк, шуңарга күрә бу юл хакында мәгълүмат җыярга булдык һәм дә бик кире кагарга да уйламадык. Ләкин бу хезмәтләр акча бәрабәренә эшләтеләчәк. Нишлисең инде, башкача мөмкин булмагач.

Бүген төштә Садрины* күрдем. Күңелсез, картайган. Сачләре агарган. Элгәре икенче бүлмәдә иде. Аннан барып күрештем. Оренбургта яттым, беркемгә дә белдермәдем, ди. Ихтимал, аның хакында бер-бер хәбәр килә торгандыр. Кичкә таба көн ачылды.

*23 нче июнь*

Бүген көн иртәдән үк аяз. Ягмур күренми. Һава бик эссе. Без, бер тарафтан, Мексика хакында мәгълүмат көтәмез. Икенче тарафтан, Омскидан берәр хәбәр. Өйләгә кадәр, Габдулланы көтеп, өйдә утырамыз. Өйләдән соң Габдулла килә. Шатлыклы бер хәбәр. Ул безнең малларны саткан. Һәм дә без уйлаганнан күп артык саткан. Бу безнең рухны бик күтәрә һәм дә өмидләр

---

[1] Хаслы – тойгылы.

[2] Татбигын – яраклы булуын.

* Садри – Садри Максуди (1878–1957), дәүләт эшлеклесе, сәясәтче.

тудыра. Ике-өч көннән бирле ул никадәр маташса да, һичбер төрле эшне юлга сала алмаган иде. Бу юлы хуҗа Баһаветдиннең ярдәме берлән бик яхшы саткан. Үземезгә илле ике мең сумга төшкән малны җиде мең дә сигез йөз иенга биргән. Бүген акчаның курсы җиде цент, ягъни сумы җиде тиен. Аңарга караганда безнең илле ике мең сум акчамызга каршы без өч мең дә алты йөз кырык иен алырга тиеш идек. Без бүген шуңарга җиде мең дә сигез йөз иен алдык. Бер тиенгә бер тиен сумына кыйммәт саттык. Бунда, әлбәттә, безнең үземезнең хезмәтемез булмады. Болар һәммәсе дә – Әмрулла әфәнде берлән Габдулла Агиш әфәнденең хезмәтләре. Әмрулла әфәнде алды, аны җибәртте, Габдулла әфәнде алып килде, йөртте, мәшәкатьләнде, сатты. Ләкин фикер, идея безнеке һәм дә аларны эшләткән, аларны йөгерткән, аларның тирләрен агыздырткан нәрсә – мәгънәви көч, без биргән көч, без тудырган көч, аларның милләтләренә мәхәббәтләре, аларның безгә иманнары, ышанулары.

Шул шатлыклы эш булганга, бүген күңел күтәренке. Башка эшләр шулай матур очланыр кебек булып китте. Әле өмидне өзәргә ярамый. Мадам ки[1] шул юлга керешкәнмез, шул алган юлымызны эшләп бетерергә тиешмез. Бүген теге тәрҗемә итәргә тиеш иде. Ахрысы, бетмәде, китермәде. Мексика хакында мәгълүмат җыяр өчен, бер америкалыны күреп сөйләштек. Мексика берлән Җәмаһире Мөттәфика[2] арасыннан үтү җиңел, ди. Испаниягә бару бөтенләй уңайсыз, шуңарга күрә анда таба китү тарикы[3] тагы куәтләнгәннән-куәтләнә бара. Бүген тагы берничә йирдән мәгълүмат алачакмыз. Иртәгә йә берсекөнгә Франсә сәфарәтханәсенә тагы барамыз һәм дә чехославларның[4] мондагы вәкилләрен күрәчәкмез. Ни булса да, бер нәрсә чыкмасмы әле.

Инглизчә укырга тотынган идем, тагы бер атнадан бирле мөгаллимем йыкып калды[5]. Яңаны һаман әле таба алмыйм. Гомәргә төрекчә укыта башладым.

[1] Мадам ки – чөнки.
[2] Җәмаһире Мөттәфика – Америка Кушма Штатлары.
[3] Тарикы – юлы.
[4] Дөресе: чехословакларның.
[5] Йыкып калды – юкка чыкты.

*24 нче июнь*

Бүген бер дә яңа эш юк: мин хисапларны тикшереп чыктым. Ике ай ярым вакытка ярыйсы – ике мең дә биш йөз иеннар чамасы – расход чыккан. Расходымыз бик аз, чөнки бик кысып тотамыз. Иртәгә Габдулла китәчәк булганга, хатлар язу берлән мәшгуль булдык. Инглизчә теге мәкаләнең тәрҗемәсе тәмам булды. Бер-ике көннән теге мөрәҗәгатемез дә тәмам булачак. Мексикага китү мәсьәләсе бик соңаячак. Пароход Кобедан* бишенче августтан иртә китә алмаячак. Димәк ки, ул юл берлән булганда, без бик иртә барып җиткәндә, Парижга егерменче сентябрьләрдә барып керәчәкмез. Бик соң түгел. Солых мөзакәрәләре башлануга тәмам ун ай тулганда гына. Нишлисе соң?

Иртәгә тагы Франсә сәфарәтханәсенә барамыз. Һәм дә чехословакларны күрәмез. Гомәр Владивостокларга барып килсә, бик яхшы булыр иде дә, бик куркак.

*25 нче июнь*

Бүген иртүк торып, Габдулланы озатырга Токиога киттек. Ул инде, без барып җиткәндә, тәмам хәзер иде. Вәгъдә буенча автомобиль алдык та Франсә сәфарәтханәсенә киттек. Беренче үтенечем – Омскига граф де Мартельгә телеграмма биреп, безнең хакта сорарга, икенчесе – Парижга яңадан телеграмма бирергә сорау иде. Әгәр үзләреннән бирергә разый булмасалар, үз хисабымыздан бирдерүне үтенергә идек. Барып карточканы биргәч тә, көтү бүлмәсенә безгә бер малай чыкты. Без аны монда лакей урынындагы малай, безне чакырырга килде дип торамыз. Ул шул без сораган мистер «Бадак» булды. Монда килгәннән бирле безне беренче мәртәбә болай илтифатсыз кабул итү булды. Ни йомыш? Мәсьәләне аңлаттык. Үтенечемезне әйттек. Унсигезунтугыз яшьле[к] яһүд малае – Франсәнең вәкиле берлән без үземезнең кулымыздан килгән һәр эшне без кылдык. Моннан соң бер эш тә эшли алмыймыз, диде. Без, белмәмешсезгә салынып, тагы үземезнең үтенечемезне – Омскига телеграма бирүне икешәрләдек[1]. Малай: «Мин әйттем», – диде дә, бик зур кеше кебек урынынnан торды. Безгә яһүд малаеның галиҗәнабына

* Кобе – Япониядәге шәһәр.

[1] Икешәрләдек – монда: «кабатладык» мәгънәсендә.

биргән «мөлякате[1]», «аудиенция»се тәмам димәк иде. Без дә акрын гына торып чыктык. Габдулла әфәнде яһүд малаеның шул кыланышыннан кып-кызыл булган, каны башына-йөзенә йөгергән. Күзенә әллә нинди бер әйтеп бетермәслек ачу чыккан иде. Ул үзенең иң матур тойгысында мыскыл ителгән. Аның милли барлыгының иң-иң авырта торган йиренә дошманлык зәһәре сугылган. Аның иң кадерле миллият хисе, аның үзенең миллиятен хокуклы итеп күрергә теләү тойгысы яһүд малаеның пычрак аяк астына тапталган иде. Автомобильдә ул авыр сулый, әллә ниләр уйлый иде. Мин, аның уйларын белгән кебек, менә бу мөгамәлә – безнең милләтнең кыйммәтен (удельный весын) күрсәтә торган эштер. Без, җәмәгать эшендә йөри торган кешеләр, һәр көндә кебек шундый шанымызга муафикъ булмаган мыскыллар күрәмез, аңарга каршы һичбер төрле җавап бирә алмыймыз, чөнки безнең алар берлән тартыша торган коралларымыз юк. Безнең Европага тәэсир итәрлек матбугатымыз юк. Безнең Европаның малиясенә тәэсир ясарлык икътисади җәмгыятьләремез, куәтләремез юк. Милләтнең йөзенә ыргытылган һәртөрле мыскылларга җавап бирерлек артымызда оешкан бер җан, бер шәй хәленә килгән милләтемез юк. Шуңарга күрә үзенең һичбер төрле җәзага очрамавына ышанганга, тавык йөрәкле куркак яһүд малае да безгә каршы батырланган булып кылана ала. Кайткач та, бу мәсьәләне мөзакәрәдән соң, бу мөгамәләне Франсә сәфарәтханәсенең безгә рәде, отказы дип мөгаен иттек[2]. Шул авыр хистән бераз арынганның соңында, Аурупадан килгән шул хафа ниятсезлек ачуыннан бераз арчылганның соңында, Гомәр әфәнде берлән чехословаклар вәкилләре доктор Тимецны күрергә киттек. Чехословаклар Русиядә озак торганга, алар безнең халыкның ролен беләләр. Безнең хәрәкәтемезне күргәннәр, алар татар-башкорт алайлары берлән бергә большевикка каршы сугышканнар. Самара комитетында, Уфа киңәш мәҗлесендә алар, безнең вәкилләремез булып, бер юлда демократик партиясен сакларга тотынганнар. Алар, безнең вәкилләремез кебек, Русиянең идарәи демократ җөмһүрият булганда гына, Русиядә

[1] Мөлякате – очрашуы.
[2] Мөгаен иттек – билгеләдек.

мәдәни хәят мөмкин, дигән фикердә булганнар. Шуңарга күрә, алар хәзерге хәлдә безгә дошман иттифакъның әгъзалары булсалар да, мәсләкләре берлә безгә бик якыннар. Аңарга башка[1], бу чехлар берничә гасырдан бирле милли тартышуда җиңеп килгәнгә, болар милли тартышуның бөтен авыр адымнарын берәм-берәм атлап, тауларны, ташларны, елгаларны, упкыннарны үзләре кичкәнгә, боларга безнең хәлне аңлау, әлбәттә, бик җиңел булачак. Өченче бер сәбәп бар, ул да – тел. Без болар берлән русча сөйләшә аламыз, боларга үземез русча язылган кәгазьләремезне күрсәтә аламыз. Зур бер өй. Тәмам сәфарәтханә кебек. Безне бик тиз кабул итәләр. Ләкин хәзер әле доктор Тимец Русиядән кайтмаган, аның урынына монда Кавоза дигән бер сәркатип кенә бар. Ул да әле юк. Ләкин ул биш минуттан кайтачак. Шуңарга күрә безне бераз көтәргә үтенәләр. Без янымыздагы чех офицеры Великошаның кәтибе берлән сөйләшеп утырамыз. Сәркатип кайта. Бик мөлаем бер егет. Ни йомыш? Мәсьәләне аңлатып бирәмез. Ул Русия[дә] бик күп булган, татар-башкорт гаскәрен бик белә, безнең фикерләремезгә бик дустанә карый, ләкин ул вакытлы кеше генә. Шуның өчен безгә доктор Тимец кайтканны көтәргә киңәш бирә. Ул җомга көн кайтачак. Ул кайткач та, безгә мәктүб язып чакырачаклар. Сүз арасында, сезгә монда Русия сәфарәтханәсе зарар итә торгандыр. Алар монда шулай эшлиләр. Сез[гә] үзеңезнең вәкиллегеңезне яшерү кирәк иде, ди. Һәм дә без, иншалла, кулдан килгәнне эшләрмез, ләкин безнең кулымыздан күп эш килми. Әлбәттә, аны да беләмез. Без, Франция, Англиягә каршы хәрәкәт итә алмыймыз, ди. Без бу егетнең матур мөлаем мөгамәләсенә эчемездән рәхмәт укып, сәламләшеп кайтып китәмез. «Империал» отельдә берничә кешедән безнең визамызга рус сәфарәтханәсенең аяк чалганлыгын ишетәмез. Мондагы Русия сәфарәтханәсендә Николай заманасыннан бирле һичбер төрле үзгәреш булмаган. Монда сәфир – элгәреге посол, карагруһ Крупенский*. Хезмәтчеләре – һәммәсе дә иске түрәләр. Эшләре юк, шуңарга күрә япон хатыны артында

---

[1] Аңарга башка – «аңардан башка» мәгънәсендә.

* Крупенский – Василий Николаевич Крупенский (1888–1945), 1916–1921 елларда Япониядә Россиянең посолы вазифасын башкара.

йөреп һәм дә сплетня ясап, Русия подданнарына[1] җәфалык итеп гомер кичерәләр. Иншалла, берәр эш чыгар әле.

*26 нчы июнь*

Бүген иртәнге газеталар Германиянең (Мәҗлесе мөәссәсаты) Учредительное собраниегә солых шартларын кабул итүгә карар биргән. Һәм дә үзенең вәкилләренә могаһәдәгә[2] кул куярга әмер иткән. Солых шартлары Германия өчен бик зарарлы булса да, Германия әхвале, күрәсең, шул хәлгә дә каршы торырлык дәрәҗәдә түгел. Ләкин бу солыхның гомере, әлбәттә, бик кыска булачак. Сиксән миллионлы немец халкы үзен терелätә кимерергә, ашарга, әлбәттә, рөхсәт бирмәячәк. Беренче караганда гына бу солыхның маддәләре бераз зарарлы киләчәк. Ләкин могаһәдә бөтен инсанияят канунының чыгарылып, фәкать көчкә таянып кына эшләнүе немецларның күңелләрендә әйтеп бетермәслек ачуны кабартачак. Беренче форсатта ук, бөтен канун гайре канун булу берлән, тагы сугыш башлаячаклар. Тагы әллә ничә миллионнар кан түгәчәкләр. Тагы французларны изәчәкләр. Фәкать ул сугышта германнарның файдасына, бөтен дөньяның әфкяре гомумиясенә[3] иштирак итәчәк[4]. Бөтен ислам галәме, бөтен Азия кыйсеме германнар тарафында булачак. Бик ихтимал, Русия дә Германия берлән иттифакъта бергә хәрәкәт итәчәк. Бәлки, бусында да Германия алдында инглиз, Американы күреп, тагы берсенә мәгълүб булачак[5]. Ләкин ниһаятендә[6], Германия бөтен җәберләнгән, мыскыл ителгән милләтләрне бер байрак астына җыеп, Ингелтерәнең дөнья падишаһлыгына хәд чигәчәк[7], инглизләрнең бөтен дөньяны савуларына хитам бирәчәк[8]. Бу, бәлки әле, тиз булмас, моны, бәлки, без күрмәмез дә, ләкин, мотлакан бу булачак. Англиянең золымы, Англиянең талавының очы чы-

[1] Дөресе: подданныйларына.
[2] Могаһәдәгә – килешүгә.
[3] Әфкяре гомумиясенә – иҗтимагый фикеренә.
[4] Иштирак итәчәк – кушылачак.
[5] Мәгълүб булачак – җиңеләчәк.
[6] Ниһаятендә – соңыннан.
[7] Хәд чигәчәк – чик куячак.
[8] Хитам бирәчәк – тәмам итәчәк.

гачак... Безгә, төрек милләтләренә, безгә, ислам өммәтләренә, бу вакыйга никадәр тиз булса, шулкадәр файдалы булачак.

Бүген телгә алырлык бер вакыйга да булмады. Теге япон гына иске японча язылган рәсемнәр, тарихи хикәяләр алып килгән иде. Хикәядә биш батыр шайтаннар берлән сугышалар. (Монда җиде йөз ел элек Суматра, Җава тарафларыннан христианнарның Япониягә һөҗүмнәре халык рухынча хикәягә әверелгән.) Безнең хан балаларының дию пәриләре берлән сугышулары кебек бер хикәя язмыш. Ике йөз элек язылган, рәсемнәре вә һакәза бик матур эшләнелгән. Шунысы гаҗәп: ул вакыттагы христианнарны япон әкияте шайтан итеп йөртәдер. Салиб[1], крест – шайтанлык галәмәте. Һәрбер шайтанның таягының эчендә бер салиб бар. Бүгенге көннең японнары үзләренең бөтен матур гадәтләренә христиан төсе бирергә теләп, эштән чыгадыр. Бер милләтнең рухында никадәр аерма. Элеккеге рух Японияне саклап алып, аны зур бер мәмләкәт ясаган, яңа рухның Японияне кая алып барачагы әле мәгълүм түгел. Төркиядән гыйбрәт алынса, җәһәннәм чокыр гына кебек күренәдер.

*27 нче июнь*

Бүгеннең беренче хәбәре Италиядәге зур хәрәкәтләр хакында булды. Андагы сәяси тартышларда җөмһүрият тарафдарлары җиңеп, хәзерге хөкүмәт истигъфа итәргә[2] мәҗбүр булган. Димәк, анда да шул мәсьәлә башлана, анда да революция китә. Безгә, төрек-татар балаларына, бу, – әлбәттә, бик сөенечле хәбәр. Италия соңгы ярты гасырда Төркиянең зарарына булган хәрәкәтләрдә иң алгы сафта булып килде. Гәнеч[3] төрек хөкүмәтенең тынычлыкка, дахили эшкә иң мохтаҗ вакытында Траблис* өчен сугыш игълан итеп, Төркияне кирәкмәгән бер сугышка керергә мәҗбүр итте, яңа хөкүмәтнең иң кадерле дахили эшләргә сарыф итә торган вакытын сугыш берлән үткәрергә мәҗбүр итте. Шуның аркасында Балкан иттифакының мәйданга килүенә юл хәзерләде. Соңгы сугышта ислам галәменең дошман тарафында булып, безнең өчен зур зарарлы роль уйнады. Димәк, хәзер шул

[1] Салиб – тәре.

[2] Истигъфа итәргә – эштән азат ителергә.

[3] Гәнеч – яшь.

* Траблис – Триполи – Ливиянең башкаласы.

дәүләтнең золымнан ләззәт таба торган машинасы ислам каны берлән тотканда сына. Ул машина яңа-яңа ислам дәүләтләрен кисәрлек, изәрлек хәлдән чыга... Әлбәттә, бу Италия дәүләтенең бетүе түгел, итальян милләтенең дә инкыйразы түгел. Безгә анысы кирәге дә юк. Ләкин бу – Италиянең азау тешенең бик күп каты нәрсә ашарга чыдый алмаенча җимерелүе, черүе. Азау теш улкадәр ыржаймаган. Музыка сөя торган итальян милләтенә каршы без бер дә дошманлык тойгысы белмимез. Моннан килеп чыгачак нәтиҗәләр хәзерге көндә безнең ислам галәме өчен, гомумән, Төркия өчен бик зур булачак. Беренче, Италиянең золымыннан туйган Траблис, тагы һөҗүм ясап, Италияне Африкадан куачак. Арнаудлыкта Италиянең көче зәгыйфьләнгәч тә, Австрия тарафдарлары күптән мәгълүб булганга[1], анда тартыша торган ике генә агым калачак. Берсе – төрек агымы, икенчесе – юнан агымы. Төрек агымына арнаудларның дүрттән өч мөселман бүлеге катышачак булганга – юнан агымы бик зәгыйфьләнәчәк, бетәчәк. Төреклек (монда, әлбәттә, ислам байрагы астында) юнанлылыкка галәбә чалачак[2]. Икенче, Италиянең Атина* вә әтрафларын Төркиядән алырга теләү хисе бик азалачак. Эчендәге эшләр аны Төркияне онытырга мәҗбүр итәчәк. Өченче, Аталар диңгезе** мәсьәләсендә Италиянең урыны зәгыйфьләнгәч, юнаннар берлән итальяннар арасында гомумән тартышу башланачак. Шул тартышуның ярыкларыннан Төркиягә борынын тыгарга уңай булачак. Менә болар һәммәсе дә безнең бизмәнне авырайтачаклар. Һәммәсе безнең ислам галәменең нәгълэт изагасын[3] арттырачаклар. Без шуңарга да сөенергә тиеш.

Башка хәбәр юк, яңалык юк.

*28 нче июнь*

Бүген сәгать бергә кадәр Германия могаһәдәгә имза итәргә тиеш. Бүген кич берлән Габдулла Чанчуньга*** кайтып җитә.

---

[1] Мәгълүб булганга – җиңелгәнгә.

[2] Юнанлылыкка галәбә чалачак – юнанлыкны җиңәчәк.

* Атина – Италиядәге зур булмаган шәһәр.

** Аталар диңгезе – Эгей диңгезе.

[3] Изагасын – юкка чыгаруын.

*** Чанчунь – Кытайның төньяк-көнчыгышында Гирин өлкәсенең үзәге булган шәһәр.

Бер-ике көннән безгә андагы хәлләр хакында телеграмма булачак. Рус газеталарында безнең Урал сугыш сафы хакында бер хәбәр дә юк. Большевиклар Урал тавы аша чагачакларммы, юкмы, мәгълүм түгел. Безнең халык өстеннән большевик, аның дошман сугышы инде алты мәртәбә үтте, инде фронт башка йиргә күчсә дә ярар иде. Халык бераз тынар, сулыш алыр иде.

Кырга чыгып кердем. Карабогдай әле чыгып йитмәгән, бәрәңгене алып яталар. Арпа-богдай тәмам урылып беткән, дөге, ямь-яшел булып, йирне каплаган. Һавалар ике көннән бирле томанлы. Сирәк-сирәк кенә вак ягмур яугалый. Үзе бик бөркү. Диңгез рәтләп күренмәс дәрәҗәдә томан каплаган. Акча курсы тагы төште. Бүген бер сумы – җиде иен.

*29 нчы июнь*

Бүген кич берлән Харбиннан безне, икемезне дә, чакырып, телеграмма килде. Имза Әмрулла берлән Нияз әфәнделәрнеке. Телеграммада мөһим мәсьәлә өчен күрешергә лязим диелгән. Бик күп нәрсә уйладык. Ни өчен икәнне һичбер төрле кистереп аңлый алмадык. Ихтималларның берсе – безнең паспорт мәсьәләмез. Паспорт алганда Әмрулла әфәнделәр алышкан иде, бәлки бер-бер уңайсызлык булды да, шуның хакында Әмруллага йирле түрәләр интикад ясадылар[мы][1]? Икенче, бәлки Милли Идарә безнең хакта сәфарәтләргә һәм хөкүмәт түрәләренә бик начар иттереп, бер-бер ялган ялганлады[мы]? Улсы бик зур кабахәтлек була инде. Әллә башка бер нәрсә чыктымы? Һичбер аңлап булмый, барырга карар бирдек. Бу тагы эшне бик нык чуалтачак инде.

Кичә Германия вәкилләренең солых могаһәдәсенә имза иттекләре телеграммасы алынды. Димәк, сугыш азгамы, күпкәме бетте. Бәлки, юллар да ачылыр иде, ләкин безгә китәргә кирәк.

Бүген Рамазан гаеде булырга кирәк. Безнең илләрдә ничек бәйрәмне каршы алганнардыр инде? Бөтен ислам галәме зур бер кайгы эчендә. Төркиянең хәле бик авыр. Һиндстан, Афган, Мисыр, Гарәбстан инглиз золымы астында. Шул канлы дүртьеллык сугыш ислам галәменең миллионлап угылларының канын әрәмгә түксә дә, ислам галәме ике якка бүленеп, ике кяфер

[1] Интикад ясадылар – тәнкыйть иттеләр.

дәүләткә өмәгә барса да, шуның нәтиҗәсендә ул үзенең соңгы хокукын да гаиб итте[1]. Аның хәлифәте, үзенең фәкать дин булган эше мең өч йөз елдан бирле һичбер вакыт христианнарның көченә мәгъруз булмаган[2]. Хәлифәт тә Ингелтерәнең кулында уйначыкка[3] әверелеп, исламият байрагы өчен, алты йөз ел бер юлдан үзенең угылларын кызганмаенча, балаларының канын дәрья кадәр агызган төрек милләте үзенең истикъллялын[4], сәяси зур бер кыйсемене югалтты. Ул үзенең истикъллялын, үзенең ислам ханлыгын, үзенең Госманлы императорлыгын – һәммәсен югалтты. Ул Харбин кебек кечкенә төрек ханлыгына әйләнде. Без, Русия мөселманнары, елдан артык дәвам итә торган канлы, эчке сугышта миллиард сумлык мал, милләтемезне югалттык. Меңнәр-меңнәр балаларымызны корбан иттек. Олуг иҗтиһад[5], гайрәт берлән аякка бастырып килә торган милли мәдәниятемезне дошман аягы астында издердек, таптаттык. Хәзер ни бер милли мөәссәсәмез бар, ни бер милли саглам[6] агымымыз бар, ни бер җәрәхәтләнмәенчә калган милли әгъзамыз бар. Сәүдә бетте. Иген чәчү, мал асрау бетте. Уку-укыту тукталды. Оят, матбугат кар астында калды. Халык өмидсезләнде, юлдан язды, куркакланды, зәгыйфьләнде. Зыялысы хулиганланды, имансызланды.

Киләчәк гаедне ничек вә кайда каршы алырмыз, Аллага мәгълүм. Без зур кайгы эчендә каршы алдык. Харбиннан безне, шөбһәсез, сөенечле эш берлән чакырмыйлар. Алла һәр эшне изге итәргә үзе йөрсен.

*30 [нчы] июнь*

Бүген чехословаклардан мәктүб булырга кирәк иде, ни өчендер килмәде. Бүген бик начар йокладым. Кичәге телеграмма башны бик мәшгуль итте. Уйны чыгырыннан чыгарды. Көн буе вак-төяк әйберләр алып йөрдек. Бу китү Япониядән бөтенләй китү булыр дип уйлыймыз. Бәлки, безнең солых сәфәремезнең дә ахыры булыр.

---

[1] Гаиб итте – югалтты.

[2] Мәгъруз булмаган – белдерелмәгән.

[3] Уйначыкка – уенчыкка.

[4] Истикъллялын – бәйсезлеген.

[5] Иҗтиһад – тырышлык.

[6] Саглам – нык.

*1 нче июль*

Бүген солых бәйрәме. Бөтен урам автомобиль берлән тулган. Һәммәсе дә төрле-төрле иттифакъчыларның байраклары берлән зиннәтләнгәннәр. Японча, инглизчә шигарьләр язганнар. Урам тулы халык. Һәммәсе солых булганга шатлыкларын белдермәкче булалар. Диңгездәге япон крейсеры, бер туктамаенча, «яч-юч» туптан ата. Ләкин рух һичбер алай түгел. Һәр кешенең йөзендә шул солыхка бер ышанмау чыккан. Барысының да йөзенә «бар да йөргәч, без дә йөримез» дигән мөһер басылган. Урамдагы автомобиль бизәкләре арасында берсендә дә рус флагы юк. Дөрестен әйткәндә, Русиянең үзенең дә хәзер флагы юк бит.

Мондагы руслар шуларның һәммәсенә бик хурланалар. Без дә, урамга тамаша карарга чыкканда, урамда бик күп чех солдаты очратамыз, сорашамыз. Владивостоктан киләләр. Анда дүртенче эшелонда безнең якын танышымыз, Учредительное собрание әгъзасы, комитетның мәгариф назыйре булып торган Егор Егорович Лазарев* булырга кирәк иде. Чехлардан «бармы?» дип сорыймыз. «Бар» дип җавап бирәләр. Кызулатып, пристаньга китәмез. Әллә никадәр чехтан сорашамыз, кайсы «бар» ди, кайсы «юк» ди. Берсеннән чакыртырга җибәрәмез. Ләкин өйдә юк, чыгып киткән, диләр. Без Йокоһаманың урамы буенча эзләп таба алмагач, сәгать өчкә килермез, дип, хат биреп китәмез. Безнең аны күрәсемез килүнең мәгънәсе бар. Чөнки алар бара торган пароход Америкага бара. Әгәр безне дә алса, безнең мәсьәлә хәл ителгән була. Егор Егорович Харбинда вакытында безгә шулай барырга тәкъдим дә иткән иде, ләкин без ул вакытта үземезнең кәгазьләремезгә ышанып, бик соңга калачак дип кабул итмәгән идек. Хәзер аны очрата алсак, бик кабул итү ягында. Сәгать өчтә тагы барамыз, җидегә кадәр көтәмез. Һаман юк та юк. Ахырдан Лазаревның анда булмавы, пароходта комитетның икенче әгъзасы Брушвитның** гына булынуы мәгълүм була. Аны күрергә тырышамыз. Ул да тугры килми. Иртә

---

[1] Егор Егорович Лазарев – псевдонимы Бровинский (1855–1937), революционер, Бөтенроссия Учредительное собрание делегаты, Комучның мәгариф министры, мөхәррир, мемуарлар авторы.

[2] Брушвит – Иван Михайлович Брушвит (1879–1946), эсер, Учредительное собрание әгъзасы, Комуч хакимиятендә финанс министры.

күрергә булып китәмез. Кичкә безгә Иван, Вафа һәм дә Окубо күрешергә киләләр. Бүген Рамазан бәйрәменең өченче көне булса да, без әрмән, бер япон, бер төрек компаниясендә бәйрәм итәмез. Өченче көнгә иртәнге поездга билет алырга куштык. Бүген кичке телеграммада кытайларның солых могаһәдәсенә кул куймаулары мәгълүм булды. Кытайның Токиодагы сәфире Токио шәһәре башлыгы тарафыннан бирелгән зыяфәткә дә килмәгән. Мескеннәр бер тыпырчынып карыйлар инде. Ләкин шау-шуга башка[1] әле мәгънә чыкмас, ләкин кытай – истикъбальле[2] милләт. Киләчәктә Шәрыкта зур роль уйнаячак.

*2 нче июль*

Бүген озак йөргәннән соң, Гомәр чехлар пароходындагы кешеләрне күреп кайтты. Боларның берсе – Брушвит, икенчесе профессор […], өченчесе Климушкин* икән. Болар өчесе дә – Учредительное собрание комитетында зур роль уйнаган затлар. Хәзер чех булып, солдат киемендә солдат боткасы ашап, Америкага качып китеп баралар, әгәр Себердә тот[ыл]салар, шөбһәсез, атылачаклар. Хәлләре шәп түгел. Аларның хәбәренә күрә, большевиклар Уфаны да, Златоустны да алганнар. Һәм дә, бик кызу иттереп, Себергә таба һөҗүм ясыйлар. Большевиклар үзләренең эчендәге сәясәтләрне үзгәрткәннәр. Бөтен социалист партияләрен легальный дип игълан иткәннәр. Социалистларны кысып тотканнар. Хәтта әсирләргә үзләренең газеталарын чыгарырга да рөхсәт биргәннәр, ди.

Зәки Вәлиди** дүрт полк башкорт гаскәре берлән большевик ягына чыккан, ди. Себер гаскәреннән бик күбесе большевик ягына чыга барадыр, ди. Шуңарга күрә большевикның хәле көннән-көн ныгый барадыр, ди. Бу хәбәрләр дөрестме, түгелме, әлбәттә, мәгълүм түгел. Һәр нә исә, бу кешеләрнең – большевиклар берлән бик озак тартышып, ахырдан үзләренә аерым

---

[1] Шау-шуга башка – «шау-шудан башка» мәгънәсендә.

[2] Истикъбальле – киләчәкле.

* Климушкин – Климушкин Прокопий Диомидович (1886–1969), Бөтенроссия Учредительное собрание делегаты, Самара шәһәр думасы гласные, Комуч эчке эшләр бүлеге җитәкчесе.

** Зәки Вәлиди – Вәлиди (Вәлидов) Әхмәтзәки Әхмәтша улы (Әхмәтзәки Вәлиди Тоган) (1890–1970), сәясәт эшлеклесе, тюрколог, тарихчы, публицист.

хөкүмәт ясап, большевиклар берлән еллар буе сугышкан кешеләрнең – әхвале рухиясе тәмамән большевик ягында. Бу – Колчакның ахмак сәясәте берлән большевикка каршы булган, ягъни никадәр зәгыйфьләнгәненә аяклы дәлил.

Иртәгә китә алмаячакмыз. Чөнки билет булмады. [...] берлән безгә виза алырга ярдәм итсеннәр дип, мәктүб яздык. Һәм дә Америка матбугаты өчен материал җибәрдек.

*3 нче июль*

Бүген вак-төяк әйберләр алгалап үткәрдек. Иртәгә[гә] билет алдык. Насыйп булса китәмез. Бүген акча курсы тагы төште. Бер сумы – алты цент. Себер акчасын бөтенләй алмыйлар. Омскида тагы үзгәреш бар, диләр. Колчак берлән Дутов* тартыша, имеш. Ни булса да, Колчакның вазгыяте бик начарланды булырга кирәк.

*4 нче июль*

Бүген, иртүк торып, поездга киттек. Поездымыз тугыз сәгать тә җиде минутта Йокоһама стансасыннан[1] китте. Бик кызу бара. Болай барганда, иртәгә иртәнге пароходка Фузанга барып җитәчәк.

Көн бик бөркү, шуның өстенә бик ягмурлы. Монда әллә нинди үзенә махсус йылы вак кына ягмур ява. Болыт шулкадәр түбән, ялганлый төшсәң, кул сузсаң, җитәчәк. Дөрест тә, ләкин таудан түбән поезд тау буйлап барганда тауның итәгенә генә яткан, башына менеп җитмәгән бик күп болыт агымнарына очрыймыз. Хәтта бер йирдә, тау өстенәрәк менгәч, поездымыз ярты сәгать чамасы болыт эченнән бара. Көн шулкадәр бөркү. Вагонда ятып торамыз. Кичкә таба сәгать җиделәрдә безгә японча әллә нәрсә килеп сөйлиләр. Ләкин без аңламыймыз. Бераздан безгә бер инглиз: «Поезд Симоносекига** бара алмый. Болыт, ягмур булган, шуның өчен теләсәңез, Кобеда*** каласыз, теләсәңез,

---

* Дутов – Дутов Александр Ильич (1879–1921), Оренбург казаклары атаманы, генерал-лейтенант.

[1] Дөресе: станциясеннән.

** Симоносеки – Япония дәүләтенең Ямагути префектурасында урнашкан шәһәр.

*** Кобе – Япония дәүләтенең Хиого префектурасында урнашкан шәһәр.

аннан ике сәгатьлек йирдә Окаямада* туктыйсыз. Әүвәлгесе зур шәһәр булганга, номерлар, отельләр күп. Икенчесе – япон шәһәре генә, Европа отельләре юк», – ди. Без, төрле-төрле уйлаганнан соң, Окаямага барырга буламыз. Кызу ягмур астында сәгать төнлә 12 ярымда Окаямага төшәмез. Вокзалда һичбер төрле русча белгән түрә юк. Шалтыр-болтыр белгәнемез берлә инглизчә сөаль бирәмез. Аңарга японча җавап бирәләр. Ахырдан бер түрәгә бераз инглизчә сөйләп аңлатамыз. Юлны өч йирдән ягмур юган. Поезд Симоносекига бара алмый. Ләкин иртәгә таң берлән сәгать биштә пароход Симоносекига китә. Шулай булгач, без номерга барып тормаенча, вокзалда гына көтәргә буламыз. Сәгать бишкә кадәр көтәмез. Алтынчы була. Тагы сорыймыз. Поезд да сәгать унда китәчәк, пароход юк, диләр. Аңарга ышанмаенча, икенчесеннән сорыймыз. Поезд да сәгать дүрттә китәчәк, ди. Шуннан соң боларның сүзләренә өмитемез юклыкны күреп, тагы белешергә керешәмез. Мәгълүм була ки, тимер юл, поездның кай вакыт китәчәге мәгълүм түгел, дип игълан иткән, шуны белгәч, номер эзләргә тотынамыз. Ерак түгел бер япон өе табып, шунда керәмез. Камыш намазлыклар, бүлмәнең идәненә пычрак юрганнардан урын салалар. Баш астымызга озынча йомры мендәрләр бирәләр. Пальтоларымыз берлән пычрак юрганнарны томалап, йокларга ятамыз. Сәгать уннарда торып, тагы белешергә китәмез. Тагы кырык төрле хәбәр. Берсе кич сәгать җидедә генә, ди. Берсе сәгать унда, берсе сәгать унбердә, берсе иртәгә иртә берлән, ди. Берәр ресторанга кереп, чәй эчәргә утырамыз. Инглизчә язылган менюсыннан йомырка, күмәч, май, чәй сорыймыз. Элгәре май китерә. Аннан чирек сәгатьтән йомырка китерә. Аннан чирек сәгатьтән әллә нинди сары бер су китерә. Аннан чирек сәгатьтән икмәк. Моңарга ачу килеп, йөдәп беткәч, буфетка үземез барып, күрсәтеп алып, ярты-йорты чәй эчәмез, тагы белешергә китәмез. Анда беразрак русча белә торган япон офицерына очрыймыз. Ул юл бик нык бозылган, ягмур һич туктамый. Поезд өч-дүрт көн көтәчәк. Шуның өчен мин Кобега китәм, ди. Без дә китәргә буламыз. Һәм дә сәгать өч ярымда Кобега китәмез. Көн буе ягмур ява. Поездымыз бертуктамаенча

---

* Окаяма – Япония дәүләтенең Окаяма префектурасында урнашкан шәһәр.

су диңгезеннән йөзә. Уң як, сул як су берлән капланган. Күктән ягмур чиләкләп актарыла. Дөге кырлары һәммәсе су эчендә. Иң зур дөге саплары да күренми. Без кичә үткәндә коп-коры ком булган елгалар зур елгага, Иделгә әверелгәннәр дә күтәрелеп агалар. Әллә никадәр авылдан агач әйберләр агызалар. Шуның өстенә һава шулкадәр эссе, бөркү. Тиргә бөтен тәнемез баткан. Сәгать сигездә Кобега киләмез. Билетлар берлә йөдәп бетеп, бернәрсә белешә алмагач, бер япон номерына китәмез. Кобе утка чумган. Японнар бәйрәм итәләр, урамда манифестация. Иллалла[1] номер гына табып, сасы пычрак япон бүлмәсенә кереп йирләшәмез. Ашаганымыз, эчкәнемез юк. Өстемез баштанаяк су, тир эчендә. Үземез арыган, йөдәгән, йончыган.

Пычрак юрганнарга сузылып ятып, чәй һәм йомырка китерергә кушамыз. Ике сәгатьтән соң сасы йомырка, пычрак чәй эчеп ятып йоклыймыз. Иртәгә Симоносекига барып булачак, диләр. Безгә номер хуҗасы билет алышырга булды. Бакалым[2], ни булыр.

*6 нчы июль*

Бүген иртүк торып, юынганның соңында пароход мәсьәләсенә керешәмез. Русча белә торган япон вәгъдәсенә килми. Аны бик тынычсызланып көткәннең соңында, вакытыннан ике сәгать кичегеп килә, пароход сәгать уникедә китә. Ләкин икенче класста да, беренче класста да урын юк. Урын фәкать өченчедә генә бар. Дүртенчедә булса да, ярый алган. Бездән билет акчасын алалар, ләкин япон юлларына нисбәтән бик кыйммәт тоела. Шуннан җентекләп сорый башлагач, бездән хата алганнары мәгълүм була. Тәхминән[3] бездән биш мәртәбә артык хатаән[4] алганнар. Япониядә хәзер мондый хатаәннар булгалый башлаган. Мең бәла берлән пароходка кереп утырамыз. Урынымыз иң асткы катта, трюмда. Анда биниһая эссе, эчәргә сорыймыз – бирмиләр. Икенче классның буфетына керәмез, өченче класс мөсафирына бирмимез, диләр. Менә пароход китә, көн дә ачыла. Ике яклап

[1] Иллалла – уртача.
[2] Бакалым – күрербез.
[3] Тәхминән – чама белән.
[4] Хатаән – ялгышып.

ата[1], аталар. Берсе ямь-яшел урман берлән капланган, берсе яп-ялангач көенчә күккә таба очланып, бишек башы кебек мен-гән, берсе, уңмаган кешенең борай кибәне кебек, уңга да сулга да бүрселеп чыккан. Диңгез кояшка каршы елмая, көлә. Аның шук балалары бертуктамаенча бииләр, уйныйлар, йырлыйлар. Бөтен тарафтан ак җилкәнле каеклар, баржалар канатларын җилпердәтеп-җилпердәтеп йөзәләр, очалар. Кечкенә-кечкенә дулкыннар арасында әле иелеп-бөгелеп чүгәләр, әле һавалы аккош кебек канатларын җәйрәтеп, башларын күтәреләләр. Һавалы күкрәкләре берлән кояшка каршы торалар. Без, үземезнең ике көнлек мәшәкатьләрне онытып, табигать алдында баш иеп рәхәтләнәмез, тынычланамыз.

Менә кич. Ай моңлы гына яктысы берлән диңгезне сөя. Ул киң багана нурын җибәреп, диңгезнең төбендәге яшерен җаннарны, диңгезнең эчендәге гизле[2] серләрне укымакчы була. Диңгезнең сакчылары, үзләренең меңнәр, миллионнар елгы серләрен читләргә күрсәтмәс өчен, диңгез эченә таулар чыгаралар, түбәләр ясыйлар. Диңгезнең өне күренүен бетерер өчен, аны шадраландыралар. Безнең пароход әйтеп бетермәслек тынлык, муллыкны ертып, һаваланып йокларга яткан диңгезне ерып, алга таба бара...

Төнне без капитаннан камыш намазлыклар сорап алып, баш очымызга пальтоларны салып, йокларга ятамыз. Ике яктагы ачык тәрәзәләр аша диңгез һавасы безне сөя-сөя йоклата. Әнә таң сызылып килә. Диңгезнең әнә теге очында зур куәтле бер кызыл нәрсә чыгарга теләп маташа. Берничә карт япон чыкканнар да кояш чыгышына карап басканнар. Кулларын берсенә-берсен кушып, безнең догамыздагы кебегрәк вазгыятьтә тотканнар, күзләрен кояш чыгышына текәгәннәр. «Һек» дип кычкыралар да, кулларын берсенә берсен бәреп, шарт иткән тавыш чыгаралар. Аннан әллә нинди сүзләр мыгырдыйлар. Шул эшне берничә мәртәбә кабатлыйлар да куллары берлән йөзләрен сыйпап, борылып китәләр. Болар кояшка гыйбадәт итәләр.

Безнең иске төрек бабайлар ничек кояшка гыйбадәт иткән булсалар, болар да шулай гыйбадәт итәләр. Японча күк «Тең»,

[1] Ата – утрау.
[2] Гизле – яшерен, серле.

«Тәң», безнең төркичә «Тәк», «Так», искечә «Тәңре», хәзерге «Такре» шуннан алган «Таңре», «Таң ире», ягъни кояш.

Юынырга төшәм. Юыну бүлмәсе ир, хатын берлән тумтулган. Ханымнар һәммәсе дә билләренә кадәр тәннәрен ачканнар. Күкрәкләрен, муеннарын юалар. Бөтен сары тәннәрен акшарлыйлар, ирләре дә гаурәт йирләрендә генә янчык кебек нәрсә калдырганнар да бөтенләй ялангачлар. Кулларын, битләрен юалар. Берсенә-берсе карамый да, илтифат та итми. Мин боларның шул гадәтләренә, шул безнең канга сеңгән «оят», «оят булу» дигән мәгънәнең булмавына гаҗәпкә калдым. Мин дә күлмәкләрне салмаенча гына юынырга керәм. Күршемдәге бер ялангач япон хатыны минем кабыргаларымны тотып карый да икенчесенә әллә ни сөйли, көлешәләр. Миңа ишарә берлән «син бик таза» дигәнне аңлаталар. Икенчесе дә килеп тотып карый. Бусы да шул фикердә кала булырга кирәк. Анысы «һу» дип көлә. Тагы японча әллә ниләр сөйлиләр, көлешәләр. Мин японча «вакари масен» гына дип, аңламыйм дигән сүз, җавап бирәм. Үзем тизрәк пароход өстенә чыгам. Анда ярым ярты киенгән япон ирләре, хатыннары – барысы да авызларына теш щеткасы капканнар да тешләрен ышкып йөриләр. Шулкадәр күп халыкның бердән зур ихлас берлән тешләрен ышкынуы бу манзарага бер гыйбадәт кыяфәте бирә. Бая гына кояшка каршы гыйбадәт иткән карт японнарны хәтерләтә. Аерма шунда: тегеләр – картлар, болар – яшьләр. Тегеләр иске гадәткә табыналар, болар, яңа дөньяның тигез хокуклы гражданнары булыр өчен, бөтен вөҗүдләрендәге бердәнбер ак әгъзалары аклыгына шөкеранадан гыйбадәт итәләр. Аклыгына аз гына да зарар килмәсен өчен, аны сәгатьләр буе юалар, ышкыйлар.

Менә Симоносеки күренә. Пароход та туктый, ләкин безне ни өчендер, икенче атага төшерәләр. Без Фузанга* чыгачак пароходка өлгерә аламызмы, юкмы дип, кырык кешегә мөрәҗәгать итәмез. Русча сорыймыз, инглизчә сорыймыз, һичберсеннән тугры бер мәгълүмат ала алмыймыз. Борчыламыз, безнең бүген дә көнемез әрәм булачакмы? Ул гына түгел, безнең әйберләремез

* Фузан – Пу-сань – Корея ярымутравының көньяк-көнчыгышындагы ачык сәүдә порты.

һаман юк. Окаямада ике чемодан әйберне калдырдым инде. Боларын да монда калдырабызмы? Сәгатьләр үтә. Менә безнең әйберләр килә. Таможняда әйберләрне өстән генә карыйлар да безне Симоносекига чыгачак пристаньга илтәләр. Анда әле пароход китмәгәнен һәм дә бер сәгатьсез китмәячәген белеп, бераз тынамыз. Сәгать унберләрдә кереп урнашамыз, ашаганымыз, эчкәнемез юк. Һава бөркү, эссе. Тәннән тир ага. Ванна алмакчы буламыз. Ванна 2 нче класста юк. Беренчене бирмиләр. Ахырдан японнар өчен ясалган, гомумхалык бергә файдалана торган агач ванна күрсәтәләр. Без тирләп, сасып беткәнгә, аңарга да разый буламыз. Бер япон чыгуга, мин кереп китәм. Миннән соң ике япон хатыны килеп, ишекне ачалар, әлләниләр сөйлиләр. Мин куллар берлән «юынам» дип сөйлим, тагы әллә ниләр сөйлиләр дә кермиләр. Мин ваннасына кермәенчә генә юынып бетереп киенеп чыкканда, Гомәр әфәнде керә. Ул юына башлый. Мин чыкканны күргәч тә, япон хатыннары кереп, тишенергә[1] тотыналар һәм дә Гомәр әфәнде янына барып, ялангач калып, ике японка юыныргa тотыналар. Бер япон тагы керергә теләп, кием салырга урын юкка эче пошып йөри.

Пароход китте. Һава бик җилле. Пароходны йомычка кебек уйната. Мин, диңгез авыруыннан курыкмаганга, пароход өстендә калдым. Бик күп кеше яткан: кайсы йоклый, кайсы диңгез тибрәтүеннән сакланыр өчен ятып тора. Безнең пароход бик кечкенә булганга, дулкын бик куәтле булганга, ул буйга да, иңгә дә тирбәнә. Кайвакытлар бөтенләй дулкын астында кала кебек була. Дулкыннар пароход өстенә менеп, йөгереп төшәләр. Мин һаман бер почмактарак коры кала барам. Менә бер дулкын икенчесен куып җитте, алар бер-берсен кочаклаштылар. Пароходка килеп бәрелделәр. Мине су башымнан аягыма кадәр коендырды. Астымдагы урындык шуып китте. Мин суга батып, киптерер өчен бүлмәгә кереп, урынга яттым. Өшегән тәнне елытыр өчен, юрган ябындым. Диңгезнең тирбәнүе арасында бер калкып, бер уянып, берәр сәгать вакыт үткәрдем. Менә баш әйләнә башлады, күңел болганды, косасы килә башлады. Һавага чыгып та өлгердем, косып та җибәрдем. Тагы җиңеләеп китте. Ләкин тулкын[2]

[1] Тишенергә – чишенергә.
[2] Тулкын – дулкын.

һаман көчәйде. Мин тагы һавада калдым. Бу – минем беренче мәртәбә диңгез хасталыгына тотылуым. Мин моңарчыга кадәр ун мәртәбәләп диңгездә булдым, берсендә дә космаган идем. Бу юлы, ни өчендер, аз булса да костым. Ул вакыт ябыграк идем, хәзер симезрәк, бәлки шул ярамый торгандыр. Диңгез симез кешене яратмый торгандыр.

Русның ахмаклыгына беренче зарар орган Цусима атауларын* үтеп, без Фузанга бик вакытлы килеп җитәмез. Әйберләремез[не] тагы бер мәртәбә таможня чиновнигына күрсәткәннең соңында, сәгать 11 ләр кич берлән ятамыз.

*8 нче июль*

Бүген иртәдән бирле без Корея буйлап барамыз. Кыр тулган халык. Һәммәсе, без әүвәле күргән кебек, ак киемнән. Ул вакытта бу халык аграк күренгән иде, хәзер һәммәсе кояшка пешкән. Битләре, тәннәре каралар – төн кебек булган. Кырда эшли торган ирләрнең барысы да билгә кадәр бөтенләй ялангач. Хатыннар тәмам ук ялангач булмаса да, юбкалары берлән кофталары арасындагы йир берәр сөям** кадәр ачык. Шуннан имчәге акаеп чыккан, аркасы ачылган. Болар шулай чыгып, шулкадәр озак кояшта торган булырга кирәк. Һәммә йире кап-кара. Балалар, биш-алты яшьлекләре, япа-ялангач. Унике-унөч яшьлек имчәге кабарып килә торган кызлар билләренә түбән генә бер чүпрәк бәйләгәннәр. Кырдагы эшнең хәзергесе берсе – дөге сугару, икенчесе – аны утау һәм дә төбен йомшарту. Ирләр төрле ысулда кораллар берлән үзләренең җыйнаган суларын дөге түтәлләре эченә коялар. Хатыннар тездән су эчендә дөге утыйлар һәм дә куллары берлән, китмән берлән төпләрен йомшарталар. Монда әле урылып бетмәгән бодай берлән солы очраштыргалый. Язгыга караганда хайван да күбрәк күренә. Ләкин иң күбесе сыер, аз гына ишәк, аннан да аз ат. Көн буе шул бертөрле эш, манзара.

---

* Русның ахмаклыгына беренче зарар орган Цусима атаулары – Япон диңгезендәге Цусима утравында 1905 елның 14–15 нче маенда вице-адмирал З.П. Рождественский җитәкчелегендәге Россия Тын океан флотының 2 нче эскадрасы адмирал Хэйхатиро Того җитәкчелегендәге Япония Император флоты тарафыннан җиңелүгә дучар була.

** Сөям – аршынның чирегенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге.

Болар, мескеннәр, тамак туйдырыр өчен, бик зур мәшәкатьләргә керергә мәҗбүрләр. Хәяттан алган гамьнәре шул мәшәкатьләр, зәхмәтләргә торырлыкмы, түгелме, анысын Алла белә. Кич берлән без мәгълүм Ялу елгасын* үтәмез. Өстендәге тимер күпер бик зур. Безнең Идел күпереннән кыска булмаска кирәк. Бу елга русларның Шәрыкка таба борын сузуларында беренче киртә һәм дә рус гаскәре Ялу буенда беренче мәртәбә Япониягә каршы мәгълүм булды**. Елганың теге ягында Аньшунь*** дигән шәһәрдә безнең әйберләремез[не] тагы таможнядан үткәрәләр. Бу юлы инде Кытай таможнясы. Хәзер без Маньчжуриягә кердек. Анда әле сүздә генә булса да Кытай хөкеме йөри. Мин үземнең Окаямада калган ике чемоданым хакында мәгълүмат сорыйм. Монда Аньшуньга килеп алырсың, диләр. Озак сөйләшкәннең соңында, мин ачкычымны калдырсам, монда таможняда каралып, Чанчуньга**** җибәрергә разый булалар. Мин бер япон түрәсенә ачкычымны биреп китәм. Аллага тапшырдык инде. Әйберләрне алып буламы, әллә югаламы?

*9 нчы июль*

Без Мукденда ат алыштырамыз. Бүген, насыйп булса, кич берлән сәгать сигезләрдә Чанчуньда булачакмыз. Анда инде берничә телеграмма бирдек. Безне көтүче булса, ни өчен безне чакырганны аңлаячакмыз. Әгәр килгән булмасалар, тагы берничә көн билгесезлек эчендә пошыначакмыз, кайгырачакмыз. Монда халык Кореяга да, Япониягә дә тәмамән башка булыр. Маньчжурлар – бик таза, зур халык. Төсләре дә японга да, кореяга да караганда бик матур. Монда тәмамән төрек кыяфәтле, зур Кавказ борынлы халык бик күп. Боларның арасына бик күп төрек каны катышкан булырга кирәк. Гомумән, Шәрык халыклары арасында иң ямьсезе, иң мәхәббәтсезе – японнар. Кыска буйлы, ыржайган авызлы, кылый күзле япон кыяфәте безнең хисе

---

* Ялу елгасы – Төньяк Корея белән Кытай чигендәге елга.

** Рус гаскәре Ялу буенда беренче мәртәбә Япониягә каршы мәгълүм булды – 1904 елның 18 нче апрелендә Ялу елгасы ярындагы Цзюляньчэн шәһәре янында рус һәм япон гаскәрләре арасында булган сугыш турында сүз бара.

*** Аньшунь – монда Кытайның Аньшань шәһәре күздә тотыла булса кирәк.

**** Чанчунь – Кытайның төньяк-көнчыгышында Гирин провинциясенең үзәге.

нәфасәтемезне шулкадәр мыскыл иткән. Безне аның башыннан аягына кадәр акшарланган йөзле хатын[ы] шулкадәр туйдырган. Безнең күзләргә маньчжурлар да бик матур кебек күреләләр. Бүген, ихтимал, безнең сәфәрнең кая таба борылуы тәмамән ачылачак. Биш ай ярым дәвам иткән минем солых сәфәрем бәлки тәмамән туктаячак. Бакалым.

*10 нчы июль*

Без кичә кич берлән Чанчуньга килеп җиттек. Монда безне Нияз әфәнде*, Гыйнаять хәзрәт**, Габдулла Газиз*** көтеп торалар икән. Безне чакырган мәсьәләләре бик кечкенә, вак, сәяси тәрбиясезлектән килеп чыккан бернәрсә генә булды. Аны ни дип тә тәгъбир итәргә[1] хәл юк. Кыскасы, моннан гыйбарәт. Нияз әфәнде үз эше берлән Читага барганда, аны Семенов**** берлән күрештергәннәр. Семенов безнең мөселман эшләре берлән бик танышасы килә һәм дә безнең берлән мөнәсәбәткә керешеп, мөмкин булса, бергә хәрәкәт итәсе килә икән. Безнең Япониядәлегемезне белә. Себер мөселманнары, Кытай мөселманнары хакында бергәләшеп, бер эш эшләп булмасмы дип уйлый икән. Шуңарга күрә безне күреп сөйләшәсе килә икән. Шуның өчен Нияз әфәндегә безнең берлән барып сөйләшергә үтенгән һәм дә юлына акча да биргән. Ләкин Нияз әфәнде үзенең шәхесене безнең икемездән дә кадерлерәк дип ышанганга, безне телеграмма берлән чакыртканнар. Сөйли торган эшнең артында японнар да барлыгы мәгълүм була. Бер мәсьәләне мөзакәрәгә[2] куеп,

---

* Нияз әфәнде – Нияз Максуди, Троицк каласында мәдрәсә мөдире. 1914 елда Нью-Йорк университетының тәгълим-тәрбия факультетында укыган.

** Гыйнаять хәзрәт – Салиәхмәтов Гыйнаятулла (1889–1926), Харбин мәчете имамы һәм мөдәррисе.

*** Габдулла Газиз – Газизов Габдулла Кәлимулла улы (?–?), журналист. Оренбург янындагы Саракташ авылында туа. Мисырга китеп, Бәйрутта көллият тәмамлап кайткач, Троицк шәһәрендә Яушевлар мәдрәсәсендә укытучы була. Революциягә кадәрге татар вакытлы матбугатында актив язышa. Революциядән соң аклар белән китеп, Харбин шәһәрендә «Мең ел» дигән газета чыгаруда катнаша.

[1] Тәгъбир итәргә – аңлатырга.

**** Семенов – Григорий Михайлович Семенов (1890–1946), казак атаманы, Ерак Көнчыгыштагы Аклар хәрәкәте эшлеклесе, генерал-лейтенант.

[2] Мөзакәрәгә – бәхәскә.

шундый тарызда[1] карарлар ясыймыз: беренче, Семенов берлән мөзакәрәгә керешергә ярый. Милли сәясәтне йөрткәндә ноктаи назар[2] фәкать милләтнең мәнфәгате генә булырга кирәк. Шул милли мәнфәгать өчен тартышуда кем ярдәм итсә, шул ярый. Семенов сәяси авантюрист булса да, башка сәясәт әрбабы[3] да, Шулай Колчак* берлән кечкенә генә мәсьәләләр өчен мөзакәрәгә кердек. Ул да бит шул авантюристның берсе һәм дә безнең өчен милли ноктаи назардан зарарлысы. Этсез куян тотып булмау кагыйдәсенә бинаән, мөмкин булса, сөйләшергә булдык. Сөйләшәчәк мәсьәләмез моннан гыйбарәт: Семеновның сәяси даирәсендә безгә бер шәһәр бирелсен, шунда без үземезгә махсус төрек-татар гаскәре төзик, аның тәшкилятына[4] кирәкле коралларны Семенов васитасы берлән японнар бирсен. Шул гаскәр берлән без Кытай Төркестанына чыгачакмыз. Япония, Семенов шул хәрәкәтемездә безгә ярдәм итсеннәр. Һәм дә безнең тәшкилятымыз фәкать шул үземезнең милли эшемез өчен генә тотылсын. Икенче, безнең тәшкилятымыз гаскәремезнең кемнәрдән мөрәккәб[5] булып, һәммәсе дә үз мәсьәләмездә генә булсын. Менә шул мәсьәләләр хакында Семенов берлән фикер алышырга без разый. Шуннан соң хәзер үк Семенов берлән барып сөйләшү кирәкме, бераз соңракмы мәсьәләсе куелды. Ул мәсьәлә безнең солых сәфәремезгә барып төртелә. Безнең солых сәфәремез, алты ай дәвам иткәннең соңында, Япониянең диңгезенә терәлде, калды. Шуны хәзер бетте, тәмам булды, нәтиҗә чыкмадымы, дип хәл итәргә кирәк[ме]? Әллә бу бер манигъ кына, моны кичәргә кирәк дип, яңадан тырышырга кирәкме? Бу мәсьәләне хәл итү җиңел түгел. Инглиз сәфарәтханәсенең безгә рәсман биргән рәд[6] җавабында, безнең Омскидан алган җава-

[1] Тарызда – ысулда.

[2] Ноктаи назар – караш.

[3] Әрбабы – иясе.

* Колчак – Александр Василий улы Колчак (1874–1920), Россия хәрби һәм сәясәт эшлеклесе, флот башлыгы, адмирал, океаннарны өйрәнүче галим. Кара диңгез флоты (1916–1917) белән җитәкчелек иткән. Аклар хәрәкәте юлбашчысы.

[4] Аның тәшкилятына – аны төзү өчен, оештыру өчен.

[5] Мөрәккәб – оешкан.

[6] Рәд – кире кагу.

бымызда Гаяз Исхакыйны Милли Идарә белми, дип әйтелгән. Әгәр бу, хакыйкатән, тугры [булса], Милли Идарә бөтен әгъзалары берлән яисә аның берничә кешесе провокация ясаганнар, милләтнең сайланган вәкиле хакында ул милләтнең вәкиле түгел дип барып әйткәннәр, милли җинаять эшләгәннәр, бөтен хәрәкәтемезгә каршы хыянәт иткәннәр. Бу уй дөрест чыкса, моннан соңгы минем һәр хәрәкәтем шул хыянәткә барып төртелеп торачак. Моннан котылырга бер генә юл бар, ул да Милли Идарәдән шул сәфарәтләргә яңадан мөрәҗәгать иттерү. Без моның хакында берничә хат һәм телеграмма яздык. Ни Милли Идарәдән, ни махсус кешеләрдән бер җавап килмәде. Анда барып, тагы шул мәсьәләне казынып йөрергә дәртем дә юк һәм дә аның өчен үземне Колчакка бирергә ярамый да, теләгем дә юк. Бөтен тирә-юньнән килгән манигъларга башка[1] яшь милли мөәссәсә дә шундый хыянәттә булса, нинди эш эшли аласың инде. Бу фикергә караганда буны солых сәфәрене бетте дип хөкем итәргә, шуның хисабын биреп, хосусый кеше буларак үзеңә юл алып, эшкә керешергә кала. Әгәр теге инглиз писаре ялганлаган булса, ул вакытта безне җибәрергә теләмәү бик зур бер юлга куелган була. Сөйли торгач, Омскига (хәзер Милли Идарә Уфадан качып, Омскига киткән, имеш) озын мәктүбләр берлән бер кеше җибәрүне лязим табамыз. Шуны эзләргә хәзер генә Әмрулла әфәндегә кушамыз. Бүгеннән үк тагы берничә телеграмма бирәмез. Семенов берлән сөйләшүне бераз кичектерәмез. Бәлки, җавап килеп чыкмасмы? Ул вакыт аяк-кул баглы булмас иде.

Бүген мин үлчәндем. Сиксән дүрт кило килдем. Япониядә йөреп, алты кило кимегән, ягъни 15 кадак. Мигъдәм начар, рух төшенке, шулар зарар иткәндер.

*11 нче июль*

Минем Окаямада калган чемоданнар бүген килде. Эчендә бик күп әйбер бар һәм дә яңлыш коелып калган уналты мең сум акча да бар иде. Һәммәсе сау-сәламәт килделәр. Японнар[ның] бу хасыятьләрен тәкъдир кылмаска мөмкин түгел. Көн буе теге мөзакәрәләр дәвам итте. Ахырдан Нияз әфәнде Кытай эченә барып кайтырга, Габдулла берлән хәзрәт китәргә дә безгә кеше эзләргә,

[1] Манигъларга башка – киртәләрдән башка.

безгә Чанчуньда көтеп торырга, аннан соң Харбинга нелегально гына кереп, бәгъзы бер хәрәкәтләр ясарга булынды. Кич берлән безнең хатларны алып, Харбинга киттеләр.

*12 сендә*

Яңа мәсьәлә – Колчак кырык өч яшькә кадәр мобилизация игълан иткән. Моңарга мин дә, Гомәр* дә керә. Һәм дә Гомәрне алмаслар да. Минем китүемдә шөбһә юк. Бу эш бөтен планнарны боза. Кичә хәл иткән эшләрне тагы чуалта. Аптырап каламыз. Күренүемнән, 19 нчы июль, ягъни бер атна монда торсак, япон полициясе тотып бирү ихтималы бар. Кытайга китсәк, Омскига кеше җибәрү, Владивостокка барып казыну эшләре юлда калачак. Аннан башка солых сәфәрен бетерү лязим табылса, безнең эшемезнең икътисади ягын да бер юлга кую кирәк. Чөнки акчалар һаман әле чуалчык хәлдә. Кайберсе николаевский, кайберсе сибирский**, кайберсе керенкаларда. Шуның өчен бик тиз берничә эш эшләп калырга кирәк, яисә күз йомып, Харбинга барырга кирәк, яисә Әмрулланы*** чакырырга кирәк. Харбинга бару безне заграничный паспортсыз калдыру ихтималы булганга, Әмрулланы чакырамыз. Эш ни булып бетәчәк. Тик безгә бу сәфәр бу кадәр тискәре килде. Милләтнең хокукын Колчакларның золымыннан коткарыр өчен, чит милләтләр алдында вәкил булып киткән кеше монда, имеш. Колчакның шул золымы дәвам итсен дип, аның коралы була, имеш. Солдат булып, Колчакны падишаһ ясарга хезмәт ит, имеш. Аллага тапшырдык, ни булыр. Без, шул икътисади мәсьәләләремезне хәл итәр өчен, Әмрулланы чакырып, хат яздык. Ул килсә, бәлки берәр карарга килермез. Бүген Нияз Кытайга китте.

*13 нче июль*

Бүген берни дә булмады. Кызулыктан, тузаннан йончып, өйдә яттык. Монда хәзер бик мәгънәсез. Һәр эш начар. Кешесе юк. Эш

---

* Гомәр – Гомәр Терегулов турында сүз бара.

** Сибирский – 1918 елның 18 нче ноябрендә Себердә Россия хөкүмәтенең идарәчесе итеп игълан ителгән адмирал Колчак хөкүмәтендә чыгарылган кәгазь акчаны шулай атап йөрткәннәр. Халыкта Колчак акчасы дип тә йөргән. Шул елларда кулланылышта йөргән николаевский, керенка дип аталган акчалар арасында соңгысы кыйммәте ягыннан иң түбән була.

*** Әмрулла – Әмрулла Агишев – Харбин Милли Идарәсе рәисе.

юк. Хәят кыйбат. Шуңарга күрә йә Харбинга керергә кирәк иде, яисә еракрак китәргә. Харбиннан әле беркемнән дә мәктүб юк. Мулла, кайткач та, хат язарга булган иде. Габдулла Газиз Милли Идарә берлән бергә килгән Яушевтан* сорашып, бар мәгълүматны җыеп җибәрергә булган иде, киттеләр дә баттылар. Гомумән бит, безнең эшләр һәммәсе шулай: үз алдыңда һәрнәрсәне эшләргә булалар да, күздән югалдың исә, кыл да кыймылдатмыйлар, яисә шуны сүтәргә тотыналар. Җәмәгать эше җәмәгатьнең иштиракы берлән булмаганда, берни чыкмый. Кечкенә генә бер мисал: инглиз матбугатына бирер өчен, бер русчадан мәкаләне инглизчәгә тәрҗемә иттергән идек. Шуны карап, мокабәлә ясап[1] чыгарга Габдулла Газиздән үтендек. Шул ике сәгатьлек эшне эшләмәде. Инглизчә беләторган кешеләремез бер-ике данә булып, алары да шулай милли саботаж ясаганда, ничек эшләргә кирәк? Мәҗид мулла пәриләренә таяныргга кирәкмени?

*14 нче июль*

Берни дә юк. Бераз ягмур яуды да һавалар матураеп китте. Бүген газета да юк. Кичәге хәбәргә караганда, большевиклар Екатеринбургка һөҗүм итәләр.

*15 нче июль*

Бүген иртүк Әмрулладан мәктүб алдык. Шимбә көн киләм, дигән. Шуңарга күрә аны шактый озак көтәргә тугры киләчәк. Монда һичбер эш юк. Безнең бу сәфәрнең уннан тугызы көтәргә китте. Хат көт, җавап көт, телеграмма көт, иптәшләрне көт.

Монда бүген бик зур тантана берлән Гириннан** Кытайның зур бер түрәсе килде. Аны каршы алырга бөтен гаскәри түрәләре җыелган. Вокзал янына гаскәри караул куелган иде. Арбасына утырып мәйданга чыгуга, атлы гаскәр бик күп сыбызгыдан кычкырта башладылар. Чыр-быр килеп зур тавыш купты. Миңа кечкенә вакытта яңа сыбызгылар тотып, төркем малайлар берлән Сабан туеннан кайтканны хәтерләтте. Бу кем килеп, ни була дип сорагач, кытайлар, большой капитан Хилин, диләр. Бу кемдер

---

* Яушев – Яушев Латыйф – Харбинда Милли Идарәнең финанс комиссиясе әгъзасы, татар сәүдәгәре.

[1] Мокабәлә ясап – чагыштырып.

** Гирин – Кытайның төньяк-көнчыгышындагы өлкә.

инде? Анысын Алла белә. Ләкин бу Гирин губернаторының бер түрәсе инде. Бу арада Гирин губернаторы берлән Мукден губернаторларының аралары ачылып тора. Икесе дә Маньчжуриягә генерал-губернатор булырга тырышалар. Бу эшне низамлы[1] рәвештә хөкүмәтләре берлән аңлашып эшләп булмый, күрәсең. Ике губернатор да берсе берлән берсе сугышып, мәсьәләне хәл кылырга уйлаганнар. Гирин губернаторы Япониягә бик күп йир саткан, гомумән, Япония берлән эш итә, ди. Шуңарга күрә Кытай әфкяре гомумиясе үзен яратмый, ди. Мукден губернаторын халык ярата, ди. Кыскасы гына, боларның берсе Кытайның истикълялын[2] саклау тарафында булып, Япониягә дошман вазгыятьтә булырга, берсе, Кытайның истикълялына уртанчы булмаенча, Япония берлән эш күрү тарафында булырга, ягъни шул ике агым, тартыша-тартыша, сугышка барып җитәләр булырга кирәк. Моннан нинди нәтиҗә туачагы мәгълүм. Гирин губернаторы җиңсә дә, Мукден губернаторы җиңсә дә, Япония, шул сугыштан файдаланып, бармагын зурраграк тыгачак. Бәлки, Маньчжуриянең аерым бер дәүләт булуына кадәр эшне җиткерәчәк. Монда сәясәт бик кызык эшләнә. Европаның ялган сәясәтен Япония монда Кытайга нисбәт итә икән. Бакалым[3], ни булыр.

Мулладан хат булмады.

*16 нчы июль*

Бүген яңа бер эш тә юк. Мулладан бер дә мәктүб булмагач, кичә үзем хат язып җибәрдем. Теге телеграммаларны җибәргәннәрдерме, юкмы, анысы да мәгълүм түгел. Бездә кеше үз алдында бөтен эшне эшләргә була, күзеннән югалдың исә, оныта. Бу мәгънәсез көтү бик туйдырды. Бүген хисапларны карадым. Әле расход бик аз тотылган. Шул акча берлән бик һәйбәтләп йөреп кереп булачак та бит, рухиятемезнең очы-кырые булмады. Аннан соң һичбер ярдәмче юк. Гомәр салам селкетми, әзергә-хәзер генә. Паспорт булса, Харбинга барып, аннан Владивостокка бару уенда торам. Мобилизация ләкин эшне бик бутый.

---

[1] Низамлы – тәртипле.

[2] Истикълялын – киләчәген.

[3] Бакалым – күрербез.

*17 нче июль*

Бүгеннең иң зур вакыйгасы большевикларның Златоустны алулары булды. Димәк, большевик Уралның бу ягына чыкты. Пермь фронтында да Екатеринбургка бик якынлашканнар иде. Хәзер Омскига таба хәрәкәт башлаячаклар. Колчакның арка таяначак һичбер көче булмаган. Колчак хөкүмәте тәмамән бетәчәк. Бу – хәзер катгый бер мәсьәлә. Фәкать аның җан бирүе озынга сузылачакмы, тиз бетәчәкме, анысы мәгълүм түгел. Колчак хөкүмәтенең җимерелүе безнең өчен никадәр сөенечле булса, идарәнең большевикка күчүе шулкадәр күңелсез. Бу мәсьәләне хәл итү булмый, «букны сидек берлән юу» гына була. Хабаровски тарафларында зур забастовкалар. Анда да большевикларның зур көчләре бар, диләр. Газета хәбәренә караганда, Краснояр берлән Иркутски арасында юл киселгән. Димәк, бөтен Себер тимер юлы буе ут эчендә. Шулай булганга Байкалга кадәр большевикның килү ихтималы бик якын. Бу якка японнар җибәрмәячәкләр. Алар анда Семеновка ярдәм итәчәкләр, бәлки, Бурятия берлән Монголияне бергә кушып, аерым бер хөкүмәт тәэсис иттереп[1], эшне тәмамларга тырышачаклар. Шуңарга күрә Семеновның безгә әйткән тәкъдименең кыйммәте тагы зураядыр. Көн бик эссе. Өйдә утырып булмый. Эссе кырык градустан артык. Милли Идарәне эзләргә вә табып җавап китерергә бер кеше җибәрергә булган идек. Омскидан Колчак кача башласа, безнең Милли Идарәнең калдыгын табу бик авыр булыр кебек күренә. Белмим, ул адымымыздан бер нәтиҗә чыгачакмы, юкка гына вакыт, гайрәт әрәм китмәячәкме? Газеталарга караганда, Омскига чит кешене кертмиләр. Димәк, анда зур паника башланган.

*18 нче июль*

Бүген Милли Идарәгә озын мәгърузә[2] яздым. Томскида Нурулла Карповка*, Омскида мулла хәзрәт [...], Петропавелда

[1] Тәэсис иттереп – төзеп.

[2] Мәгърузә – доклад.

* Нурулла Карпов – Нурулла Мөхәммәтҗан улы Карпов (1877–?), сәясәт эшлеклесе, нашир, Томск мөселман тәрәккыятчеләре җәмгыяте рәисе, Томск шәһәре гласные, Томск губерна мөселман шурасының башкарма комитеты рәисе. Себер өлкә думасы әгъзасы, 1918 елның сентябрендә Уфа дәүләт киңәшмәсендә шул думаның делегациясе башлыгы булган.

Мостафа Төмәновка* озын-озын хатлар берлән мәсьәләне тәмамән ачтым. Һәммәсеннән дә берничә сөальләргә җаваплар сорадым. Бу мөрәҗәгать беренче мәртәбә генә булмаса да, бәлки, берсеннән-берсеннән бер җавап килеп чыгар. Мәсьәлә фәүкыльгадә чуалчык дәвергә керде. Булмады дип, эшне туктатсак, вөҗдан канәгатьләнми. Дәвам иттерергә дип карар итсәк, ялгыз бер кеше һичбер ярдәмсез шулкадәр мөшкилят[1] эчендә ни эшләмәкче буласың. Әгәр заграницага чыгып киткән бер-ике кешемез булса, әлбәттә, шуларга телеграмма, мәктүб берлән эшне аңлатып, алардан эшне дәвам иттерергә үтенер идек. Ул да булмагач, милли мәсьәләләремезне бәйнәлмиләл[2] мәйданга чыгару фәкать минем өсткә генә йөкләнгәннән булмады, дип, кайтып китү[не] тагы вөҗдан кабул итми. Шул манигъларга карап, кире китү тагы милләтнең шәэненә[3] муафикъ түгел хәрәкәт кебек була. Шул карарсызлыкка аптырыйм. Алты ай вакыт әрәм ителгәч, болай итеп ярты юлдан кайту да бик читен, бик мәгънәсез. Тагы ярты ел мәшәкатьләнеп, һаман нәтиҗә шул була торган булса, вакытны, фаразны, акчаны әрәм итү тагы авыр. Белмим инде, Алла үзе тугры юлны күрсәтсен.

*19 нчы июль*

Бүген мобилизациягә баруның беренче көне. Монда Чанчуньда артык бернәрсә булмады. Без мондагы япон идарәсе русларга ярдәм өчен, һәм дә японга кирәгеннән артык солдаттан качып урынлашкан яһүдтән котылыр өчен, 43 кә кадәр булганнарның һәммәсен рус хөкүмәтенә бирмәсен дип уйлаган идек. Әле улбу юк. Мобилизациянең үзе хакында да бернәрсә тавыш-тын юк. Бәлки, фронтта хәлләр бик начар булганга, туктатып торганнардыр.

Бүген өйләдән соң Чанчунь тирәсендә бер авылда япон офицеры берлән кытай офицеры исереп сугышканнар. Аларны

---

* Мостафа Төмәнов – Төмәнов Мостафа (Мөхәммәтмостафа) Хәсән улы (1892–?), милли азатлык хәрәкәтендә катнашучы. 1917–1918 елларда Мәскәү губернасында Милли Шура рәисе; үзәк Милли Шура әгъзасы.

[1] Мөшкилят – кыенлыклар, читенлекләр.

[2] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[3] Шәэненә – дәрәҗәсенә, холкына.

яклап, солдатлар катышып киткән. Эш кызып китеп, мылтык, пулеметка кадәр барып җиткән. Японнардан 12 ләп кеше үлгән. Кытайлардан күпме үлүе мәгълүм түгел. Алардан азрак, имеш. Өйләдән соң мондагы япон гаскәриләре бертуктамаенча автомобильдә, атта чаптылар. Красный Крест автомобиле кичкә кадәр җәрәхәтлеләрне ташыды. Тагы ике арада зур бер аңлашылмау булып, сугыш башланып китмәсә ярар иде. Хәерчегә җил каршы, ди бит. Тагы монысы килеп чыкмасын инде. Иртәгә Әмрулланы көтәмез. Аның берлән акча мәсьәләләрен хәл итмәкче буламыз. Акчамыз бик мөшкел хәлдә. Шәйхулла абзый* алтмыш мең сум сибирскийга мал алмаган булса, алар эштән чыкты, димәк. Себер акчасын тәмам алмый башладылар. Яшелнең бәһасе бик түбән. Кичә бер сум биш тиен иде.

*20 нче июль*

Кичә кичтән яисә бүген иртә берлән Әмрулла әфәнде килергә тиеш иде. Мәктүбтә кеше артыннан әйткән вәгъдәсе дә шулай иде. Ни өчендер килмәде. Һәм дә сәбәпләрне күрсәтеп, мәктүб тә булмады. Әллә мобилизация мәсьәләсе манигъ булды, әллә башка эш? Инде аны тагы көтәргә кирәк. Безнең бу хәерсез сәфәремез көтүдән гыйбарәт булып чыкты. Бүген мин авырый башладым. Дөресте, авырыйм дип курыктым. Тамакка «бака» калыкты. Баш авыртты. Ангина була дип шөбһәләндем. Башка эш бетте кебек инде, авырырга гына калды, ди. Бертуктамаенча тамак чайкап торып чыктым. Кичкә таба «бака» бетте.

Кичке поездда булмасмы дип көттек. Анда да үзе дә, хәбәре дә булмады. Бүген газетадан Екатеринбургны алу хәбәрен укыдык. Омскида эвакуация башланырга тиеш. Безнең Колчак, падишаһ булып җитәм дигәндә генә, чегән аты кебек булыр, ахрысы. Үзен бик кызганам.

*21 [нче] июль*

Бүген без көн буе Әмрулланы көттек, килмәде. Ахрысы, килми торгандыр, хәерле булсын. Нияздан хат алдык. Артык хәбәр юк. Токиодан Вафадан хат алдык. Берни дә язмаган. [...] отельгә Петерсонга телеграмма биргән идек. Җавап һаман юк.

---

* Шәйхулла абзый – Шәфигуллин Шәйхулла, милли хәрәкәткә теләктәшлек күрсәткән Иркутск сәүдәгәре.

*22 нче июль*

Бүген киткән[нән] бирле беренче мәртәбә (ягъни алты [ай] эчендә) мин Милли Идарәдән мәктүб алдым. Мәктүб 12 нче июльдә генә язылган. Безнең күп мәсьәләләргә җавап биргән кебек, бик күп эшләрне томанда да калдыра. Беренче, конференциядә сайланган Ибнеямин, Фуад, Солтанбәк әфәнделәрнең килүе мәгълүм түгел. Алар рәсми рөхсәт алырга дип тотынган булганнар да, шуны дәвам иттергәннәрме, юкмы, мәгълүм булмаган. Солтанбәк солдатка алынган. Фуады Омскида тик торадыр, ди. Шуңарга Милли Идарә аларны көтеп тормады. Икенче, безнең виза мәсьәләмез хакында. Анда зур чуалулар чыккан. Чиләбенең аксак ишаны, Омскига килеп, безнең солых сәфәренә килүемезне Колчак хөкүмәтенә гарыз иткән[1] һәм дә аларны һичбер халык сайламаган, без разый түгел, диелгән. Шуннан Колчак хөкүмәте Омскидагы Франция, Англиянең вәкилләренә безне җибәрмәү хакында мөрәҗәгать иткән һәм дә Парижга Сазоновка да телеграмма биргән. Безгә булган рәд җавабының төп сәбәбе шул булырга кирәк. Ләкин шунысы гаҗәп: аксак ишан шулкадәр зарар итәр өчен эшләр эшләгәндә, безнең Милли Идарә, юлны ачар өчен, бер хәрәкәт тә ясамаган. Ул гына да түгел, ул шул хәбәрне безгә бүген эш эштән чыккач белдерде. Үзе тагы ни дип, моңарчы китмәенчә ятасың, дип, сөаль куя. Гомәр хакында сүз дә юк. Үзең чык та Садрины, фәләнне табып, берәр эш эшлә, ди. Ягъни, моннан өч ай ярым элек биргән Солтанбәк берлән Фуадны көт дигән әмерен халык хөкеменә бирә. Эшләр болай барганда, шулай алтыда бер мәктүб алып, өч айда бер карарлар белдерелеп торганда, мин уникे елдан Солых Мәҗлесенә барып җитә алырмын. Инде шул мәсьәләләргә алты ай вакыт сарыф ителде. Эш әле һаман бер урында. Шунысы да сөендерерлек инде: Милли Идарә үзенең вазифасының башында булып, һичбер төрле безгә ярдәмдә булынмаса да, аксак ишан кебек үк барып, донослар ясап йөрмәгән икән. Югыйсә алардан, теге телеграмма җибәргән кешеләрдән, аны да көтәргә мөмкин иде. Монысы да, бәлки, болар да аксак ишан кадәре интрига булмаганнан гына килгәндер. Бу мәктүбтән соң мәсьәлә тагы бераз үзгәрде. Ничек тә тагы

[1] Гарыз иткән – җиткергән.

бер мәртәбә тыпырчыну лязим кебек күрелде. Бара алсам, тагы үзем чыгарга, тагы бер мәртәбә маташып карарга кирәк. Бара алмасам, Садрига*, Йосыфка** тагы мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Йосыфтан хат-хәбәр юк. Садри, имеш, Финляндиядә. Ул вакытта акча мәсьәләмез тагы килеп алга баса. Шул акчаны һаман бер юлга куя алмадык. Безгә ышандырган кешеләр шул эштә бик йомшаклык күрсәттеләр. Латыйф Яушев Милли Идарә әгъзасы була торып, шуларның сибирскийларын алыштырырга тапшырылса да, шуны эшләмәде. Бер ай тик тотып, кайтарып бирде. Шәйхулла абзый, безнең үтенечкә карап, шуңарга мал алмады. Тагы шул Әмрулла гына калды. Ул да килеп китә алмаганга күрә (килергә утырган икән, Кытай берлән Япон арасындагы сугыш зурайтылып күрсәтелгән дә куркып, төшеп калган) һәм дә Владивостокка барырга лөзүм кебек күренгәнгә, үзем Харбинга барырга карар иттем. Фәкать үз паспортың берлән барудан бик күп уңайсызлыклар бар. Берсе, мин[ем] заграничный паспортымның хөкеме югалса, яңадан алу – бик авыр бер мәсьәлә, бирмәү ихтималлары да бик якын, бу – бер. Икенчедән, миңа солдат каралырга кирәк. Солдатка алулары да бик якын. Ул вакытта бөтен план тыран-мазаран килгән була. Шуның өчен боларның берсе дә ярамый, фәкать кала качып керергә. Аның өчен минем кулымда нинди булса да паспорт булырга кирәк. Миңа Харбиннан җибәрергә вәгъдә иткән булсалар да ул да килмәгән. Кала качып-посып, күренмәенчә чыгарга маташырга. Ләкин бу вакытта тотсалар, бик зур күңелсезлекләр булу ихтималы бар. Һәм дә бөтен план асты-өсткә килү, аннан башка төрмәгә эләгү ихтималы бик якын. Ләкин мондый вакытта куркып торсаң, бернәрсә чыкмый. Аллага тапшырырга да хәрәкәт итәргәме? Мин мондагы әфьюнчы абзыйлардан мәгълүмат җыям. Чыгып булырмы, юкмы? Берсе әйтә, паспортсыз мөмкин түгел. Берсе, мөмкин, ди. Ахырдан бер абзыйның ярдәме берлән рус ягындагы Куаньчэнцзы дигән стансага ат берлән барырга да аннан утырып китәргә буламыз. Ләкин анда да күп вакытта паспорт сорыйлар,

* Садри – Садретдин Низаметдин улы Максудов (1878–1957), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, юрист.

** Йосыф – Йосыф Хәсән улы Акчурин (1876–1935), җәмәгать эшлеклесе, журналист, публицист.

ди. Аллага тапшырдык. Мин әйберләремне җыештырам да көндезләп, теге стансага китәргә булдым. Рус тимер юлында әле Себер акчасын ала. Ул миндә юк. Шуңарга күрә шуны алырга кытайларга керәм. Һәм дә бер иен да җитмеш центка безнең илле сумлыкны алып чыгам. Минем поезд төнге сәгать 12 ләрдә китә дә анда көндез барып калырга кирәк. Бердән, ул вакытта күзгә ташланмый, икенчедән, күптән түгел генә монда Кытай, Япон [басымы] булганга, монда һәр йирдә караул, кич кешеләр җибәрмиләр, ди.

## 6 нчы дәфтәр

### 1919 ел

*Июль – октябрь*

Шуңарга күрә бер абзый сәгать алтыларда мине килеп алып китә. Без бик тыныч кына рус-япон чигеннән үтәмез. Анда алар мине бик зур кунак итәләр. Һәм дә бөтен эшне эшләргә булалар. Көн фәүкыльгадә эссе, чәйне эчеп туеп булмый. Сәгать 11 гә кадәр берничә чәй эчеп, аш ашап, вокзалга китәмез. Мине өч кеше озаталар. Берсе билет ала, берсе әйберләр карый, берсе урын карый. Менә поезд да килде, бөтен тимер юл милиция платформага тулды. Минем абзыйлар да кереп китеп, урын алдылар. Һәм дә минем әйберләрне керттеләр. Мин вокзалга йөрергә генә килгән кеше булып, тик утырып тордым. Тимер юл офицерлары, вагоннан вагонга кереп, паспортларны тикшереп, штамплар сугып йөриләр. Менә паспортлар өләшенеп бетте. Офицерлар чыкты. Ләкин кулында бер паспорты калган. Ул шуның хуҗасын эзләп йөри. Ул туп-тугры миңа таба килә. Хәзер миннән паспорт минекеме, түгелме, дип сораячак. Минеке диярга ярамый, хуҗасы бар. Түгел дисәң, синең паспорт кайда, диячәк. Ул миңа туктап карап тора. Паспорт хуҗасы түгеллегенә ышана булырга кирәк, борылып китә. Менә икенче звонок. Тир китә. Мин акрын гына үз урыныма керәм. Арттан теге абзыйларның берсе керә. Ләкин без берәр сүз сөйләргә өлгермимез, икенче озатучы керә. Офицер икенче класска кереп

китте. Хәзер безгә керү ихтималы бар, ди. Йөрәк леп-леп суга. Офицер керми дә керми. Ләкин поезд да китми. Менә өченче звонок. Аллага шөкер. Теге абзый күрешеп чыга. Ул тәрәзә төбендә. Теге офицер чыкты поездан, беркем дә озатмый, тыныч бар, ди. Поезд да кузгала, мин дә иркенләп бер сулыйм. Аллага шөкер, бусыннан котылдык әле. Киләчәк станцага кадәр йоклый алмыйм, һаман көтәм. Аннан да үтәмез, берни юк. Кондуктор билетларны тикшереп үтә, берни юк. Пычрак урынга сузылып ятам. Азрак калтырыйм, уянам да тагы калтырыйм. Шулай итеп, иртәнге сәгать дүрткә кадәр ауналдым. Әнә ямь-яшел Маньчжур кырын кызартып кына кояш күтәрелә. Йылысы йомшак кына, нуры хисле генә, акрын гына искән җиле дустча гына, хәерле таң булсын. Шул таңнан башлап, безнең милли эшләр дә уңга әверелсен.

*23 нче июль*

Иртүк Харбинга килеп җиттем. Вокзалда Әмрулла әфәнде автомобиль берлән каршы алды. Көн фәүкыльгадә эссе. Поездда йокламаганга да, эссегә дә мин изелеп торам. Монда Ибраһим Кәмал килеп чыкты. Ул бераз безнең якның хәбәрләрен белә. Безнекеләр сау-сәламәт, имеш. Милли Идарәнең хәлләрен газетадан гына белә. Уфага кайтып, берәр ай юлда йөреп, Уфада өч көн торып, тагы юлда өч атна вакыт үткәреп, Омскига килеп йирләшкәннәр. Мәгънә чыкмаган, казыйлардан Урманов* кына килгән. Үзләре бик аз булырга тиеш. Кич берлән Әмрулла берлән бакчага барып утырамыз һәм дә аңарга бөтен планны сөйлим. Аның ярдәменә иң зур мохтаҗлыгымыз – безнең акчаны малга алыштыру, аңарга каршы килми. Бүген әле астан-өстән генә сөйләп үткәрәмез, иртәгә, насыйп булса, тәмамән эшкә керешәм.

Милли Идарәгә кеше җибәрү – һаман карар-карар, фәкать шуңарга тагы бер нәрсә – акча мәсьәләсен кушмакчы булам. Ни килеп чыгар? Гомәргә хат яздым, ул да кайтыр инде. Аннан соң Ичанйога барып, теге җавапның кайтуын бераз көтәргә тугры килер төсле тора.

---

* Урманов – Оренбург мөселман Диния нәзарәте казые, Милләт Мәҗлесе депутаты Салихҗан Урманов булса кирәк.

*24 нче июль*

Бүген солых сәфәренә чыгып киткәнемә алты ай тулды*. Алты ай ярты гомер булса да, хисап бирерлек бер эш тә күренми. Мин үз кулымнан килгәнне эшләдем кебек күренә. Ләкин нәтиҗә шул бик кечкенә чыкты. Чөнки башка мәсьәләләр, башка кешеләргә баглы шартлары берсе дә эшләнми. Иске схоластика китапларында маһиятьнең вөҗүде өчен[1] гамәлнамәсе хәзер булырга, гамәлнамә бөтен гамәлләр накыйсның мәҗмугасыннан[2] гыйбарәт. Кечкенә генә бер гамәлнамә накыйс[3], йиренә килмәсә дә, гамәлнамә хәзер булмый, диелә. Бу эштә дә шулай булды. Бик күп гамәлләр, накыйслар[4], хәзер булмады. Тискәренчә[5], аның зарарына булачак әллә никадәр гамәлләр чыкты.

Әмрулла берлән теге мәсьәләне сөйләгәндә, алу мәсьәләсен өстемә ала алмыйм, диде. Ягъни матур гына иттереп отказать итте. Фәкать, берәр кеше товар табып китерсә, карашып алышырмын, диде. Мин Вәли Аппакаев дигән егетне чакырып сөйләдем. Товар табып бирергә вәгъдә итте. Белмим, ни чыгар. Бүген Гайшә ханым берлән Габдулла кайтачак. Алар берлән Ичанйода тору мәсьәләсен хәл итәчәкмез. Минем тору мәсьәләм паспорт булмаганга бик авыр. Агишевлар[да] кунак була[м]. Аларга да мәшәкать. Эчне дә бик пошырачак. Дәрәҗәне дә бик төшерә. Нишләргә дә белми йөрим. Ичанйода, бәлки, паспорт мәсьәләсе ул кадәр каты булмас. Төн буе һичбер йоклый алмадым. Бүлмә фәүкыльгадә эссе. Эсселектән бөтен тәнем чабыртты.

*25 [нче] июль*

Бүген иртүк Гыйнаять әфәнде килде. Гомәрне аларга урынлаштырырга булып, хат яздым. Көн фәүкыльгадә эссе. Паспорт мәсьәләсе шәп түгел. Милли Идарәгә тиз көннән курьер җибәрәм, дип, телеграмма суктым.

---

* Бүген солых сәфәренә чыгып киткәнемә алты ай тулды. – Димәк, Г. Исхакый Кызылъярдан 1919 елның 24 нче гыйнварында чыгып китә.

[1] Маһиятьнең вөҗүде өчен – эш барып чыксын өчен.

[2] Гамәлләр накыйсның мәҗмугасыннан – кыска, кечкенә гамәлләр тупланмасыннан.

[3] Накыйс – тулы булмаса.

[4] Накыйслар – м о н д а : тулысынча, тиешенчә үтәлмәделәр.

[5] Тискәренчә – киресенчә.

*26 [нчы] июль*

Бүген-иртәгә Гомәр килгәч, Ичанйога барып, андагы мөгаллимне Омияга* җибәрәчәк идем. Ләкин тимер юл хезмәтчеләре эш ташладылар, шуңарга күрә Гайшә ханым да китә алмады, юлда тукталды. Гомәр дә өзелеп калу ихтималы бар. Курьер да җибәрә алмавымыз ихтимал. Ул вакытта мин Харбиннан беркая китә алмыйча калачакмын. Бу мәгънәсез көтү шулкадәр туйдырды, шулкадәр вакытны әрәм итте, һич әйтеп бетерерлек түгел.

Бүген Нияз Пекиннан кайтты. Артык күп кеше күрә алмаган, җыйган мәгълүматы зур түгел. Кытайның Маньчжурия һәм Пекин әтрафындагы мөселманнары хакында өмидле бернәрсә юк. Фәүкыльгадә надан, ялкау, аңсыз халыктыр. Ганьсу** вилаяте хакында мәгълүмат бераз өмидле. Анда бик күп мәртәбә барып йөргән һөнәрле мөселманның сүзенә караганда, Ганьсу – аерым мохтариятле бер вилаять. Халкы кытайча сөйләсәләр дә, кыяфәт берлән һич кытайга охшамаганнар, үзләре һәммәсе – мөселман. Аерым гаскәрләре бар. Батыр, сугышчан халык. Голямасы бик үк надан түгел. Юлы – Пекиннан өч көн тимер юл берлән барганның соңында, ике атна кәрван берлән. Юл яхшы, юл буе мөселман авыллары. Мөсафирпәрвар халык. Ганьсу волосте Чини[1] Төркестанга кушыла, ике арада зур юл бар. Кәрван берлән ай ярымлык юл. Ләкин Төркестане Чинидан мәгълүмат ала алмаган. Аларның Кытай парламентында берничә депутатлары бар икән. Алар Нияз берлән күрешүдән тартынганнар. Мөселман булганга, берәр нәрсә чыкмасын, дип курыкканнар булырга кирәк. Теге әфәндегә Нияз кайтуыннан белдерергә булыр. Паспорт мәсьәләсе хәл кылынса, мин Владивостокка барырга була идем, ләкин әле һаман ул бер ноктада тора. Гомәргә, кайт, дип, телеграмма бирдем. Ләкин кайта алмавы ихтималы бар. Бүген ягмур яуганга, бүген көн яхшырак.

Хәзер минем алдымда дүрт мәсьәлә тора. Берсе – Омскига Милли Идарәгә курьер җибәрү. Икенчесе – теге акчаларны товарга алыштырып, иенга чәверү[2], өченчесе – Владивостокка

---

* Омия – Япониянең Сайтама шәһәрендәге тимерьюл вокзалы.

** Ганьсу – Кытай провинциясе.

[1] Чини Төркестан – Кытай Төркестаны.

[2] Чәверү – күчерү, алыштыру.

барып, тагы юл эзләп карау, дүртенчесе – теге әфәндене күреп, яңа план хакында сөйләшү. Юллар тукталганга, боларның берсен дә хәзер эшләп булмый. Бу сәфәрдә безнең юлга һәрвакыт көтелмәгән «аю» чыгып торды. Хәерле булсын.

*27 нче июль*

Бүген тимер юл эшчеләренең забастовкалары бик зур куәт берлән дәвам итә, шуңарга күрә мин Ичанйога барып, теге әфәндене җибәрә дә алмыйм, ул да монда килә алмый. Килсә дә, юл юкка китә алмый. Һәрбер эштә көтелмәгән манигь[1] чыга да тора. Милли Идарәгә әллә тагы телеграмма биримме дигән фикер дә бар. Белмим инде. Гимошинга биргән телеграмма алынган булса, анда һәрнәрсә әйтелгән иде. Алынды-алынмавы мәгълүм түгел. Гомәр килә алмады.

Товар һаман булганы юк. Эш әле бертөрле дә юлына куелганы юк.

*28 [нче] июль*

Бүген иртә берлән тимер юл йөри башлады дигән хәбәр чыккан иде. Ул да тугры булып чыкмады. Забастовка бетмәгән булырга кирәк, йөрүенең йәбәлә ягы[2] юк. Шуңарга күрә минем, безнең эшләргә юл ачыла, дигән сөенүем иртәрәк булды. Кунак булып тору бик уңайсыз, шуңарга күрә бүлмә эзләдем. Ләкин паспорт мәсьәләсе бик авыр. Берне тапкан булдым, ләкин бер дә ярарлык түгел. Тагы нелегальный хәяткә күчәм, ахрысы. Моңарчы торганымда 19 паспорт алыштырган идем, бу инде егерменчесе, ләкин нелегальный торуга җиде ел вакыт үтте. Димәк, тагы шул хәят башлана. Ул вакытта яшьрәк идем. Хәзер чыдау авыррак булыр. Тәнемә кып-кызыл бер нәрсә чабырынды, эсседәнме, суданмы – мәгълүм түгел, ләкин бик эчне поштыра, кечетә.

*29 нчы июль*

Бүгеннең иң зур вакыйгасы – Милли Идарәдән телеграмма алдым. Теге мәсьәлә хакында кирәкле адымнарны атлыймыз. Тиздән нәтиҗәсеннән хәбәр бирермез, диелгән. Димәк, голя-

[1] Манигъ – киртә.
[2] Йәбәлә ягы – рәте, юне.

маларга йибәрелгән телеграмма ирешкән. Бик ихтимал, тиздән безгә виза килер. Ләкин акчасы мәсьәләсе фәүкыльгадә начар хәлдә. Хәзерге кебек иенның күтәрелгәне юк иде. Шуңарга күрә тугрыдан-тугры иен да алу мөмкин түгел дәрәҗәдә. Хәзер яшел берлән бер иен – егерме ике сум. Сибирский берлән – утыз ике сум, николаевский берлән – ундүрт сум илле тиен. Товар алырга һаман җай юк, ягъни бүген генә аны алып булмый. Сәүдәгәр халкымыз безгә шул мәсьәләдә ярдәм итмәделәр. Харбинга килгәч тә, акча мәсьәләсен Әмрулла Агиев, Вәли Ибраһимов*, Латыйф Яушевларга тапшырган идем. Алар, ичмасам, яртысына товар алуны мәслихәт күргәннәр иде. Ләкин шуны эшләмәделәр. Фәкать Әмруллалар гына ахырдан кечкенә генә бер партия алдылар. Латыйф бөтенләй бер эш эшләмәде, ул гына түгел, Шәйхулла абзый Шәфигуллин безнең алтмыш-җитмеш мең сумымызга товар таба алмады. Шул арада ул Агишевларга бер-ике миллион сумлык товар алган, безгә алтмыш-җитмеш меңлек товар тапмаган, имеш. Инде Агишевлар да хәзер кул селтиләр. Инде рөхсәт чыгар, акча булмас. Аллага тапшырдык.

Шәйхулла абзыйга тагы бер телеграмма сугып сорап карыйм, Милли Идарәгә дә озын телеграмма сугам.

*30 нчы июль*

Гомәр һаман килә алмады, өзелеп калды, күрәсең. Шәйхулла абзыйга товар алмассыңмы, дип, телеграмма суктым. Милли Идарәгә дигән телеграмманы Гомәр килгәнче дип көтмәкче идем, ләкин һаман килми дә килми. Булмаса, иртәгә сукмаенча ярамас. Бүген төнлә бик каты ягмур яуды. Урамнар су тулган, бик күп урамнан үтеп булмый. Һава кеше рәтле булды. Тимер юл забастовкасы һаман дәвам итә, шуңарга күрә кеше җибәреп булмый.

*31 нче июль*

Бүген мин авырып тордым. Мигъдәм бик бозылган. Рәтләп йоклый да алмадым. Көн буе әлсерәп чыктым. Тормыш бик

---

* Вәли Ибраһимов – (1888–1928), кырымтатар дәүләт эшлеклесе, Кырым АССР эшче-крестьян инспекциясе халык комиссары (1921–1924), Кырым АССР Үзәк башкарма комитеты рәисе (1924–1928).

мәгънәсез дә, бик тәмсез дә, бик ямьсез дә. Хуҗаларның торышлары Мәкәрҗәгә* килгән кешенеке кебек. Өй карау, йорт тәрбиясе дигән нәрсә һич юк. Баштанаяк дөнья кууга чумганга, аларга, әлбәттә, мондый җитешмәгәннәр күренми торгандыр. Минем кебек тик тора торган кешегә күзгә бик бәрелә.

Бүген өйләдән соң Иркутскидан Фуадтан, электрист[1] берлән чыктым, дигән телеграмма килде. Моннан дүрт ай элек килергә тиеш булган Фуадымыз хәзер килә. Ни алып килә, нинди йомыш берлән килә, әлбәттә, хәзер әйтеп булмый. Әгәр Маньчжур стансасыннан поезддан[2] җибәрсәләр, бер-ике көннән килеп җитәргә тиеш. Ничек килсә дә, мәсьәлә бик яхшы ачылачак. Бәлки, рөхсәт тә алып килә торгандыр, ләкин инде ул рөхсәттән файдалану мөмкин булмаячак. Чөнки акча мәсьәләсе бик чуалды. Безнең килгән чактагы 20–25 иенлык мең акчамыз хәзер ун мең иенлыкка төште. Сәүдәгәрләремезнең ярдәме аркасында безнең сибирский акчаларымыз бүгенгә кадәр алышмаенча калды. Ни булса булсын инде. Мин алты ай баш ваттым инде. Җитәр, мондый эштә организацияң булмагач, бер кешенең тырышуыннан гына берни дә чыкмый икән.

*1 нче август*

Бүген Фуадны көттек, ләкин килмәде. Ул якта тимер юлны су юган икән дә, шунда Маньчжур стансасы башында поездлар көтеп ята икән. Саулыгым начар. Мигъдә һаман ташуында дәвам итә. Тәрбияләп булмый. Ашау-эчүне үзгәчәрәк йөртсәң, бәлки бер хәл иде. Ләкин мин монда хәзер нахлебник хәлдә булганга, һичбер төрле эш эшли алмыйм. Әллә инде дизентерия була, эч бик бозылган. Корчаңгы да бетми. Бәхетсезлек бит һәммәсе дә бергә килә. Бүген Себер акчасына иен кырык биш сум. Иркуттан[3] җавап көтәм, берәр нәрсә ала алмасलармы.

---

* Мәкәрҗә – Россиядәге иң дәвамлы сәүдә ярминкәләреннән берсе – Мәкәрҗә ярминкәсе күздә тотыла. 1817 елга кадәр Идел елгасының сул ярында, Макарьево авылы (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе Лысково районы Макарьево бистәсе) янында урнашкан булган.

[1] Электрист – электр поезды.

[2] Поезддан – «поезд белән» мәгънәсендә.

[3] Дөресе: Иркутскидан.

*2 нче август*

Бүген авыруым дәвам итте. Докторга бардым. Дизентерия түгел, диде, ләкин рух бик төшенке. Бик ялыктым. Кич берлән, арып эштән чыгып, Гомәр килеп чыкты. Бик зур мәшәкать берлән, мең бәла берлән границадан үткән. Инде Фуадны гына көтәргә калды.

*3 нче август*

Бүген иртә берлән Вәли әфәнде Ибраһимов Маньчжурдан килде. Фуадны Маньчжурда күргән. Фуад, мин Милли Идарә берлән тәмам аерылышып, үзем генә Харбинга киләм, дигән. Үзе килгәч сөйләтермен инде. Бик күп хәбәрләр, хәбәрдән дә күп гайбәтләр бардыр. Шуларны төяп килә инде. Ләкин эш эштән чыккач, олуг эшемез тәмамән күздән төшерелеп бетеп, аяк астына тапталгач килә. Әгәр шул килүне ул теге вакытта эшләсә, элгәреге план буенча килгән булса, безнең сәфәрнең бөтенләй башка якка борылуы ихтималы бар иде. Ләкин ул әллә нинди интригаларга салынып, эшне өстеннән чыгарышуда бик зур роль уйнап, хәзер инде үзенең безгә каршы корган планы да җимерелеп, сөрелгән шайтан кебек килә. Ниләр сөйләр, ниләр китерер. Тыңлыйк әле. Бүген кич берлән килергә тиеш иде, поезд туктап калган да, иртә[гәгә] калганнар, имеш.

*9 нчы август*

Бүген минем Мәскәүдән чыкканыма бер ел тулганга гына каләм алдым. Юк исә әле хәлем алга түгел. Мин бер атнадан бирле постельдә бик каты авырыйм. Эсселек булды, эч барды[1]. Өч тәүлек авызыма бер локмә[2] алмадым. Хәзер күземне ачтым, терелеп киләм, ләкин һич көчем юк һәм дә тәм юк. Мигъдәм бик начар эшли. Бөтен авыру буе Агишевларда яттым. Үзең кеше өстендә, үзең авыру, үзең паспортсыз, үзең бара торган юлыңнан өзелгән. Әлбәттә, болар рухка бик начар тәэсир итеп торды, шуның өчен өйдә хезмәтче марҗа гына, башка кеше булмаганга, караучы бер дә булмады, пычрак эчендә яттым. Минем

---

[1] Эч барды – эч китте.

[2] Локмә – бер кабым.

иң җирәнгән нәрсәм – пычрак ятак такымы[1]. Монда килгәннән бирле шул чирне бик тулы күрдем. Хосусан, авыр вакытта пычрак япмалар мине бик мыскыллады. Инде, Аллага шөкер, тордым. Мигъдә һаман юлда булмаса да[2], авызыма тәгам кермәсә дә, хәзер өйдә йөрим. Аннан-моннан яңа авыру өстәлеп китмәсә, акрын гына терелермен инде. Ләкин бу арада монда холера куәтләнгән. Кытайлар арасында авыру, үлү бик күп. Бу Алланың каһәре төшкән Харбинда холерага каршы һичбер нәрсә юк. Больницаларында карболкалары* да юктыр әле. Монда һәркем спекуляция берлә генә мәшгуль булганга, һичбер төрле андый-мондый эшләр хакында уйлау беркемнең башына да керми. Әле менә буш торып йөдәп беткәнгә булырга кирәк, Харбин больницасының докторлары үз арада комиссия ясап, рус теленең иске имлясе берлән язарга кирәкме, яңасы берләнме дигән мәсьәләне тикшерергә тотынганнар. Күбрәге иске имля тарафында, имеш, чөнки иске дигән сүздә халык үзенә аерым бер тәм тапкан кебек, докторлар да «иске имля» дигәнгә күбрәк ышаналар булырга кирәк. Холерадан авырганнарны яткырырга урын юкка, ташырга арба юкка, урамда үлеп яталар.

Бүген Мәскәүдән качып чыкканыма тәмам бер ел тулды. Мөселман комиссариатының доносы берлән, унынчы августта Мәскәүдә миңа революционный трибуналда хөкем булачак иде. Минем контр-революционлыгымның дәрәҗәсенә карап, миңа җәза бирәчәк иде. Ләкин төрмәләр бик тулы булганга, ашау-эчү төрмәдә тәмамән юк дәрәҗәдә булганга һәм дә төрмәгә алып барганда красный армеецларның үтерүләре гадәт булганга, мин качып киттем. Шуннан Идел аша көймә берлән төшеп, юлда тугыз көн калып, бик куркынычлы минутлар үткәреп, сугыш фронтын ерып, унсигезенче августта Казанга килеп кердем. Анда бер туктамаган туп-бомба тавышы астында берәр атна торып, Самарага киттем. Анда безнең халык җыелып бетмәгәнгә, Киңәш Мәҗлесе дә Уфада булганга, анда киттем. Уфада Милли Идарә тарафыннан Дәүләт Киңәш Мәҗлесенә

[1] Ятак такымы – урын-җир комплекты.
[2] Мигъдә һаман юлда булмаса да – ашказаны һаман рәтләнмәсә дә.
* Карболка – дезинфекция ясый торган сыекча. Карбол кислотасы эремәсе.

иштирак иттем[1]. Киңәшкә килгән кыргыз, башкорт, сарт[2] вәкилләреннән җыеп, конференция ясаштым. Милли Идарәнең башка эшләренә иштирак иттем. Уфаның хәле начарлана башлагач, Милли Идарә берлән Петропавелга күчтем. Максатымыз анда барып, зур гына газета куеп[3], Себергә хезмәтне күчерү, Себердә милли хәрәкәтне ныгыту иде. Ләкин, матбага начарлыктан, газетамыз кечкенә булды. Себердә моңынча[4] милли хезмәт бик сатых[5] булганга, икенче яктан, монда искелек бик куәтле булганга, зур хезмәт итеп булмады. Алай да газета берлән, мәкаләләрем берлән һәм дә лекцияләр берлән, Петропавелны шактый кайнаттым. Икенче эш – Солых һәйәтен оештыру иде. Петропавелда аңарга каршы зур хәрәкәт булганга, Петропавел татарлары бик зур киртәләр салдылар. Иң әүвәл төрле-төрле саботаж берлән эшне кичектерделәр. Ахырдан тугрыдан-тугры көпчәккә таяк тыга башладылар. Ике ай алар берлән маташырга вакыт әрәм булганның соңында, Милли Идарәне бераз хәрәкәткә китереп, аны оештырып, Солых һәйәтене яңа әсаска[6] кордырдым. Озын киңәшләрдән соң, минем янга Фуад берлән Гомәрне кушып җибәрергә карар иттек. Гомәр Милләт Мәҗлесенең төрекчеләр фиркасе нәмаиндәсе[7] булачак, Фуад Учредительное собраниедән төрекчеләр фракциясенең нәмаиндәсе булачак иде. Боларның икесендә дә җәмәгать акчасы булганга, алар шуннан үзләренә расход тотачаклар. Һәйәтнең гам расходлары[8] милләт акчасыннан тотылачак иде. Менә шул ниятне уйлап, Иркутскида берләшергә булып, Гомәр алдан чыгып китте. Мин 24 нче гыйнварда акча җыярга чыгып киттем. Фуад атна-ун көннән чыгачак булып калды. Шуннан соң, мин шәһәрдән шәһәргә кереп, халыкны җыеп, лекция укып, моназарә кылышып, кычкырышып-бакырышып, ай ярым юлда калып, ике йөз мең сум акча җыйнап,

---

[1] Иштирак иттем – катнаштым.
[2] Сарт – үзбәк.
[3] Куеп – м о н д а : «чыгарып» мәгънәсендә.
[4] Моңынча – моңарчы.
[5] Сатых – өстән генә.
[6] Әсаска – нигезгә.
[7] Нәмаиндәсе – вәкиле.
[8] Гам расходлары – гомуми чыгымнары.

Харбинга килеп җиттем. (Гомәрне Иркутта очраттым, Фуад юк иде.) Вәгъдә буенча Фуад Иркутта очрашырга булса да, ул әле Харбинда да юк иде. Иркуттан аңарга, тиз кил, дип, телеграмма бирдек. Без Харбинда паспорт алырга берәр ай вакыт үткәрдек. Ул һаман килеп җитмәде. Без көтә-көтә көтек булып, унынчы апрельдә Япониягә чыгып киттек. Шул вакытта Петропавелдагы конференция минем мәгърузәмне[1] игътибарга алмаенча (Милли Идарә күрсәтмәгән), тагы дүрт кеше сайлады. Шуларның Фуад берлән Солтанбәк* рәсми вәкилләр булып китәмез, дип (без гайре рәсми буламыз, имеш) торганнар. Үзләрен генә вәкил дип уйлаганга булырга кирәк, безнең берлән тәмамән мөнәсәбәтне кискәннәр. Без, Японийдә өч ай торып, виза ала алмаенча, Милли Идарәдән, Фуадтан һичбер хәбәр ала алмаенча, Харбинга кайттык. Менә моннан дүрт ай элек килергә тиеш булган Фуад хәзер килеп чыкты. Тегендә Милли Идарә берлән берләшеп, безне читтә калдырып, үзләре генә вәкил булып китү эше барып чыкмаганга, инде безнең [берлән] берләшеп, Милли Идарәне читтә калдырып, барырга булып килгән. Вакыты бераз соңрак, үзе безнең виза алмавымызны белә торып, виза Омскида икәнлекне аңлый торып, авызын күтәреп килгән. Менә шул Фуад, монда килгәч, безгә доклад ясады. Конференциядә ике вәкил сайлау мәсьәләсе куелган. Шул вәкилләрне билгеләр өчен дә, махсус комиссия аерылган. Минем мәгърузәм укылмаганга күрә, яңадан сайлау кирәк түгел, фәкать элеккеләрен генә рәтләп җибәрү дигән мәсьәлә мәйданга куелмаган. Милли Идарә, минем берлән бергә кабул иткән карарны бозып, яңа әсәска куйган вә шул үзгәртүне миңа һичбер төрле белдермәгән. Конференциядә озын кычкырышлардан соң комиссиянең һәм дә Милли Идарәнең күрсәткән кандидатларыннан Фуад берлән Солтанбәкне икесен сайлаганнар. Монда, имеш, (Фуад сүзенә караганда) Фуадны сайлаган өчен Милли Идарә зур иҗтиһад иткән[2]. Солтанбәкне сайлауны ультиматум кебек куйган, чөнки Солтанбәк булмаса, һәйәттә мин, Садри, Фуад булачак, имеш. Безгә Ибнеямин әфәнде һичбер төрле ошамый, имеш (болар Фуад сүзеннән). Шуннан

[1] Мәгърузәмне – проектымны.

* Солтанбәк – Мәмлиев Солтанбәк (?–1920), сәясәт эшлеклесе, кече офицер.

[2] Иҗтиһад иткән – тырышлык күрсәткән.

соң берәр атна-ун көн торып, Омскига китәләр. Аннан элгәре килгәндә Ибнеямин Әхтәмов* Франсә вәкиле граф де Мартельгә** барган икән. Ул вәкилләрегезгә бөтен җиңеллекне эшлимез дигән икән. Шул вәгъдә буенча Ибнеямин әфәнде, солых сәфәренә бару бер кәефле бер прогулка гына була, дип уйлаган да үзен дә сайлаттырган. Ләкин бу килүдә граф де Мартель элгәреге кебек кабул итмәгән. Вәгъдә кылырга дигән җиңеллекне бик үк тиз эшләмәгән һәм дә заграничный паспортларыңыз булса, виза бирермез берлән илтика иткән[1] (димәк, Милли Идарә безнең хакта әйткән булса, безгә дә виза бирәчәк булганнар).

Шуннан соң Милли Идарә Солтанбәк берлән Фуадка заграничный паспорт алырга керешкән. Шул эшне чыгарып бетермәенчә, үзе Уфага кайтып киткән. Фуад берлән Солтанбәк, үзләре тырышып, паспорт алырга калганнар. Сайланган вәкилләргә алай итеп йөрү килешкән булырга [кирәк]. Болар, олуг башларыны кече итеп, мөттәкыйнләнеп[2] йөрүне муафикъ күрмәенчә, Милли Идарәнең Уфадан килүен көткәннәр. Шул арада Солтанбәк гаскәрлеккә алынган. Безнең ник безгә телеграмма, бер мәктүб, бер хәбәр генә җибәрмисез дигән сөальләргә, аннан бит мин Милли Идарәне көтеп торам, дип җавап бирә. Менә шулай итеп көн дә көн үтә, Колчак хөкүмәтенең Милли Идарәгә мөнәсәбәте үзгәрә. Безнең хакта аксак ишаннар донослар ясыйлар. Фуад паспорт алып биргәнне көтеп тора. Шуннан Милли Идарә Уфадан качып килә, Фуад яңадан паспорт һәм виза алып бирергә мөрәҗәгать итә. Шул арада безнең виза ала алмау хакында телеграмма килә. Милли Идарә Фуадның мөрәҗәгатен кабул итми, аңарга паспорт алырга тырышмый. Бәлки, билгакес[3], Фуадны Солых һәйәте акчасын алырга һәм дә миңа

---

* Ибнеямин Әхтәмов – Ибнеямин Әбүсогуд улы Әхтәмов (1877–1941), хокук белгече, сәясәт эшлеклесе.

** Граф де Мартель – Дамьен де Мартель (1878–1940), сәясәтче һәм дипломат. 1918–1920 елларда Франция хөкүмәтенең Себердәге дипломатик вәкиле һәм хәрби комиссар ярдәмчесе дә була. Ул чехословак гаскәрләренә Россия территориясеннән тизрәк китүне, ягъни нинди юллар белән эвакуацияләү мөмкинлеген хәл итәргә булыша.

[1] Илтика иткән – очрашкан.

[2] Мөттәкыйнләнеп – шикләнмичә.

[3] Билгакес – киресенчә.

җибәрергә карар итә. Шул карарга Фуад, разый булмаенча, акчаны бирмәенчә, монда чыгып китә. Хәзер менә монда килгән. Максаты – ничек булса да солых сәфәренә чыгып китү. Янында йөз кырык мең сумнар акчасы бар.

Фуад берлән мин, әлбәттә, оршышып тормадым. Солых сәфәрен җимерүченең берсе икәненә иманым камил булса да, хәзер кычкырышудан мәгънә юк. Бер сүз дә әйтмәдем. Ләкин аны үзем берлән бергә кушмадым. Милли Идарәгә, Фуад берлән нинди мөгамаләдә булырга, дип, телеграмма бирдем. Саулыгым төзәлгәч, бер карарга килермен.

*25 нче август*

Харбинга кайткач, хәят шулкадәр чыгырыннан чыкты, хәтта көндәлек хатирә язарга да мөмкин булмады. Башыннанрак башламасаң, аңлашылмас та. Мин терелә башлагач, Харбинда бик каты холера китте. Кытай кыйсемендә көненә берничә йөз кеше үлә, диделәр. Агишевларда тормыш һаман кунак төсендә булганга, кунакның мәгълүм һичбер төрле хокукы булмаганга, үзем теләгәнчә бер эш тә эшли алмадым. Шул арада Ичанйодан (җәйлек урын) Гыйнаять хәзрәт килде. Анда кичә генә шәһәргә хунхузларның* һөҗүме булган. Хунхузлар берлән гаскәр арасында ике сәгатьләп атыш барган. Хунхузлар Кытай базарын яндырып киткәннәр, фәкать сугышта унбиш-егерме кешеләрен югалтканга, яңадан үч алырга килү ихтималлары бар, имеш. Шуңарга күрә бөтен җәйлеккә чыккан кешеләр качалар икән. Агишевлар гаиләсе дә бик курыкканнар, китәргә карар биргәннәр. Ләкин монда Харбинда холера булганга, мулла берлән Заһидулла килгәнгә килгәннәр. Агишевлар киңәштән соң үзләренең гаиләләренә кайтырга карар бирәләр. Мулланың фатиры да хәзер булмаганга, бала-чага берлән холерага барып керү дә уңайсыз булганга, ул дачада кала. Ахырдан без киңәшкә катышып, муллаларга без барып, бергәләп торырга карар чыгарамыз. Вә шул карар буенча, мин 15 нче августта мулла берлән Ичанйога

---

* Хунхузлар – Кытайның төньяк-көнчыгыш өлешендә (Маньчжурия), шулай ук XIX гасырның II яртысында – XX гасырның I яртысында Россиянең Ерак Көнчыгыш өлешендә, Корея һәм Монголия тирәсендәге территорияләрдә оешкан банда әгъзалары.

киләм. Ләкин Ичанйода безне тагы бер күңелсезлек каршы ала. Күпләп ирләр килгәч, хунхуз куркусы бетә дә икенче кәефсезлек бөтен өй өстендә падишаһлык сөрә. Гайшә ханымның бердәнбер углы бик каты авырый, шуның настроениесе бөтен өй эченә сираять итә[1]. Һәм дә, бала авырганга, Агишевлар гаиләсе китә алмый, дачада кала. Ул гына булмый, иртәгесен мулла авырырга тотына. Ул бүлмәгә кереп ята. Өйнең икенче хуҗа хатыны Заһидә ханым (мулла хатыны) шәфкате һәмширәлеккә[2] әверелә. Шулай итеп, өй больница кыяфәтен ала. Сүзләр: Ибраһимның хәле ничек? Дару бирдеңме? Клизма куйдыңмы? Доктор килдеме? Ни диде? Мулланың хәле ничек? Борыны кайттымы? Эссесе беттеме? Берәр нәрсә ашадымы-эчтеме? Монда язарга утырып, бернәрсә уйлау кайда? Гакылдан язмасаң, ул да табыш инде. Менә шулай торганда Ибраһимның хәле тагы начарланды. Харбиннан Әмрулла әфәнде килде. Малайның хәле начарланганын күреп, Харбиннан доктор чакырдылар. Заһидулла барып, бер яһүд докторын алып килде. Яһүд шунда килеп, бер мәртәбә карар өчен, үзләреннән өч-биш мең сум алган (яшел акча берлән). Ялганчы гына бер яһүд докторы. Үзләре шуңарга ышаналар. Әлбәттә, яһүд булмаенча, мөселман докторы булса, профессоры булса да, ул кадәр акча да бирәчәк түгелләр иде, ошатачак та түгелләр иде. Шул больница һавасында бер-ике-өч көн вакыт үтеп китте. Мулла бераз терелә башлады. Безгә мондагы хәят тагы без теләгән хәят түгеллеге мәгълүм булып җитте. Без аерым-аерым бүлмәләр эзләү юлына керештек. Ләкин миңа, алай иткәндә, тагы паспорт мәсьәләсе килеп туа. Шул мәсьәләне хәл итә алмый торганда, яңа вакыйга булды. 19 нчы августта өйләдән соң сәгать алтыларда Агишевларның верандаларында чәй эчеп утыра идек, бердән, бер-ике мәртәбә мылтык тавышы ишетелде. Бу нәрсә? Хунхуз килдеме, дип, карар чыгарырга өлгерә алмадык (хунхузны көтү һаман дәвам итә инде), пулеметтан ату башланды. Бакчада берничә пуля төшеп ярылды. Без, чәйләремезне салган пиялаларымызны ташлап, өйгә кереп бикләндек. Балаларны идәнгә яткырдык. Ләкин бер тәрәзә ачык калган. Аны ябарга барырга мөмкин түгел. Бер туктамаенча мылтыктан һәм пулеметтан ату

[1] Сираять итә – күчә.
[2] Шәфкате һәмширәлеккә – шәфкать туташына.

дәвам итә. Урамда көтү берлә мылтык күтәргән кытай солдаты ата-ата йөгерәләр. Кемгә аталар, кемне аталар, һичнәрсә мәгълүм түгел. Бу йөгерүчеләр хунхузлармы, кытай солдатларымы (хунхузлар гаскәрдән качкан солдат төркеменнән гыйбарәт булганга, аларны аерырга мөмкин түгел). Хунхуз кайдан килгән? Пулемет хунхузныкымы, гаскәрнекеме? Һичбер нәрсә мәгълүм түгел. Әнә безнең бакчага бик күп шул кораллы кытайлар тулды. Алар бер туктамаенча «бах-бух» колак төбендә мылтык аталар. Әнә безнең өйнең алдына бик күп кытай солдаты җыелды. Алар бик кызу вә әллә ни сөйлиләр, быгыр-быгыр киләләр, «бах-бух» әллә кая аталар. Без һәммәмез, тәрәзәдән кергән пулядан сакланыр өчен, идәнгә сузылып ятканмыз. Балалар, хатыннар, ирләр – һәммәсе залга яткан. Тавыш ишетелмәсен өчен, һәммәмез эчтән генә сулыймыз. Хатыннар иман әйтә. Ирләр, куркуларыны бастырыр өчен, тәмәке кабыза. Балалар тәкбир әйтә. Мылтык, пулемет тавышы кызуланганнан кызулана бара. Менә атышу бераз басыла. Ирләр гайрәткә килеп, урыннарымыздан торып, икенче бүлмәләргә чыгамыз. Ерактан гына урамны карыймыз. Мин ачык тәрәзәле бүлмәдә калган чемоданымны алырга чыгам (эчендә җәмәгать акчасы кырык меңләп бар). Барып кына життем, менә тагы атышу кызулана, тагы безнең өйнең алды-арты бөтен әйләнәсе тавыш берлән тула. Бөтен почмагыннан мылтык тавышы чыга. Мин чемодан янында идәнгә ятам. Ләкин бу бүлмә ике ягында бер ягы ишеккә караганга, тәрәзәсенең берсе ачык булганга, бу – фәкать иң куркынычлы урын. Мин, акрын гына чемоданымны алып, күкрәк берлән шуып-шуып, күрше бүлмәгә чыгам. Анда бер генә тәрәзә. Караватт астында Петропавелның Рабига ханым Ибраһимова кереп яткан. Идәнгә сузылып ятсаң, тәрәзәдән күренә. Менә комод. Шуның берлән күрше бүлмә арасында буш урын бар. Шунда кереп посам. Хәзер мин урамнан күренмим. Һәм дә кыйбла тарафы тәрәзәсеннән атканда комод берлән сакланганмын да. Ләкин күрше бүлмәнең ачык тәрәзәсеннән атканда, мин бөтенләй ачыкта күкрәгемне киереп утырам. Кытай солдаты безнең өй янына җыелганнан-җыела бара. Менә бер ядрә безнең тәрәзәгә килеп бәрелде. Бөтен өй «чык» итеп китте. Колаклар яңгырады. Кемгә тиде-тимәде? Сорарга мөмкин түгел. Менә тышкы ишекне шакыйлар. Әнә аны җимерер-

гә теләп төяләр. Өй алдындагы кытай төркеме, бик кызу-кызу сөйләп, әллә кая йөгерешәләр. Кытай тавышы, мылтык тавышы безне чормаганнан-чормый. Җанымыз учымызда. Акрын гына сорыйм, бар да сәламәтме? Безнең бүлмәдә сәламәт. Караваттагы Гомәр сәламәтме? Сәламәт! Ишек төбендәге Хөсәен сәламәтме? Сәламәт. Тагы бәла. Ни күтәргә хәбәрен җыеп йөрешәмез. Тагы тавыш, тагы атыш. Тагы ишек кагу. Хөсәен, хунхузлардыр дип, «мауза, мауза» дип кычкыра (ягъни руслар дигән сүз). Тагы катырак кагалар. Ләкин ишекнең биге ачылмый. Атышу читкә табарак китә. Кытай тавышы азая. Тагы акрын гына чыгамыз. Ишек ачамыз. Бакчада беркем юк. Урамга карыймыз. Беркем юк. Безнең бакча башында бер рус милиционеры гына күл кебек кан эчендә сузылып ята. Ату бетте дип кычкыралар. Урамга чыгамыз. Кораллылар – рус солдатлары. Хунхуз килдеме, киттеме? Нәрсә бар? Юк. Берни юк. Кытай эшелонының солдатлары безнең пулеметны килеп карарга тотынганнар да «кит» дигәч, китмәгәннәр. Шуннан безнең солдатлар левольвердан[1] атканнар. Тегеләр дә ата башлаган. «Пулеметтан җибәрдек, турап салды. Бары качып бетте». – «Соң монда бит шәһәр халкы бар, аларга тияр дип курыкмадыңызмы?» – «Сугыш вакытында халык игътибарга алынмый». Тагы сорашамыз. Тагы белешәмез, чынлап та, шулай булып чыга. Чыгып йөримез, хәбәрләр җыямыз. Дача халкыннан алты кеше үлгән. Болар, әлбәттә, һичбер төрле пулемет та карамаган, нитмәгән дә, фәкать исерек рус солдатының дураклыгына корбан булган. Бер әрмәннең бердәнбер углын пулемет тәмам тетеп чыккан. Безнең күршедә ике фатирны кытай солдаты талаган. Верандада калган минем пиджагымны, кесәсендә акчалар портмонеты белән, Әмрулланың пиджагын кесәсендә алтын чылбырлы яхшы сәгать белән алганнар.

Кич була башлый. Курыккан халык вокзалга кача. Һәр минутта тагы атышу башланыр дип куркып тора. Берсе артыннан берсе хәбәр тарала. Кытай эшалоны вагоннарыннан төшәләр дә Кытай шәһәренә китәләр. Аларның беренче быргычылары бербуйдан кычкыртып тора. Гаскәрне җыялар. Без, ирләр, киңәш итешәмез. Бу өйдә төнгә калырга ярыймы, юкмы? Юк дигән

[1] Дөресе: революьвер.

карарга киләмез. Чөнки кытай солдатлары үч алырга дип һөҗүм башласалар, безнең өйгә таба атачаклар. Шуны хатыннар, балаларга ничек аңлатыйк дип торганда, менә бик күп кораллы рус гаскәре урамны явып[1] килә. Кая барамыз? Кытай гаскәре җыелды. Монда таба һөҗүм башлау ихтималы бар. Тизрәк өйгә кереңез, диләр. Без, шул хәбәрне ишеткәч тә, балаларны күтәреп, авылның икенче очына таба китәмез. Андагы Хөсәен Унишевлар фатирына, кымызханәгә барып торамыз. Барымыз утызлап кеше. Капканы бикләп алып, киләчәк казаны көтәргә телимез. Ату юк, төн була, һаман юк. Көн туа, һаман юк. Икенче көнне Агишевлар берлән Ибраһимовлар китәргә булалар. Без Гомәр берлән кымызханәдә каламыз. Көн дә бүген килә, бүген килә дигән хәбәр арасында яшимез.

Егермесендә Милли Идарәдән телеграмма алдым. Виза хакында өмид юк, диелгән. Актык бер адым дип, егерме икесендә Фуад Владивостокка китте. Мин әле шуннан җавапны көтеп торам. Харбинга кайтсак та, бик начар. Бердән, холера, икенчедән, урын юк. Монда торсак та, бик шәп түгел.

Бу елымыз шулай көтүгә багышланган икән.

*28 нче август*

Кичә Нияз әфәндегә мәктүб язган идем. Шуның җавабы бүген үк булды. Мәсьәлә моннан гыйбарәт. Нияз теге Кытайга барып кайтканнан бирле һаман әле Семеновны күрмәгән иде. Семенов шул көндә Харбинга килгәнгә, Ниязга аны күреп, теге мәсьәләне ачып бетер дигән идем. Бүген Нияз үзе Востокка* үтте. Семеновны күрә алмаган. Ул Востокка китеп өлгергән. Анда баргач, мөмкин булса күрергә булды. Минем эшнең тәмамән бертөрле бетүе өчен, ул мөнәсәбәтнең дә ачык булуы тиеш. Шул көннәрдә Колчак 43 кә кадәр бөтен халыкка мобилизация игълан итте. Ләкин әле Харбин, Востокта мобилизация юк. Мин тагы әләгәм.

*2 нче сентябрь*

Монда хәят шулай бертөрле генә үтте. Бер эш тә эшләп булмады. Күңел тыныч түгел. Хәят та мин теләгәнчә түгел. Ялңыз бер

---

[1] Дөресе: ябып.

* Восток – Владивосток турында сүз бара.

эш булды. Әүвәлдә, кичә кичке поездда мулла берлән Нури Дивиев килде. Нури Дивиев Семеновта адьютант кебек хезмәт итә. Һәм дә соңгы вакытларда татар полкы төзи башлаган. Кичтән сөйләшеп, танышып яттык (моның берлән беренче күрешү иде). Ул, хосусан, безнең берлән күрешер өчен килгән. Иртә берлән чәйдән соң ул безгә теге мәсьәлә хакында, Ниязның Читага баруы хакында доклад ясады. Аның докладлары буенча, Семенов безнең Японниядә китә алмаенча торуымызы белгәч, мөселман халкы алдында бер хезмәт күрсәтер өчен, безне җибәртү юлына керешкән һәм дә Ниязга теге карточканы биргән (ул карточка хакында Нияз безгә өстән генә әйткән иде). Һәм дә аңарга, Япониягә барып, безнең берлән сөйләшергә һәм дә карточка бирелгән кеше берлән таныштырырга кушкан. Үзе безнең хакта тугры чыбык берлән Япония берлән сөйләшкән һәм дә, безнең берлән бергә китәргә дип, бер монгол да Япониягә җибәргән. Ул шул хезмәт берлән безнең мөәссәсәләремез алдында дәрәҗә алмакчы, шуннан соң мөнәсәбәткә кертмәкче булган. Хәзер дә безне киттеләрме, юкмы дип, һаман сорашып тора икән.

Шулай бу сөйләгәнчә тугры булса, Нияз үзе барасы урында безне чакырып, Семеновның зур әһәмият биргән нәрсәсен вак итеп күрсәтеп, бик зур җинаять ясаган була. Безнең өчен китәргә ачылган юлны яңадан каплаган була. Хәзер эш шуны ачып белүгә калды. Нияз кайткач та белешәчәкмез. Бүген Гомәр Харбинга кайтып китте. Мин, насыйп булса, иртәгә китәм. Җомга көнгә, бишенче сентябрьгә – корбан гаеде.

*10 нчы сентябрь*

Мин гаедкә килеп, муллага төштем. Аңарда бик күп халык булганга, аңарда тору миңа да уңайсыз, аңарга да. Ләкин башкача имкян юк. Шулай торып торам инде. Бишендә гаед укылды. Гаедкә мондагы бөтен халык: җәрәхәтле солдатлар, барысы да килгәнгә, мәсҗед шыгрым тулы иде. Мулла бик һәйбәт вәгазь сөйләде. Ләкин монда халык бик аз булганга һәм дә мәхәллә халкының иң зур кыйсеме спекуляция берлән мәшгуль булганга, аның сүзләренә, вәгазьләренә монда зәмин[1] юк. Алар беркемгә

[1] Зәмин – җирлек.

бер тәэсир калдырмаенча, һәбаән мәнсүра итәләр[1]. Мулланың хезмәтеннән кирәге кадәрле файда чыкмый. Шуңарга күрә имкян туды исә, аны зуррак бер урынга алу юлына керергә кирәк. Мулла алдан ук корбаннарын яралы солдатларга ашатырга итеп рәтләп куйган. Һәм дә өч көнгә мөселман солдатларына мәсҗедкә килергә рөхсәт алган. Вә аларны ашатыр өчен, кирәк-ярагын күргән. Гарәфәдә* үк мәсҗед юлына мөселман солдатлары тулды. Барысы да ябык, боек, зәгыйфь. Һәммәсе дә Балтиядән, һәммәсе Идел буйлары. Мескеннәр Колчак гаскәрендә сугышып, эштән чыгып, бетләнеп беткәннәр. Әллә никадәре тифтан үлгән. Боларның күбесе инвалид булгач, өйләренә кайтарырга дип, кулларына бөкре сум сибирский (мондагы бәһа берлән утыз тиен көмеш) тоттырып чыгарып җибәргәннәр. Хәзер өйләре, илләре большевик кулында булганга, халык аптырап, каңгырып йөриләр. Солдатларның сүзләренә караганда, фронтта ике яктан да сугышучы татар-башкортка бу якның русы теге якка әсир була. Казагы артта йөри. Татар-башкорт, мескен, ут эчендә. Теге якта да шулай. Безнең татар балалары теге яктагы Дон Кихотларның** ахмаклыкларына каннарын өмәгә[2] агызалар. Бу яктагылары, Колчак падишаһ булсын өчен, газиз җаннарын корбан итәләр. Икесе дә – кеше эше, икесе дә – үз халкымыз өчен зарарлы эш. Нишлисең соң, үзең эшеңне эшләмәсәң, кеше эшен эшләргә тугры килә шул.

Гаеднең икенче көнендә Омнан*** Гыйбадулла Госманов**** гаиләсе килде. Аларның сүзенә караганда, Милли Идарә тәмамән таралып беткән. Ибраһимны, Шәйхулланы, Гарифны, Гали Еникиевны солдатка алганнар. Аннан соң, диния һәйәтен күздән төшерер өчен, штабс-ахун дип, Баязитов заманасында хезмәттә булынган Сәлимгәрәев дигән бер мулланы зур урынга

---

[1] Һәбаән мәнсүра итәләр – юкка чыгаралар.

* Гарәфә – корбан бәйрәменнән алдагы көн.

** Дон Кихот – Испан язучысы Мигель де Сервантесның дөнья әдәбиятында популярлык казанган «Хитроумный идальго Дон Кихот Ламанчский» романындагы төп герой.

[2] Өмәгә – күмәк эш өчен.

*** Ом – Омск шәһәре.

**** Гыйбадулла Госманов – Уфа бае, иганәче-меценат. 1913–1918 елларда Уфада чыккан «Тормыш» газетасының нашире.

утырткannнар. Диннәр департаменты дигән мөәссәсә әллә нинди карагруһ руслардан җыйналып, мөселманнарның дин эшләренә катнашулары өчен, берничә элеккеге охранникларны җыйнап алып, Себердә мөфтилек дигән мәсьәләне тудырган башкортлар өчен аерым мөфтилек дигән эш китереп чыгарып маташа икән, ягъни алар һаман элеккеге Николай заманасындагы юлларында, мөселманнарга мөселман уларак та бер мөәссәсә җыйдырмау эшендә, әфкяре гомумия берлән хисаплашмаенча, провокацияләр ясап маташалар икән. Безнең бердәнбер булган Милли Идарәмезне төптән корытмакчы булалар икән. Менә русларның аңлы сыйныфының государство төзү тарафындагыларның безнең төрек-татарның шулкадәр хезмәт өчен иткән мөкяфәте[1].

Гаеднең өченче көнне Нияз кайтты. Теге мәсьәләне тагы озын узады[2], сөйләшеп аңлаштык. Мәсьәлә шул, шулай булып чыкты. Нури әйткән кебек үк, Семенов безнең китүне беренче эш иттереп карамаса да, шул кәгазьләргә таянып хәрәкәт итсәк, Европага барып чыгу ихтималымыз бик зур икән. Чөнки шул юлда монголлар киткәннәр. Ләкин Нияз үзенә барырга кушылган шул эшне үзе эшләмәенчә, безнең артыннан анда бармаенча, үзе безне бөтенләй читләтеп кайтарып китерүне мәслихәт күргән. Һәм дә Әмрулланы да шуңарга калдырган. Шулай итеп, безне өстерәп китергәннәр. Безнең Мексикага дигән планымызны да җимергәннәр. Бу карточкаларның әһәмиятен дә тәмамән бетергәннәр. Шулай итеп, ике зур өмидкә тагы зарбә[3] сукканнар. Ахмаклык тәрбиясе шулай булганда, бер халык берлән ни эшли алсын. Менә хәзер Америкада төрле милләтләрнең вәкилләре, җыелып, тагы шул милләт мәсьәләсен куерталар. Американың сенатына докладлар ясадылар. Без дә шунда булсак, без дә үземезнең милләтнең тавышын ишеттерә алачак идек. Димәк, тагы бер зур форсат качырылды, һәм дә тагы чит кешеләрнең безнең эшкә әһәмият бирмәүләре яисә юри эшне вагайтулары аркасында качырылды. Тагы бер хәерле булсын.

Сөйли-сөйли, Семенов мәсьәләсе тагы мәйданга куелды. Нияз, аңарга әллә кайчан барып, шулар хакында доклад ясарга

[1] Мөкяфәте – бүләге.
[2] Узады – сузды.
[3] Зарбә – зыян.

тиеш булса да, һаман әле соңга калдырган. Хәзер аңарга тизрәк барырга тиеш таптык. Андагы әхвальне күрер өчен, Гомәрне дә җибәрергә карар иттек. Алар, шулай итеп, кичә киттеләр. Безнең сибирскийлар[ны] анда товарга алыштырып булмасмы яисә яшелләргә, дип, перевод берлән акча җибәрергә булдым.

Гыйнаять әфәнде Варшауга[1] китте. Аның артыннан, Фуад мәсьәләне суза, дип, хат яздым. Һәм дә хәзрәткә, мөмкин булса, мал алганда безнең акчаны да кушарга үтендем.

*11 нче сентябрь*

Бүген Америка консулына барып килдек. Максат аңардан тагы ярдәм сорау иде. Шул арадагы газеталарда Американың сенатына төрле милләтләрнең мәгъруфлары[2] булуы язылды. Әгәр безне монда өстерәп кайтармаган булсалар, без дә шунда булачак идек. Безнең милләтнең дә тавышы азмы-күпме ишетеләчәк иде. Консул авыру булды. Иртәгә барырга булып кайттык.

*12 нче сентябрь*

Габдулла Газиз* берлән Америка консулына бардык. Америкада хәзерге көндә төрле милләт мәхкүмәләренең[3] вәкилләре җыелуны сөйләп, Американың сенатының шул вәкилләрнең докладыны тыңларга булган карарыны әйтеп, безгә дә Америкага барырга ярдәмдә булуны үтендек.

Консул һаман Токиода сөйләнгән сүзне сөйләде. Ягъни бер телеграмма берлән Вашингтонга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аннан җавап килсә, консул виза бирәчәк. Без бит мөәссәсә вәкилләре, аларга башкача мөгамәлә булырга тиеш дисәк тә, юлы бары бер, дип җавап бирде. Америкада безнең таныш-белешемез, безнең телеграмманың артыннан йөрүче һәм дә безнең большевик түгеллегемезне тасдыйк итүче америкалы кешемез булмаганга, аннан акча әрәм итүгә башка бер мәгънә чыгачак түгел. Шуңарга моңардан да ваз кичтек.

---

[1] Дөресе: Варшавага.

[2] Мәгъруфлары – яхшы эшләре.

* Габдулла Газиз – Газизов Габдулла Кәлимулла улы (?–?), журналист, Троицк шәһәрендә Яушевлар мәдрәсәсендә мөгаллим.

[3] Мәхкүмәләренең – хөкем ителгәннәрнең.

*13 нче сентябрь*

Бүген төнлә берлән Фуад Востоктан кайтты. Һәм дә озын доклад ясады. Маиле[1] моннан гыйбарәт: ул инглиз һәйәтенә барган. Анда шул мәгълүм сүзләрне сөйләп, безгә Аурупага китәргә виза сораган. Инглиз вәкиле: «Соң сезнең Колчак хөкүмәте берлән мөнәсәбәтеңез ничек?» – дигән. Фуад: «Дустанә түгел, дошман да түгел». Инглиз: «Алай булса, ник соң сез Омскидан безнең вәкилдән бер кәгазь алмадыңыз? Аңардан кәгазь булмаенча, без бер эш тә эшли алмыймыз», – дигән. Франциягә барсам да, шул җавап булачагын белдем дә бармадым, ди. Шуннан чехлар берлән мөнәсәбәткә керешергә теләдем. Һәм дә анда дуст-иш аркылы мөнәсәбәткә дә кердем. Алар кулдан килгәнен эшләрмез, дип вәгъдә иттеләр. Һәм дә китәчәк пароходта җибәрергә булдылар. Шуннан соң үземнең мәсьәләм хәл ителгәч, сине сорадым. Аңарга да бер рустан мәктүб булса, кабул итәрмез, дип җавап бирделәр. Мин теге рустан барып сорагач, рус мәктүб язарга да булды, ди. Шуның берлән безнең китүемез тәэмин ителде. Пароход ун-унбиш көннән китәчәк, ди. Менә Фуадның доклады шуннан гыйбарәт. Без Харбинга ул килгәндә шундый имкян булса да, без ул вакытта бик озакка калачак, дип, аннан файдаланмаган идек. Инде хәзер шуннан башка юл калмады. Ләкин бару бик мәшәкать булачак, чөнки без чехның авыру солдаты булып барачакмыз. Болай йөрү, әлбәттә, бик уңайсыз булмаячак. Тиешлесе, алдан бару да бер эш булачак.

Шуны уйлаштык-уйлаштык та барырга булдык. Ләкин Гомәр тегендә. Аңарга бу мәсьәләне аңлатмаенча мөмкин түгел. Аңарга телеграмма бирергә кирәк. Һәр нә исә, шул яктан чуалу ихтималы юк түгел. Бакалым, ни булыр.

*18 нче сентябрь*

Фуад килгәннән бирле, без сәфәр хәзерлекләре күрергә тотындык. Һәм дә Гомәрне белдерергә тырыштык. Безнең мәсьәләнең иң гаҗәлә[2] йире хәзер – Себер акчаларымыз. Аларның миндәгеләре алтмыш өч мең сум. Фуадтагылары йөз мең сум. Мин үземнекеләрне килгәч үк Агишевларга алыштырырга бирсәм дә,

[1] Маиле – м о н д а : «эчтәлеге» мәгънәсендә.

[2] Гаҗәлә – ашыгыч.

аларда, әлбәттә, эштә йөртеп, шул акчаны әллә кайчан алыштырып бирсәләр, Себер акчаларының курсы бик түбәнге булганга, шуны бирделәр. Яшел, романовский алырга теләвемезгә дә, әлбәттә, һичбер төрле ярдәмдә булмадылар. Безнең татарның бит агае бик кыска була. Безнең эшнең башларында аз-маз ярдәм иткән кешеләрнең гайрәтләре ахырына кадәр, әлбәттә, җитмәде. Без, Себер акчаларын төяп, Владивостокка киттек. Ләкин минем паспорт ягым бик начар. Чөнки мин үземнең заграничный паспортымны һаман алыштырмаганга, аны күрсәтәсем килми. Әллә нинди бер үлгән мишәрнең паспорты, бик карт, илле яшендә. Шуннан озак уйлаганның соңында Семеновның татар полкының кәгазьләреннән берсен аламыз да, Востокка командировать ителде дип, үз исемем язамыз. Хәерле булсын. Ләкин өстбаш цивиль[1] булганга, һичбер төрле солдатка охшамыйм. Пограничныйда паспортларны караганда шөбһә уятса, минем хәл бик начар. Тагы бөтен документлар, кәгазьләр – һәммәсе үз янымда, акчалар да, үз чемоданым да. Шуңарга күрә, пограничныйга барып җиткәнче, минем җаным учымда гына. Барып җитәмез. Бөтен халыкның паспорты берлән минем дә ялганнамәмне алып китәләр. Мин, кайвакыт жандармскийга чакыралар дип, әҗәл көткән кебек көтәм. Бу без дигәнчә дә китми. Менә таможкараучылар үтте. Эш бетте. Ләкин ни паспортларны кайтаралар, ни мине чакыралар. Нервлар шулкадәр тартылган. Барып, тизрәк булыңыз, ул ялган кәгазь минеке, үзем яздым, дип әйтердәй буласың. Менә икенче звонок, Аллага шөкер, димәк, минем паспортымны, монда карамаенча, Востокка җибәрәләр. Өченче звонок көтәм. Һаман юк. Тагы көтәм, тагы – юк. Менә бер әһәмиятсез генә солдат, кереп, паспортлар өләшеп йөри. Безнең купега да керде. Үз паспортларыңызны үзеңез танып алыңыз, ди. Мин бик күп кәгазьләр арасыннан үземнең ялганнамәмне тартып алдым. Артына, пограничныйдан, үтте дип, мөһер баскан. Димәк, берни булмаган, димәк, минем шулкадәр шөбһәләнүем юкка гына чыккан. Күңел бераз тынычланып китә. Востокка якынлашамыз. Менә тагы контролер. Бу юлы гаскәри контролер: безнең паспортларымыз эченнән, калтырый-калтырый, үземнең

[1] Цивиль – гражданский, хәрби булмаган (кием).

ялганнамәмне бирәм. Офицер дикъкать берлән карый. Менә хәзер ник сез штатский киемдә, дип сөаль бирәчәк. Вә тагы башка сөальләр берлән минем кәгазьнең ялганлыгын беләчәк. Ләкин офицер, бер сүз әйтмәенчә, минем кәгазьне кайтарып бирде вә шуның берлән минем Востокка керергә хакым барлыгыны да тасдыйк итте[1]. Номерга төшәмез. Анда бүлмә юк. Маташа торганның соңында, бер мөгаллимәне үзен чыгарып, бүлмәсенә керәмез. Ул мәсьәлә дә хәл ителде. Инде теге кәгазьне милициягә заявить иттерү генә калды. Һәм дә военный контрольгә эләкмәү калды. Без шөбһәләнгәнгә, минем кәгазьне язмый торырга кушамыз һәм дә берәр йирдә мөселман арасында бүлмә табарга буламыз. Шулай итеп, бер-ике көн үтә. Беркөнне төнен берлән өйгә кайтсак, безнең бүлмә бикләнгән. Дөбердәтәмез, эчендә бер кеше бар. Ул кем, ачыгыз, димез. Мин – бүлмәнең хуҗасы, ди. Безнең мөгаллимәдән алган бүлмәмез ул мөгаллимәнеке түгел, бер мишәрнеке икән. Мишәрнең дә үзенеке түгел, бер Казан татарыныкы икән. Ул татар малае безнең барлыкны белсә дә, безнең йозакны ватып керүне муафикъ тапкан. Шундагы татар егетләре янына кереп кунарга мөмкин булса да, безгә каршы андый хөрмәтлелекне ясый алмаган. Инде без бүлмәсез каламыз. Маташа торгач, тагы хуҗасы киткән бер бүлмәгә керәмез. Шул ара да булмый, номерда документларны һәм дә бүлмә хуҗаларын тикшерәләр. Чөнки Востокта торыр өчен хәзер махсус рөхсәт кирәк. Номерда бүлмә тотар өчен, тагы рөхсәт кирәк. Бездә боларның берсе дә юк. Ләкин Алланың ярдәме берлән без читтә каламыз. Безнең документлар каралмый, безнең бүлмә элеккеге хуҗасыныкы булып кала. Шул тикшерүдән куркып булырга кирәк, конторщик безнең документларны да әйтеп яздыра. Һәм дә миңа кайтарып та бирә. Шуның берлән минем тагы бер куркуым йитеп кала. Шулай итеп, бүлмәне рәтләп йөргәндә, чехларның штабына барамыз, анда безгә тагы бер кәгазь бирәләр. Һәм дә миңа яңа исем биреп (минем исемем Һайнек Схазел, Hynek Schazel*), безне якын бер чех мөәссәсенә җыялар. Анда безнең беренче пароход берлән китәчәгемезне белдерәләр. Һәм дә

[1] Тасдыйк итте – раслады.

* Бу исем латин хәрефләре белән язылган.

пароходның 28 нче сентябрь киләчәген вәгъдә бирәләр. Мин, кайтып, тагы Гомәргә телеграмма бирәм. Һәм дә китүче артыннан хат язам. Ләкин җавап һичбер юк. Менә егерме сигезе җитә. Тагы барамыз, пароход әле һаман килмәгән. Тагы бер көн соң килергә чакыралар, утызында барамыз. Пароход килгән һәм дә иртәгә китә дә, сез иртәгә килеңез. Хәзерләнеп килеңез, диләр. Без бик кызуланып хәзерләнергә тотынамыз. Тагы теге Себер акчасы. Аңарга иен алырга мөмкин түгел. Чөнки яшел чыш-чыш ике тиенгә романовскийны алыштыручы юк. Ахырдан, этләнә-этләнә, алтын табып аламыз. Һәм дә мыскалы ике йөз җитмеш сумнан биш йөз илле ике мыскал алтын аламыз. Яшелләрне никадәр алыштырырга теләсәк тә, һич мөмкин түгел, шуңарга күрә аларны төяп китәргә карар бирәмез. Көн буе әле бер нәрсә, әле бер нәрсә эзләп йөдәп бетәмез. Әйбер табу бик авыр булганга, бик күп нәрсә таба алмыймыз. Мәсәлән, минем мендәрем юк, юрганым юк. Шулай итеп барлы-юклы хәзерләнеп, икенче октябрьдә барамыз. Безгә кәгазьләрне бирәләр. Пароходның тагы бер көн кичегүен бәян итәләр. Безнең калган әйберләрне тагы бер кат эзләп чыгамыз. Акча алыштырырга тагы тырышып карыймыз. Безгә ак алтын тәкъдим итәләр. Ләкин бик кыйммәт, мыскалы яшел берлән биш йөз сум. Без дүрт йөзгә алмакчы буламыз, бирмиләр. Тагы шуның нинди мал икәнен белмәгәнгә шөбһәләнәмез дә, безгә пушнина тәкъдим итәләр. Ләкин пушнина бик начар булганга алмыймыз. Шулай итеп, теләр-теләмәс яшел акчалар төяп китәргә мәҗбүр буламыз.

*3 нче октябрь*

Көн иртәдән үк бик матур. Без, иртә сәгать җидедә торып, җыймаган нәрсәләрне җыеп, чех штабына китәмез. Анда безне пароходны озатучы капитан көтеп торачак иде. Ул инде пристаньга киткән, безгә пароходка барырга кушкан. Монда пароходның бүген сәгать дүрттә сәфәргә чыгачагын беләмез. Өйгә кайтып, мин Харбинга Гыйнаять муллага хат язам. Милли Идарәгә вә башка таныш-белешкә Шанхайдан язмакчы буламыз. Берәр сәгатьтән пароходка чехларның кечкенә пароходлары барачак булганга, шуңарга өлгерергә ашыгамыз. Чөнки пристаньда рус милициясенең безгә бәйләнүеннән шөбһәләнәмез.

Пристаньдагы пароход тиз китәчәк булмаганга, без, кайтучы капитанны яллап, әйберләремезне төяп, диңгез уртасындагы «Karachi maru»* пароходына китәмез. Анда безне теге чех офицеры каршы ала. Пароходны озатачак офицерга безне таныштыра. Урын күрсәтәләр, йирләшәмез. Безнең урын түбәндә, солдатлар берлән бергә, бик үк шәп түгел. Пароход яңа булганга пычрак түгел. Монда килгәч, безнең ашарга бернәрсә дә алмаганымыз мәгълүм булды. Безне озатучы Исхак дигән егетне әйберләр алырга җибәрәмез. Сәгать өчләрдә пароходны озатырга мондагы чехларның олуглары киләләр. Мондагы солдатлар аларны музыка берлән каршы алалар. Чехлар үзләренең милли гимннарын уйныйлар. Уйнарга хаклары да бар. Чөнки алар юктан бер дәүләт мәйданга китерделәр. Без, зур бер милләт була торып, үземезнең вәкилләремезне милләт вәкилләре дип таныттырлык дәрәҗәсенә килә алмадык. Үпкәләрсең дә, көнләрсең дә, көләрсең дә, егъларсың да. Безнең Исхак та ашамак, эчмәк алып килгән. Ләкин тагы чәйнекне оныткан. Аны тагы шуларны алырга җибәрәмез. Ләкин дүрт сәгать биш минутта безнең пароход, якорьны күтәреп, диңгезгә чыга. Мескен безнең Исхак кайта алмаенча кала. Русияне ташлап илле, алтмыш көнлек диңгез сәфәренә чыгамыз. Һәм дә чех солдат кәгазе берлән, рухан бөтенләй безгә башка бер халык арасында. Аларның кунагы сыман шул озын юлга китәмез. Ни булачак, ни булмаячак – көзге төн кебек караңгы. Безнең күрше чехлар безне дустча каршы алалар. Мөнәсәбәтләре әлегә бик һәйбәт, бара-тора ни булыр. Диңгездә мөсафир бер чех каршы ала. Көн матур, һава ачык. Җил аз. Дулкын юк дәрәҗәсендә. Востокның бормалы-бормалы бугазларыны карап үтәмез. Аның ныгытылган флакларын[1] күздән кичерәмез. Флакларның иң әһәмиятлесендә, Востокка керә торган юлның тәмам бугазында, инглиз байрагы җилбердәп тора. Димәк, Востокка керү юлыны инглизләр үзләренең «әминиятьле[2]» кулларына алганнар. Кичкә кадәр кәеф күтәренке булып тора. Соң гына йокларга ятамыз. Диңгез эчендә бүген беренче

---

* Пароход исеме латин хәрефләре белән язылган.

[1] Флакларын – монда: флагштоклар күздә тотыла.

[2] Әминиятьле – ышанычлы.

көн. Инде бер яктан да йир күренми. Кайчан коры күренәчәк, кайчан без тагы йиргә басачакмыз, кайчан Русия тупрагына яңадан керәчәкмез – бер Аллага гына мәгълүм. Мондагы команданың сүзенә караганда, без, Шанхайда туктамаенча, тугры Сингапурга* китәчәкмез. Сингапурда ун көннән соң булачакмыз. Аңганчы һичберноктада туктамаячакмыз. Бу хәбәр безнең планны боза, димәк, безнең Милли Идарәгә Харбинга язачак мәктүбләремез Сингапурсыз язылмаячак. Һәм дә француз, инглиз цензоры аша гына китә беләчәк. Бер бу кәефне җибәрә. Ләкин нишлисең. Безнең хәзер бөтен планымыз иттифакый[1] вакыйгаларга баглы. Максатымыз да иттифакый вакыйгаларның кулында әсир генә.

*4 нче октябрь*

Без, солдат булганга һәм дә хәятта торырга бик ашыга торган яңа дәүләт ясаучы чех солдаты булганга, бик иртә аякка калкамыз. Иртә торганда, безнең бүлмәмез минем элекке яткан төрмә бүлмәсенә бик охшый. Мондагы кылыныш, йөреш тә шундагы кебек. Чәй артыннан, кайнар су артыннан чабу да андагы кебек. Халыкның омтылган йиреннән ерак булуы да андагы кебек. Фәкать юыну урыннары гына зинданныкына охшамаган. Японнар суны бик сөйгәнгә, бик күп краннар берлән киң тәһарәтханә ясаганнар. Көн бүген дә бик матур. Пароход, кечкенә генә дулкыннар арасында күкрәгеннеп киереп, алга бара. Бүген без тәмамән мондагы режимга табигъ[2]. Иртә берлән алтыларда чәй эчәмез, уникедә аш ашарга тиешмез. Бишләрдә чәй. Ләкин ашханәсе начар булганга, боларның берсе дә вакытында үтәлә алмый. Мин инглизчә укытырга бер мөгаллим табам. Иртәгә дәрескә башларга буламыз. Иртәгә иртә сәгать биштән алтыга кадәр генә чәй була диеп игълан иткәнгә, иртәрәк ятып йоклыймыз.

---

* Сингапур – Көньяк-көнчыгыш Азиядәге күпмилләтле шәһәр-дәүләт, дөньякүләм финанс үзәге санала. Ул шул исемдәге утрауда урнашкан. Малакка ярымутравының көньягындарак. Малайзиянең көньяк өлеше белән чиктәш.

[1] Иттифакый – очраклы.

[2] Табигъ – буйсындык.

*5 нче октябрь*

Бүген иртүк сәгать биштә аякка калкамыз. Тышта чиләкләп ягмур актарыла. Диңгез тәмам дулаган. Безнең пароходны йомычка кебек уйнатып йөртә. Болытлар шулкадәр түбән, пароходның арты томан берлән капланган. Кайда диңгез, кайда болыт башлана – аерыр хәл юк. Аста да су, өстә дә су, уңда да су, сулда да су. Таһарәтханәдә су, истирахәтханәдә[1] су, ятак бүлмәсендә дә су. Утырып торырга болай да урыннар булмаганга, диңгез бик каты селеккәнгә, халыкның иң зур кыйсеме урыннарына яткан. Ләкин йокларга яткан кебек түгел. Авырудан яткан кебек сузылган. Безнең бүлмә хәзер хастаханә кыяфәте алган. Миңа бик каты томау төшкәнгә, баш бик авырта. Кәеф бик төшенке. Шуның өчен һавадагы авырлык бөтен җанны, тынны баса. Ашыйсы килми, мигъдә начар эшли. Күңел күтәрелми, ашка кадәр вакытны бүлмәдә ябылып ятарга мәҗбүрмез. Ләкин бүген һәрнәрсә безгә каршы, аш та вакытында юк. Сәгать 12 дә ашалачак ашны безгә сәгать алтыда гына бирәләр. Дүрттәге чәйне тугызда гына өлгертәләр. Ул гына да түгел, безнең пароход радио берлән безнең юлымызда Формоз аталары* ачыкларында зур тайфун уйнавыннан телеграмма алган. Шуңарга күрә ул Кореяның яры буенда бер авылдан ерак түгел бер култыкка кереп сыенырга мәҗбүр. Монда озак калачакмы, түгелме – бер Аллага гына мәгълүм. Кич берлән төн ачыла. Дулкын кимемәсә дә, якорьдагы пароходны улкадәр чайкамый. Ай, йолдызлар, берсеннән-берсе узышып, диңгездә коеналар. Лезгинка биегән кебек, йөгерепйөгереп, берсен берсе куалар. Бик озакка кадәр йокларга ятмыймыз. Чөнки ачык һавага, матур күккә, йолдызлы диңгезгә һәммәмез сагынганмыз. Иртәгә монда озак калачакмызмы, әллә иртүк китәчәкмезме – мәгълүм түгел. Берәр пристаньда булса, чыгып, мәктүбләр салырга, бер кирәкле нәрсәләр алырга уйлаган идек. Бәхетсезлеккә каршы, балыкчы авыллар янында гына туктадык.

[1] Истирахәтханәдә – ял бүлмәсендә.

* Формоз аталары – Формоз утраулары – Тын океандагы көнчыгыш Кытай ярларына якын булган зур утрау.

*6 нчы октябрь*

Бүген уянганда, безнең пароходымыз һаман Кореядагы култыкта була. Көн бик матур. Һава ачык. Ләкин җил бик каты исә. Безнең култыкка безгә башка тагы ике пароход кереп сыгынганнар. Иртә берлән, өйләдән соң кузгаламыз, дигән хәбәр чыга. Ләкин кичкә таба ул хәбәр тагы дөрест булмый. Без шул култыкта кунарга каламыз. Радио телеграфның хәбәренә күрә, Япониянең яры буенда тайфуннан бер инглиз пароходы баткан. Тайфун әле һаман ачык диңгездә хөкем сөрә. Көн буе вакыт тик үтә. Чехларның оркестры бер-ике мәртәбә музыка уйнап концерт ясый. Йырчы груһы берникадәр мәртәбә җыелып йырлыйлар. Пароходның хезмәткәрләре – япон егетләре – фехтование ясап маташалар. Төн дә бик ачык, болытлар бик аз. Ләкин җил һаман бетми. Без тау арасында булсак та, кай вакытлар әле аннан, әле моннан килгән җил аз гына пароходны телеп алып, селкеп сала. Бүген ужин булмый, азыклары аз булганга, икътисад ясыйлар булырга кирәк. Хәбәрләргә караганда, иртәгә таң берлән юлга чыгачакмыз. Ни булыр, анысын киләчәк күрсәтер. Гомумән, хәзерге вакыт – Япон-Кытай диңгезләренең иң шашкан вакытлары.

Сингапурга барып җитсәк, куркынычлы урыннан бераз котылган буламыз. Ләкин әле Сингапурга бик ерак. Аз дигәндә ун-унике көн барырга кирәк. Бу вакытта ниләр булыр, ниләр булмас – бер Аллага гына мәгълүм. Үземнең кәеф шәп түгел. Мигъдәм тагы эшләми. Инглизчә укырга һаман тотына алмадым.

*7 нче октябрь*

Бүген без йокыдан пароходның якорь күтәрү тавышына уянамыз. Киенеп, юынырга чыкканда, пароходны инде кузгалган табамыз. Көн матур, һава саф, күк ап-ачык. Шимале шәркый[1] җил шактый куәтле иссә дә, диңгез зур дулкынлы түгел. Көн буе Корея буйлап киләмез. Өйләдән соң сәгать өчләрдә рус-япон сугышында шөһрәт тоткан Цусима аталарын кичәмез. Кояш баеганда гына, киң диңгезгә ачыламыз. Ачык диңгез, һава бераз сәрд[2], җил куәтлерәк, ләкин дулкын улкадәр көчле түгел. Һич-

---

[1] Шимале шәркый – төньяк-көнчыгыш.

[2] Сәрд – салкын.

беркем дә диңгез хастасына тотылмый. Бик озакка кадәр тулып килә торган айның диңгездә йөзүен карап рәхәтләнәмез. Бик озак, пароходның төрле почмагына чыгып, Җидегән җиде йолдызны эзлимез. Ләкин күкнең һичбер почмагыннан таба алмыймыз. Аны тапмагач, Тимерказык йолдызын да була алмыймыз[1]. Җидегән җиде йолдыз кая киткәндер, иртәгә чыгармы, юкмы – белмим. Безнең пароход хәзер Формоз ачыкларына таба тугры хәрәкәт итә. Һичбер йиргә туктамаенча, Сингапурга бармакчы була. Булдыра алырмы, юкмы – анысы мәгълүм түгел. Пароходта әле авырлыклар бер дә юк. Пароход шактый яңа, ләкин ашханәсе кечкенә булганга, ашау-эчү шәп түгел. Кичке ашны сәгать дүрттә бирәләр дә төн буе гаскәр ач кала. Икмәге дә чиле-пешле, кайнар суы да бик рәтсез. Шуңарга күрә сәфәр бик озайса, авыру сырхау булу ихтималы бик якын. Доктор берлән сөйләштем. Дару юк дияр дәрәҗәдә. Больницасы бик начар, дип зарлана. Бүген инглизчә укый башладым. Ләкин мөгаллим һичбер ысулы тәгълим[2] белми торган кеше булып чыкты. Файда итү бик шөбһәле. Мигъдәм бераз юлга куелыр кебек булды. Ачлы-туклы тору, ахрысы, яхшы тәэсир итә бирә.

*8 нче октябрь*

Бүген һава яхшы. Көн буе шимале гарби[3] җил иссә дә, зур дулкын юк. Иртә берлән сәгать тугызларда Япониянең иң очындагы кечкенә генә бер җәзирә[4] башыннан үтәмез. Җәзирә шактый озын, өч-дүрт сәгать күздән югалмый. Безнең пароход хәзер Кытай диңгезеннән бара. Иртәгә иртән Шанхай тугайларыннан үтәргә тиеш. Көн буе һава ачык булып килгәнгә, халыкның кәефе йирендә. Барометр киләчәктә дә ачык һава күрсәтә. Көн суык та түгел, эссе дә. Алай да без коенырга бераз куркамыз. Тәннәр керләнде. Күлмәк, штан да каралды. Юынмаенча алыштыруның мәгънәсе юкка, йылырак һава чыкканчы шулай барырга уйлыймыз. Ике-өч көннән без Формоз атасына җитәчәкмез. Анда һава йылыга алышыначак. Безнең барачак юлымыз ун мең миль,

[1] Була алмыймыз – таба алмыйбыз.
[2] Ысулы тәгълим – укыту методикасы.
[3] Шимале гарби – төньяк-көнбатыш.
[4] Җәзирә – утрау.

ягъни унсигез мең чакрым. Бөтен юлга дип утырып чыккан пароходымыз – Япон компаниясе «Карачи мару» («Karachi maru») дигән пароходы, зурлыгы дүрт мең тон. Бару тизлеге сәгатенә ун-унбер миль (ягъни унсигез-егерме чакрым). Пароходтагы чех гаскәре барысы мең дә илле, пароходның хезмәткәрләре – илләләп япон. Чех хөкүмәте компаниягә пароход өчен көненә җиде мең иен түли. Ашату-эчертүне үзе алып бара. Көненә өч иенлык ашатканда да, бер гаскәр көненә ун иенга төшә. Без шулар арасында. Ике ай юлда булсак, без чех хөкүмәтенә икемез бер мең дә ике йөз иенга мал булачакмыз. Ни өчен безгә шулкадәр акча сарыф итәләр? Ник без шул юмартлыкны кабул итәмез? Чехословак дәүләте яңа бер дәүләт булганга, әлбәттә, аларга дөньяның әфкяре гомумиясендә[1] яхшы назар казану матлуб. Шуның өчен безне дә бушлай алып баралар. Икенчедән, алар, безнең халыкка зур мәшәкать салганга, үзләрене шул халыкның вәкилләре алдында азмы-күпме бурычлы иттереп хисап итәләр булырга кирәк. Без шул хөрмәтне кабул итәмез. Чөнки бу халык бер ел эчендә безнең халыктан бик зур хөрмәт, бик зур ярдәм күрде. Аларның илле меңле гаскәре иң аз дигәндә безнең халыкта берәр генә көн кунак булды. Ул илле мең көн була. Безнең аларда булачак кунаклыгымыз, бик озын булса, икемезгә йөз егерме-йөз илле көн булачак. Аларда милләтнең алачагы кырык тугыз мең дә сигез йөз илле иен кала әле. Шуңарга күрә бу хөрмәтләр, сыйлар һәммәсе дә – үземезнең хакымызның меңнән берсен алуымыз гына. Кич бераз болытлы. Тулы ай кечкенә генә болыт, дөресте, сүрән эчендә йөзә.

Иртәгә һава ничек булачак, ниләр булачак, бер Аллага гына мәгълүм. Әлегә кадәр әле беремез дә диңгез хасталыгына тотылмадык. Мигъдәм бераз рәтләнеп килә. Ләкин ашарга, эчәргә шактый аз. Бүген чех солдатлары комендантка аш азлыгыннан барып зарландылар да, ни булып калыр. Кич берлән бер кош бик озак пароход янында очып йөрде, йөрде дә килеп кунды. Мескен, бик арыган булырга кирәк. Кара кош, безнең якта андый кош күргәнем юк. Бу якның козгыны булырга кирәк.

[1] Әфкяре гомумиясендә – гомумфикерендә.

*9 нчы октябрь*

Һава ачык, көн йылы. Йил тугры гаребтән исә. Ләкин дулкын кечкенә. Иртә сәгать тугызларда диңгездә кешесез йөзеп бара торган берничә балыкчы көймәсенә очрыймыз. Кешеләре булмаганга, пароход туктамый. Үткән тайфунда яр якасыннан ычкынып киткән көймәләр булырга кирәк. Сәгать 12 ләрдә җилкәнле ике көймәгә очрыймыз. Берсе шәрыкка таба бара, берсе – гаребкә таба. Монда кечкенә-кечкенә утраулар булырга кирәк. Төш вакытларында көн шактый эсселәнә. Бик күп солдат коеналар. Мин дә коеныրга телим дә, су туктаган чакка тугры киләм. Бүген безнең пароход янына шактый күп кошлар киләләр. Элгәре куркып, кунмый йөриләр, ахырдан куналар. Кошларның бер төрлесе – күгәрченнәр, ләкин төсләре безнең күгәрченгә охшамаган, сорырак. Бер төрлесе – бытбылдык кебек кош. Бер төрлесе – май песнәге кебек. Араларында бер каракош та бар иде. Аны лачын, диделәр. Көн бик һәйбәт үтте. Бүген айның ундүртесе булырга тиеш. Ай бик матур. Ләкин көн бераз томанлы. Кояш та болытка батканга, аны күрә алмадык. Кич берлән Тимерказык йолдызы эзләдек. Кайбер кешеләр бер йолдызны күрсәттеләр. Ләкин ул булуына ышанып бетә алмадык. Чөнки урыны бик югары. Ул монда шактый түбән булырга тиеш иде. Җидегән җиде йолдызны таба алмадык. Һава сүрәнле. Бүген чехлар тагы концерт ясадылар. Иртәгә иртүк Формоз атасына барып җитәчәк, имешмез. Пароходлар очрамады. Радио телеграмма бүген бик күп эшләсә дә, дөньядан һичбер хәбәр ишетмәдек.

*10 нчы октябрь*

Иртәдән һава ачык. Җил сабыр. Сәгать тугызларда безнең пароходны ике морҗалы бер пароход үтеп китә. Һәм дә бик тиз күздән югала. Шуннан соң гына без үземезнең пароходымызның үгез[1] бер уй берлән баруын беләмез. Сәгать уникеләрдә безнең пароход Формоз атасы берлә Кытай арасындагы бугазга керә, ләкин бугаз бик киң булганга (ике йөз илле чакрымнар), без Формоз ярын да, Кытай тупрагын да күрә алмыймыз. Кичкә таба сәгать алтыларда юлда кечкенә-кечкенә атаулар очрый. Караңгы

[1] Үгез – монда: «кире» мәгънәсендә.

төшкәч, аларның һәммәсеннән дә маяклар ялтырый. Кичкә таба җил бераз куәтләнә төшә. Ләкин дулкын артык зур түгел. Диңгез хасталыгы беркемдә дә юк. Көн һәм төн бик йылы. Мин бүген коендым. Бүген без чыкканга бер атна тулды. Бу атнаны әле шактый яхшы үткәрдек. Киләчәк атна да шулай үтсә, киләсе җомга без Сингапурда булачакмыз. Аллага тапшырдык.

*11 нче октябрь*

Бүген без торганда, пароход Кытай яры буендагы бер култыкка таба кереп бара иде. Торып җитәргә өлгермәдек, якорь салдылар, пароход матур бер йиргә килеп туктады. Туктаган йиремез – Кытайның зур гына сәүдәле бер диңгез буе шәһәре. Исеме – Һамой. Моннан Гонконгка җитмеш миль икән. Барометр төшкән, имеш. Капитан, куркып, шул култыкка чыккан икән. Ләкин без култыкка кергәндә, җил бик басынкы иде. Куркырлык һичнәрсә юк иде. Аңарга башка ачык диңгезгә Кытай балыкчылары карван-карван чыга иде. Димәк, әллә нинди зур җил – тайфунга гаепне ябу дөрест түгел. Монда ни булса, японның бер хәйләсе бар. Хәйләсе, әлбәттә, тик кенә торып, чехословактан акча алу. Чөнки болар пароходка көнлекләп түлиләр. Барганына да түли, торганына [да]. Шуңарга күрә японга хезмәтчесен арытып, машинасын ашатып йөрергә бер дә лөзүм юк. Берәр көн пош-пош иттерәдер дә берәр култыкка кереп хәл җыя. Икенче тәфсир[1] – пароходның йөге бик аз. Ул телеграф берлән йөк эзли булырга кирәк. Менә монда килгәч тә, агентларны чыгарып җибәрделәр. Әүвәл төрле якка телеграмма бирделәр. Без шуның җавабын көтәмез булырга кирәк. Ачык иттереп әйтү уңайсыз булганга, барометр төште – аңарга сылтый. Шул ук диңгездән килеп, шул юлдан инглиз пароходы үтеп китте, аның барометры төшмәде, күрәсең. Кич бик матур. Һамой култыгы төнлә берлән бик күңелле. Утлар бик мәхәббәтле карыйлар. Һава бик йомшак. Бездәге май һавасыннан да татлырак. Акрын гына искән җил аз гына тәнне сөеп китә. Иртәгә иртүк кузгаламыз дигән хәбәр чыкты. Дөрест булырмы, юкмы – Аллага гына мәгълүм. Ичмасам, бер шәһәргә туктаса, чыгар идек, күрер идек. Болай читтән селәгәй агызып тору һәркемгә бик начар тәэсир итә.

[1] Тәфсир – аңлатма.

*12 нче октябрь*

Моннан тәмам бер ел элек без, большевиклардан качып, барымыз Уфадан чыктык. Бик зур өмидләр булмаса да, шактый күп зыялымыз бергәләшеп, Себердә милли хәрәкәтне дәвам иттерә алуымызга иманымыз камил иде. Инде ел тулды. Хисап бирергә вакыт җитте. Ләкин җавапта «һич» дигән сүзгә башка берни юк. Без үземез теләгән милли хезмәтнең йөздән берен дә итә алмадык. Сәбәбе бик күптер. Ләкин иң зуры – Себердә арка таяначак бер рухның юклыгы. Себернең мулла, мәзине гыйльми түгел, сыер кебек корсак тутырган хайван. Себернең сәүдәгәре милли мәгънәдә сәүдәгәр түгел, ул яисә жулик, яисә мәгънәсез мөтәгассыйб[1], яисә имансыз хулиган, Себернең зыялысы юк. Шуңарга күрә монда милли әйбер дә юк. Шуңарга күрә эшләргә дә имкян юк. Бүген – 12 нче октябрь. Үткән ел без телячий вагонда, милләтнең зыялысының шактый зур бер кыйсеме оешып, Себергә һиҗрәт итеп[2] бара идек. Бүген, 12 нче октябрьдә, без Уфадан алып чыккан көчне дә вәйран итеп[3], һәлак итеп, бер-беремезгә ышанмый торган ике кеше, чех инвалиды булып, Кытай диңгезе буйлап Европага таба барамыз. Милләтнең мәгънәвисе безне, үзенең бәйнәлмиләл[4] сәхнәгә чыга торган вәкилләрен, вәкил иттереп җибәрерлек булмады. Милләт оешкан. Милли көче – тарихи зур вазифаны үтәүдә үзенең вәкилләрен милләтнең шәэненә[5] мөнасиб иттереп сакларлык дәрәҗәдә генә, минем теләнеп җыйган акчамны җибәртерлек дәрәҗәдә оешкан хәлгә килә алмады. Ул интрига урыны, хулиганлык урыны булды. Без хәзер, үземезгә йөкләнгән вазифаны үтимез дигән булып, Европага чыгып барамыз. Андагы мәнфәгатемезгә каршы аз гына булса да, бер эш эшли алырмызмы, әллә юкмы – бер Алла белә. Менә хәзер чиләкләп коя торган ягмур астында хатты истиваның[6] даирәсенә кереп барамыз. Без хәзер үземезнең Казаннан утыз биш дәрәҗә

---

[1] Мөтәгассыйб – кире.

[2] Һиҗрәт итеп – китеп.

[3] Вәйран итеп – җуеп.

[4] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[5] Шәэненә – дәрәҗәсенә.

[6] Хатты истиваның – экваторның.

җәнүбтә[1], Кытай диңгезендә хатты истивага таба хәрәкәт итәмез. Тыш, безнең милләтнең истикъбале[2] кебек, дөм караңгы. Безнең ята торган турымыз – безнең милләтнең хәле кебек сасы исле. Безнең мондагы чех инвалидлары арасындагы хәлемез безнең милләтнең рухының тормышындагы урыны кебек. Утырырга, торырга урынымыз юк. Язарга, укырга йиремез юк. Бу хатны чүгәләп язам. Менә инде тугыз тәүлектән бирле юлда. Әле барамыз дигән бер ноктага барып җиткәнемез юк. Табигый юлда өч көндә үтә торган юлны үткәнемез юк. Бу тыгызлык, бу сасылык, бу эсселектә, бу начар ашау, начар йоклау, көн буе аягүрә торып баруга күпмегә чыдармыз? Мең төрле авырулы инвалидлар арасында исәнлекне саклый алырмызмы? Шул өмидсез истикъбаль алдында рухымыздагы пакьлекне саклый алырмызмы? Үземез теләгән Марсельгә барып керә алырмызмы, әллә сырхаулап, эт булып, әйберләремезне югалтып, әллә кайда юлда вәйран булып калырмызмы? Киләсе елгы 12 нче октябрьдә кайда булырмыз, ни эшләрмез? Ни кылырмыз? Җаваплылык мәхфузда[3].

*13 нче октябрь*

Бүген иртә торганда ягмур дәвам итә иде. Кичке сәгать алтыларга кадәр өзлексез яуды. Кояш баеганда көн ачылды. Төн шактый аяз булды. Озак итеп Тимерказык йолдызын эзләдем, таба алмадым. Бераз болыт бар, бераз томан каплаган иде. Җил шимальдән исә. Безнең пароход хәзер кош юлы берлән туптугры бара. Без бүген Гонконгны уздык. Хәзер егерменче градусларда барамыз булырга кирәк. Төн йылы булса да, эссе түгел. Безнең ятак бүлмәсе генә бик эссе. Ятар алдыннан җил бераз куәтләнә, пароход чайкала башлый, ләкин авыру булырлык түгел. Бүген көн бик буш үтә. Утырырга урын юкка, укып та булмый. Мигъдәм тагы начар. Эсселектән бик зур читенлек күрәм. Пароход тагы туктамаса, якшәмбе көннәргә Сингапурга барып җитсәк кирәк.

[1] Җәнүбтә – көньякта.
[2] Истикъбале – киләчәге.
[3] Мәхфузда – күңелдә.

*14 нче октябрь*

Көн өйләгә кадәр ягмурлы. Шуңарга артык эссе түгел. Аштан соң һава ачык, кояш бик каты кыздыра. Яланбаш һавада торып булмый. Кичә көн буе ягмур яуганга, йончыган солдатлар һәммәсе дә пароход өстендә, шуңарга бүлмәмезнең трюмы да бераз һавалана. Алай да трюмдагы пычрак көннән-көн арта бара. Аш өстәле өстендә көн буе, төн буе эшсез солдат, әле пычрак карта уйнап, әле пычрак шатранж[1] уйнап, әле чиртеш уйнап, эштән чыгалар. Шуңарга күрә болай да юылмый торган өстәл өсте тагы кырык төрле пычрак берлән нәҗесләнә[2]. Хәзер инде чирканмаенча ашарлык, эчәрлек урын бетте. Кич үзләренең милли ашларын пешерделәр. Чех солдатлары алдан ук бик көттеләр. Без дә ни булачак дип көттек. Ул шиңгән кәбестә берлән ярты шалкан кыягына киптереп салынган чи камыр булды. Исеме кнедлики икән. Үзе чи, үзе йылы, үзен авызга алырлык түгел. Үзләре бик яратып ашадылар. Күрәсең, милли булуда һичбер мантыйк гакылга йөрми. Юк исә бу ашны нинди генә кешегә (шул ук чехка да) [...] берлән ашатсаң, авызына да алмаячак. Гомумән, әле боларда үзләренең бөтен барлыкларына каршы саф бер мәхәббәт бар. Үзләренең һәрнәрсәләре гакыллы, тәмле, мантыйкый дигән фикер уйламаенча, җыйнакламаенча, кергән дә утырган. Шуның аркасында, күрәсең, болар милли байлыкларын төзи алганнар. Шуңарга күрә аларны үзләренең милли байраклары янына туплый алганнар. Кием берлән пароход өстенә чыгып яттык. Ләкин ягмур ява башлагач, керергә мәҗбүр булдык.

*15 нче октябрь*

Көн бераз болытлы, бераз җилле. Шуңарга кояш шәфкатьсез кыздыра алмый. Алай да чех солдатларының инде йөзгә җитмеше күптән кулмәксез йөриләр. Бу көннәрдә штансызлары да күренә башлады. Хатты истивага җитә-җитә, бөтенләй Адәме пәйгамбәр киемендә калырлар, ахрысы. Минем кебек җирәнә торган кешегә бу ялангачлык тагы зур газап тудырды. Бу ямьсез җәрәхәтле тәнле кешеләр көтүен иртәдән алып кичкә кадәр күз алдында тоту, ашаганда-эчкәндә, йөргәндә, сөйләгәндә

[1] Шатранж – шахмат.

[2] Нәҗесләнә – пычрана.

шуларның ялангач төшләренә бәрелү күңелне уйната, косасыны китерә. Җирәнү, чиркану, хурланудан мөрәккәб[1] бер хис уятып, егъласыны китерә.

Хәзер безнең пароход унынчы дәрәҗәгә таба кереп бара. Мин беренче мәртәбә хатты истивага шулкадәр якынлаштым. Сингапурда без хатты истивадан бер-ике дәрәҗәдә генә булачакмыз. Мин сөргендә вакытта котыб шимале даирәсендә елдан артык торган идем. Хәзер, узып кына булса да, хатты истива даирәсендә айдан артык барырга тугры килә. Минем кием-салымым бу эссегә барырлык булмаганга, яхшырак ак киемнәр мондагы пычрак арасында бер сәгатьтә казан тастымалы кебек булачак булганга, алар кебек анадан тума йөрергә тәрбия манигъ булганга, эсселектән иң күп газап чигүче – мин. Сингапурда, мөмкин булса, юка гына, начар гына киемнәр алырга уйлыйм. Бүген ятак, ашау бүлмәсендә, пычрак артудан башка, ялңыз эш булмады.

Эшелон мөәссәсәсе шактый начар корылган. Алар бик аз эшлеклелек күрсәтә алалар. Мәсәлән, пароходка кергәннән бирле икмәкчеләрне[ң] икмәк пешерү[ен] тиешле генә канәгатьләндерә алмыйлар. Икмәкнең өчтән икесе чи булганга, аңардан иң күп файдаланучылар, чех солдатларыннан битәр, диңгез балыклары булалар. Һава никадәр эссе булса да, солдатлар диңгез суын кырыныр өчен никадәр омтылып торсалар да, коену бүлмәләрендә бик сирәк су була. Булганда да йылы, кайвакыт кайнар да була. Эчә торган су, күгәргән тимер савытта торып, күпвакыт кып-кызыл була. Боларның һәммәсе дә аз гына гайрәт, аз гына иҗтиһад[2] берлән бетәчәк булса да, шуңарга беркем дә дикъкать итми. Шунысы гаҗәп: солдатлар шуларга каршы һичбер төрле начарлык күрсәтмиләр. Боларда үзләренең олугларына каршы бик зур бер ихтирам урынлашкан булмаса, әлбәттә, бик зур кычкырышлар, низаглар булыр иде. Мин азрак инглизчә укыйм. Ләкин теләгәндә утырырга урын юкка, бик аз вакыт табып була. Язарга да омтылу булынса да, урын юкка дәрт әрәмгә китә. Куәтнең иң зур эшләгән эше – йокы. Иртә йоклый, кич йоклый. Бик күп йокысын җыеп килгән, күрәсең.

---

[1] Мөрәккәб – кушылган.

[2] Иҗтиһад – тырышлык.

*16 нчы октябрь*

Кичә пароход өстенә яткан идек. Бик яхшы булды, бик тәмле йокладык. Бу – пароходка кергәннән бирле беренче татлы йоклау булды. Көн бераз болытлы, бераз җилле, һава эссе түгел. Дулкын зур түгел, пароход бик яхшы бара. Халыкта аруга башка күңелсезлек юк. Юлымыз хәзер туп-тугры җәнүбкә таба. Бүген унынчы, тугызынчы дәрәҗәләрне үттек булырга кирәк. Бүген сәгать 12 дә Сингапурга 628 миль калды, диделәр. Болай булганда, һавада зур үзгәрешләр булмаса, унтугызынчы октябрьдә якшәмбе көн Сингапурда булсак кирәк. Пароходка кошлар куну шактый күп очрый. Бүген бер карлыгач кунган иде. Һичбер кешедән курыкмаенча йөрде. Аркасыннан сыйпаудан да курыкмады. Бер-ике көннән бирле энә карагы да очкалый. Өч-дүрт көннән бирле пароходның ике ягыннан да, пароходтан куркып, балыклар очалар. Судан күпләп чыгалар. Судан берәр аршын гына күтәрелеп, биш-ун сажин очалар да тагы суга чумалар. Элгәре мин боларны берәр төрле кечкенә коштыр дип уйлаган идем. Җентекләп карый торгач, балык икәнлеге мәгълүм булды. Үзләре зурлар түгел, бер чирек озынлыкта булмас. Бераз зурраклар, тик канатлары зәңгәррәк, кояшта бик матур булып кала. Зуррак балыклар, дельфиннар күренгәне юк. Бүген кич сәгать җиделәрдә җил бик кызуланып китте. Элеп алып, селкеп салды. Ләкин диңгезне хәрәкәткә китерерлек озын дәвам итә алмады. Тыш болытлырак булганга, бүген тышка ята алмыймыз, тагы шул сасы эчендә пернәргә[1] кирәк була инде. Бүген кибәргә элгән йирдән зур гына бер сөлгемне алдылар. Өченче көн бер түшәк япмам югалган иде. Аннан элек Фуад бик һәйбәт савыты берлә сабын югалткан иде. Димәк, араларында вак-төяк караклар бар. Зурлары бардырмы, юкмы – анысын Алла белә. Юк исә безнең дәүләтемез шунда үземез берлән бергә.

*17 нче октябрь*

Бүген сәгать уникедә без бишенче дәрәҗәгә кердек. Менә язганда, дүртенче дәрәҗәләрне үтеп бара торганмыз. Хатты истивага бик якынлашсак та, көн артык эссе түгел. Кояш күп вакыт

[1] Пернәргә – тынчырга.

болыт астында, җил әле аннан, әле моннан һаман исеп кенә тора. Шуңарга артык эссе түгел. Пароход өстендә шәүләдә торып йөреп була. Кояш чыгып киткәндә, җилсез якта тәмуг кебек яндырып ала. Бүген берничә мәртәбә аз-маз ягмур яугалап алды. Ләкин берсе дә озынга бармады. Хәзер пароход янында кош-корт күп. Иң күбе – карлыгач. Мин эсселектән бик җәфа чиккәнгә, хәзер штансыз яланаяк кына йөрим. Солых һәйәте әгъзасына, бәлки, бик килешеп бетми torгандыр, ләкин мондагы эсседә Вильсон* үзе дә штанын салырга мәҗбүр булыр иде. Бер-ике көннән бирле аш начарланды. Итләре чиркәнде[1]. Шуңарга ачлы-туклы барамыз. Бүген бет күренгәли башлаган икән, дип, солдатларның керләрен карадылар. Берничәсендә шул мәхлукны табып, әйберләрен алып, мичкә кыздырырга куйдылар. Ләкин баштан ук хафизе сыйххәткә[2] игътибар итә төшсәләр, боларның берсе дә булачак түгел. Боларда шул урын юкны алдан күреп, шуның чарасын күрү юк икән: булгач кына, эш чыккач кына кызуланып тотыналар. Гомумән караганда, бер дә уңган халыкка охшамыйлар, араларында зур мәгълүматлы, талантлы кешеләр дә күренми, һәммәсе дә бер дәрәҗәдәрәк кенә. Ләкин барысы да, дөньяның иң зур милләте – чех, дөньяның иң тәмле ашы – чехның пешмәгән камыры, дөньяның иң матур тормышы – чех тормышы, дип ышанганнар. Шуңарга күрә үзләренең олуглары, эш башындагы кешеләренә һичбер төрле тәнкыйть күзе берлән карау кермәгән. Шуңарга күрә олугларына итагать икенче табигать булып урнашкан. Боларның сүз тыңлаулары хәйранга калмаслык түгел. Мәсәлән, пароходка утырган көнне эшалон[3] башлыгы үзенең приказында пароходның борынындагы мәгълүм хөдүден узмаска кушкан иде. Инде ике атна – ник шул приказны бер генә чех бозсын. Вә башка мәсьәләләрдә дә вә һакәза[4], болар кушкан-

* Вильсон – Томас Вудро Вильсон (1856–1924), АКШның 28 нче президенты. Идарә еллары: 1913–1921. Версальдә үткәрелгән солых килешүен оештыручы һәм төзүче төп авторларның берсе. Бу тырышлыгы өчен Вильсонга 1919 елда Нобель премиясе бирелә.

[1] Чиркәнде – монда: җирәнгеч.

[2] Хафизе сыйххәткә – сәламәтлекне саклауга.

[3] Дөресе: эшелон.

[4] Вә һакәза – һәм башкалар.

ны бозмас өчен, һәртөрле корбанга хәзер икән. Боларның сугыш вакытында бер милләт булып хәрәкәт итә белере дә, боларның Русиядә уйнаган рольләре дә – һәммәсе дә шул итагать берлән генә тәфсир ителә икән. Үзләренең дәүләтләре булып, үзләре үзләренең түрәләрен, олугларын тәнкыйтькә мәҗбүр булгач – боларның саф дәрунлыклары[1] беткәч, әлбәттә, әхваль үзгәрәчәк. Әлбәттә, бу сукыр итагать бетәчәк, ләкин ул итагать үзенең ролен уйнап кала. Чехларны олуг юлга чыгара. Аларга дәүләт ясап бирә. Боларга каршы безнең башбаштаклыкны күзгә китерсәң, егълыйсылар килә.

Бүген безнең сәфәргә чыгуымызга ике атна улды. Марсельгә барып җиткәнче, шулай ике атналар, өч кенә үтәрме, әллә дүрткә җитәрме? Киләчәк күрсәтер.

*18 нче октябрь*

Мин бүген баш авыруы берлән уянам. Бердән, гаять сасы, эссе булганга йоклый алмадым. Икенчедән, төнлә сәгать берләрдә шыр тир өстеннән ягмур коену алдым. Өченче, мигъдәм тагы ката башлады. Рух бик төшенке. Көн артык эссе түгел, җил бар. Бүген без дүртенче, өченче дәрәҗәдә барамыз. Бүген сәгать уникегә Сингапурга йөз кырык миль генә калды. Юлда вак-төяк атачыклар[2] күренгәли башлады. Кош-корт күбәйде. Иртәгә иртә берлән Сингапурга барып җитсәк кирәк. Анда бик эссе булыр инде. Шуннан без беренче мәктүб язарга булып торамыз. Сингапурда без тәмам өч мең миль киткән буламыз. Бу әле юлның өчтән берсеннән дә ким. Бүген халык кәефлерәк, һәммәсе корыны көтәләр. Вакыт соң булса да, бар да әле карта уйнап әвәрә булалар[3]. Өстәлдәге пычрак тагы артты. Бу чехларга мәдәният әллә ничек, кисәкләп-кисәкләп кергән. Һәммәсе үзләрен пакь йөртергә өйрәнгәннәр. Һәммәсе иртә берлән бик тырышып сабын берлән башларын, муеннарын юалар. Ләкин һичберсе ашау-эчү урынын пакь тоту кирәклеген аңлар дәрәҗәгә кермәгән. Ашау өстәлләренең кодсияте[4] берсенә дә сеңмәгән. Шунда пычрак кар-

---

[1] Саф дәрунлыклары – саф күңеллелекләре.
[2] Атачыклар – утраучыклар.
[3] Әвәрә булалар – маташалар.
[4] Кодсияте – изгелеге, кадерлелеге.

та уйныйлар, шунда шатранҗ, шунда чиртмеш уйныйлар, шунда сакал кистерәләр, шунда чәч алалар, шунда киемнәрен ямыйлар, шунда итекләрен яңарталар. Шуңарга күрә иң пычрак, иң нәҗес урын бөтен пароходта – аш өстәле. Минемчә, моның сәбәбе боларның мәдәниятенең немецларның тәэсире астында гына булуда. Тышкы хәятта немецлар зур тәэсир ясаганнар. Урамда, эшләгән йирдә пакьлеккә өйрәткәннәр. Эч, җаннарында, гаилә тормышларында болар үзләренчә калганнар. Үзләренең хәятларында мохтар[1] булганнар. Шул мохтарлык аркасында үзләренең ашау-эчүдәге пычраклыкларны алып килгәннәр. Инде бөтен тормышларында читтән таяк күрсәтеп тора торган немец мөгаллиме булмаса, болар үзләренең моңынча өйрәткән һөнәрләрне, мәдәниятләрне саклый алачакლармы, әллә шул гамәл бетү берлән, акрын-акрын гына әүвәлге хәлләренә кайтып, өстке мәдәниятләрен дә юга[л]тачаклар да рус мужигы булып калачакლармы?

Монысын киләчәк күрсәтер.

*19 нчы октябрь*

Бүген иртә берлән сәгать икедә пароходымыз бер маяк янында якорь салды. Сәгать алтыда якорьны алып, кузгалып китте. Ике тарафтан йир күренсә дә, сәгать уннарсыз Сингапур шәһәренә барып җитә алмадык. Инглизләр, үзләренә бугазны сакларга җиңел булсын өчен, шәһәрдән егерме мильдә төнгә пароходларга туктарга ясаганнар икән. Сингапурга өч-дүрт чакрым калгач, тагы туктадык. Бугазның мәэмүрләрен[2] көттек. Берсе артлы берсе шәһәр идарәсе вәкиле, доктор, бугаз вәкиле килеп, эссе эшләрне эшләп, рөхсәт биреп китте. Сәгать уникеләрдә шәһәргә бик якын йиргә килеп, якорь салдык. Инде без шунда туктадык. Шәһәргә чыгу мәсьәләсе шәһәрнең милициясенең рөхсәтенә баглы. Без чыгарга рөхсәт сораганда, чех коменданты: «Менә хәзер милициянең рөхсәтен генә көтәм. Аннан соң чыгарга мөмкин булыр», – диде. Без шул җавапны көткәндә, комендант үзе шәһәргә китеп барган. Аннан соң рөхсәт килде, ләкин дежурный офицер аның берлән генә безгә рөхсәт бирмәде. Без көн буе комендантның кайтуын көттек. Ләкин ул һаман кайтмады. Безнең

[1] Мохтар – ирекле.
[2] Мәэмүрләрен – чиновникларын.

урыннарны астын-өсткә китереп, пароходка товар ташыдылар. Без әйберләрне җыеп куйдык. Бүген шәһәргә чыгып, иркенләп кунарга уйлаган идек, ләкин сәгать унга кадәр комендант кайтмады. Башка офицерлар да, төрлесе төрле хәйлә берлә китеп, чыгып киткәнгә, алар да күренмәде. Монда солдат кына калды. Шулар берлән без дә сасып калдык. Ул гына булмады, кич берлән коенырга манигъ иттеләр[1]. Кичкә сабын бирмәделәр. Көн эссе булганга, фәүкыльгадә эчәсе килә – чәй юк, шәһәр ялтырап, үзенә чакырып тора. Барыр хәл юк. Ике атнадан бирле хайван хәяты берлән торып килгәнгә, ак, пакь ятак, кеше төсле кешеләрнең кыяфәтен күрү, ниһаять, йиргә басып йөрергә бик сагынганмыз. Ләкин шул ахмак малайчакларның кабахәтлекләре хакында монда сасып ятарга мәҗбүрмез.

Сингапур үзенә аерым бер мөселман әмирлеге икән. Фәкать идарә инглизләрдә икән. Монда килгән дәүләтнең аста инглиз канатлы тәреле байрак таккан пароходның исеме инглизчә «Мөхәммәд» дип язылган иде. Бу йирләр ахмакларга инглизнең биргән бүләге, күрәсең. Шундагы бер мөселман түрәнең сүзенә караганда, шәһәр – мөселман шәһәре. Бик күп җамигъ бар, мәдрәсәләр бар, имеш. Халыкның күбесе фарсыча белә, хәвасы[2] гарәпчә белә, ди. Шәһәр хакында күргәч язармын инде.

## 7 нче дәфтәр

*20 нче октябрь*

Без бүген иртүк Сингапур* шәһәренә чыгамыз. Кич вакытымыз әрәм булганга, иртүк чыгу юлында буламыз. Мондагы чини коменданты берлә аңлашканның соңында, сәгать җиделәрдә шәһәргә юнәләмез. Шәһәр бик пакь. Диңгез буенда бик матур бакчалар ясалган. Урамнар безнең пароходка караганда бик күпкә пакь. Аурупа халкы һәммәсе ак киемдә.

---

[1] Манигъ иттеләр – каршы булдылар.

[2] Хәвасы – җәмгыятьнең югары катлавы.

* Сингапур – Көньяк-көнчыгыш Азиядәге күпмилләтле шәһәр-дәүләт, дөньякүләм финанс үзәге санала. Ул шул исемдәге утрауда урнашкан. Малакка ярымутравының көньягындарак. Малайзиянең көньяк өлеше белән чиктәш.

Бүген иртүк Сингапур шәһәрендә. Ерактан ап-ак булып күренә торган шәһәр эченнән тагы да пакьрак. Киң урамнар күзгә кебек ялтырап тора. Сөт[тәй] ак биналар, биек-биек хөрмә, банан, әфлисун агачлары берлә чигелеп, яшелләнеп торалар. Диңгез буйлары[на] без күрмәгән, колак ишетмәгән агачлар утыртылган. Әллә ничә төрле милләткә бүленә торган халыкның иң күп кыйсеме үзләрендәге мода буенча акка киенгәннәр. Аз гына исә торган җил хатты истиваның эссесен йомшартып, битне, тәнне сөеп тора. Шәһәрнең иң матур йирләрендә – инглизләр. Диңгез буенда – алар. Диңгездә фирүзә кебек күренеп торган яшел таучыкларда – инглизләр. Банан, хөрмә, әфлисун – әллә ни, әллә ни агачлары берлә өртелгән, чинар агачы берлән күләгәләндерелгән, җәннәт бакчасы кебек бакчаларда – инглизләр.

Шәһәрнең уң ягына таба – мөселманнар, сул катында – кытайлылар, японнар, христиан малайлар*.

Шәһәргә кергәч тә, әллә никадәрле кызыл кәләпүш кигән кешеләргә очрыйсың. Ара-тирә үзләренә махсус чалма чалган гарәпләргә, сирәк-сирәк кенә көязләндереп төрек фәсе кигән Һиндстан мөселманнарына очрыйсың.

Базарларына керәсең, гарәп язуы берлән язылган вывескалар. Ләкин рәсемнәреннән бернәрсә аңламыйсың. Вак-төяк сәүдә кибетләре тулган. Һәммәсе мөселман кулында. Һәммәсе кызыл кәләпүшләрен (ләкин боларның кәләпүшләре безнекенә караганда бераз биегрәк, чалмалы хәзрәтнеке кебек) кигәннәр дә магазиннарында сәкесендә янә йоклап утыралар. Кайберләре берлән сөйләшеп китеп танышамыз. Күбесе малай телендә сөйләгәнгә, аңлашу фәкать инглизчә генә. Гарәпчә сөйләп карыймыз – белмиләр, фарсыча сөйләп карыймыз – аңламыйлар. Шулай итеп, мең бәла берлән генә аңлашамыз. Көн буе урамнан урамга шәһәр карап йөргәндә, гарәп кыяфәтендәге бер адәмгә очрыймыз. Аны туктатып, гарәпчә сөйли башлыймыз. Куаныч, гарәпчә сөйли. Үзе мәдинәле, исеме Сәид Әхмәд. Монда комиссионерлык итеп тора икән. Аның берлән сөйләшеп киткәч, ул безне Хаҗи Йосыф дигән бер һиндстанлы мөселманның кибетенә алып китә. Алар

* Малайлар – малайя милләтеннән булганнар, малайзиялеләр.

берлән күрешәмез. Сәид Әхмәднең тәрҗеманлыгы хакында, һинд хакында бераз мәгълүмат аламыз. Шуннан соң, бер-ике-өч көн торыр өчен, номер табып бирүләрен үтенәмез. Мәсьәлә бик тиз Төркия хәленә җитә. Төркиянең хәле ничектер, монда инглиз газеталары бик начар язалар. Без, боларга ышанып җитмәгәнгә, бераз сакланып сөйлимез. Русия хакында аз-маз мәгълүматлары бар. Кавказ, Төркестанны, фәләнне беләләр.

Аларның ярдәме аркасында, бер япон номерына да урнашамыз. Шул ук Сәид Әхмәт әфәнде безне аз-маз гарәпчә сөйләшә торган Касыйм исемендәге бер малай берлән таныштыра. Номерымызда юынып, сөенеп, аның берлән мөселман ашханәсенә китәмез. Мөселман ашханәсе һәр йирдә бертөрле, һәр йирдә пычрак, һәр йирдә эчпошыргыч ямьсез. Һәр йирдә аш бүлешеп, кытай мөселманымы, һинд мөселманымы, дин берегеп, халык берлән аш ашыймыз. Ашлары тәмле генә. Безгә кашык, пычак, чәнечке бирделәр. Без[дән] башка мөсафирлар һәммәсе кул берлән ашый.

Ашханә хуҗасы бер гарәп булып чыга. Аның берлән бераз сөйләшәмез дә ат алып мөселман мәхәлләсен, зур җамигын, солтанның сараен, мәктәпләрен, көтепханәләрен – хасыйле ислам дөньясының[1] дахили[2] тормышларын күрергә китәмез.

Юлда бер мивә[3] кибете очрап, мивә аламыз. Мондагы мивәләр моңганчы без күргәнгә башка. Берсе помидор төсле бик тәмле, татлы. Берсе басынкы, сары, баклажан кебек. Төше бик зур, ите төшенә бик нык ябышкан. Үзләреннән аз гына шәрәгән[4] йомырка исе чыга. Ашарга бик тәмле, исе бик хуш. Берсе кара төсле, пешкән инжир кыяфәтле. Ләкин эче чикләвек кебегрәк. Берсе безнең кабакның кечкенәсе кебек. Эчендә сусыл, ләкин татлы. Берсе безнең карбыз кебек. Уртасын тишкәч, эченнән бик татлы, шикәрле ак төслерәк су чыга. Суы өчәр, дүртәр стаканга кадәр җитә. Төбенә төшкәч, төбен дә ашыйлар икән.

---

[1] Хасыйле ислам дөньясының – (мөселманнарның) ислам дөньясын барлыкка китергән.

[2] Дахили – эчке.

[3] Мивә – җиләк-җимеш.

[4] Шәрәгән – сасыган.

Әфлисуннары шәп түгел. Мандариннары түгәрәк, лимон кебегрәк, ләкин тәме бик татлы түгел. Әле өлгереп җитмәгән булырга кирәк. Күптән фрукта ашамаганга (Маньжуриядә холерага күрә ашалмаган иде) бик зур дәрт берлән ашап, мәсҗед янына килеп туктыймыз. Мәсҗеднең манарасы юк. Аның урынына зур бер барабан тора. Намаз вакытын шуны дөбердәтеп игълан итәләр икән. Ихатаны кергәч тә күзгә ташланган нәрсә – зур гына бер бассейн. Иңе-буе дүртәр сажин булыр, тирә-ян ихатасы. Мөселманнар моннан су алып истинҗа кыла[1]. Шунда кул юалар, шунда йөз юалар, шунда авыз чайкыйлар, шунда аякларын тыгып юалар да мәсҗедкә кереп китәләр. Су ямь-яшел. (Бу гына гөнаһсыз булырга кирәк.)

Без тәһарәтле кешеләр кебек мәсҗедкә керәмез. Мәсҗед зур. Түшәме юк. Башы гына ябылган. Идәненә камыш намазлык җәелгән. Алга таба паласлар да күренгәли. Михраб, мөнбәре зиннәтле түгел. Ап-ак таш баганалар түбәсен күтәреп торалар. Төрле ягындагы төрле ишекләрдән халык кереп-чыгып йөриләр. Бер йирдә намаз укыйлар, бер йирдә йоклап яталар. Бер йирдә дүрт-биш кеше утырып ләчтит саталар. Һичбер намаз вакыты булмаса да, мәсҗедтә кырык-илле кемсә бар. Без туп-тугры михраб янына барып утырамыз да дога кыламыз. Шуннан соң багана яннарына өелгән китапларны карарга тотынамыз. Китапларның һәммәсе диярлек Коръән. Йөзләп Коръән. Башсыз Коръән, ахырсыз Коръән, тузган Коръән, ярты Коръән, тулы Коръән. Һәммәсенең тәртибен эзлимез. Һичберсен дә рәтләп таба алмыймыз. Барысы да ошбу тарафта өемләнгән. Аннан китеп, икенче өемгә туктыймыз. Аларын актарырга тотынамыз. Анда «Дәлаил-илхан» кебегрәк («Тәхтел-ислам» шикелле) бер китапка очрыймыз. Аның ахырында Бумбайда* нәшер ителүе язылган. Ул ара да булмый, безне төрле яктан чормап алалар. Бик зур дикъкать берлә безнең мөгамәләмезне җентеклиләр. Берсе, килеп, инглизчә миңа: «Ник кара эшләпә киясез?» – дигән

[1] Истинҗа кыла – тәһарәттән соң юына, пакьләнә.

* Бумбай – Бомбей – Һиндстанның көнбатышында, диңгез ярында урнашкан зур индустриаль шәһәр. Илнең икътисади һәм мәдәни үзәкләреннән берсе. 1995 елдан аның исеме Мумбай дип үзгәртелә.

сөален бирә. (Монда әле кылышуда мәҗүси мәсьәләсе бетмәгән, күрәсең.)

Шуннан сөйләшеп китәмез. Үземезнең мөселманлыкны сөйлимез. Бик үк ышанмасалар да, ярты-йорты гына мөселманнар инде дигән фикергә киләләр. Мәдрәсәңез бармы? Юк. Мәктәп бармы? Юк. Китапханәңез бармы? Юк. Кыйраәтханәңез бармы? Юк. Идарәңез кем кулында? Үземезнең мөселман кулында, Әмир Гали кулында. Ләкин инглизләр дә контроль ясый. [Шәп] торасызмы соң? Бик шәп, бик һәйбәт. Дингә бер дә тимиләр, рәхәтләнеп торамыз.

Ләкин үзләрендә һичбер төрле безгә бирергә сөальләре юк. Андагы мөселман ни эшли? Төркиянең хәле ничек? Сездәге мөселман хәлифәт мәсьәләсенә ничек карый? Шуларның һәммәсе дә боларның башын ватарга кирәк иде. Сөйләшә-сөйләшә, җамигътан чыгамыз. Мәдрәсә кайдалыгын сорыймыз. Ерак түгел генә бер өйне күрсәтәләр. Без, җамигъның ихатасында ни бар икән дип, карарга китәмез. Бер мөселман фарсының безгә ачуы килә булырга кирәк, барыңыз, барыңыз, чыгыңыз, дип кулын бутый. Безнең паспортымыз ялган булганга, әлбәттә, аның берлә мөназарә[1] кылышып тора алмыймыз. Аякларымызга киеп, сәлам биреп чыгып китәмез. Шуннан юлбашчымызга мәдрәсәгә алып барырга кушамыз, тегеләр күрсәткән бинага таба атны бордырамыз. Ләкин ул бармый. Ул мәдрәсә түгел, солтанның сарае, ди. Зур гына, һәйбәт кенә йорт, бөтен тарафыннан бик зур бакча берлән чолганган. Мәмләкәтнең идарәсен иминиятле[2] инглиз кулына тапшыргач, әмир шунда хәл җыя икән. Шуннан барып-йөреп, инглизчә-гарәпчә «Әл-мәдрәсәти әлвия»[3] дигән бер бинаны күрәмез.

Матур гына бер бина. Тәрҗеманны көчләп кенә мәктәп янына килеп туктыймыз. Мәктәп капкасы ябык. Тегенең куркып торуына карамаенча, ишеген төртеп ачып, йортка керәмез.

Аннан берничә малай килеп чыга. Берсе шактый гына гарәпчә сөйли. Кулларында китаплары, дәфтәрләре. Һәммәсен карыймын: гәрәпчә, инглизчә. Фәннәре – инглизчә, дин – гарәпчә.

---

[1] Мөназарә – бәхәс.

[2] Иминиятле – ышанычлы.

[3] «Әл-мәдрәсәти әлвия» – мәктәп байраклары.

Мәктәпкә кермәкче буламыз. «Мөгаллимнәр юк. Иртәгә киләсез», – диләр. Безнең вакытымыз булмаганга, без тышыннан гына карарга дип керергә телимез. Малайлар, хезмәтче чакырып, мәктәпне күрсәтәләр. Мәктәп – дүрт мәнзилле[1] ибтидаи[2] мәктәп. Иң зур дикъкать инглизчәгә, безнең русско-татарский ысулынча, аның инглизчәсе. Дәрес программаларын карыймыз. Иң зур дикъкать инглизчәгә юнәлтелгән. Мөгаллимнәрнең кем икәнен белешәмез, сорашамыз. Һәммәсе дә үз мөселманнары, һәммәсе дә малайларның үзләренең [...] учительләре.

Диварда бер календарьга күземез төшә. Артына гарәпчә мәкальләр язылган. Кайда басылганын карыймыз. Сингапурда диелгән. Малайлылардан матбаганы сорыймыз (табгыханә). Гарәп урамында, диләр. Малайлылар берлә күрешеп, мөселман мәхәлләсе буйлап китәмез. Менә ачык бер китапханә. Без, атны туктатып, китапларын кереп карамакчы буламыз. Безне кертмиләр. Ник, дип сорыймыз. Хуҗасы өйдә юк, дип җавап бирәләр. Өйләр монда бераз мөселманча, урамга тәрәзә юк диярлек дәрәҗәдә. Ләкин өйләр дивардан якын булганга, икенче катларның тәрәзәләре һәммәсе күренә. Һәммәсендә дә хатынкызлар гарәпчә сөйли торган кяферләрне тамаша итәләр булырга кирәк. Өстләре-башлары пакь кына. Качуларының рәте юк. Рәсман качсалар да, ябыну башка гына калып бара икән.

Юлда мөселман зиярәте дигән берничә кечкенә мәсҗед, ябык мәдрәсә кебек нәрсә күреп, өйгә таба борыламыз. Мәктәпләрен никадәр, күрсәтегез, дисәк тә, күрсәтүче дә булмый, үземез дә мәктәп таба алмыймыз.

Бүген, пароходка барып, номерда торырга рөхсәт алып киләмез. Йөреп бик арыганга, кичке аш эзләргә чыгамыз, өстемез-башымыз бик садә[3] булганга, зур ресторaннарга керергә база алмыймыз. Йөреп-йөреп, чибәррәген таба алмагач, бер урам ашханәсенә генә керәмез. Ул мөселманнарга махсус ашханә булып чыга. Монда ашлар бераз тәрәккый бер дәрәҗәдә. Бу үзе дә без-

[1] Мәнзилле – дәрәҗәле (сыйныфлы).
[2] Ибтидаи – башлангыч.
[3] Садә – гади.

нең «Сарай»*. Ашларын аз-маз гына ашап, кайтып йоклыймыз. Бик арылган.

Рәтләп йоклап булмый, чөнки номерда бик тавышланалар, йөриләр, чуалалар.

*21 нче октябрь*

Бер туктамаенча японча, малайча, инглизчә сөйләп, лыгырдап торганга, мин иртүк торырга мәҗбүр. Бүген дә йокы туймады. Фуадны** йокларга калдырып, базарга чыгып китәм. Бәгъзы аласы әйберләрне алдым. Акча алыштырам. Монда акча мәсьәләсе тагы мөшкел. Безнең рус акчаларымызны монда бер тиенгә дә алмыйлар. Романовскийларга биш-алты цент кына бирәләр. Яшелләрен бер дә алмыйлар. Ул гына түгел, минем япон акчаларым арасында дүрт йөз иен Корея акчасы бар. Болар Маньчжуриядә, Япониядә иен берлә бер бәһадә йөриләр. Монда аларны егерме процент ким хисаплыйлар. Фуадта да алар өч йөз иеннан артык. Франсәгә алып китсәк, анда курс тагы төшенке булачак. Шуларны алыштырыр өчен, япон банкасына керәмез. Болар бар да иен курсы берлән, [...] арасында аерма юк, бәһаләре бер, диләр. Безгә алыштырып япон иены бирегез, дигәч, безнең япон акчамыз юк, диләр. Инглиз, француз акчасы биреңез, дигәч, без чит мәмләкәтнең акчасы берлән сәүдә итмимез, диләр. Боларның бу алдауларыннан көлеп чыгып китәм. Сорашып, рус консулына барырга уйлыйм. Ләкин рус консулханәсе бик ерак булып чыга да икенче вакытка калдырам. Көн бик эссе, тиргә батам. Эчәсе бик килә. Ачык базардагы бер кәләпүшле чәйчегә утырып чәй эчәм. Чәй монда безнеңчә эчелми. Кофе кебек куе иттереп ярты чынаякка салына да, шуңарга сөт кушыла. Шуннан шикәр берлән эчелә, шактый тәмле. Ләкин сәйлүн чәе*** булганга, бераз әчесе бар. Мөселманлыгымызны белә дә чәйче тагы ашарга күмәч, тагы чәй тәкъдим итә. Тагы эчәм. Акча түли

* «Сарай» – бередә XX гасыр башында Казанда (Париж Коммунасы урамы, 9 нчы йорт) «Сарай» номерлары һәм андагы ашханә күздә тотыла.

** Фуад – Фуад Туктаров (1880–1938) сәяси эшлекле, юрист, публицист, Бөтенроссия Учредительное собрание әгъзасы.

*** Сәйлүн чәе – Цейлонда җитештерелгән чәй.

башлагач, биш-ун тиеннән артык алмый. Сингапурда бу минем беренче очсыз файдаланган тәгамем була.

Өйлә ашына без үземез берлән бергә бара торган бер офицерны кунакка чакырганга, көн буе гомер аның берлән үтә. Аласы әйберләр булса да, аның акчасы булмаганга, акчасыз кеше алдында әйбер алу уңайсыз булганга, без бу көнне тагы шәһәр күрүгә җыенамыз.

Трамвайда йөримез. Шәһәр читендәге бакчаларга барамыз. Кичен ут яктысындагы Сингапур хәятын күзлимез. Кунагымыз бездә кунарга теләгәнгә, теләр-теләмәс аны кунак итәмез.

Бүген төнлә берлән бер инглиз мөсафире гакылдан яза. Без аны исерек дип көлеп, төрлечә әварә итәмез. Шуның берлән, инглизләрнең мондагы хәлләрен, бөтен дөньядагы вазгыятьләрен куәтләгәнгә, аз гына булса да үч алмакчы буламыз. Ләкин аның гакылдан язганын белгәч, уңайсызланып каламыз. Мәҗнүн төн буе йокламаенча, әле бер номерга, әле бер номерга кереп, тавыш чыгарып йөргәнгә, төн буе йоклый алмый каламыз.

*22 нче октябрь*

Йокы да туймаганга, кунагымыз лөзүменнән артык торганга, мин бик кәефсез аякка калкам. Һичбер төрле эш булмаса да, әллә нинди хәйләләр табып, тик моннан котылыр өчен, рикша* алам да (мондагы рикшалар икешәр-өчәр кешене тартып йөриләр), күз күренгән бер якка китеп барам. Бер урамнан үтеп барганда, гарәп чалмасындагы кешеләргә очрыйм. Аннан, бераз йөргәч, бер китап магазинын күрдем.

Рикшаны җибәреп, китап кибетенә керәм. Сәлам бирәм. Хуҗасы теләр-теләмәс кенә сәламемне алды. Бераз гарәпчә аңлый. Китаплар карарга тотынам. Төрле дин китаплары. Китапларының кайберсе малай телендә, кайберсе урду телендә**. Гарәпчә бик аз, фарсыча юк дәрәҗәдә. Китапларны ачып-ачып карыйм. Хуҗасы бик салкын булганга, куып чыгармасын дип, тиз генә чыгып китәм.

---

* Рикша – ике тәгәрмәчле кечкенә арбага җигелеп кеше яки йөк ташучы.

** Урду телендә – һинд-Европа семьялыгына керә торган урду теле һинди теленә бик якын. Һиндстандагы 22 рәсми телнең берсе санала. Пакистанда да 2 рәсми телнең берсе, икенчесе – инглиз теле.

Базар. Мөселман базары. Бер йирдә чалмалар, тәсбихлар саталар. Бер йирдә кызыл мал* саталар. Бер кибеттә җимешләр саталар. Менә тагы китап кибете. Тагы кердем. Тагы сәлам бирәм. Монда ачык йөз берләнрәк каршы алалар. Хуҗасы гарәпчә күп сөйләмәсә дә, утырып тора торган бер гарәп бик яхшы сөйли. Ул ара да булмый, һиндле бер мөселман егет керә. Ул гарәпчәне бик яхшы сөйли. Утырамыз. Сөйләшергә тотынамыз. Ике-өч сүздән сәясәткә күчәмез. Русиядә күпме ислам бар? Төркиянең хәленә ничек карыйлар? Бик тиздән самими иттереп сөйләшергә тотынамыз. Магазинга тагы берничә кеше киләләр. Тагы сүзгә катышалар. Сүзнең иң кызу урынында – мин безнең инглизне яратмавымызны сөйләгән чакта – магазин хуҗасы миңа искәртте. Үзе, сүзен башкага борыр өчен, китаплар күрсәтә башлый. Шул арада берничә кеше килә, берничә кеше китә. Һиндле егет:

– Монда инглизләрнең хәйләләре бик күп. Монда сөйләргә һич форсат юк. Малай мөселманнары үзләре дә бик куркаклар, – ди. Сүзләр өзелә. Чәй тәкъдим итәләр. Сөйләшә-сөйләшә:

– Һинд мөселманнары ник Төркияне яратмыйлар? – дип сөаль бирәм.

– Юк, бик яраталар. Бөтен күңелләре берлән Төркияне сөяләр.

Мин:

– Алай булгач, ни дип һинд гаскәре Дарданелда** төрек гаскәрләренә каршы сугышты?

– Бездә гаскәрлек мәҗбүри. Алай да бездән куркып, руслар безнең гаскәрләрне төрек матавыгына җибәрмәделәр. Безнең әсир төшкән гаскәрләремез, аерым полклар ясап, Дарданелны бурадан[1] Төркия кулында саклар өчен, инглизләр берлән сугыштылар. Ләкин анда [төрекләр] каршыларында һинд мөселманнары булганны күреп, хәйранга калдылар. Минем бу бәяным эчләрен бик поштырды. Бездә төрле хулиган күп. Ялланып бара

---

* Кызыл мал – тукымалар, мануфактуралар, аршынлы мал.

** Дарданел – Дарданелла – Төркиянең Европа (Балкан ярымутравы) һәм Кече Азия өлешләре арасындагы диңгез бугазы.

[1] Бурадан – биредән, бу яктан.

бирәләр, диделәр. Ләкин шул мәсьәлә хакында үзара да озын[1] сөйләштеләр.

Бу китап кибетендә өч төрле телдә китаплар бар. Малайча, урдуча, гарәпчә. Һәммәсенең чыга торган урыны Бумбай икән. Монда дини китапларына башка, тарих, әдәбият та бар. Миңа «Гөлстан»ның* малайчага тәрҗемәсен күрсәтәләр. Ибне Хәлликәннең**, ибне Хәлдүннең*** хезмәтләрен күрсәтәләр. «Әлфе ләйлә вә ләйлә»нең**** тәрҗемәсе бармы, дип сорыйм. Юк икән. Бу әтрафта мөселман күпме, дип сорыйм. Суматра*****, Җава****** халкы – һәммәсе мөселман. Мәктәбе, мәдрәсәсе бармы? Хәер[2], дип җавап бирәләр. Сингапурда газета бармы? Бар. Ләкин яртысы инглизчә, яртысы малайча чыга. Фәкать инглиз мәнфәгатенә хезмәт итә. Матбага кайда? Шул урамда, диләр. Күрсәтегез, дигәч күрсәтмиләр. Үзләреннән матбага берлән араларында дуслык юклыгын хис итәм. Күрешеп чыгып китәм. Бу магазинның хуҗасы Хафиз әфәнде – шактый ачык кеше. Аз-маз безнең хәлдән дә хәбәре бар. Үзе, Һиндстаннан китаплар алдырып, Җава, Суматра мөселманнары арасында шуларны сата икән.

Аштан соң Фуад тагы ятып йоклый. Мин чыгып китәм. Шәһәрне гизәм. Эчәсе килгәч, бакча эчендәге бер япон киоскысына

---

[1] Озын – монда: «озак» мәгънәсендә.

* «Гөлстан» – бөек фарсы шагыйре Сәгъдинең (1203/1210–1292) 1258 елда иҗат иткән әсәре. «Гөлстан» урта гасырларда ук Көнчыгыш илләре, Көнбатыш Европа, гарәп, төрки һ.б. телләргә тәрҗемә ителә һәм бик популярлашып китә.

** Ибне Хәлликән – Шәмседдин Әбүл Габбас Әхмәд бине Мөхәммәд (1211–1282), гарәп язучысы, тарихчы һәм хокук белгече.

*** Ибне Хәлдүн – Әбү Зәед Габдрахман бине Мөхәммәд әл-Хазрами (1332–1406), гарәп философы, тарихчы, фикер иясе.

**** «Әлфе ләйлә вә ләйлә» – «Мең дә бер кичә» – төрле телләргә тәрҗемә ителгән маҗараларга бай гарәп әкиятләре тупламасы.

***** Суматра – Индонезиянең зур утрауларыннан берсе. Ява утравыннан көнбатыштарак, Малай ярымутравыннан көньяктарак урнашкан.

****** Җава – Ява утравы – Индонезиянең Суматра һәм Бали утраулары арасында урнашкан. Илнең икътисади үзәге санала. Индонезия халкының яртысыннан күбрәге биредә яши.

[2] Хәер – монда: «юк» мәгънәсендә.

кереп су эчәм. Шунда бакчадагы агачларны карап йөрим. Бер хөрмә төсле агачта биш-алты яшьлек бала башы төсле, карбызга охшаган нәрсәләр үсеп ята. Хезмәтчедән: «Бу нәрсә?» – дип сорыйм. Һиндчә исемен әйтә. Ашаламы? – дип [сорыйм]. Ашала, пешкәч бик тәмле була, ди. Теләсәң, берсен [бирәм]. Мин: «Телим», – дим.

Һиндле бик тиз талдан зифа үскән пальманың иң өстенә үрмәләргә тотына. Һәм дә бик зур бер яшел җимешне өзеп төшерә. Йиргә төшкәч, ул кечкенә карбыз кадәрле була. Һиндле зур пычак алып килә дә шуның башын кәләпүш түбәсе кебек кисеп ала. Аның астыннан ап-ак бер нәрсә чыга. Шул ак йирлектә ул кое казырга тотына. Өстке катын алгач, аннан су чыга. Ул стаканга салып миңа бирә. Эчәм. Татлы бер ширбәт төсле. Ләкин үзе йылы. Һиндле кашык тыгып, теге җимешнең эчендә казына, яңадан стаканга су сала. Бу юлы су сыек сөтле чәй кебек аксыл чыга. Тагы эчәм, монысы тагы татлырак.

## 8 нче дәфтәр

Кашык берлә итен казып чыгара. Ак төсле ите бик татлы һәм тәмле. Һиндле:

– Бу әле пешмәгән, пешкәч бик зур була һәм дә татлы була, – ди. Мин агачта ширбәт үсүенә гаҗәпкә калам. Монда табигатьнең байлыгына гаҗәпкә калмаслык түгел. Монда банан үсә, ананас үсә, әфлисун үсә. Әфлисун берлән лимон арасындагы әчкелтем-төчкелтем бер нәрсә үсә. Хөрмә үсә. Алар һәммәсе дә бик күпләп үсә. Мәсәлән, бананнар бер талкымында[1] ике пот, ике пот ярым кадәр була. Ананас та бик күп.

Кич берлә акча алыштырырга маташып йөримез. Ләкин бер эш тә эшләп булмый. Маклер малай мөселманнары бик алдашырга маташалар. Без үземезгә күрә гакыллы булган булып маташамыз. Без монда тагы әле өч-дүрт кич куначак булганга,

[1] Талкымында – тәлгәшендә, сабагында.

әйбер алырга бик ашыкмыймыз. Кичкә таба мин тагы, Фуадны калдырып, трамвайга утырып, шәһәрнең бер тарафына китәм. Бара тора, гыйбадәтханә кебек бер нәрсә күреп, шунда керәм. Ул һиндле буддистларның гыйбадәтханәләре булып чыга. Будда монда Япониядәге төсле түгел. Ләкин гыйбадәтханәдәге урыны һаман бертөсле. Алдында ут янып тора. Олуг Буддадан башка вак-төяк буддачыклар бик күп. Болар бик ямьсез эшләнгәннәр. Кайберләре балта берлән агачтан гына ясалган.

Табигатьнең шулкадәр бай, матур йирләрендә шундый ямьсез төрбәләргә адәм баласының табынуының сәбәбен аңламаенча чыгып китәм. Менә шәһәрнең чите. Әнә тагы бер Будда гыйбадәтханәсе. Ул матур иттереп, гөмбәзләп эшләнгән. Гөмбәзенең башы бераз манарага охшаган төсле булса да, кырт киселеп беткән. Барам. Ишеге ачык. Өй алдында берничә кара егетләр басып торалар. Зур гына Будданың алдында ут янып тора. Йортны карарга тотынам. Бер якта – зур гына бер күл. Суы яшәреп беткән. Менә өстләренә кызыл йирлеккә ука берлән чиккән азарлар[1] бәйләгән ике яшь хәлфә киләләр. Тугры суга киләләр. Элгәре, яланаяк суга кереп, аякларын юалар. Аннан соң, кулларын, битләрен юып, гыйбадәтханәгә кереп китәләр. Монда пычраклыкта мәҗүси берлән мөселманның бер дәрәҗәдә булуына бераз гаҗәпкә калдым. Чынлап уйлаганда, мондагы төрле дин әһелләре һәммәсе берсеннән-берсе бик күп нәрсә алганнар. Алучыларның күбесе гавам булганга, әлбәттә, алар үзләренең рухларына мөнасиб[2] гадәтләрне алганнар. Мондагы мөселманнар берлән мәҗүсиләрнең батыйльлеккә[3] карашлары бер дәрәҗәдәрәк булганга, болар былчыраклыкны тигез бүлешкәннәр. Шуннан ерак түгел кыска гына манара кебек нәрсәнең башында ай берлән йолдыз күренә. Шуны карарга дип барам. Арада бик күп биналар булганга, рәтләп күрә алмыйм, фәкать капкасына язылган «Бисмилла» укыйм. Ахырысы, бу – бер зиярәттер.

Көн матур гына. Эссе булса да, сирәк-мирәк килеп ягмур явып торганга һәм дә бер туктамаенча җил исеп торганга, һава

[1] Азарлар – будда монахларының киеме.
[2] Мөнасиб – яраклы, туры килә торган.
[3] Батыйльлеккә – бозыклыкка, файдасыз эшкә.

йомшак, хатты истивадан[1] бер дәрәҗәдә, унҗиде минутлы шәһәр өчен көтелмәгән дәрәҗәдә хуш.

*23 нче октябрь*

Бүген өчен безнең бик күп эшемез бар. Берсе – бүген кирәкле әйберләрне алып бетерергә. Пароходта утырырга урын юкка, мотлакан[2], утыргычлар алу лязим. Фуадның урыны өченче катта булганга, ул карават та алырга уйлый. Икенче, бездәге Корея акчаларыннан монда арынып китәргә, чөнки еракка киткән саен, аның бәһасе төшәчәк. Өченче, ашамак-эчмәк алырга кирәк. Иртүк чыгып акчага тотынамыз. Һич рәте юк. Корея акчасына без егерме процент югалтырга кирәк. Ул төшереп калдырудан начар. Чөнки бу Корея акчалары миңа Агишевларда* карзы хөснәгә[3] каршы кайтарылып бирелгән нәрсә. Мин аларга япон иеннарын, алар миңа Корея иеннарын кайтарды. Анда аларның һич аермасы юк.

Шуннан соң әйберләр алырга тотынамыз. Магазиннан магазинга кереп, шактый кирәкле әйберләрне аламыз. Өйләдән соң япон банкасына кереп, тагы алыштырырга сорыймыз. Японнар аз гына ояла. Безнең йөз иенымызны башма-баш алыштырырга булалар. Башкасына акчамыз юк, диләр.

Без япон банкасы бездән дә фәкыйрь икән дип көлгәч, бераз хурланалар. Тагы йөз иен алыштырырга булалар. Калганнарын ике процент берлә Сингапур долларына алыштырырга булалар. Аннан эшне бетереп чыгамыз.

Бүген кичкә малай театрына барырга берничә кеше берлә вәгъдәләшеп, башка әйберләр артыннан китәмез. Көн буе йөреп арып беткәнгә, театрга барыр алдыннан бераз юыныр өчен, өйгә кайтамыз. Анда безгә бер записка бирелгән. Запискада, иртәгә пароход сәгать 12 дә китә. Сез сәгать унда пароходта булыңыз, диелгән.

---

[1] Хатты истивадан – экватордан.

[2] Мотлакан – ничек булса да.

* Агишевлар – бертуган Заһидулла һәм Габдулла Агишевлар. Кытайда яшәүче төрек-татар милли хәрәкәтендә катнашкан актив җәмәгать эшлеклеләре, сәүдәгәрләр.

[3] Карзы хөснәгә – алган бурычларына.

Көтелмәгән бу хәбәр безнең бөтен планны боза. Малай театрына бару да кала. Теге мөселманнарны барып карап йөрү дә кала. Без тиз генә тагы китәмез дә, калган әйберләрне алырга чыгамыз, ләкин вакыт бик соң булганга, бер эш тә эшли алмыймыз. Безнең алдымызда хәзер тагы яңа мәсьәлә туды: Сингапур акчаларын инглиз йә французга алыштыру (банкта аларга алыштыру мөмкин булмаган иде). Саррафлар[1] бар да ябык, ачыгы бик комсыз кылана. Һичбер эш эшләп булмый. Рикша алып, гарәп урамына китәмез. Анда әлеге китап кибетенә барып керәмез, алар баш өстенә утырталар. Безгә вак-төяк әйберләр кирәк, алышып биреңез, [димез]. [Алар:] «Баш өсте», – [диләр]. Китапчы Фуад әфәнде берлән бер якка китә, мине Мәхмүд Газнәвинең* балаларыннан, Һиндстанда тора-тора телен югалтса да, төреклек кыяфәтен саклаган бер әфәнде берлән, икенче якка җибәрә. Берәр сәгатьтән бик күп эшемезне эшләп бетереп, алар берлә бик самими күрешеп, китәмез. Ләкин иртәгә иң зур эшемез калды: акча алыштыру. Сәгать унда без пароходта булырга тиеш булганга, унга кадәр шул эшне бетерергә мәҗбүрмез. Аннан башка әйберләр дә бик күп, аларны да алып барырга кирәк. Пароходта үземезгә денщиклык хезмәтен итә торган бер хадимне чакырып хат яздык. Таба алса, килсә ярар иде. Килмәсә, эш харап. Тагы ниләр калганын бер мәртәбә тикшереп, йокларга ятамыз.

*24 нче октябрь*

Мин сәгать берләрдә аякка калыктым. Мәшәкать тә күпкә күрә, рәтләп йоклап булмаганга, йокы ачылсын өчен, ваннага кердем.

Аннан Фуадны торгызып, әйберләрне җыештырырга тотындым. Кырык төрле әйберне төрлечә әпен-төпен иттереп оештырып, чәйгә утырганда, теге сәяхымыз да килеп җитте. Сәгать сигездә, түләп, номердан чыгып киттек. Юл буе эшемез сарраф-

---

[1] Саррафлар – акча алыштыручылар.

* Мәхмүд Газнәви – Йәмин әд-Дәүлә Мәхмүд ибн Сәбух-тәгин әл-Газнәви (971–1030), Ганнәвиләр әмире һәм патшасы. Идарә иткән еллары – 998–1030. Талантлы хәрби һәм сәясәт эшлеклесе, ислам тарихында танылган шәхес. Чыгыш белән гарәп түгел, төрки кавемнәм. Һиндстанда исламны җәелдерүдә Мәхмүд Газнәви һәм аның дәвамчыларының роле зур була.

та сатулашу булды, һичбер төрле очына чыга алмагач, бер магазинга кереп алыштырдык. Тагы бер мәртәбә базарны йөреп, тагы бәгъзы бер нәрсә алып, пароходка килдек.

Сәгать инде унбер булса да, пароход әле китәргә уйламый да. Безне кирәкмәгәнгә ашыктырмаган булсалар, без иркенләбрәк эшләрне бетерәчәкмез икән, иркенләбрәк вакытымызны бүлә аламыз икән. Без шулкадәр ашыктык. Хәтта озын хатлар язарга да булдыра алмадык. Милли Идарәгә моннан да мәктүб язылмады. Востокка[1] вә һакәза[2]. Харбинга, без бик сәламәт барамыз, дип, ачык хатка яздым. Пароходка килгәч, безнең бик күп кирәкле әйберемез калганы мәгълүм булды. Ләкин пароход хәзер китә, хәзер китә дип торганга, без тагы чыгып йөри алмадык. Сәгать биш тә егерме минутта, Востоктан чыкканымызга өч атна тулган минутларда кузгалдык. Инде без Малакка бугазы* буйлап бераз шимале гарбигә[3] таба хәрәкәт итәмез. Аннан соң Һинд диңгезенә** чыгып, туп-туры барып, Баб-әл-Мәндибкә*** китәчәкмез. Пароход киткәч, безнең, Сәрандип атасына[4] туктамаенча, тугры Баб-әл-Мәндибкә, Җибутига**** барачагымыз мәгълүм булды. Димәк, безнең алган азыкларымыз, кирәк-яракларымыз тагы җитмәячәк, Аллага тапшырдык.

---

[1] Д ө р е с е: Владивостокка.

[2] Вә һакәза – һәм башкаларга.

* Малакка бугазы – Көнбатыш Малайзиянең Малакка ярымутравы һәм Индонезиянең Суматра утравы арасындагы бугаз. Географик яктан Малакка бугазы Кытай белән Һиндстан арасындагы мөһим маршрут санала. Андаман һәм Көньяк Кытай диңгезләрен тоташтыра.

[3] Шимале гарбигә – төньяк-көнбатышка.

** Һинд диңгезе – монда Һинд океаны күздә тотыла. Ул зурлыгы ягыннан дөньяда өченче урынны били. Африка белән Австралия континентлары арасында урнашкан.

*** Баб-әл-Мәндиб – Кызыл диңгез белән Гаден култыгын тоташтыра торган Баб-әл-Мандеб бугазы.

[4] Сәрандип атасына – Цейлон утравына.

**** Җибути – (Джибути) – Төньяк-Көнчыгыш Африкада Гаден култыгында урнашкан зур булмаган ил һәм аның башкаласы Җибути (Джибути) шәһәре. Ул – мөселман иле. Халкы гарәп һәм француз телләрендә сөйләшә.

Сингапур шәһәре хатты истивадан бер дәрәҗәдә унҗиде минутта гына тора. Үзе кечкенә генә бер җәзирәдә[1] бу шәһәр. Бу җәзирәнең төп халкы – малайлар[2]. Боларның иң зур кыйсеме[3] – мөселман. Монда идарә элгәре мөселман кулында булган. Хәзердә солтанның исеме бар, җисеме юк. Фәкать акчаларына малайча язылган була. Фәкать идарә тәмамән инглизләр кулында.

Бу бугаз Кытай, Япония, Себер юлының күпере булганга, һәм дә, Һиндстан, Кытай, Япон тарафыннан саклар өчен иң зур йозак булганга, инглизләр моңарга күптән әһәмият биргәннәр һәм дә бик җиңеллек берлә кулда иткәннәр. Хәзер идарәләре бик аксак. Аның әсасы[4], мондагы мөселман халкының кувәи дикъкатен[5] бетереп, алар урынына христиан малайларны утырту. Ләкин элгәре аларны инглиз рухы берлә рухландырып утырту. Шуның өчен монда, һәрбер почмакта, зур-зур инглиз мәктәпләре. Һәммәсендә дә шыгрым тулы. Христиан баласы, чин баласы, һәммәсендә дә дөньяның иң зур милләте – инглиз милләте, иң шәп милләт – инглиз милләте, иң матур хәят[6] – инглиз хәяты дигән фикерләр йирләштерелә. Шулай итеп, өченче дәрәҗәдә инглизләр йирештерелә. Шулардан кечкенә мәэмүрләр куялар, шуларны кечкенә «буржуйчиклар» ясыйлар, шулар берлән үзләрен урап алмакчы булалар. Шуларга таянып, мәмләкәтне идарә итмәкче булалар. Фәкать шул сәясәттән йирле мөселман[нар]ны гына читкә калдыралар, чөнки алар – мөселман. Алар – җәннәт кошлары, аларга дөнья кирәк түгел, аларга ахирәт тансык. Ахирәт дисәң, мә, рәхим ит, мәсҗедкә кер. Сасы суда ун мәртәбә тәһарәтлән. Мәсҗедкә [кереп], ун мәртәбә, йөз мәртәбә намаз укы. Инглизләр бөтен ислам галәменә каршы. Диндә консерваторлык, ягъни иске фикер тарафы мөселманнарны химая итүне[7] монда да [...] итәләр. Монда да ислам диненең хамисе[8]

[1] Җәзирәдә – утрауда.
[2] Малайлар – малайзиялеләр.
[3] Кыйсеме – өлеше.
[4] Әсасы – нигезе.
[5] Кувәи дикъкатен – игътибар итү көчен, кызыксыну сәләтен.
[6] Хәят – тормыш.
[7] Химая итүне – саклауны, яклауны.
[8] Хамисе – яклаучысы.

булып күренеп торган һәртөрле яктылыгына каршы, һәрбер төрле аң таратуга каршы. Үзләренең кара көчләре берлән аларны издерәләр.

Дөньяның башка җирләрендә моңынчыга кадәр инглизләрнең садыйкы[9] мәсьәләсе булып килгән тәгассыб[10]. Монда да әле инглизгә кол булып хезмәт итә [торган] малайларның мөселманнары фәүкыльгадә[11] куркак булырга охшый. Араларыннан һичбер төрле хәрәкәтләр галәмәте юк. Мәктәп юк, мәдрәсә юк, әдәбият, матбугат юк.

Мөселманнар даирәсендә һичбер төрле хәятлар күрмәдек. Мөселманлыклары шул пычрак суда юынып, намаз укудан гына гыйбарәт булырга охшый. Өч көн йөреп, араларында «Сездә ни хәл бар?» дигән бер сөаль ишетмәдек. Шуңарга күрә актык көннәрдә боларга каршы бертөрле ачу килү, җирәнү, кызганудан мөрәккәб[12] бер хис баглый башладык.

Пароходымыз, әүвәл уйлаганча, иртән китә. Һиндстан мөселманнары аша, әлбәттә, мондагы әхвальне яхшырак беләчәк идек.

*25 нче октябрь*

Пароходка яңадан өйрәнү бик авыр. Тагы шул товарищлар берлән бару бик күңелсез. Ләкин нишлисең?

Фуад авырый башлады. Күзе авырта. Тәненә бик күп сыткылар чыккан да шулар йөдәтә. Рәхәтләнебрәк ятарга дип алган караваты бернигә ярамады. Беренче ятуда ук төбе ертылып төште. Пароходта кияр өчен дип алган туфлиләремез шул көнне үк сыпылып чыкты. Бөтен халыкның монда алган әйберсе ертылып, сүтелеп эштән чыкты. Мал фәүкыльгадә начар икән. Мондагы алучы сәрбәст[13] булганга, инглизләр, күрәсең, монда махсус начар нәрсә саткалыйлар.

Көн эссе түгел. Һава болытлы. Берничә мәртәбә ягмур да явып китте.

---

[9] Садыйкы – тугрылыгы.

[10] Тәгассыб – фанатизм.

[11] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[12] Мөрәккәб – катлаулы.

[13] Сәрбәст – читен хәлгә төшкән.

*26 [нчы] октябрь*

Без тагы чәйнек алырга оныткanмыз. Урындыклар булгач, безгә бераз мохтаррак[1] барырга мөмкин иде. Ләкин чәйнек юклык безне тагы башкалар алдында мохтаҗ итә. Көн зарарсыз. Без әле һаман Малакка бугазы буйлап барамыз. Көн буе кечкенә агачлар күренеп кала. Төн буе әледән-әле монда утлар ялтырый. Монда диңгез. Хәрәкәт көчлерәк булырга кирәк. Бер көннән өч пароходка очрыймыз. Фуад тәмам авырып ята. Бу көн әйберләрне урынлаштырып үтә.

*27 нче октябрь*

Иртә берлән көн ягмурлы. Сәгать уннарда гына бераз көн ачыла. Алай да кояш һаман болыт астында. Сәгать унберләрдә без Һинд диңгезенең уртасындагы Никамбур аталарына* җитәмез. Бик озакка кадәр аталар күренә. Кояш бату алдыннан гына күздән югалалар. Без хәзер бераз чыгып, гаребкә[2] табарак барамыз. Аннан тугры юл буйлап, Сәрандипкә таба китәчәкмез. Бүген сәгать уникедә Җибутига әле өч мең дә егерме тугыз миль калган иде. Һава яхшы булса, пароходымыз бозылмаса, унөч көнлек юл дигән сүз. Бүген иртәрәк ятарга приказ булды. Халыкның һәммәсе тугызда ятып беттеләр. Боларның сүз тыңлаулары гаҗәп. Төн буе карта уйнап тора торган чехлар һәммәсе яткан.

Бүген азрак диңгез уйный. Кайбер кешеләр диңгез хасталыгына да тотылдылар.

*28 [нче] октябрь*

Бүген – чехларның истикъляль[3] игълан итүләренең бер елы тулу бәйрәме**. Иртүк торгызып, бәйрәмчә сыйларга тотынды-

---

1 Мохтаррак – ireклерәк. Б и р е д ә : иркенрәк, җайлырак мәгънәсендә.

* Никамбур аталары – Никобар утраулары, Һинд океанында Бенгаль култыгындагы утраулар группасы.

[2] Гаребкә – Көнбатышка.

[3] Истикъляль – бәйсезлек.

** Бүген чехларның истикъляль игълан итүләренең бер елы тулу бәйрәме. – 1918 елда Автро-Венгриянең таркалуы нәтиҗәсендә Беренче Чехословакия республикасы барлыкка килә. 1918 елның 28 нче октябрендә Чехословакиянең бәйсезлеге игълан ителә. Бу дәүләт 1938 елның сентябренә кадәр яши.

лар. Иртә берлән теге чәй урынына имән әкәләсеннән[1] кайнаткан кофе бирделәр. Су савыты тимер косканга, суы да бик тәмсез. Шуңарга кофе үзләренең милли ашлары кнедлики кебек чыкты. Сәгать җиделәрдә оркестр милли гимн уйнады. Хорлары милли вә дини бер нәрсә җырладылар. Шуннан соң пароходның коменданты булып бара торган яшь офицер рәсми нотык сөйләп, нотыгын Чехословак җәмһүриятенең рәисе Масарикның* исәнлегенә өч мәртәбә «Наздар»** кычкырды[2]. Шуның берлән бу кыйсеме[3] тәмам булды. Халык ашарга хәзерләнә башлады. Бүген аш та бәйрәмчә булачак, имеш. Сәгать уникедә дөге өйрәсе бирә башладылар. Бу бүгенге ашның беренчесе генә икән, әле тагы сәгать өчтә башка аш та биреләчәк икән. Анда тапаган ит берлә бәрәңге бирелде. Бусы – без пароходка кергәннән бирле әле беренче аш. Аннан соң, үзләре әйтүе буенча, кабаре[4] башланды. Оркестр уйнады, хор җырлады. Араларындагы бер артист – Кублинский әллә ниләр сөйләп көлдерде. Шуннан соң тагы теге эчәргә ярамый торган суны кайнатып бирделәр. Караңгыда күрмичә, шуның берлән бер стакан какао эчкәнгә, әле дә күңел уйнап тора. Аннан соң консервларда итләр тараттылар. Анысы тагы бик тәмсез иде. Шуның берлән бәйрәм тәмам булды. Халыкның үзендә һичбер бәйрәмлек күрелмәде. Берсен берсе тәбрик тә итешмәде. Күңел күтәрерлек бер эш тә эшләнелмәде. Бәйрәмнәре бик тонык чыкты. Мин гомеремдә үзенең шундый зур бәйрәмен, һәм дә беренче мәртәбәсендә [үк], шулкадәр суык иткәнен күргәнем юк иде. Бәлки, бу милләт бәйрәм итә белми торгандыр.

Көн өйләгә кадәр бик эссе булды. Аннан соң җәнүбтән[5] искән җил бераз суык китерде. Безнең пароход хәзер, туп-туры

---

[1] Имән әкәләсе – имән чикләвеге.

* Масарик – Томаш Гарриг Масарик (1850–1937), Чехословакиянең дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, социолог һәм философ. Чехословакиянең бәйсезлеге өчен көрәшүче һәм аңа нигез салучы, оештыручы лидерларның берсе һәм җитәкчесе. Ул 1920–1935 елларда президент була.

** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

[2] «Наздар» кычкырды – сәламләде.

[3] Кыйсеме – өлеше, бүлеге.

[4] Кабаре – күңел ачу, тамаша, концерт.

[5] Җәнүбтән – көньяктан.

иттереп, кояш баешына бара. Без хәзер ачык Һинд диңгезендә. Шул ачык диңгездән Баб-әл-Мәндибкә кадәр бармакчы буламыз. Бүген бераз пароход саллана[1]. Күп кеше диңгез хасталыгына тотылды.

*29 [нчы] октябрь*

Көн артык эссе түгел. Диңгез тынып килә. Гаребтән[2] исә торган җил диңгезнең өстен шадраландырудан уза алмый. Кичкә таба берничә мәртәбә ягмур явып үтә. Пароходымыз һаман тугры гаребкә таба бара. Кояш бүген дә болытка баеды. Без чыкканнан бирле кояш бер мәртәбә дә аязга батмады.

Күк [йөзе монда] төнлә берлән әзрәк кенә башкарак. Йолдызларның бездә күренмәгәне бик күп. Шәрык[3] ягында бер Иләк йолдызы бик матур җемелди. Галәм һәйәтенә[4] махсус елмая. Бу йолдызларның кайдагылар, исемнәре ничек икәнлеген белеп булмый. Ләкин безнең күктән башкалык күзгә ташлана. Монда тагы болытлар безнекенә охшамый. Бик калын күренәләр. Һәм дә төсләре бик ачык төстә була. Берсе сөт кебек ак, ап-ак кар тавы кебек күренә. Берсе чем-кара, кара төн кебек, коточкыч, йотардай булып тора. Берсе ут кебек кызыл.

Диңгез көндезләрен зөмред[5] кебек.

Урындыклар булгач, хәлемез бераз яхшырды.

*30 нчы октябрь*

Бүген иртә берлә, бөтен дөньяны каплап, ягмур ява башлады. Көн буе шулай була дип, бик курыктык. Өйләгә көн ачылып, сәгать уникеләрдә Сәрандип атасы күренә башлады. Кояш баеганчы, атага бик якын йирдән килдек. Корыдагы агачлар, балыкчы йортлары бик ачык күренде. Монда пароход йөрүе бик зур булырга кирәк. Бервакытта тәмам дүрт пароход булып торды, бервакытта алты булды. Кич берлән Сәрандипнең маяклары һаман күренде. Сахилдән[6] узачакмы, юкмы, белмим.

---

[1] Саллана – чайкала.
[2] Гаребтән – Көнбатыштан.
[3] Шәрык – Көнчыгыш.
[4] Галәм һәйәте – күк йөзендә әйләнә торган Җир һәм барлык галәм.
[5] Зөмред – зөбәрҗәт.
[6] Сахилдән – яр буеннан.

Җибутига бүген сәгать уникедә ике мең дә өч йөз алтмыш миль калды, ягъни тугыз көн барасы дигән сүз. Сау-сәламәт булсак, бу якшәмбе үтеп, киләсесендә җитсәк кирәк.

Бүген Мәскәүдә бер көйне сөеп уйната торган гаиләне төштә күрдем. Иттифакый[1], шул көйне монда да уйнадылар. Минем хакта уйлый торгандыр, ахрысы. Мин бит үзем төшкә ышана торган мөсафирдан. Уй-тойгының бер кешедән икенчегә бирелүенә ышанмый торган кеше.

## 9 нчы дәфтәр

*31 нче октябрь*

Көн матур. Һава эссе түгел. Иртә берлә бераз ягмур булып үтте. Без инде Сәйлүнне[2] үттек. Көн буе каршы-каршы берничә пароход очрый. Мин шактый начар йоклыйм. Көндезләрен баш авырта. Бүген Востоктан чыкканга, ай исәпләре берлән, бер ай тулды. Сингапурдан чыкканга бер атна булды. Бу атнаны шактый җиңел үткәрдек. Җибутига әле бик күп, ничек үткәрермез инде.

*1 нче ноябрь*

Көн матур. Иртүк без берничә җилкәнле көймәгә очрыймыз. Димәк, без сахилдән[3] ерак түгел. Сәйлүннең бу ягында берничә кечкенә аталар[4] бар. Шулар яныннан үтәмез булырга кирәк. Бүген сусызлыктан халык йөдәде, юынырга татлы су да, тозлы су да булмаенча торды. Минем башым бүген шактый авыртты. Суык тидеме, әллә эссе суктымы. Көн бүген дә эссе түгел. Без хәзер җиденче дәрәҗәләрдә барамыз булырга кирәк. Хәзер монда көн берлән төн тигезрәк. Кояш алтыларда чыга, алты чирекләрендә[5] бата. Җил һаман аз-маз бар. Тирә-юнь һаман

---

[1] Иттифакый – очраклы рәвештә.

[2] Сәйлүнне – Цейлонны (утрау).

[3] Сахилдән – диңгез ярыннан.

[4] Аталар – утраулар.

[5] Алты чирекләрендә – алты сәгать 15 минутлар тирәсендә.

болытлы. Бүген сәгать уникедә Җибутига йөрмәктә дә сигез йөз миль калды. Без инде Востоктан Марсельгә барачак юлның яртысын үттек. Димәк, тагы берәр айдан без Марсельдә булачакмыз. Алла исәнлек бирсен инде.

*2 нче ноябрь*

Бер дә яңа эш юк. Баруымыз һаман бару. Һава һаман бер хәлдә. Көн шактый җилле. Кояш артык эссе түгел. Без хәзер Омскилар тугрысына килеп җиттек.

Мин бүген шактый начар йокладым. Ятак бүлмәсе һаман эссе. Ашау-эчү начарлана төште. Берничә көннән бирле кичке ашка ит консервасы бирәләр. Шактый черегән, шактый тәмсез. Сингапурдан инглиз гаскәренең калдыгын сатып алганнар.

*3 нче ноябрь*

Бүген без Востоктан чыкканга тәмам бер ай булды. Бездән хат алмагач, инде безне югалтканнардыр. Хәерле булсын. Бер айда биш мең мильдән артык юл үттек. Ләкин күргән йиремез Малакка шәһәр-җәзирәсе* генә булды. [...] Бумбайда туктаган булсак, бик һәйбәт булыр иде дә, нишлисең инде. Ихтыяр бездә түгел.

Бүген төннән бирле шактый каты җил безгә каршы исә. Шуңарга пароходымыз акрынрак бара. Җил һаман Көнбатыштан булса, пароходымыз тагы кичегер. Ашау әйберләремез азаеп килә. Бүген көн буе кулланырга диңгез суы булмады. Ни дип диңгез суын кызгана торганнардыр. Алла беләсе. Идарәләренең уңмаганлыклары көннән-көн күзгә ташлана. Җибутины көтү шактый авыр. Диңгез дә һич үзгәрәсе юк. Һаман су, су, су. Әле бер өч көнсез тупрак күрелмәскә тиеш.

*4 нче ноябрь*

Көн яңа бернәрсәсез үтте. Җил һаман дәвам итә. Пароход төнлә берлән шактый салланды. Хәзер без ун дәрәҗә ярымда барамыз. Озынлыгы – без бүген Уфа тирәсеннән үттек. Бүгеннән Җибутига бер мең дә ике йөз миль калды. Якшәмбесез ба-

* Малакка шәһәр-җәзирәсе – Малайзиянең Малакка ярымутравы территориясендә шул исемдәге штатның административ үзәге булган Малакка шәһәре.

рып җитә алмады. Бүген тагы кнедлики биргәннәр иде. Бер чех авырды. Бу аш – чехларның вәхши вакытларыннан, утны белмәгән чакларыннан калган аш булырга кирәк. Ләкин милли булгач, бик мәңгы[1] гасырда да ашап киләләр. Бу диңгез бик ахмак икән. Һичбер нәрсәсе юк: ни балыгы, ни кошы, ни дельфины, ни дулкыны. Иләмән ишәге кадәр су басуы, су сахрасы. Диңгез, имеш.

*5 нче ноябрь*

Көн яхшы. Һава уртача. Төнлә дулаган җил бераз басылган. Төннәрен җил булганга, миңа йокларга мөмкин була башлады. Урын ул кадәр эссе түгел. Күлмәксез ятып була. Бүген өйләдән соң безнең пароход Гаденнан* бер телеграмма тотты. Һава җилле булганга, телеграмма бик үк тулы түгел. Мәгънәсе моннан гыйбарәт: «Себердәге сугышта чехлар тагы җиңелделәр. 27 полкын әсир алганнар». Бу ни дигән сүз? Гадендагы телеграфистларның Себердәге сугышчыларның җөмләсен[2] чех дип атауларыннан килгән хата гынамы, әллә чыннан да Себердә чехлар сугыша башлаганнармы? Сугышсалар, кемгә каршы сугышалар? Без китү алдыннан Колчакка** каршы күтәрелү көннәре иде. Аның организациясе инглизләр кулында булып, көч җитмәүләр булачак иде. Ләкин русларның демократиясе ышанмаенча караганга, эшкә керешә алмаенча тора иделәр. Бәлки, бездән соң рус демократиясе, хосусан, эсерлар берлән аңлашканнардыр да Колчакка каршы хәрәкәт башлангандыр. Болай булганда, һәм дә бу хәрәкәттән чехлар җиңеп чыкканда, идарә демократия кулына биреләчәк. Директорийның бәгъзы әгъзалары һәм дә Себер областной Думасының декреты аша биреләчәк иде. Бу юл калса, бәлки, Русиядәге үзара сугышлар бетәр иде. Демократия большевиклар берлән аңлашыр иде. Икенче ихтимал – Колчакның шул планнан хәбәрдар булып, Япония берлән аңлашып,

---

[1] Мәңгы – тыелган.

* Гаден – Йәмәндә Гарәп диңгезенең Гаден култыгы яры буенда урнашкан шәһәр. Зур диңгез порты. Төп халкы – гарәпләр.

[2] Җөмләсен – һәммәсен.

** Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус сәясәт эшлеклесе, галим, океанограф. Россиядә Гражданнар сугышы вакытында акгвардиячеләр хәрәкәте җитәкчесе.

чехларга каршы үзенең һөҗүме. Ул вакытта чехларның хәле бик начар булу ихтималы бар. Һәм дә Колчак җиңеп чыкса, Себердә фәүкыльгадә ахмакча бер реакциянең урнашу ихтималы бар. Һәр нә исә, бер эш булырга кирәк. Мондагы чехларга бу хәбәр зур тәэсир итте. Һәммәсе шуны мөзакәрәгә[1] тотынды. Бик күбесе үзләренең баш[лык]ларының Колчак берлән дусча мөгамәләсеннән риза түгел икән. Бакалым[2], ни булыр.

*6 нчы ноябрь*

Бүген иртән сәгать тугыздан ук коры [җир] күренә башлый. Сәгать унберләрдә аның якасына[3] килеп җитәмез. Ул Гаден көрфәзенең[4] уртасындагы Сокотра* дигән озынча бер ата булып чыга. Ул ата Африкада хисаплана.

Без атага бик якыннан үткәнгә, беренче мәртәбә Африка тупрагын күрәмез. Беренче күргән Африкамыз шәп түгел – таулык, ташлык, комлык. Һичбер яшеллек күренми. Җәзирә буйлап көн буена барсак та, ни атауның үзендә, ни яр якасында җан галәмәте сизелми. Кем дә юк. Пароход та юк. Халәнки[5], унике мең әһали[6] булырга кирәк. Җәзирәнең бу ягы таулык, ташлык, комлык булганга, бөтенләй ташландык булырга кирәк. Атаның алдысына[7] чыгамыз. Бер томан берлән капланган. Кояшның эсселегеннән күтәрелгән бумы, әллә җил искәннән тузан күтәрелгәнме? Көн шактый эссе, диңгез дә җанлырак. Берничә мәртәбә кит күрәмез. Монда кит балыгы булмаска кирәк. Күрүебезчә, бар.

Кояш бүген, без чыкканнан бирле беренче буларак, ачык диңгезгә бата. Ләкин шәфәкъләре еракка китми, суга төшә дә югала.

Бүген халыкның рухы күтәренке. Минем дә кәеф бар. Мигъдәм[8] шактый яхшы эшли. Фуад әллә нинди чуаннар, кыяраклар берлән йөреп беткәннең соңында терелеп килә.

---

[1] Мөзакәрәгә – сөйләшергә, фикер алышырга.
[2] Бакалым – карарбыз, күрербез.
[3] Якасына – янына, яры буена.
[4] Гаден көрфәзенең – Гаден култыгының.
* Сокотра – Йемен дәүләтенә караган Гаден бугазындагы утрау.
[5] Халәнки – чынлыкта.
[6] Әһали – халык, кешеләр.
[7] Алдысына – алдына, ал ягына (икенче ягына).
[8] Мигъдәм – ашказаным.

Кичә чехлар хакындагы телеграмманың тәфсире[1] бүген дә булмады. Җибутига бармаенча беленмәс инде. Бүген төнлә, йә иртәгә иртүк пароходымыз Гаден көрфәзенә керә. Бер-бер төрле бәла-каза булмаса, якшәмбе көн Җибутига барып җитә.

*7 нче ноябрь*

Без торганда инде, пароход Гаден көрфәзендә иде. Африканың яры буеннан көн буе бардык. Гаден көрфәзендә һава тагы тынрак. Җил бик аз. Көн тагы эссерәк. Көн буе пароходның әле бер ягында, әле бер ягында кит балыклары күренеп китәләр. Бөтен гәүдәләре берлән чыкмасалар да, берсендә койрыкларын бутыйлар, берсендә башларын чыгаралар. Өйлә вакытына Җибутига да дүрт йөз илле миль кала. Димәк, якшәмбе көн иртә сәгать җиделәрдә Җибутида булачакмыз. Кич берлә безнең пароход Җибутидан «Монда мал юк, Гаденда бар» дигән телеграмма ала. Шуның берлә ул курсын Гаденга таба бора. Без хәзер Африкага таба түгел, тагы Урта Азиягә карап хәрәкәт итәмез. Гаден Җибутига караганда якынрак булганга, без иртәгә үк Гаденга җитәмез. Бу хәбәр бөтен пароход әһленә зур тәэсир ясый. Һәммәсе хәрәкәткә килә. Пароход әһле бик озакка кадәр шул үзгәрешне мөзакәрә итә[2]. Мәдрәсәләрдәге ифтар көткән кебек, Гаденны көтәргә торамыз. Безнең өчен Гаден, бәлки, уңайрак булыр. Анда без, бәлки, күбрәк мәгълүмат җыя алырмыз. Бәлки, төрекләрне очратырмыз. Бәлки, татарлар да килеп чыгар. Ансат юлдан Русиядән, бәлки, хәбәр ала алырмыз. Икенче яктан, Африканың яныннан китеп, аның тупрагына аяк баса алмаенча китәмез. Кайчанга тагы монда киләчәкмез дә кайчан бу йирләрне күрәчәкмез.

Иртәгә Гаденга чыгарга хәзерләнәмез. Безнең ният – монда да номерга чыгып, кунып бераз хәл җыю. Кояш бүген дә диңгезгә батты. Кич җылы булганга, җил аз булганга, ятак бүлмәмез бик эссе, бик сасы. Бүген бөтенләй йоклап булмас, ахрысы. Кичә дә шул сасыда йоклый алмаенча баш авырткан иде. Чехларның сасысын иснәргә Алла күркәм сабырлык бирсен.

[1] Тәфсире – аңлатмасы.
[2] Мөзакәрә итә – тикшерә, фикер алыша.

*8 нче ноябрь*

Иртүк Гарәбстан сахиле[1] күренеп бара. Сул якта да, Африка тарафында да еракта гына җир күренә. Харитага[2] караганда, Гаден бугазы шактый киң булганга, Африка яры күренмәскә тиеш иде. Бәлки, берәр ата бардыр. Өйләдән соң сәгать дүртләрдә Гаден кальгасы[3] күренә башлады. Зур ташлы кыяларда, шуларның астында ерылып кергән култыгын сәгать бишләрдә кальгадан бик якын җирдән үтәмез. Туплар, ныгытылган урыннар күренеп кала. Сәгать алтыларда култыкның урта бер җирендә, диңгез ярына ярты чакрымнар чамасында, безнең пароход якорь салды. Шуннан соң берсе артыннан берсе безнең пароходны төрле түрәләр зиярәт итә[4] башлый. Кальганың хәрби мәэмүре, чик түрәсе, полиция мөдире, әллә нинди гарәп-инглиз катыш спекулянтлар.

Сәгать җиделәрдә утлар алына. Пристань шактый матур ялтырый. Бу әле Гаден шәһәре түгел, бу пристань гына. Гаден шәһәре моннан җиде чакрымда. Пристань зур түгел. Тау битенә салынганга, төнлә ай яктысында бик матур күренә. Яр буендагы бер клубтагы күп ут, музыка күңелне ашкындыра.

Безгә иртәгә пристаньга чыгарга һәм дә шәһәргә барырга мөмкинлек белдерелә. Пароходның ике тәүлек торачагы игълан ителә. Тагы әллә нинди кешеләр, тагы сүзләр китә. Безгә икенче мәртәбә: «Пароход иртәгә сәгать алтыда Җибутига китәчәк, монда җитәрлек товар юк», – диләр.

Без шул кыска вакытта шәһәргә барып килергә буламы дип сорыймыз. Була, рәхим итеңез, диләр. Тагы бераз вакыт үтә. Шәһәргә чехословак солдаты киеменнән генә барырга мөмкин дип игълан итәләр. Безнең киемемез үземезнеке булганга, чех солдатының сасы, эссе киемен киеп чыгарга имкян[5] булмаганга, без Гаденны күрмимез дигән сүз булып чыга. Бу хәбәр безнең кәефне бик боза. Тагы сорашабыз. Кырык кеше кырык төрле

[1] Сахиле – яр буе.
[2] Харитага – картага.
[3] Кальгасы – шәһәре.
[4] Зиярәт итә – килеп карый.
[5] Имкян – мөмкинлек.

сөйли. Дөресен белгән һичкем юк. Бу чехларның мөәссәсәләре[1] төрек мәхкәмәләренә[2] бик охшый. Аларның мәхкәмәләрендә көн буе кятибтән[3] кятибкә йөреп, эшеңнең очын таба алмый идең. Боларда да шулайрак. Хосусан[4] офицер халкы бик начар, мәгънәсез, тәртипсез.

Төн бик тын. Диңгез тулы ай яктысында көзге кебек ялтырый. Диңгезнең тынычлыгына аз гына да зарар итәрлек җил юк. Тулы ай рәхәтләнеп диңгездә йөзә бирә. Җир шарында тып-тын. Һаваның үзендә әллә нинди гаҗәп бер тынлык. Шул табигать диңгезе, һавасы, тавы, шәһәре, кешесе, балыгы – һәммәсе озын сәҗдәгә киткән дип белерсең.

Иртәгә ни булыр? Иртәге көннән бераз файдалана алырмызмы? Әллә авыз суымызны агызып, шәһәргә карап кына торырмызмы?

Уналты көнербуйдан суда булганга, корыга бик сагынылган. Аякларның җиргә басып йөрисе килә. Күзләрнең чехословак солдатыннан башка кешеләрне күрәсе килә. Телләрнең чехларның сөйләгән сүзләреннән башка сүзләрне сөйлисе килә. Баш чех Масарик, Прага дигәннән туеп беткәнгә, һәр ничә башка уйлар уйлыйсы килә. Бакылым, ни булыр. Бүген көпә-көндез Зөһрә йолдызы күренеп торды. Һава бик саф булырга кирәк.

*9 нчы ноябрь*

Бүген мин таң берлән аякка калыктым. Таңның сыек яктысы астында Гаденны тагы бер мәртәбә карыйм. Гарәбстанда кояш чыгуын каравыллап алмакчы булам. Иртә бик тын. Ни адәм, ни хайван, ни кош бар – һәммәсе йоклый. Кояш таш атау артыннан шәфкатьләрен җибәрә башлауга, диңгез җанлана. Әллә кайдан йөзләп-меңләп акчарлаклар пароход өстеннән очалар. Кап-кара.

Әйберләрен төяп, әллә никадәр көймәләр пароходны камап алалар. Кояш чыга. Пристаньдагы сәгать алтыны суга.

[1] Мөәссәсәләре – оешмалары.
[2] Мәхкәмәләренә – хөкем йортларына, судларга.
[3] Кятибтән – секретарьдан.
[4] Хосусан – бигрәк тә, аеруча.

Сахилдәге[1] инглиз чиркәве вәкарь генә чиркәү [чаңын] кагарга тотына. Бу тавыш, Гарәбстанга һичбер мөнәсәбәте булмаган тавыш, безгә әллә нинди бер хис уята, әллә кай йиремезне мыскыл итә. Ләгыйнь, юньсез Гарәбстанда, исламның чыккан җирендә, исламиятнең башланган гасырыннан бирле христианлык манигъ ителгән[2] йирдә, 14 нче гасырда христианлыкның билфазыйль[3] килеп керүе бик ямьсез тәэсир калдыра. Ошбу исламият асылда җиңелде. Ул башка илләрне, башка йортларны, башка милләтләрне үзенә буйсындыру кайда? «Үзенең төп йортын, кендек урынын саклый алмас», – диюгә, килеп: «Ул инде бетте», – дигән кебек булды. Бу чиркәүнең һәрбер чыңлавы безгә, шуны тотмаган кебек, эчне пошырганнан-пошырды, ачуны китергәннән китерде. Шул чиркәү, шуны кагучыга, шуны салучыга, шул чиркәүне саклаулары күңелнең эчендәге ачуын кайнатып-кайнатып чыгарды. Әйе, дөресте шул. Исламият хәзер үзенә өммәт арттыру дәртеннән үткән. Исламият инде хәзер яңа йортлар, яңа илләргә җәелү дәвереннән үткән. Исламият хәзер оборона дәверенә кергән. Гарәбстандагы кебек беренче мәртәбә туган йирендә инде ул үзен үзе сакларлык дәрәҗәдә дә калмаган. Ул картайган, искергән, мескенләнгән.

Үзенең бабасының йортын да, үзенең пәйгамбәренең зиярәтен дә саклый алмаган ул халык христиан инглизгә әсир булган. Ул халык христианлык мәзһәбе шәфкате аркасында яши торган мескен, гариб булган.

Пәйгамбәрнең үлү алдындагы васыятьләреннән берсе – гарәп йортында исламнан башка динне калдырмау булган. Фәкать Гомәр заманасында* Гарәбстанда мөселман булмаган беркем калмаган.

---

[1] Сахилдәге – яр буендагы.

[2] Манигъ ителгән – тыелган.

[3] Билфазыйль – өстенлек белән.

* Гомәр заманасы – Гомәр – Гомәр ибн әл-Хаттаб әл-Фарук (591–644), Мөхәммәд пәйгамбәрнең фикердәше һәм варисы, дәүләт эшлеклесе, дүрт изге хәлифәнең Әбүбәкердән соңгы икенчесе. Гомәр хәлифәлеге заманында (634–644) хәлифәт күпмилләтле, әмма бер динле мәмләкәт булып оеша. Аның заманында мөселман гаскәре Палестинаны, Мисырны, Ливияне һәм Персиянең зур өлешен яулап алалар.

Ливамызның[1] шул вакытын, Мәккәдә өч йөз елларга кадәр сакланылган ливамызның шул вакытын, йирендә тотар өчен безнең төрек баласы әле габбасый хәлифәләре* командасында, әле төрле-төрле төрек әмирләре командасында, әле Сәлҗүк падишаһлары, әле Сәлахетдин Әюби** командасында, әле госманлы солтаннары командасында миллион-миллион җаннар көрәшкән, миллион-миллион углын корбан иткән, ләкин дошман галәменең, христиан галәменең бөтен тырышуы-тырмашуын – һәммәсен астын өскә китерә килгән. Мең ел бербуйдан гарәп йиренә, пәйгамбәрнең ата йортына христианны аяк бастырмаган, христианның чиркәвен салдырмаган. Гарәпнең тупрагын мыскыл иттереп чиркәү кактырмаган. 14 нче гасырда гарәп шәехләренең хыянәте, сатлыклыгы аркасында, Гарәбстанның сахилләрен[2] саклый алмаган. Инглизләр, гарәп шәехләрен акчага кызыктырып, мөкаддәс йирләрен сатып алганнар. Монда китереп чиркәүләрен салганнар. Гарәпнең ни дине, ни малы үзен үзе сакларга җитәрлек булмаган. Үзенең каравылындагы төрек углы гарәпнең хәятын, йирен каравылын ташларга мәҗбүр булгач та, шул йиргә гарәп үзе килеп баса алмаган. Ул йир буш калган. Ул мөкаддәс урын каравылсыз калган. Шунда инглиз китереп үзенең чиркәвен салган.

Тиз-тиз генә чәй эчкәч, тагы чыгу чарасын күрергә тотынамыз. Чехларның башы ахмак бер малай[3], безгә төрле-төрле юллар берлә манигъ булырга[4] маташа.

---

[1] Ливамызның – байрагыбызның.

* Габбасый хәлифәләре – өммәвиләрдән соңгы хәлифәләр династиясе. Идарә еллары – 750–1258.

** Сәлахетдин Әюби – монда күренекле гаскәр башлыгы, Мисыр һәм Сүрия солтаны Сәлахеддин Әюби (әл-Мәликән-Насыйр Сәлах-әд-дөнья вәддин Әбүл-Мозаффар Йосыф бине Әюб бине Шади әл-Көрди, 1138 – 1193) һәм аның җиңүле хәрби походлары турында сүз бара. Чыгышы белән төрки кавемнән булган, Мисыр мәмлүкләре династиясе вәкиле, полководец Сәлахеддин Әюби Европадан тәре паходы белән килгән христианнар гаскәрен тар-мар итә. Коддесне азат итеп, мөселманнарга кайтара. Аның гаскәре составында мөселман төркиләр дә күп була.

[2] Сахилләрен – яр буе полосасын.

[3] Малай – м о н д а: «яшь офицер» мәгънәсендә.

[4] Манигъ булырга – киртә куярга, тоткарларга, тыярга.

# 10 нчы дәфтәр

Ахырдан, ачу килеп, инглизләрнең гаскәри «Фиакант» дигән фрегатларын* тотар өчен, башымызга чехның фуражкасын киеп, дөрестен әйткәндә, Гарәбстан туфрагына басканда, без, төрек балалары, бөтен гомерләре шул исламиятне мөхафәзәгә[1] сарыф ителгән төрекнең балалары, чехның солдат фуражкасына сыгынып, гарәп тупрагына аяк басамыз.

Гаяз Исхакый, Фуад Туктар булып түгел, әллә нинди ахмак исемнәр берлә сахилгә чыгамыз. Анда безне куркыткан һичбер нәрсә булмый. Бездән ни паспорт сорыйлар, ни рөхсәт сорыйлар. Гарәбә[2] алып, Гаден шәһәренә китәмез. Гарәбәче[3] – африкалы бәрбәр. Начар гына гарәпчә сөйли. Акрынлап пристаньнан ерагаямыз. Алдымызда да, янымызда да – кыя.

Яп-ялангач кыя. Ни бер үлән бар, ни бер агач бар, ни бер чәчәк бар. Һәммә нәрсә янган, һәммә нәрсә көйгән. Менә гарәп авылы. Түбәләре тип-тигез итеп ябылган өйчекләр: кайсылары таштан ясалган, кайсылары камыш берлә балчыктан. Кечкенә тәрәзәләре, зур гына ябык ишекләре урамга карап тора. Тәрәзәләргә челтәр куелган. Ишек алдына чүпрәк чыптадан пәрдә тартылган.

Кисеп ясалган юлдан менәмез, төшәмез. Безгә түбәләренә күтәреп утын ташучы гарәпләр, автомобильләрдә оча торган гарәпләр бик күп очрый. Кәкре аягы берлән чаба вә бара торган гарәпләр, аллы-гөлле чүпрәккә өртелгән балалар, гарәп хатыннары туры килә.

Алдымызда бөтен тарафтан таулар берлән чормалган кечкенә генә, уйсу йиргә сузылып яткан, яхшы бер шәһәр күренә. Биналар тәбәнәк, крышалары[4] юк. Биналар, кояштан курыккан кебек, күккә таба күтәрелмәгән. Манаралар да күккә чыгарга курыкканар. Алар да кояштан качканнар. Бөтен шәһәре, урамы, кешеләре, төяләре, ишәкләре, атлары – һәммәсе һәвефлек,

* Фрегатларын – өч мачталы паруслы элекке сугыш кораблен.

[1] Мөхафәзәгә – саклауга.

[2] Гарәбә – арба, экипаж.

[3] Гарәбәче – кучер.

[4] Крышалары – түбәләре.

фәкыйрьлек, ачлык хисе калдыра. Мондагы бөтен кеше, бөтен хайван, бөтен кош-корт – һәммәсе ач кебек тоела. Һәммәсе ашауны гына уйлыйлар кебек хис ителә. Аттан төшәмез. Безне әллә никадәр кап-кара малайлар, сакаллы кешеләр, күзләре ялтырый торган егетләр чормап алалар. Әллә нәрсә сөйлиләр. Һәммәсе кулын суза. Бәхшиш[1], һәммәсе, бәхшиш, ди. Әгәр кесәңә тыгылып берәрсенә бирә башласаң, кибетендә сату итеп тора торган сәүдәгәр дә сәбәпсез кулын сузачак. Урам буйлап китәмез. Артымыздан, алдымыздан әллә никадәр халык бара. Кибеткә керсәк, бер көтү кеше кибетне тутырып ала. Туктап, кая барырга дип сөйләшә башласак, бөтен тирә-юньдәге бала-чагасы, олысы-кечесе, картрак хатыннары – һәммәсе җыела да безне карый. Өсләренә күтәрелеп карасаң, бәхшиш, диеп, тәсбих әйтергә тотына. Ишекләр ачыла, ярыкларга хатыннар, кызлар тула. Шулай итеп, без, ике-өч сәгать эварә булып йөрегәннең соңында, бер чәйханәгә килеп керәмез. Сәлам бирәмез. Аягүрә торып, безне каршы алалар. Сорашырга, сөйләшергә тотынамыз.

Илемезне сорыйлар, кая баруымызны сорыйлар. Татарлар, Казан шәһәреннән, димез. Һичбер нәрсә белмиләр. Безнең йорт – мөселман йорты, димез. Һичбер тәэсир калдыра алмыймыз. Газетагыз бармы, дип сорыймыз. Юк. Мисыр газеталары бармы? Юк. Монда төрекләр бармы? Юк. Ни берлән тора бу халык? Нинди мәгънәви азык берлә тормыш итәләр? Алла белә.

Болардан мәдрәсәләре бармы, дип сорыймыз. Зур мәдрәсә бар, диләр. Бер дәллял[2] сорыймыз. Бер бәрбәр бирәләр. Акча түләмәкче буламыз, түләтмиләр. Һәм дә бәхшиш сорамыйлар. Аннан чыгып, бер мәктәпкә керәмез. Һинд мөселман[нары]ның ибтидаи[3] мәктәбе икән. Парталары бар. Дәресләре шактый тәртипле булырга кирәк. Ләкин дәрес вакыты булмый. Бик күп хариталары бар. Хариталары һәммәсе урду телендә. Харитадан безнең Казанны күрсәтәмез һәм дә үземезнең юлымызны күрсәтәмез. Һичбер хис уятмый. Күп кеше, «йөри инде» дигән кебек кенә була. Шуннан автомобиль алып, зур мәдрәсәне карарга барамыз. Ул мәдрәсә булмый, мәсҗед булып чыга. Бер очында

[1] Бәхшиш – бүләк.

[2] Дәллял – арадашчы, монда: озатып, күрсәтеп йөрүче.

[3] Ибтидаи – башлангыч.

алты зиярәт бар. Болары (шәех [...] зиярәте, диләр) [...] булырга кирәк. Мәсҗед шактый зур, таштан бина ителгән[1]. Кыска гына манарасы да бар, эчендә түшәме дә бар. Түшәменә Истанбул мәсҗедләре кебек бик күп кандил[2] тагылган. Манарасына чыгамыз. Бөтен шәһәрне өстән карыймыз. Ә мәдрәсә кая, дип сорыймыз. Мәсҗеднең ихатасындагы өсте ябылган бер лабаска алып чыгалар. Ләкин һичбер шәкерт юк. [...], диләр. Кайчан укый торганнардыр, Алла белә. Дога кылып чыгамыз. Безне шул тирәдәге бөтен халык чолгап ала. Зурысы, урта яшьлекләре, баласы, «бәхшиш» дип, кулын суза. Безгә күрсәтеп йөргән берсенә ярты рупий (тугыз анна*) (акчаның дөрест чагында илле тиен) биреп чыгып китәмез.

Мәсҗед шактый матур, гарәп стилендә. Бина ителүенә йөз еллар бар, имеш. Ихатаның эчендә тагы берничә зиярәт бар. Боларына «зиярәте әүлияи хөҗрә» диделәр. Йортның кырыендагы зиярәткә Габделкадыйр әл-Гилани** зиярәте, диделәр.

Бу җамигъ шәфигыйлар*** җамигысы икән. Манарасының башында ай юк. Аннан соң хәнәфиләр**** җамигысына киттек. Ләкин, җамигъ бикле булганга, анда кертмәделәр. Әллә кемнән рөхсәт кирәк, диделәр. Безнең рөхсәт сорап йөрергә вакытымыз мөсагыйд түгел иде[3]. Шуннан, йөреп торганда, бер урамның чатында урамга тезелеп утырган балаларга очрадык. Балалар ике сафка бүленеп, тезелеп утырганнар. Урта бер йирдә – ак кәләпүш кигән хәлфәләре. Һәммәсенең кулында Коръән. Бик кычкырып,

---

[1] Бина ителгән – төзелгән, салынган.

[2] Кандил – фонарь, люстра.

* Анна – Һиндстанда акча берәмлеге.

** Габделкадыйр әл-Гилани – Әбү Мөхәммәд ибн Муса, ибн Габдулла Гилани (1075–1166, дин галиме, хокук белгече, суфичылыкның кадыйрилар тарикатенә нигез салучы, шәфигыйлар мәзһәбенең күренекле вәкиле.

*** Шәфигыйлар – мөселманнарның хокукларын аңлата торган дүрт юнәлеш, мәзһәб бар. Алар – шәфигый, хәнәфи, малики, хәнбәли мәзһәбләре. Шәфигыйлар юнәлешен башлап җибәрүче – имам Мөхәммәд эш-Шәфигый (820 елда үлгән). Әлеге мәзһәбләр бер-берсеннән хокук һәм йолалар үтәү мәсьәләсендә генә аерылганнар. Һәрберсенең аерым мәчетләре һәм имамнары булган.

**** Хәнәфиләр – мөселманнарның хокукларын аңлата торган дүрт юнәлешнең берсе. Хәнәфиләр мәзһәбенең җитәкчесе – Әбү Хәнифә имамәгъзам Ногман бине Сабит (якынча 696 – 767 елларда яшәгән).

[3] Мөсагыйд түгел иде – юк иде.

Коръән укып яталар. Яннарына килдек, карадык. Коръәннәре һаман һинд басмасы.

Юлымыз ашамак-эчмәк базарына туры килеп, берәр нәрсә алырмыз дип һәм дә халыкның ни ашаганын күрер өчен, базарга кердек. Базарында күзгә ташланырлык бернәрсә юк. Булса-булса, шул безнең кавын кебек озынчарак үскән карбыз, аннан аз гына баклажан бар, аз гына помидор, әнис бар. Ни балык бар, ни коры йөземнәр бар. Иң гаҗәбе шул: хөрмә дә юк. Бармак башы кебек кенә әфлисуннар бар. Бөтен базарындагы әйбер ун чех солдатына бер ашарга җитәрлек түгел. Аннан чыгып, урамда тугры килгән китап кибетенә керәмез. Һичбер кулга алырлык китап юк, бер газета юк. Шунда гарәпнең үз эшеннән берәр нәрсә эзләргә тотынамыз. Һичбер нәрсә юк. Кибетләр бик кечкенә, әйбер бик аз. Сатучылар – яһүдиләр яисә һинд мөселманнары. Аларның да эшләре бик кечкенә. Бер урамда фәс кигән бик күп яһүд капчыкларга көмеш акчалар тутырганнар да, шалтыр-шолтыр иттереп, алучы чакырып утыралар.

Бик эсселәнеп, бер чәйханәгә кереп, чәй эчәмез. Безнең өстәлне ил кебек чебен сырып ала. Кузгатып җибәргәч, гөжләп уйнап тора. Чебен, таракан һәр йирдә дә мөселманны бик сөя булырга кирәк. Мөселман артыннан болар ахирәткә үлгәч тә кермәсәләр ярый инде.

Аннан соң сонгый[1] су базларын карарга китәмез. Алар иң биек кая[2] эченә ясалган. Берсе өстенә берсе күтәрелеп, баскыч ысулында эшләнгән.

Шундый берсеннән-берсе күтәрелеп чыккан базлар дүрт-биш бар. Боларның иң югарыгысы тулгач, аннан түбәнгесенә ага, аннан соң аннан түбәнгегә, ахырына кадәр. Бу базлар ягмур суын җыяр өчен ясалганнар. Монда су бик кадерле булганга, йирдән казып чыгарырга бик тирән булганга (ике йөз карыштан* сай кое юк, диделәр), ягмур суын җыю монда, әлбәттә, искедән мәгълүм. Искедән шул ике таудан ага торган ташуны җыярга базлар ясалган булган. Инглизләр шуны җайлап төзәткәннәр һәм

[1] Сонгый – ясалма.

[2] Кая – кыя.

* Ике йөз карыштан – карыш – озынлык үлчәү берәмлеге, якынча 18 см чамасы. Ике йөз карыш – 3600 метрлар.

дә суны бик [яхшы] сакларлык дәрәҗәгә китергәннәр. Монда ягмур мәүсиме[1] июнь, июль аенда була икән. Шул вакыттагы ташу сулары шунда җыела икән дә шуны халык ел буе эчә икән. Ләкин инглизләр үзләре шул судан эчмиләр, ди. Алар диңгез суын арчытып[2] эчәләр икән. Бу базлар бик һәйбәт эшләнгән. Суны саклар өчен, бер баздан икенчесенә агызыр өчен әллә никадәр юллар ясалган.

Шулай итеп, Гаденда иң кадерле булган суны халыкка җиңел алу юлына куелган. Шуның берлән юкка канәгатьләнә торган гарәпне канәгатьләнгәндергән дә булырга кирәк.

Баскыч кебек баздан базга менә-менә, шактый югары күтәреләмез. Ике каяның иң тар йиренә кадәр җитәмез. Шунда бер почмакта бер зур агач үсеп ята. Тамыры да бик күпләп киткән. Сабы да, бик күп иттереп очланган чыбык кебек, бик күпләп үсеп киткән. Үзе бик биек. Яфрагы бик куе, күләгәсе бик һәйбәт. Күләгәнең кадерен беләсең килсә, Гарәбстанга кил икән. Шуның өчен гарәп ул агачны бик ярата икән. Шуның өчен ул агачның төбендә җәннәт [...], дияләр икән. Без бик рәхәтләнеп шунда тордык.

Безгә күрсәтүче шул базларның искелеген сөйләп торды. Күрсәтүчегә бер рупийны биреп чыгып китәмез. Инде безгә пристаньга вакыт. Юлда безне әүвәл китергән арбачыны очратып, шуңарга утырып пристаньга төшәмез. Күзгә күренерлек һичбер нәрсә булмаганга, Гаден ядкәре диярлек һичбер нәрсә таба алмадык. Кибетләрендә француз, инглизнең иң начар товарларына башка бер нәрсә юк.

Пристаньда, бәлки, берәр нәрсә табармыз өмиде берлән утырып киттек. Аннан «Европа отеле» дигән бер отельгә ашарга кердек. Безнең «Сарай»ның* яңа вакыты кебек бер отель. Үзен гарәпләр тоталар икән. Европа ысулындарак, имеш, йир, диләр.

Туяр-туймас кына ашадык. Берәр шешә лимонад берлә куас эчтек. Шуңарга сигез рупий алдылар. Сингапурда моңардан бик күп яхшы ашка берәр доллар ярым түләгән идек. Аштан чыккач, безнең пароходның тиз китүе мәгълүм булды. Без мондагы ба-

---

[1] Мәүсиме – сезоны.

[2] Арчытып – чистартып.

* Безнең «Сарай» – Казандагы «Сарай» кунакханәсе күз алдында тотыла.

зарны карап та йөри алмадык. Иртәгә барыбер Җибутида булачакмыз, дип, сәгать өч ярымнарда пароходка кердек. Анда кергәч, безнең пароходның тугры Порт Сәгыйдкә* барачагы, Җибутига туктамавы мәгълүм булды. Димәк, без һич азыксыз-нисез [тагы] бер атна барырга мәҗбүр булачакмыз. Сәгать биштә безнең пароход кузгалып китте. Кояш баеганчыга кадәр без Гаден көрфәзенән үтә алмадык. Сәгать җиделәрдә шимале гарбигә[1] таба йөреп, Баб-әл-Мәндибкә[2] кереп киттек. Гаденга барып, шундагы кәкре, нечкә муенлы гарәпләрне, корчаңгы гарәп баласын күргәч, атаудагы кыя-таш берлә капланган, һичбер нәрсә үстерми торган гарәп йирен күргәч, без бу гарәпләрнең шул дәрәҗә һиммәтсезлекләрен[3], гарәпнең зыялысының, шәехнең шул дәрәҗә сатлыгын, инглизнең алтынына каршы динен, милләтен, кыскасы, нәфесен[4] – ни барын – шуны сатуын бераз аңладык.

Бу саран табигать берлән сугышып, аны җиңеп, аңардан файда чыгарырлык мәдәнияте булмагач, болар, элгәре Рим казлары кебек, без гарәп – пәйгамбәр нәселе дип, бөтен шул ислам галәменең хәбәрчесе булып килгән, шуның берлән кечкенә карынын, нечкә муенын, кәкре аягын туйдырган. Шуннан соң аның таулык, ташлык, кыялыкларына каршы алтын бирә торган, рупий бирә торган инглиз килеп чыккан. Ул аңарга шул саран тау-ташын, тозлы сулы диңгезе берлән бергә саткан. Әле инглизне алдадым, дип, арзанга саткан. Башыңа капла, кяфер! Шулай итеп, үзенең азыгы килә торган, үзенең бердәнбер юлын да – диңгез юлын да инглизләргә тапшырган. Инде үзенең эссе, сусыз кыялар эчендә җисмән[5] вә рухан бетә, ябыга, ярлылана, вагая. Муены нечкәрә, башы очлана, аягы кәкрәя. Җисмән зәгыйфьләнгәч, рухында да һичбер нәрсә калмый. Тарихи ганганәсе[6] хакында зиярәтләре генә кала. Шуларны карарга килүче

---

* Порт Сәгыйд – Мисырда Урта диңгез буендагы Сүәеш каналына кергән җирдә урнашкан порт һәм шул исемдәге шәһәр.

[1] Шимале гарбигә – төньяк-көнбатышка.

[2] Баб-әл-Мәндибкә – Әл-Мәндиб бугазына.

[3] Һиммәтсезлекләрен – эшлексез булуларын.

[4] Нәфесен – горурлыгын.

[5] Җисмән – гәүдә ягыннан (телесный).

[6] Ганганәсе – телдән телгә күчеп килгән традицияләре.

инглизләр, европалылар һәм дә шуларны изге кемсәләр дип зиярәткә килүче төрек йортының мөселманнарына хезмәт кенә кала. Хезмәткә каршы шул изгеләрнең баласы, күршесе булганга, «бәхшиш» сорау кала. Гомумән, без Гаденны күрүдән бер бик зур канәгать[лек] хасыйл иттек. Хәзер исламиятнең тарихының бик күп сәхифәләре ачыграк аңлашылды. Пәйгамбәрләр заманасындагы хәят, эчтән кыяс итәрлек[1] гарәп хәяты күз алдында булды.

Инде бер ягымызда Африканы, без ягымызда Гарәбстанны калдырып, Бәхре әхмәргә[2] таба кереп барамыз. Ләкин Җибутида туктамаганга, Африканы күрә алмыймыз инде. Хәерле булсын. Бәлки, башка бер вакыт тугры килер әле.

Төн бик матур. Һава тын. Җил юк. Йолдызлар диңгездә йөзәләр.

*10 нчы ноябрь*

Бүген иртән торганда, Африка сахиле[3] дә, Гарәбстан яры да күренә иде. Бик озакка кадәр ике як та күренеп барды. Сәгать уннардан башлап, безнең пароход вак-төяк аталарга очрады. Сул яктагы кечкенә генә бер атада пристань да, шәһәрчек тә күренеп калды. Сәгать өчләрдә безнең пароход ачык диңгезгә чыкты. Җил куәтләнде. Ике якта да сахил ерагайды. Бара-тора Африка бөтенләй күздән югалды. Гарәбстан да төтен кебек кенә күренә башлады. Кичке сәгать сигезләрдә тагы аталарга очрадык. Үзләре кечкенә, үзләре берсе артлы берсе тезелеп киткәннәр. Кояш бүген дә диңгезгә батты. Артык матур манзара ясый алмады. Ләкин кояш батар алдыннан, үзенең гүзәллеген югалтты. Төрле ягыннан кирткәләнгән кибән кыяфәтен алды. Суга бата башлагач, кибән кебек булды. Кыргызның киез өе төслеләнде. Ахырга таба театрдагы суфлер халаты төсле булды. Ай да, диңгездән туганда, үз формасында булмады. Ул да бөтен ягыннан кыркыган кебек иде.

[1] Кыяс итәрлек – үрнәк алырлык.
[2] Бәхре әхмәргә – Кызыл диңгезгә.
[3] Сахиле – яры.

Көн бик эссе булды. Кояш яндырды. Төн бик матур. Җил бик аз гына. Дулкын һич юк. Кичә бүлмә бик эссе булганга, бик начар йокладым. Баш авыртты.

Бүген дә йоклап булмас төсле тора. Порт Сәгыйд берлә Гаден арасы бер мең дә дүрт йөз мильләр икән. Шулай барсак, шимбә көн Порт Сәгыйдтә буламыз. Без хәзер хатты истивадан[1] 15 нче, 16 нчы дәрәҗәләрдә[2], хәзер шимале гарбигә[3] таба барамыз. Порт Сәгыйдкә кадәр һаман шимальгә таба хәрәкәт итәчәкмез. Инде без Казан тугрысыннан үттек.

*11 нче ноябрь*

Төнлә бик бөркү булды. Яп-ялангач ятсам да, бөтенләй тир эчендә идем. Йокы бик начар булды. Кояш чыгар-чыкмас эсселек башланды. Җиле дә юк. Кояш шәфкатьсез кыздыра-кыздыра, эсседән һичбер качар урын юк. Күләгәдә утырган йирдә тиргә батып утырамыз. Бүген без Бәхре әхмәрнең иң киң йиреннән барамыз. Шуңарга бер яктан да коры [җир] күренми. Бәхре әхмәрнең иң киң йиренең иңе өч йөз илле чакрымнар чамасы.

Кояш бүген дә диңгезгә батты. Кич берлән берничә кеше, Тимерказык йолдызы дип, бер йолдызны күрсәттеләр. Җидегән җиде йолдыз юкка мин шул икәнлегенә канәгать хасил итмәдем. Бүген төнлә берлән без Мәккәи Мөкәррәмә тугрысыннан үтәмез. Диңгез монда бинийая[4] тозлы. Кырынгач та, бик озак тәнне әчетеп тора. Аннан, тирләгән көенчә коенсаң, тәнгә бик күп кызыл бөрчекләр кабарта. Минем тәнемдә дә шул нәрсәләр күп. Озынга китмәсә ярый инде.

Бүген Бөтендөнья сугышының бетүенең баш көне. Үткән ел 11 нче ноябрь Германия мөтарәкәгә[5] рәсман имза итте. Шуннан башлап, иттифакы мөрәбәгъ[6] үзен үзе дошманнарының ихтыярына тапшырды. Үткән ел без мөтарәкәнең шартларына ышанмаган идек.

---

[1] Хатты истивадан – экватордан.

[2] Дәрәҗәләрдә – градусларда.

[3] Шимале гарбигә – төньяк-көнбатышка.

[4] Бинийая – чиксез, бик нык.

[5] Мөтарәкәгә – вакытлы килешүгә.

[6] Иттифакы мөрәбәгъ – дүртлек союзы.

Бу итляф[1] дәүләтләрнең ялганнарыннан булган бер ялган дип игътикад иткән[2] идек. Үткән ел ул хәбәрләрнең дөреслегенә инандык. Шул игътиля[3] ил эчендә Германия бик авыр солых шартларын кабул итәргә мәҗбүр булды. Австрия тәмам таралып бетте. Мескен Төркия эштән чыгып, үзенең кечкенә генә сәяси барлыгын саклап кала алачакмы-юкмы – Алла гына белә.

Бүген дә шактый күп пароход очрады. Ләкин монда диңгез киң булганга, очрашмаенча үтәләр булырга кирәк. Кичә көн буе Баб-әл-Мәндибнең иң тар йиреннән үткәндә, көн буе унбиш пароходка очрадык. Диңгездә пароход хәрәкәте куәтләнгән булырга тиеш. Бүгеннән Сүәешкә* сигез йөз алтмыш миль калды.

*12 нче ноябрь*

Бүген без сәфәргә чыкканга кырык көн булды. Шул кырык көндә сәфәрнең дүрттән өчен үттек. Әлегә мин сәламәт, Фуад та терелеп килә. Киләчәктә ни булыр? Анысы, әлбәттә, мәгълүм түгел. Үземезнең максатка ирешербезме, әллә шул мәшәкатьләремез әрәмгә генә китәрме?

Бүген без Җиддә** тугрысыннан үтәмез. Көн иртәдән бик эссе булачак кебек күренә. Кичәгегә караганда мәрхәмәтлерәк булды. Кичкә табарак суыграк җил дә исә башлады. Диңгездә бүген бик күп ком сибелгән кызыл эзләр очрады. Зур-зур юл булып агып баралар. Комнарның бөртекләре суга да батмаган. Үзенең кызыл төсен югалтмаган. Бер төслесе, суга бераз коелып, кызыл төсен югалткан. Ләкин үзе батмаган. Болар Африка CIAN буенча***, ком сахраларыннан буран берлә килгән комнар гына булырга тиеш. Диңгез суы бик куе булганга, суга батмыйлар булырга тиеш. Бәлки, Бәхре әхмәрнең исеме дә шуннан килгәндер.

---

[1] Итляф – үтерүче, ватучы, җимерүче.

[2] Игътикад иткән – ышанган, уйлаган.

[3] Игътиля – дәрәҗәсе күтәрелгән, бөек.

* Сүәеш – монда Сүәеш шәһәре һәм каналы турында сүз бара.

** Җиддә – Согуд Гарәбстанында Кызыл диңгез буенда урнашкан зур порт-шәһәр.

*** Африка CIAN буенча – Көньяк Сахара һәм Төньк Африка илләрендәге тикшеренүләргә караганда.

Диңгез өсте бүген көзге кебек тигез булды. Мин әле бу сәфәрдә моның кебек матур, тын диңгез өстен күргәнем юк иде. Менә Айвазовскийны* шул диңгезгә китерәсе иде.

## 11 нче дәфтәр

*13 нче ноябрь, 1919*

Без бүген хатты истива[1] даирәсеннән тагы чыктык. Моннан соң һаман шимальгә[2] таба барачакмыз. Бүген Мәдинәи Мөнәвәрә тугрысыннан да үттек. Көн бүген бик эссе булмады. Шимале гарби[3] җиле һаман үзенең барлыгын белдереп торды. Кояш баткач, хәтта кич бераз суыгаеп та китте. Бәгъзы бер кешеләр өстләренә казакиларын да киделәр. Мин һаман үземнең җилән, күлмәк-ыштанымнан, яланаяктан барам. Бүген иртәдән үк Африка тарафында аталар[4] күренеп кала. Кояш батар алдыннан, бөтенләй Африка яры күренеп бара. Кичкә кергәч, Африка тарафында әле анда, әле монда авыллар бик күп очрый. Безнең пароход Африка ярына бик якыннан бара. Китап-фәлән укып булмый. Күңел төрлеләнде. Бу арада Харбин өйләрен, тагы әллә кемнәр[не] бутап-бутап төштә күрдем. Үзем, Аллага шөкер, җисмән вә рухан[5] бик сәламәт.

*14 нче ноябрь*

Бүген иртүк ике яктан да аталар күренеп килә. Өйләдән соң безнең пароход Синай җәзирәсе** берлән Африка арасындагы

---

* Айвазовский – Иван Константинович Айвазовский (1817–1900), мәшһүр рус рәссамы. Аеруча табигать күренешләрен, бигрәк тә диңгез пейзажын сурәтләгән картиналары белән танылган. Сәнгать белгечләре аның барлык иҗат мирасының яртысыннан артыгы диңгез пейзажын тасвирлауга багышланган дип күрсәтәләр.

[1] Хатты истива – экватор.

[2] Шимальгә – төньякка.

[3] Шимале гарби – төньяк-көнбатыш.

[4] Аталар – д ө р е с е: одалар – утраулар.

[5] Җисмән вә рухан – физик һәм рухи яктан.

** Синай җәзирәсе – Кызыл диңгездәге ярымутрау, Мисыр территориясенең бер өлеше. Төньяктан – Урта диңгез, көньяктан Кызыл диңгез арасында урнашкан. Коры җирдән Азия белән Африканы тоташтыра торган күпер хезмәтен дә үти.

Бәхре әхмәрнең тар йиренә керә. Монда диңгез бик тар. Ике тараф та бик ачык күренеп бара. Ике якта да ком, таш. Тауга башка[1] бернәрсә юк. Яшеллекнең исеме дә юк. Кояш баегач, җил шактый куәтләнә, безнең пароход саллана[2] башлый. Бүген төнлә сәгать икеләрдә безнең пароход Сүәеш кальгасына барып җитәчәк. Шуннан Сүәеш каналына кереп китәмез. Иртә торып кальганы күрер өчен, халык иртә ятты. Азыклар да азайды. Ашау бик начарланды инде. Бер атнадан артык итләре юк. Иске консерва берлән баралар. Әллә ничә көннән бирле кичке ашлары булмый. Гаденда без дә азык алмаганга, без дә бик бай түгел, ачлы-туклырак барамыз. Көн эссе булмады. Насыйп булса, бүген дә йоклап булачак.

*15 нче ноябрь*

Бүген кояш чыгар-чыкмас, Сүәеш шәһәренә барып җиттек. Сүәеш шәһәре – каналның башындагы кечкенә генә гарәп шәһәре. Ләкин шәһәр каналдан читтәрәк. Канал буена европалылар үзләренә аерым бер шәһәр салганнар. Шәһәрләре кечкенә генә, матур гына. Кирәк гарәп шәһәрендә, кирәк Европа шәһәрендә яшел[лек] күп, бик күп. Пальма агачлары күренә. Гарәп шәһәре дә бакчалык берлән чорналган. Рәсмият беткәч тә китәмез дигәнгә, без шәһәргә чыгарга уйламыймыз. Ләкин бераздан соң бер кыйсем[3] халык каһвәгә барырга була да, безне дә чакыра. Ләкин без Сүәеш каналын күрәсемез килгәнгә бармаска буламыз. Пароходымыз Порт Сәгыйдтә ике көн торса, барып киләчәкмез. Бер генә көн торса, инде күрмәенчә китәмез. Тиз дигән нәрсә сузыла-сузыла сузылды. Пароходымыз сәгать бердә генә кузгалып китте. Иң әүвәл Аурупа Сүәеше яныннан киттек. Бер-ике чакрымда күл артында гарәп шәһәренең дүрт почмаклы, башы япмаган ак таш биналар калды. Бик тиздән пароход диңгез, нәһерләрне[4] калдырып, чын каналга, адәм баласының гакылы берлән уйлап чыгарылган, кулы берлән казылган каналга

---

[1] Тауга башка – дөресе: таудан башка.
[2] Саллана – чайкала.
[3] Кыйсем – өлеш, төркем.
[4] Нәһерләрне – елгаларны.

кереп киттек. Канал бик тар. Дим суы* киңлеге. Беренче карауда моңарга зур диңгез пароходы сыймас кебек күренә. Бара-тора каршы пароход килсә, уза алмаслар кебек хис итела. Ләкин пароходлар берсе артлы берсе килеп, кара-каршы үтешеп китәләр. Ике арада шактый күп йир буш та кала. Шәһәрләрдән үтәр-үтмәс сугыш галәмәтләре күренә башлый. Европа шәһәрләренең ындырлары төбендә бик күп кызыл фәсле бик күп гаскәр торалар. Болар – яисә төрек әсирләредер, яисә инглизләрнең гарәпләрдән акчага сатып алган, Аллаһның ахмак бәндәләре.

Бераз киткәч, Синай ягында бик күп ныгытылган йирләр, тимерчыбык читәннәре, биек итеп өелгән зур тупларның урыннары, гаскәр йөрер өчен базлар, йир астыннан юллар очрый. Болары каналның янында ук. Болар инглизләрнең каналны саклар өчен ясалган кальгалары[1] булырга кирәк.

Аннан бер-ике чакрымда бик күп өелгән, казылган, ныгытылган, тагы саклар күренә. Алары һөҗүм итә торган төрек гаскәренеке булырга кирәк. Каналдан эчкә киткән саен, бу сугыш саклары зурая, күбәя баралар. Горник күленә** керер алдыннан, алар зур бер сугыш мәйданы хәлен алалар. Бу тирәдә бик каты сугышлар булган булырга кирәк. Мескен төрек углының әллә никадәр каны түгелеп, җиңәргә мәҗбүр булган, күрәсең. Ләкин каналның тарлыгына караганда, моны үтү бер дә авыр булмаска тиеш иде. Фәкать Төркия ягыннан гаскәрнең килүе өчен качынырлык һичбер нәрсә юк. Ни урман бар, ни су бар, ни дә юл бар. Комлык, комлык. Инглиз тарафыннан су берлән Сүәеш арасында тимер юл бар. Каналда әллә никадәр пароход бар. Диңгездә әллә никадәр дәһшәтле инглиз флоты бар. Шулай булса да, моңарга төрекләр генә түгел, немецлар дә лөзүме кадәр[2] әһәмият бирсәләр, сугышның башларында, шөбһәсез, төрек гаскәре Сүәешне кичәчәк вә Мисырга керәчәк иде. Мисырга төрек гаскәре

---

* Дим суы – Дим елгасы. Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы.

[1] Кальгалары – крепостьлары, ныгытмалары.

** Горник күле – Сүәеш каналының уртасында калган зур күл. Ул каналның көньяк һәм төньяк өлешләрен тоташтырган. Гарәпчә исеме – Муррат-әл-Кубра, русча – Большое Горькое озеро.

[2] Лөзүме кадәр – тиешенчә.

кереп, Сүәеш каналы киселгән булса, инглизләрнең Һиндстан берлә юллары киселсә, хәлләре бик мөшкел булачак иде. Хәзер шул үткән форсатларга егъларга гына кала.

Сәгать бишләрдә Горник күленә керәмез. Канал апрельнең су ташуы вакытындагы төсен ала. Бик озак шул күл буйлап барамыз. Кич сәгать сигезләрдә генә яңадан каналга керәмез. Иртә берлән сәгать алтыларда барып җитәчәк, имешмез. Каналның бөтен озынлыгы җитмеш сигез миль. Ләкин без бик акрынлап, туктап-туктап кына барамыз. Юл хәвефле, күрәсең.

*18 нче ноябрь*

16 нчы ноябрьдә таң берлән, кояш чыгудан элек, пароходымыз Порт Сәгыйд алдында якорь салды. Порт Сәгыйд үзенең озын буена тезелгән фонарьлары, маяклары берлә безне көлеп-елмаеп каршы алды. Кояш чыга башлагач, шәһәрнең аерым урамнары, аерым өйләре бөтен төсе-буе, сыйфаты-сыны берлән чыкты. Озын гына бер шәһәр, диңгез буеннан гарәп шәһәре икәне беленерлек тә түгел. Фәкать гүмрүкханәсенең[1] башында җилферди торган ике тәреле инглиз байрагы астындагы гөмбәз башында гына, кечкенә генә ай галәмәтләре күренә. Үзенең мөселманлыгын баса торган мирза кебек, зур инглиз тәреләреннән оялып качканнар, посканнар. Ни бер мәсҗед манарасы күренә, ни бер башка ислам галәмәте, ни гарәп мәдәниятенең бер әсәре.

Кояш чыгу берлән, пароходка башына фәс кигән, формасына айлы йолдызлы сары төймәләр таккан, биленә киң каеш берлән инглизчә язган зур җиз такта кушанган[2] полис[3] керә. Бу – инглизнең садыйк[4] хезмәтчесе, исламиятнең чын дошманы, гарәп милләтенең җәллады[5]. Буе зур, гәүдәсе дорфа, күзе ахмак, йөзе фил итеннән балта берлән юнган да куйган. «Болар кемнәр?» – «Чех», диләр, аңламый. – «Австрия», диләр. Австрия, Австрия әһле герман дип, бик кызуланып чыга. Бераздан инглиз офицеры берлән тагы берничә гарәп полициясе керәләр. Алары, чехлар

---

[1] Гүмрүкханә – таможня.
[2] Кушанган – таккан.
[3] Дөресе: полицейский.
[4] Садыйк – турылыклы, тугры.
[5] Җәллады – баш кисүчесе, палачы.

берлән сөйләшеп, Порт Сәгыйдкә беркемгә дә чыгарга рөхсәт бирмиләр. Безнең чех түрәләре, яңадан барып, инглизләр берлән сөйләшеп, офицерларга үтенеп, офицерларга чыгарга рөхсәт алалар. Без Каһирәгә барырга хәзерләнәмез. Пароходның күпме торачагы мәгълүм түгел. Безнең пароход япон капитаны [берлән] барганга, без бик тыныч барамыз. Без офицер да, унтер офицер да булмасак та, чех фуражкасын киеп чыгып китәмез. Юлда, полициягә кереп, Каһирәгә барырга рөхсәт сорыймыз. Безгә катгый иттереп сөйләп җавап бирәләр. Без бик аптырап каламыз. Шәһәргә чыгып китәмез. Япон капитаны безне зур бер япон магазинына алып керә. Алар безне бик дустча каршы алалар. Капитан мәсьәләне аңлата, япон фирмасының хуҗасы үзенең доверенныен полицмейстерга рөхсәт сорарга җибәрә. Без вә япон капитаны боларның большевик түгеллегенә шәһадәт бирәмез. Аңлашып, болар руслар түгел, болар – чехлар. Бераздан доверенный кайта. Полиция башы рөхсәт бирмәгән. Болар рус түгел, чех диюгә каршы, чех рустан да начар, дигән. Безнең иптәш чехларның бик ачулары килә. Ләкин бер эш эшли алмыйлар. Инглизләрнең болай кылынулары инглиз мәнфәгатенә шулкадәр хезмәт иткән чехларга бераз гаҗәп төслерәк тоела. Ләкин без шулай буласын белгәнгә, боларның яраларына тоз гына сибәмез. Шулай итеп, без Каһирә[гә] бара алмыймыз. Тегенең манигына каршы китәргә дигән тәкъдимне без ясасак та, чехлар, инглизләр берлән уйнарга ярамый дип разый булмыйлар. Көн буе Порт Сәгыйдне карап йөримез. Кич берлән бер номерга кереп кунамыз. Икенче көнне мин, иртүк торып, чыгып китәм. Фуад йоклап кала. Чехларны очратып, пароходның бүген китмәвен белеп, башыма бер әйбер алып киям һәм дә акча алыштырам да Фуадны Каһирәгә барырга уятырга кайтам. Сәгать унда яткан Фуадка иртә унбердә тору бик авыр булса [да], акрын гына калка. Кызулап алып чыгып китәм. Тагы чехларга очрыймыз. Пароходның кайчан китүен тагы белешәмез. Иртәгә көндез сәгать уникедә. Каһирәдән поезд унике дә егерме минутта килә. Димәк, тагы өлгермимез. Тагы каламыз. Мин гарәп урамнарына китәм. Китап кибете эзлим. Юк. Гарәп газеталары эзлим. Юк. Урамда гына сатып йөриләр, диләр. Алар очрамый. Кич берлән бер гарәп каһвәсенә кереп, гарәп газетасы укыйм. Бөтен

Мисырда зур хәрәкәтләр. Октябрь башыннан бирле Искәндәриядә, Мисырда вә башка шәһәрләрдә демонстрацияләр. 15 нче ноябрьдә Искәндәриядә бик зур демонстрация булган. Инглиз гаскәре, атып, бик күп кешене җәрәхәтләгән, бик күп кеше үлгән. Үтерелгәннәр арасында бала-чага бик күп. Шул 16 сында үлгәннәрнең җеназасына илле мең кеше җыелган. Мисырда ике көннән бирле демонстрацияләр бара. Атышулар, таяк, таш сугышлары дәвам итә. Инглизләр әллә никадәр кешене юк итәләр. Урамдагы демонстрация[гә] аталар, кыйныйлар. Мисырлылар, «Яшәсен истикъляль![1] Каһәр улсын инглизләр!» диеп, демонстрацияләрендә дәвам итәләр. Газетага караганда, бөтен Мисыр «гү» килә. Газетаның язмасы бик «утлы» хәбәрләр, телеграммалар – һәммәсе дә – демонстрация, халкының истикъляль теләве, инглизләрне куулар хакында.

Гарәп урамнары, магазиннары буйлап сөйләп-сөйләп йөрим. Берәр төрек, татар табып булмасмы дип эзлим. Бер төрекчә белә торган болгарга башка беркемне дә очрата алмыйм. Гарәпләр берлән сөйләшеп карыйм. Һичбер мәгънәле сүз алып булмый. Бик куркаклармы, әллә һич хәрәкәтнең әсәре монда юкмы?

Кич сәгать уннарда гарәп урамнарында йөргәндә, бик каты барабан кагып йырлау, музыка тавышын ишетәм. Монда да демонстрация, күрәсең, дип, кызулап барам. Барабан бик каты кага, музыка әллә ничә төрле коралдан бик каты тавышлар чыгара. Менә яннарына барып җитәм. Электрик утларыннан зур ай берлән йолдыз ясаган (ае зур дугадан зур) бер нәрсәне берничә бала күтәргәннәр. Шуның янына ун-унбиш музыкант төрле коралларда музыка уйныйлар. Алардан дүрт-биш аршында гына, киң нәрсәдә, электрик утыннан агач ботаклары кебек ботаклар чыгарган ике нәрсә күтәргәннәр. Болары теге ай берлән йолдыздан ике мәртәбә зур, биек, киң. Шуларның алдында өч егет өр-яңа киемнәр кигәннәр, калыплаган фәсләр кигәннәр, акрын гына атлыйлар. Һәммәсенең дә күкрәкләрендә кызыл чәчәкләр, уң якларында зур чалмалы бер гарәп зур бер букет тоткан. Менә урамның почмагына туктыйлар. Алларындагы бер чалмалы баш, гарәп, әллә нинди бер сүз кычкыра. Сүзен һич аңлап булмый.

[1] Истикъляль – бәйсезлек.

Менә шуннан бер гарәп чыгарып, тегенәргә дүрт-биш кәгазь акча бирә. Ике йөз-өч йөз груш* чамасында. Теге шул акчаны алып, кешеләрнең исемнәрен, хатыннарының исемнәрен әйтеп кычкыра-кычкыра да, теге өч егетнең берсенә тоттыра. Ул, әллә ни кылындырып, акчаны кайтарып бирә. Теге гарәп акчаны бая биргән кешенең үзенә кайтара. Тагы берсе акча бирә, тагы теге чалмалы гарәп, күчереп йөртеп кычкыра. Моның демонстрация түгел икәнен аңлыйм, ләкин нәрсә икәнен аңлый алмыйм. Берсеннән, икенчесеннән сорыйм, һич канәгатьләндерерлек җавап ала алмыйм. Шуны белешмәенчә китәм дигәндә, икенче тарафтан тагы шундый ук бер нәрсә килеп чыга. Алар, берсеннән-берсе узышкан кебек, барабаннарын катырак дөбердәтәләр. Теге чалмалы гарәпләре тагы ачырак кычкыралар. Бу нәрсә?

Тәмәкече бер гарәп кешесенә барып, бу нәрсә, дип сорыйм. Туй, дип җавап бирә. Бөтен ихласым кайтып, борылып китәм.

Моннан дүрт сәгатьлек йирдә, урамнарда сугышалар, үзләренең хөрриятләре өчен кан түгәләр. Монда барабан кагып, музыка уйнап, ишәк тарткан мотордан электрик утлар алып, зур фонарьлар ясап, төнлә ахмакланып йөриләр. Боларның ахмаклыгына, бу тамашаның урынсызлыгына исем китеп, өйгә таба борылдым. Инде төн, Порт Сәгыйд йоклый. Каһвәләр дә ябыла. Мин дә өйгә кайтам.

*18 ндә* иртә торып, урамга чыгам. Безнең чехлар урамда бик күп йөриләр. Кайчан китәмез мәгълүм түгел. Кичә пароходта бик күңелсез вакыйга булды. Безнең башлыкка Восток банкасыннан чек буенча солдатларга жалуниегә[1] өләшергә француз франкларын алып килгәндә, инглиз полициясе пароходка җибәрмәгән. Безнең акчаны арестовать иткән. Шуның артыннан көн буе йөрделәр. Ахырдан яртысын гына кайтарып бирделәр. Аның да көмешләрен кәгазьгә алыштырып бирделәр. Шуңарга солдатлар бик аз жалуние алды. Һәм дә бик соң алды. Бер әйбер дә ала алмадылар. Бүген һәммәсе [нәрсәдер] алу берлән мәшгуль, шуңарга, сәгать дүртсез китмимез, диделәр. Мин,

---

* Груш – көмешләтә 8 тиенгә тигез булган төрек пиастры.

[1] Дөресе: жалованье – хезмәт хакы.

кичә Каһирәгә бармавымызның тагы хата булуын уйлап, тагы эч поша. Инглизләрнең чехлар берлә шундый вәхши мөгамәләдә булуларына кәефем килә. Бу ахмак сукырларның күзләрен ачуга азрак сәбәп булыр. Аннан соң, кеше малын конфисковать итүнең тәмен бераз беләләр. Былтыр төрек әсирләренә дигән йөз сиксән мең сумны үзләре бик җиңел конфисковать иткәннәр иде. Вакыт шактый күп булганга, мин мәктүбләр язарга тотынам. Истанбулга берничә ачык хат язам. Кырымның Ак мәсҗеденә, Бакчасарайга, Одессага ачык хатлар күндерәм. Һәм дә Харбин, Иркут[1], Томск, Владивостокка ачык хатлар. Владивостокка баручы артыннан Латыйф Яушевка, Милли Идарәгә озын мәктүб язам да аларын Владивостокка китә торган русларга тапшырам. Ул руслардан Русия хәбәрләрен, Истанбул хәбәрләрен сорашам. Русиянең җәнүбендә[2] Деникин* бик шәп бара, инде озакламас, Мәскәүне алыр, диләр. Истанбулда рус кабагы – бик зур хәят, бик бәһале түгел. Һәр нәрсә бар. Идарә төрекләрнең үз кулында. Ләкин инглизләр бик зур роль уйныйлар, диләр. Болар һәммәсе дә буржуазный даирә кешеләре булганга, хәбәрләренә бик үк ышанып җитеп булмый. Чынлабрак мәгълүмат алу өчен, рус консулына китәм. Бер аксак карт грек ишек ача. Мине алып кереп утырта. Шул ук грек консул да булып чыга. Үзе русча начар сөйли. Русиядән һичбер хәбәре юк. Русиянең һичбер мөәссәсәсе[3] берлән мөнәсәбәте юк. Фәкать искедән калган буш хатирә сату итеп тора.

Истанбулга китмәкче булам, мөмкинме, дип сорыйм.

Паспортың йирендә булса, мөмкин. Менә иртә[н] грек пароходы китә. Аның агенты да монда була. Иртәгә рәхим ит. Билет та сатармыз, ди. Мин бу кешенең, рус консуллыгыннан битәр, пароход агенты, кечкенә сатучы икәнлегенә ышанып, бер мәгълүмат ала алмыйча чыгып китәм.

Сәгать икеләрдә пароходка төшәмез. Һәммә халык җыелып беткән. Пароход тиз китәчәк. Ләкин тизләре бик тиз булмый. Без

---

[1] Дөресе: Иркутск.

[2] Җәнүбендә – көньягында.

* Деникин – Антон Иванович Деникин (1872–1947), Гражданнар сугышында совет властена каршы торган аклар хәрәкәте лидерларыннан берсе, генерал.

[3] Мөәссәсәсе – оешмасы.

сәгать җиделәрдә генә Порт Сәгыйдтән кузгаламыз. Төн матур. Һава бик һәйбәт. Кич җылы. Порт Сәгыйднең утлары безне бик озакка кадәр саубуллап калалар.

Менә без Бәхре сәфидтә[1]. Без хәзер Аурупа диңгезендә. Җил куәтләнә, һава суыта. Монда безне яңа хәбәр каршы ала. Безнең пароход Марсельгә китми, Триестка* бара. Кирәк булса, аннан Прагага бара. Аннан Франсәгә ничек барып чыгарымызны[2] бер Алла гына белә.

*19 нчы ноябрь*

Мин иртә торганда, шималь җиле пароходны күтәреп селкә. Дулкыннар берсеннән-берсе авырсынып, берсеннән-берсе качып, пароход өстенә менеп китәләр. Һава суык. Көзге болыт бик түбән. Палубада һич кеше юк. Бик күп кеше авырган, коса, егыла. Бик күбесе, башын күтәрә алмыйча, урынында ята. Дулкын кыюланганнан-кыюлана бара. Ашның дә рәте булмый, чәйнең дә рәте юк.

Суыкка күрә укыр да хәл юк, язар да хәл юк. Кич берлән безнең трюмның өстен ябалар. Тагы без биш йөз кешенең сасысы эчендә йокларга мәҗбүрмез. Пароход бик акрын бара. Бүген сәгать 12 гә кадәр, ягъни унтугыз сәгатькә 130 миль[3] генә барган.

*20 нче ноябрь*

Салкын җил, каты дулкын һаман дәвам итә. Солдатларның яртысы авырып бетте. Палубада йөрер хәл юк. Дулкын коендыра, җил, алып ыргытырга теләп, куып йөртә. Кич тагы суыта. Пароход бик акрын бара. Бүген бер тәүлеккә бары 167 миль генә барган.

Бүген без Измир тугрысыннан үттек. Иртәгә Крит атасы тугрысына җитәчәкмез. Болай барганда, бик озак барачакмыз. Порт Сәгыйдкә бару безнең бөтен планымызны җимергәнгә, без бик аптырап калганмыз. Нишли алырмыз? Шул Чехиядә

---

[1] Бәхре сәфидтә – Урта диңгездә.

* Триест – Балкан ярымутравының төньяк-көнбатышында, Әдрән диңгезенең Триест култыгында, Венециядән 145 км көнчыгышта урнашкан портшәһәр.

[2] Чыгарымызны – чыгуыбызны.

[3] Миль – м о н д а: диңгез миле (1852 метр).

кысылып, тыгылып каламызмы, бер Алла гына белә инде. Бакалым. Без көн буе Порт Сәгыйдтән алган гарәп газеталарын укыймыз.

## 12 нче дәфтәр

*21 нче ноябрь*

Бүген без Востоктан чыкканга җиде атна тулды. Иртүк Крит атасының[1] маягы күренә, кояш чыгар-чыкмас атаның ярлары күренә башлый. Сәгать уннар-унберләрдә карлы таулар күренә. Кичкә кадәр Крит буйлап барамыз. Көн тыныч, җил әз, һава матур. Пароходымыз бүген ике йөз миль[2] барган. Кичке сәгать бишләрдә тагы җил күтәрелә. Бик каты ягмур явып үтә, диңгез тагы дулый, безнең пароход тагы биергә тотына. Диңгез хасталыгыннан куркып, бик күп кеше иртүк йокларга ята. Пароход бераз тына. Көн буе бүген ящик кагып, ящик ясап, Порт Сәгыйдтән алган җыен чүп-чарны бүлеп эштән чыкканнар иде. Бүген безнең юлның Триесткамы, Марсельгамылыгын* тәгаен итә торган телеграмма көтелде. Кичкә кадәр Прагадан** җавап килмәде, иртәгә кадәр килмәсә, без Адриатик диңгезенә*** кереп, Триестка тугры барачакмыз. Ләкин безнең өчен бу – көтелмәгән борылыш: бик уңгайсыз булу ихтималы бар. Бердән, Боһемиядә**** кирәк-ярак җитәрлек булмаганга, тору бик кыйммәт булу ихтималы бар. Икенчедән, без тагы максатымыз булган Париждан бик читтә калып, тагы бара алмавымыз бар. Өченчедән, шуннан әллә ничә мәмләкәттән күчеп барганда акчаларымыз

[1] Атасының – утравының.

[2] Миль – миля.

* Марсельгамылыгын – Марсель – Франциянең көньяк-көнчыгышында урнашкан зур шәһәр һәм порт.

** Прага – Чехия Республикасының башкаласы.

*** Адриатик диңгезенә – Әдрән диңгез – Урта диңгезнең бер өлеше. Апеннин һәм Балкан ярымутраулары арасында урнашкан.

**** Боһемия – Үзәк Европаның тарихи төбәге, Чехиянең тарихи торак пункты территориясенең искергән, немецча атамасы, хәзерге Чехия Республикасының көнбатыш өлеше.

алышынмый, бер төрле мөшкиляткә[1] очрау ихтималы бар. Марсельдә булса, булыр, бик җиңел хәл ителер кебек иде. Монда чехлар Боhемия берлән Франсә[2] арасында тәмамән юл ачык, бик җиңел барачакмыз, дип җуаталар. Ничек булыр, баргач күрермез. Юл инде бик туйдырды, бераз корыда, үз бүлмәңдә утырасы килә башлады.

*22 [нче] ноябрь*

Иртә торганда, җил элеп алып, селкеп сала иде. Палубада йөрер хәл юк. Җил алып ыргытырга тели. Пароходның өсте дулкын суы берлә юылып кына тора. Ул гына җитмәгән кебек, тагы ягмур да чиләкләп актара. Бөтен ишекләр hәммәсе ябык. Җилдән, ягмурдан тышка борын тыгар да хәл юк. Иртүк безнең пароход Марсельгә таба юл тотты дигән хәбәр тарала, ләкин бик тиз ул хәбәрнең дөрест түгеллеге мәгълүм була. Пароход Триестка таба борыла. Ләкин дулкын бик куәтле булганга, бик акыртын бара. Бүген дә без тәүлеккә бары 166 миль бара алган. Өйләдән соң, сәгать өчләрдә, диңгезнең шашынуы чигенә җитә. Дулкыннар бер яктан сикереп, икенче яктан чыгалар, шуның өстенә, дөм томалап алып, ягмур актара. Безнең пароход бер туктамаенча кычкыртып тора. Кояш баегач, диңгез бераз басыла, hава да ачыла. Җолдыз тулы күк. Диңгез дә төсен карарга тотына. Шул көннәрдә Порт Сәгыйдтән алган гарәп газеталарын укып бетердем. Мисыр революциясе, башка күңелле хәбәр бик аз. Әфганстан берлән Англия арасында сугыш hаман дәвам итә. Большевиклар «Эссекүл»дә, димәк, Петропавловскины алып, Омскига туксан чакрымлык йирдә Колчак, галәйhил-ләгънә[3], боз өсте берлән китә икән. Рус әйтмешли, «Одним негодяем меньше»[4]. Солых конференциясе Истанбулны Төркиядә калдырырга вә төрек күп вилаятьләрене Төркиядә калдырып, Төркиянең истикъляльн[5] сакларга карар иткән. Бу – бераз булса да, күңеллерәк бер хәбәр. Башка рәтле вакыйга юк. Бүген пароходта рожа берлән бер чех

---

[1] Мөшкилятка – кыенлыкка.
[2] Франсә – Франция.
[3] Галәйhил-ләгънәти – аңа ләгънәт булсын.
[4] Чыганакта кириллицада язылган.
[5] Истикъляльн – бәйсезлеген.

авырый башлады. Пароходымыз шуның аркасында карантинга эләкмәсә ярый инде. Безнең икемезгә дә диңгез хасталыгы тимәде, ләкин урын бик бөркү вә сасы булганга, йоклау бик начар. Алла сәламәтлек бирсен инде.

*23 [нче] ноябрь*

Иртә уянганда, җил элеп алып, селкеп сала. Көн ачылгач та, җил куәтләнә генә бара. Бик еш ягмур да явып, тулмаган йирләрне тутыра. Җил тәмамән безнең пароходка каршы булганга, без бик акрын хәрәкәт итәмез. Сәгатьтә ике миль – ике миль ярымнан артык бара алмыймыз. Дулаган диңгез өстендә биеп йөри торган дулкыннары берлән бу көн бик матур. Аның йотаргa киләм дип килә торган тау кадәр дулкыннары егетчә җитез. Аның (дулкынның) өсте кигән ап-ак челтәр киеме, җефәк челтәр кебек нәфис, Себер кары кебек ак башы күккә күтәрелгәндә, аның ачылып китә торган зөмреддән[1] яшел муен, Зөһрә йолдыз нурыннан да саф, бөтен диңгез ап-ак челтәргә киенгән. Аның нечкә, нәфис күлмәге үзе биегәндә аерым-аерым бии, үзе һавага таба сикергәндә күккә таба, күкнең егетләренә таба бүсәләр[2] җибәрә. Күктәге егетләргә каршы елмая. Аларның дикъкатен җәлеп итәр өчен кычкырып көлә, аларны уятыр өчен сызгыра, йырлый.

Диңгез пәриләренең исерек туйлары кичкә кадәр дәвам итә, кояш баер алдыннан, алар, тәмам исереп, ни кылынганнарын белмиләр. Кайсылар безнең пароходның башына, кайсы безнең пароходның койрыгына утырып таган атылалар[3]. Үзләре йырлыйлар, үзләре уйныйлар, үзләре көләләр, үзләре күтәрелгәннән күтәрелеп, таган атылалар. Шуларның олылыгыннан безнең пароходның койрыгына зарар килде, ул шул кадәр күп диңгез кызларының биюен күтәрә алмады, әллә нәрсәсе шартлады. Үзләренең артыкка китүләреннән курыктыларммы, әллә таган атылырга ялгыз пароход күрделәрме, алар бердән безнең «Карачи Мару»ны ташладылар. Безнең бара торган юлымызның

[1] Зөмреддән – зөбәрҗәттән.
[2] Бүсәләр – үбүләр.
[3] Атылалар – атыналар.

тәмам тирес[1] ягына таба вә бик кызулап бара башладык. Диңгез кызлары, артымыздан никадәр кусалар да, безне җитә алмадылар. Алар куган саен, без куәтлерәк китә бардык. Имеш, без Юнанстан якасындагы бер портка кереп чыгачакмыз, бакалым. Без бүген 156 миль киткәнмез. Хәзер без Корфу атасы тугрыларында. Һава суык, һәммә кеше көзге киемнән. Юрган юкка, миңа төннәры суык.

*24 [нче] ноябрь*

Төн буе безнең пароход төрле якка таба борылып йөреп туйган булырга кирәк. Таң атканда, ул шимале гарбигә бара, тагы да каршы килә торган җил берлән сугыша иде. Имеш, төнлә безнең пароход, җилгә каршы тора алмаенча, берничә сәгать артка таба киткән. Төн яртысыннан соң тагы үз юлын тапкан. Иртә берлән суык. Салкын җил шимальдән исә. Ул, безнең пароходны Адриатик диңгезенә кертмәс өчен, бөтен көчен-куәтен сарыф итә. Ләкин пароход һаман акрын булса да бара. Иртүк Юнанстан, кечкенә-кечкенә аталар күренәләр. Өйләдән соң Италия ягында да коры күренә. Димәк, без Адриатикның үзендә, Атрант[2] бугазында. Җил бераз сабырлана, пароход кеше төслерәк атлый башлый. Кич суык. Тышта озак торып булмый. Трюмда бик тавышлы, бик сасы. Бөтен өстәлләрдә карта уйныйлар. Бөтен почмакларда чиртмеш кебек бер ахмак уен уйныйлар. Бу казарма хәяты бик туйдырды инде. Тизрәк очы чыксын иде инде. Бүген безнең пароход бер тәүлектә 55 миль киткән.

Без хәзер һәр көнне шимальдән шимальгә китә барамыз. Бүген без Истанбул тугрыларында. Без инде, мондагы хайван хәятыннан бик арыгангамы, үземезнең киләчәкне уйлый да алмыймыз. Прагага бару безнең өчен җыгылмый торган туфракка керү ихтималы булса да, аңарга каршы бер эш тә эшли алмыймыз. Италиядә, таныш-белешсез йирдә калуда без[гә] һич мәгънә чыгачак түгел. Чехстанга барганда Австриядә калу мөмкин булса да, анда да дус-иш юкка, калырга шөбһәләнәмез. Прагада бертөрле рәсмият бирә алмамызмы дип уйлыйм. Бармаенча берни әйтеп булмый, ләкин юл буе күргәннәремезгә караганда,

[1] Тирес – кире.
[2] Атрант – Отранто.

боларның Европада кыйммәтләре бик аз булырга кирәк. Монда килүдән үземезне үземез дискридировка[1] итмәсәк ярый инде.

Австриядән үткәндә Берлинга берничә дуст немецыма һәм дә андагы татар таләбәләренә мәктүбләр салып китмәкче булдым. Бәлки, берәр мәгълүмат-фәлән алып булыр. Берничә көннән бирле башым бик авырта. Суык тияме, җил сугамы, әллә диңгез тотамы?

Бүген сәгать 12 дә Триестка 375 миль калды. Атрант бугазының Италия ягындагы маягы безгә юл күрсәтеп кала. Хәерле юл. Адриатик диңгезе –миналарның иң күп йөри торган урыны булганга, иң куркынычлы диңгез. Алла үзе сакласын инде. Бүген кич берлән безнең бүлмәдә унҗиде компания карта, чиртмеш, шатранҗ[2] уйныйлар. Һәрбер уен янында дүртәр-бишәр кеше. Иң күбе, – әлбәттә, карта уены: кайсылары корыдан, отышсыз уйныйлар, кайсылары шырпыдан уйныйлар, кайсылар акчадан.

*25 нче ноябрь*

Иртүк тып-тын һава, көзге кебек диңгез, кояш саф. Тын диңгезен элгәре утын җибәреп кыздыра-кыздыра да, диңгез йомшарып җиткәч, төртеп тишә. Аның эссесеннән, кызуыннан тирә-юньдәге бөтен болытлар ут яна. Зөһрә йолдызы, төннең сакчысы кебек, бик озак үзенең каравылында тора. Ул бик озакка кадәр кояш берлән төннең сугышын җентекли. Кояш җиңеп, үзенең байрагын күтәргәч тә, җиңелгән команданның кальгалар ачкычын дошманга тапшырып җиңелүе кебек, Зөһрә дә үз ниятен ташлый, ул да бата. Ике яктан да коры күренә. Далмация* тарафында кечкенә аталар[3] кала, Италия ягында озын сахил сузыла. Адриатик диңгезе шактый киң булганга, ике яктан да коры күренмәскә тиеш иде. Көн бик матур, диңгез гомердә дуламаган кебек тын, саф. Һава елы, кояш йомшак, мәхәббәтле. Җил бик аз, ул диңгезгә сөеп кенә, кичәге дулаудан алган җәрәхәтен төзәтер

---

[1] Дискридировка (рус. дискредитировать) – абруй түгү.

[2] Шатранҗ – шахмат.

* Далмация – хәзерге Хорватия (күбесенчә) һәм Черногория территориясендә, Балкан ярымутравының төньяк-көнбатышында, Әдрән диңгезе ярында урнашкан тарихи төбәк.

[3] Аталар – утраулар.

өчен кебек кенә, акрын гына, өф итеп кенә өрә. Диңгез дә аңгарга каршы иркәләнеп, назланып, елмаеп кына җавап бирә. Көн буе ике якта да коры күренә килә. Кояш баер алдында, диңгездә кош-корт бик күбәя. Безнең юлны кисеп, бер җилкәнле көймә үтеп китә. Төн дә бик ачык, бик саф. Ай – яңа ай – урак кебек, күкләрне бизәкли. Бөтен йолдызлар һәммәсе үз урынында. Әнә Тимерказык йолдызы, әнә Иләк йолдызы. Әнә йөгән аты җигелгән җиде йолдыз да үз урынын тоткан. Безнең ашыкканны белгән кебек, җил дә артка төште, ул да авыр басып, пароход артыннан куа. Пароход селкенмәенчә, салланмаенча кызу-кызу алга таба бара... Насыйп булса, без иртәгә кичкә Триестка барып җитәчәкмез. Бүген безнең пароход ике йөз дә ун миль йөргән. Без бүген үземез берлән бергә килгән чех солдатларына рәхмәт укып, язып бирдек. Ләкин забитлары[1] хакында бер сүз дә әйтмәдек. Чын да, солдатлар фәүкыльгадә[2] хөрмәт күрсәттеләр. Шуның күк забитлары шулкадәр игътибарсызлык күрсәттеләр.

Дөрестен әйткәндә, боларда забит дигән нәрсә юк икән. Берникадәр бала-чага. Кайберсе – прапорщик, кайберсе – солдат. Үзләренә үзләре дәрәҗә биргәннәр дә, забит булганнар. Солдатлар бик яхшы тәрбияле, итагатьле, ни кушсалар, шуны эшлиләр. Забит дигәннәре никадәр мәгънәсезлекләр, никадәр идарәсезлекләр эшләсәләр дә, һичбер төрле каршы килмиләр, мондый гаскәр берлән сугышу да, эш эшләү дә оят кынадыр. Ләкин үзләрендә һичбер төрле стеснение юк. Шул дәрәҗәдә юк, гаҗәпкә каласың. Мәсәлән, бер вакытны ягмур яуганда, безнең трюмны японнар яптылар. Ягмур туктады, көн кыздыра башлады, японнар килеп ачарга оныттылар. Безнең трюмда шулкадәр эссе булды, тын алырга мөмкин түгел. Менә аш вакыты җитте. Мин берничә чехка ачарга кирәк дип әйттем, һичбер кеше ачарга батырчылык кыла алмады. Шул мунчадай эссе трюмга ашарга кереп утырдылар. Шуннан соң мин тоттым да ачтым, тегеләр рәхәтләнеп киттеләр. Араларында кулга алырлык шәпләр юк, һәммәсе дә бертигез тәрбияле, бертигез мәгълүматлы, һәммәсе дә берсенә-берсе охшаган бер уч ситса кебек, бер

[1] Забитлары – офицерлары.
[2] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

машинадан чыккан макарон кебек. Руслар арасындагы кебек гавамнан кеше буе, кул сузымы озын бер кеше юк. Кулга тотарлыграк бер кеше, бер мөгаллим – ул чехларның пароходтагы газеталарының редакторы. Бик күп эшли, яза. Солдатларга мәгънәви тәэсир ясый. Гакыллы гына, укыган гына, тырыш кына бер кеше. Артык бер хаҗәте юк. Икенчесе – бер карт чех. Яшьләре 56–60 та. Ул – чехларның оркестрында барабанчы. Музыка уйный башлаганда, ул һәрвакыт барабан янында рәсми киеменнән (солдатча киенә) вә кыяфәтенә мөнасиб[1] мөтәәссиррәк[2] булсын өчен, күзенә күзлек кия. Барабанны сукканда мәгълүм тавыш чыксын өчен генә кулын күтәреп төшерми, намаз укыган кебек фәна фил-барабан[3] булып суга. Һәрбер сукканында Чех-Словак Җөмһүриятенә зур бер хезмәт итәм дип ышанып суга. Чехстанга оҗмахка барган кебек бара. Аннан соң, бер кап-кара чегән. Бу мескен ат урлап йөрү урынына чех гаскәренә килеп кергән дә, чех җөмһүриятен төзеп маташа. Үзе бик ачык, бик күп сөйли, иптәшләрен бик көлдерә, бик күп эш эшли. Һәр көнне бер төрле дежурстводан чыкмый. Моңарга башка тагы телгә алырлык – безгә хезмәт итүче чех кына. Ул – гади, дорфа авыл мужигы. Үзе теләп руска әсирлеккә төшкән. Әллә ничә ел чех гаскәрендә хезмәт иткән инде. Өенә кайтып бара. Кайтып җиткәч, икенче көнне үк мылтык алам да, күршедәге алпавыт йиренә куян атарга китәм. Элгәре куян аттырмаенча җанны алалар иде, менә хәзер инде куянның кирәген бирәм, ди.

Без Триесттан аерым китикме, солдатлар берлән китикме мәсьәләсен бик озак төшендек. Ахырдан, ялгыз киткәндә дүрт төрле хөдүдтән[4] үтәргә кирәк булганга, аларның һәммәсендә дә, үзләренең мөстәкыйльлекләрен исбат итәр өчен, жандармалар әллә ниләр кылыначак булганга, солдатлар эшелоны берлән китәргә булдык. Ике ай түзгәнбез, Алла теләсә, ике-өч көн генә түзәрмез.

---

[1] Мөнасиб – туры килгән.
[2] Мөтәәссиррәк – тәэсирлерәк.
[3] Фәна фил-барабан – барабанда эрү.
[4] Хөдүдтән – чиктән.

*26 нчы ноябрь*

Иртүк ике тарафтан да коры күренә. Өйләгә таба безнең пароход Истри* яры буйлап бара башлый. Җил безнең астан. Пароход шәп йөри, көн бик ягмурлы. Өйләдән соң без сахилгә бик якын барамыз. Маяклар, фонарьлар, кечкенә-кечкенә авыллар күренеп кала. Әгәр без Италия сахиленнән барган булсак, безгә Альпа тауларының карлы башлары күренәчәк иде. Ни диптер, безнең капитан уңга тотты. Бүген приказ берлән безнең солдатларга рәхмәтне игълан иттеләр. Чех солдатларының кәефе бик килде. Тайтлар бераз кәефсезләнгәннәр. Пароходның башы булып бара торган тайт безгә килеп гафу үтенгән кебек кылынды. Үзе ахмак, үзе надан, үзе малай булганга, эше ахмакча чыкты. Кояш аяз диңгезгә ятты. Насыйп булса, бу сәфәрдә кояшны диңгездә актык күрүебез. Кояш яту берлән, еракта гына Триест күренә башлый. Сәгать җидедә безнең пароход Триестның алдында, шәһәрдән ике-өч чакрым йирдән якорь салды. Без кичегеп килгәнгә, безнең пароходны бүген кабул итмәделәр. Бүген, иншалла, пароходта актык кичемез. Илле биш көнлек диңгез сәфәремез очына җитте. Диңгез исән алып, сау китерде. Коры инде ничек кабул итәр, нинди мөгамәләдә булыр – киләчәк күрсәтер. Үземезнең максатымыз булган Парижга барып чыга алачакмы без, әллә шул Чехстанда бикләнеп каламызмы? Хәзер без Прагага барамыз. Аннан Франсәгә[1] чыгарга иҗтиһад итәчәкмез. Аннан өйгә. Әле дә инде бу чех сәфәре бик сузылды. Вакыт башка эшкә керешергә.

*27 нче ноябрь*

Иртүк Триестка алып барырга безгә каршы лоцман килә. Пароход Триестның беренче рейды эченә кереп туктый. Шәһәр тау битендә: матур гына, җыйнак кына, кечкенә генә. Бераз Владивостокка охшаган. Шуннан соң Италия полиция[се], Италия докторлары килә, безнең бөтен гаскәрне аерым-аерым карарга булалар: имеш, итальяннар әллә нинди йогышлы чир килүдән куркалар. Ләкин бу аерым-аерым карау доктор алдыннан үтеп китүдән гыйбарәт булып, мәгънәсез вакыт әрәм итү генә булып

* Истрия ярымутравы күздә тотылса кирәк.

[1] Дөресе: Франциягә.

чыга вә безнең ике-өч сәгать вакытымызны ала. Шуннан соң пароход тагы кузгалып, диңгез яры буена килеп туктый. Безне берникадәр чехлар каршы алалар. Триестта славян халкы бик күп булса да, бу каршы алу бик кечкенә күренә. Безнең Казаннан Чистайга килгән пароходны каршы алган кадәр дә кеше юк. Сәгать унберләргә кадәр үзләренең комиссия әгъзаларыннан да беркем дә килми. Гомумән, болар шундый хөрмәтләргә бик саран булырга охшыйлар. Докторлар карап, полиция визит ясагач та, безгә корыга чыгарга рөхсәт бирмиләр. Чех офицерлары, «менә рөхсәт килә, менә рөхсәт килә» дип, солдатны кичкә кадәр көттерәләр дә, кич берлән итальяннарның чыгарга рөхсәт бирмәүләре мәгълүм була. Бу вакыйга чехларның икенче күзен дә ача. Италиягә никадәр хезмәт итсәләр дә, Триестның төзелүенә

## 13 нче дәфтәр

әллә никадәр көчләрне, малларны, гомерләрне сарыф иткән булсалар да, хәзерге көндә үзләренең иттифакчылары[1] саналган Италиянең шулкадәр ярдәм иткән гаскәргә чыгып, урам карарга да рөхсәт бирмәве бик күбесен хәйранга калдыра. «Без соң шуның өченме сугыштык, шуның өченме Австрияне җимерештек?» дигән сөальләрне бирәләр. Берникадәр чех килеп сөйләшәләр, берничә газета китерәбез. Хәбәрләр чехлар өчен күңелле түгел. Беренче, аларда вакытыннан иртә кыш булганга, бәрәңге берлән чөгендер кар астында калган. Шуңарга күрә бәрәңге бик бәһале, чөгендер җитмәгәнгә, шикәр заводлары теләгәнчә эшли алмый. Икенче, чехларның күршеләре – балахлар[2], югославяннар, мaҗарлар[3] берлән мөнәсәбәтләре шәп түгел. Өченче, үзләренең ташкүмер чыгаручы эшчеләре эш ташлаганнар, үзләренең большевикларын хәбесханәдән[4] чыгаруны таләп итәләр. Дүртенче, хәят Чехиядә бик бәһале, һәрнәрсә карточка берлән алына, күп нәрсә җитми. Болар безне дә уйга калдыралар: без Русиядән бозылган, ярлыланган, эштән чыккан бер мәмләкәткә барып ты-

[1] Иттифакчылары – союзниклары.
[2] Балахлар – румыннар.
[3] Маҗарлар – венгрлар.
[4] Хәбесханәдән – төрмәдән.

гылмыймызмы дигән шөбһәгә төшәмез. Баргач күрермез инде. Иртәгә без китәмез, диләр. Никадәр дөрест чыгар, анысын бер Алла гына белә. Триест шәһәренең порты бик яхшы корылган. Бик күп пароход туктарга урын хәзерләнгән. Бик күп мал сакларга магазиннар[1] төзелгән. Бу – моңганчы[2] мин күргән портларның иң яхшысы, ләкин хәзер ул мазарлык[3] кебек: һичбер җан әсәре юк. Пароход юк, мал төяүче юк, мал китерүче юк. Шәһәр хәзер тәмамән эшсезлектән йөди икән. Италиянең үзенең аңарга башка портлары булганга, аның барлы-юклы товары монда килә алмый. Югославиядә мал юк. Австриядә һәм мал юк. Мал булса да, ул аны хәзер монда җибәрмәячәк, Германия аша озатачак. Шуңгарга күрә Триест үзеннән-үзе тончыгып ачка үләчәк. Мондагы йөз пароходтан бер юлы бушана торган йөз пароходка бер юлы төйи ала торган машиналар әрәм булып торачак та, күгәреп бетәчәк.

Көн буе вак ягмур яуды. Һава бик сыйсыз булды.

*28 нче ноябрь*

Иртә берлән һаман әле безгә шәһәргә чыгарга рөхсәт юк. Ләкин мин, үземнең цивил[4] киемдә булудан файдаланып, башка кешеләр берлән бергә буталып шәһәргә чыгып киттем. Шәһәргә әллә кайлардан йөрелеп-йөрелеп барып менеп кайттым. Ул вакытта һәммәмезгә чыгарга рөхсәт булган, ләкин бүген поезд китәчәк булганга, өчтә кайтырга кушылган иде. Шәһәргә тагы чыктык. Шәһәр бик куе утырган, халык бик күп, магазиннарда мал күп, кешеләр дә, базарларда ашамак-эчмәк тә бик күп. Димәк, бу шәһәр хәзер ачлык күрми. Икмәкнең килосы илле сантим*. Шикәрдән башка һәрнәрсә кибеттә бар. Без, вакытымыз аз булганга, өстән генә карап үтәмез. Без кайткач, ике поезд бирелә. Солдатларны утырту башлана. Безгә һичбер йирдә урын юк. Бик озак аптырап йөримез. Ахырдан бер офицер

---

[1] Магазин – м о н д а: склад.

[2] Моңганчы – моңарчы.

[3] Мазарлык – зират (кулъязмада «мазралык» дип язылган).

[4] Цивил – гражданский, хәрби булмаган (кием).

* Сантим – акча берәмлеге, Франция, Бельгия, Швейцария һәм башка илләрнең алмаш тәңкәсе, франкның йөздән бер өлешенә тигез.

безнең өчен мәшәкатьләнеп, безгә өченче класс вагонына, чех забитлары янына утырта. Урыны зарарсыз. Вагонның урындыклары катыг[1], тар булса да, бик пычрак түгел. Безнең поезд тиз китәчәк, диләр. Кич була – китми, сәгать уннар була – китми. Ниһаять, иртә[гә] китәмез, диләр. Шәһәргә бармакчы буламыз, шәһәр военный положениедә, диләр. Бара алмыймыз, йокларга ятамыз. Кием-салым безнең бик юка. Минем пәлтәм булса да, Фуадка бирдем, ул бигрәк тиз суык алдыручан. Үзем ягмур пәлтәсеннән генә төрлечә иттереп йоклап карыйм, туңып уянам. Шулай эшләнә[2] кичне үткәрдем. Төнлә йокы арасында безнең чехларның беренче эшелоны китә. Без аннан соң дүрт сәгатьтән китәчәкмез. Бүген без Востоктан* чыкканга атна исәбе берлә сигез атна тулды.

*29 нчы ноябрь*

Төн буе туңып эштән чыктым. Кием нечкә, ятак такымы[3] юк. Һава бик юеш һәм суык. Иртә берлән сәгать бишләрдә туңудан уянып, елынырга тышка чыктым. Бик озак арлы-бирле йөрегәннең соңында гына, бераз елы җыя алдым. Актык мәртәбә пароходтан кайнар су алып, чәй эчәмез. Владивостокка китүче бер чех забиты[4] аркылы Гомәргә озын гына хат яздым. Сәгать тугызларда безгә паровоз бирәләр. Ул безне, төрле юлларда йөртеп, зур вокзалга китереп туктый. Анда тагы астан үтүче бер машина да эләктерәләр. Сәгать ун ярымда без Триесттан китәмез. Ләкин бер сәгатьтән артык без Триест тирәсендә әйләнәмез. Триестны төрле ягыннан карый-карый, тауга менәмез. Ләкин һава бик томанлы булганга, шәһәрне рәтләп күрә алмыймыз. Менә шулай йөри-йөри, туннельдән туннельгә керә-чыга, без Крас тауларына** менә башлыймыз. Көн буе безне ике паровоз көчкә өстерәп бара. Сәгать бишләрдә без Горицага*** барып җитәмез.

[1] Катыг – каты.

[2] Эшләнә – м о н д а: иттереп.

* Восток – Владивосток порты күздә тотылса кирәк.

[3] Ятак такымы – урын-җир кирәк-яраклары.

[4] Забит – офицер.

** Крас таулары – бүгенге Словения территориясендә һәм Италиянең көнчыгыш чигендә урнашкан плато – яссы таулык.

*** Горица – бүгенге Италиядәге Гориция шәһәре.

Аңарга җитәр алдыннан очраган бөтен авыллар җимерелеп беткән, әллә никадәр тимер чыбыклардан сугыш саклары ныгытылган. Горицаның үзендә һичбер җимерелмәгән өй калмаган. Австрия берлән Италия арасында монда сугыш бик озын һәм дә бик каты булганга, монда җимерелмәгән өй-бина, туп-мылтык тимәгән агач-таш калмаган... Йир бөтенләй казылып беткән. Безнең ашыйсы бик килгәнгә, вокзалга ашарга чыгамыз. Ләкин вокзал ватылып беткән, һичбер буфет-фәлән юк. Шәһәргә чыгамыз. Вокзал күршесендә генә начар гына бер ашханә табамыз. Поездымыз бик озак тора дигәнгә, кызу-кызу гына булса да ашыймыз. Аннан вокзалга килсәк, безнең поездддан җилләр исә. Анда чабамыз, монда чабамыз. Бер Италия хезмәтендәге чех солдатын очратамыз, аннан безнең поездның ун минут элек китүен беләмез. Шунда нишләргә аптырап торганда, ул безне хәзер поездга алып бара. Шундагы түрәләр берлән сөйләшеп, безне утырта. Без үземезнең эшелонны куарга китәмез. Итальяннарның пассажир поездлары шактый тиз йөри икән. Ләкин ул безнең трамвайларга охшаган. Кешеләр багажсыз, стансаларда чыгып йөрү юк, торуы та бик аз, Оддин дигән стансада безнең эшелонны куып җитәмез. Көндездән үк еракта гына Альпа тауларының ап[-ак] карга буялган башлары күренә. Хәзер инде без шунда килеп җиттек. Бинида биек, мәһабәт таулар. Башлары сөт кебек ак. Караңгы булганга, рәтләп күреп булмый. Һава тагы суыгая төшә. Кар йирдә күренгәли. Без һаман, бер паровоз тартып, берсе төртеп, Альпаның өстенә менәмез дә менәмез. Карарга бик теләсәм дә, төнлә күренмәгәнгә, тышта торырга кием бик сыек булганга, йокларга ятам. Йоклап булмый – суык ирек бирми. Алай авам, болай авам – һичбер йокыга китә алмыйм. Менә тагы поезд туктый. Һәм дә шул туктаудан поездымыз кич буе шунда кала. Иртә берлән сәгать бишләрдә торып йөри башлыйм. Ватык вокзал, халык юк. Менә таң ата, көн ачыла. Вокзалдан кешеләр чыга. Карасак, вокзалның исеме Пун Туба («Pune tubba*»). Бу –Италиянең элеккеге шәһәре, монда бик зур сугыш булган. Шәһәрләр, стансалар ватылып беткән. Сәгать

* Бу сүзләр чыганакта латин хәрефләре белән язылган.

сигезләрдә кузгалып китәмез. Безнең туктаган стансамызның[1] диңгездән югарылыгы 6400 кырык митрә[2] булса да, без һаман Альпага таба күтәреләмез, күтәреләмез. Монда бөтен дөнья кар берлән капланган. Ап-ак кар ярты аршын тирәнлегендә. Альпа таулары, күккә кадәр күтәрелеп, болыт астында башларын бастыралар. Монда нарат күбрәк үсә, миләш тә бәрабәр. Моңганчы Италия кыйсемендә иң күп агач кәстәнә[3] иде.

*30 [нчы] ноябрь*

Бу таулар төркеменең исеме төрекчә «Караван» булып («Караванка*»га мондагы славян алыштырган), кичетнең** исеме Пун Туба булды. Бу исемнәрнең төрекләр тарафыннан бирелгән булу ихтималын күрсәтәдер. Безнең бабайларның бер гаскәре шул исемне биреп калдыргандыр, ахыры. Без[гә] Караванка дигән Альпа тавының бер ботагын үтә кисеп, Австриянең увалыгына[4] төшәргә кирәк. Менә үтә торган арасының исеме Пун Туба икән. Бу тау арасы Австрия берлән Италияне куша торган иң зур юл булганга, тимер юл да шунда эшләтелгән. Соңгы сугыш та шул тау арасы өчен бик зур булган. Без хәзер Австриянең сугыштан элгәре булган хөдүденә[5] бик якын булганга, бөтен йирләр җимерек, ватык. Зур-зур солдат зиратларын үтәмез. Чех солдатларының күбесе шул фронтта булганга, күп сугышны белә, мондагы бәла-казаны да күргәннәр. Аларның сүзенә кар[а]ган[да], Пун Туба өчен ике яктан да сиксән мең кеше үлгән, имеш. Һаман алга барамыз. Табигать бик ала һәм бик төрле. Болыттан биек, бер таштан кисеп ясаган тау башында – ак чалма. Аның ап-ак карсыз кырыеннан ук кебек кызу итеп шарлавык ага. Юл юынлап, борылып-борылып елгалар чаба. Анда авыл, монда авыл. Һәммәсендә дә чиркәү башында сәгать. Кайбер тауларның башын-

[1] Дөресе: станциябезнең.
[2] Митрә – метр.
[3] Кәстәнә – каштан.
* Караванка – Альпа тауларының көньягында Караванке дигән тау сырты.
** Кичет – тау сырты аша үтә торган юл, үткел (перевал).
[4] Увалыгына – тигезлегенә.
[5] Хөдүденә – чикләренә.

да – коруне вөстадан[1] калган замкалар[2], сарайлар*. Кайсыларында – крепость (кальга) кебек иттереп эшләнгән чиркәүләр. Күз карарга өлгерә алмый. Вагонның бер ягыннан карасаң, икенче ягы кала. Менә бу иске Австрия иде. Ләкин бу йирләрне инде итальяннар забыт иткәннәр[3]. Биналар, йортлар, йирләрнең архитектурасы Триест тарафындагы башка[4] – һәммәсе зур, өлкән, нык. Пакь немец эше икәне күренеп бара. Менә озакламаенча без хәзерге Австрия-Италия чигенә җитәмез. Зур вокзал, әллә никадәр Италия-Австрия машинасы бар, әллә никадәр тимер юл хезмәтчесе. Монда безнең әйберләрне карарга тиешләр иде, ләкин берни булмый: без үтәмез. Вокзалда акча алыштыра торган касса бар. Шул кассада тугыз итальян лирасына йөз Австрия кроны бирәләр. Без кронның очсызлыгына гаҗәпкә каламыз. Менә тагы поезд китә. Ике-өч сәгатьтән соң без Виллаф (Виллаф**) дигән Австриянең бер шәһәренә килеп җитәмез. Шәһәр биек йирдә булганга, Альпаның бик матур урыны булганга һәм дә шуннан ерак түгел Альпа башында зур күл булганга, бу курорт икән. Зур-зур отельләр, банклар, магазиннар, йортлар – барысы да бай иттереп, нык иттереп эшләнгән. Шәһәрнең манзарасы бик матур, Альпаның күренеше бик мөнасиб, бөтен тирә-юнь агачлык. Безнең эшелон монда дүрт сәгать торачак. Аш ашарга, шәһәрне карарга китәмез. Бер каһвәгә[5] керәмез, аш сорыймыз – аш юк. Ни булса да ашарга сорыймыз – юк. Каһвә бар, шәраб бар һәм дә казылык бар. Каһвәсен, берәр стакан шәрабын, казысын сорыймыз. Казыга икмәк бирмиләр. Яңадан сорыймыз – юк. Каһвәгә шикәр бирмиләр. Яңадан сорыймыз – юк. Шуларны корылата ашап-эчеп елынамыз, шуларга илле дүрт крон түлимез. Чехларның сүзенә караганда, монда шул нәрсәгә сугышка кадәр бер кроннан артык түләнми икән. Безнең берлән бер залда

[1] Коруне вөстадан – урта гасырлардан.

[2] Дөресе: замоклар.

* Замка – замок (урта гасыр Аурупасында феодал гаиләсе һәм хезмәтчеләре яшәгән кечкенә кала).

[3] Забыт иткәннәр – кулга алганнар, басып алганнар.

[4] Тарафындагы башка – тарафындагыдан башка.

** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

[5] Каһвәгә – монда: кафега.

ике егет, ике немец марҗасы утыралар. Аларның бер пары бөтенләй кочакланып утырган. Бер пары икенче бүлмәдә уйный торган граммофонга бик тырышып бииләр. Урамга чыгамыз. Халыкның күбесе иске киемнәрдән, яңа киемнән. ирләр бик аз. Зур-зур урамнар, сарай кебек отельләр, йортлар – һәммәсе буш, һәммәсе җансыз, рухсыз. Бер шәһәр шулай итеп үлә, күрәсең. Бер халык шулай итеп фәкыйрьләнә, рәзилләнә[1], күрәсең. Сәгать җиделәрдә тагы Альпа буйлап китәмез. Инде без Альпаны Австрияга таба төшә башлаганга, бер генә паровоз өстери. Юеш кар арасыннан ике якта да Альпаларны калдырып, без акрын гына, туктый-туктый гына барамыз. Исән-сау булсак, бик озак туктап йөдәтмәсә, без иртәгәдән арыга Чехстанга керәчәкмез.

*1 нче декабрь*

Без бүген Каринтия* дигән Австриянең әяләтесеннән[2] үтеп, Штирияга** кердек. Сәгать унберләрдә Австриядә тимер мәгъмүлятының[3] мәркәзе саналган Леобен*** шәһәрен үтәмез. Юлымыз бер буйдан Мур елгасы буйлап бара. Без һаман әле Альпа тауларында, ләкин инде аның бер түбәсен үтеп тигезлеккә, увага[4] чыктык. Тагы бер түбәсен үтәчәкмез дә Вена тирәсендәге увага инәчәкмез. Леобенның вокзалы бик шәп: халык бик күп һәм сыйдыра. Штирия немецлары[ның] хатыннары дорфа гына, таза гына, балалары шактый начар киенгән, ирләрнең күбесендә иске кием. Мондагы халыкның иң яраткан төсе сыек яшел төс булырга кирәк. Һәммәсе дә киң эшләпәләренең тасмаларын яшелләткәннәр. Аннан соң, ирләренең бик күбесе эшләпәләренең арт ягыннан, тасмасы арасына кылдан бер чук утыртып куй-

---

[1] Рәзилләнә – түбәнгә тәгәри.

* Каринтия – бүгенге көндә Австриянең көньягында урнашкан федераль дәүләт. Башкаласы һәм иң зур шәһәре – Клагенфурт-ам-Вёртерзе.

[2] Әяләтесеннән – җиреннән.

** Штирия – бүгенге көндә Австриянең көньяк-көнчыгышындагы федераль дәүләт. Башкаласы һәм иң зур шәһәре – Грац.

[3] Тимер мәгъмүлятының – тимер промышленностеның.

*** Леобен – бүгенге көндә Австриянең Штирия федераль дәүләтендә, Мур елгасы буенда урнашкан борынгы шәһәр.

[4] Увага – тигезлеккә.

ганнар. Кайсыларының чукларының озынлыгы берәр сөям* бар, кайсысыныкы өч вә илле кадәр. Кылның төсе күп чукта җирән. Кайберләре ул чук башына әллә нинди көмеш кисәкләре, бака кашыклары такканнар. Болар йирле халык икән. Боларча, шулай киенү матур икән. Менә сиңа матурлык, матурлык хакында тагы бер фикер. Халык монда да фәкыйрь. Вокзалдагы каһвәдә чәй дә, шикәр дә бар. Ашарга да ясмык берлән бер камырдан ясаган нәрсә бирәләр. Ләкин ачлык һәр нәрсәдә күренеп тора. Тимер юл хезмәтчеләре безнең солдатлардан ашарга икмәк сорыйлар. Сәгать икеләрдә Брук** (Bruk***) дигән шәһәргә туктыймыз. Аның стансасыннан[1] зур поездга берләшкән француз гаскәренә очрыймыз. Гаскәр яхшы киенгән, бите-башы тулы, таза-сәламәтләр. Забитлар арасында башына фәс кигән берничә кеше бар, ләкин кыяфәтләре төрек түгел. Тәрәзә янына килмәгәнгә, сөйләшә алмыйм. Французларның әл-Җәзаир[2] гаскәрләренең забитлары булырга кирәк. (Болар Ләһстаннан[3] кайта торган француз гаскәре булып чыгалар.)

Сәгать җиделәрдә без Симмеринг**** дигән шәһәргә килеп җитәмез. Бу шәһәр Альпаның иң югары йирендә. Без хәзер диңгездән мең митрә[4] югары. Шуннан без Австриягә төшәчәкмез. Мең митрәлек тауны егерме киломитрәдә[5] төшеп бетәчәкмез. Без кузгалып киткәндә төн якты, безнең бәхеткә, айда шактый зур томан юк. Безне өч паровоз терәп, төшә башлыймыз. Тугры төшәргә мөмкин булмаганга, немецлар юлны боргалап-боргалап урап эшләгәннәр. Кузгалып киткәндә, тау башында зур бер номерлар[6] калдырамыз. Тау астында ялтырап тора торган бер шәһәр күрәмез. Акрынлап төшеп китәмез, номерның утлары

---

* Сөям – аршынның чирегенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге.

** Брук – монда сүз Австриянең Штирия федераль дәүләтендә һәм Мур елгасы ярында урнашкан Брукк-ан-дер-Мур шәһәре турында бара булса кирәк.

*** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

[1] Дөресе: станциясеннән.

[2] Әл-Җәзаир – Алжир.

[3] Ләһстан – Польша.

**** Симмеринг – Австриядәге Земмеринг (Semmering) шәһәре.

[4] Дөресе: метр.

[5] Дөресе: километрда.

[6] Номерлар – кунакханә.

югала. Без, елан кебек борылып, тау тишекләренә бер кереп, бер чыгып, бер тауның бер баскычын төшәмез. Уң ягы – искиткеч тирән чокыр. Анда шәһәрләр, анда елгалар, анда халык. Сул ягымыз – тау. Менә тагы бер борыламыз. Бездән югарыда теге номер ялтырап күренә, ләкин ул инде югарырак. Тагы аны калдырып китәмез, тагы тауны беләзек кебек кочаклап алган юл буйлап бер әйләнәмез, тагы теге номерымыз алга килеп баса. Инде ул шактый югары. Теге упкын чокыр һаман коточкыч. Алда-артта – тау, уңда-сулда – ап-ак башын болыттан уздырган таулар. Тагы тауны бер мәртәбә кочаклап урыймыз, тагы номер безгә сәлам бирә, тагы теге упкын күз алдымызга килә. Ләкин бу юлы аның эченнән шарлап ага торган суның тавышы да колакка ишетелә. Шулай итеп, тагы берничә мәртәбә урыймыз, берничә мәртәбә тауларны борынымыз берлән тишеп чыгып китәмез. Ярты сәгатьтә егерме киломитрәлек тауны төшеп чыгып, тигезлектәге бер шәһәргә туктыймыз. Бу шәһәр – Глухвиц*. Инде без түбән Австриягә кердек. Инде тигезлек, инде Альпа артта калды. Монда һава да җиңел, монда кар да юк. Исән барсак, төнлә сәгать икеләрдә Венада булачакмыз.

*2 нче декабрь*

Төн буе поездымыз туктап торды. Иртә берлән сәгать уннарда без Венаның җәйлек урыннарына килеп җиттек. Поездымыз бер

## 14 нче дәфтәр

озын-озын туктап, Венага керде. Без шәһәрнең бер кырыеннан барамыз. Шәһәр зур, нык иттереп эшләнгән, ләкин өйләр, биналар – барысы да моңаеп тора, күбесенең ышкатуры[1] купкан, күбесенең буявы коелган, күбесендә тәрәзәләр ватылган, урамнар былчырак. Тимер юл буе, Русия тимер юлы кебек, нәҗасәт[2] берлән тулган. Очраган халык ябык, боек, кием-салым начар. Йөри-йөри, Венаның шималь вокзалы дигән вокзалга туктыймыз. Бу – шәһәрнең урта бер җире: матур кебек урамнар, һәй-

* Глухвиц – Австриядәге Глогниц шәһәре булса кирәк.

[1] Дөресе: штукатуркасы.

[2] Нәҗасәт – пычрак.

кәлләр күренеп кала. Ләкин монда да пакьлек сизелми. Поездымыз берәр сәгать торырга булганга, без вокзалга ашарга китәмез. Буфеты бик юк кына, җыйнак. Ашъяулыгы ап-ак, хезмәтчеләр пакь киенгән, аш сорыймыз. Бик тәмле шурпа, бозау ите һәм дә бер камыр ашы бирәләр. Бар да һәйбәт иттереп пешерелгән. Шуларга әллә никадәр бәрәңге, кәбестә, чөгендер китерәләр. Икмәк кенә юк. Тәмам туйганчы ашыймыз. Өч кешегә Австрия акчасы берлән йөз егерме крон, француз франкы берлән ун франк түлимез. Чит валютага бик очсыз. Сәгать икеләрдә поездымыз Венадан кузгала. Без Дунай аша үтәмез; Дунай үзе монда Иделдән кечкенәрәк икән, ләкин агышы бик каты. Елганың иңе киң булмаса да, юлдан киң булганга, күпер бик озын. Тәрәзәдән икенче бер күпер күренеп кала. Анысы да мәһабәт, поездымыз экспресс кебек кызу бара. Болай барсак, бик тиз Чехстанга чыгачакмыз, ләкин бәласе шул: стансаларда[1] бик озак туктый. Күп вакытта авыл янында килә да ката. Безне күрү берлән әллә никадәр немец балалары сырып алалар, һәммәсе икмәк сорый. Кайсыларының өстләре-башлары да начар түгел. Вокзалларда тимер юл хезмәтчеләре тәмәке, икмәк келәнә[2], консерва сорый. Чех солдатлары үзләренә никадәр еллар яше булган немецның боларга бөгелеп-сыгылып, инәлеп икмәк соравына бик кәефләре килә. Үзләренең җиңгән икәнлекләрен озаграк, тәмлерәк хис итәр өчен, икмәкләр, тәмәкеләр, консерваларын бик юмарт өләшәләр. Менә без Чехстанга бер генә станса калдык. Чехлар бик сагынып кайтканга, бик тиз китәселәре килә. Ләкин станса җибәрми дә, җибәрми. Көн үтә, кич була, һава салкын, вагон суык. Бер адымнан әллә никадәр каннарын түккән, әллә никадәр күз яшьләре агызган, үз көчләре берлән үзләре ясаган туган илләре анда беленә. Анда матур да, анда юл да туры, тизрәк шунда. Безнең арттан килгән поездлар китә. Безгә каршы Чехстаннан, яхшы вагоннарга тулып, әллә ничә поезд үтә. Безне җибәрмиләр дә җибәрмиләр. Чехлар ярылырга җитәләр. Түземле чехлар сабырларын югалталар, немецлар берлән кычкырышалар, үз мәмләкәтләренә телеграммалар бирәләр. Менә төнлә берлән сәгать

---

[1] Д ө р е с е: станцияләрдә.
[2] Келәнә – теләнә.

җиделәр, поезд кузгалып китә. Ярты сәгатьтән инде без Чехословак җөмһүриятенең Моравиясендә* буламыз. Бөтен вагон җанлана, бөтен поезд хәрәкәткә килә, һәммәсе йырлый. Менә вокзал. Әллә никадәр халык. Е577ктан «Наздар!**» дигән тавыш моннан тагы «Наздар», шау килә. Менә бу биш ел туган иленнән җөда булып торган[1] милли гаскәр хәзер өендә. Үзенең күптән уйлаган идеалына ирешкән өендә. Без күбесен тәбрик итәмез. Һәммәсе шат, һәммәсе җанлы. Инде алар туган илдә, инде алар өйдә, инде аларның бөтен йөдәшкән мәсьәләләре, ярлылыгы, ачлыгы, хокуксызлыгы – һәммәсе беткән. Озын мөстәкыйль юлда тәмам дошман Италия биргән суык вагоннар да хушыңыз, дошман немец юри туктатып тота торган стансалар артта. «Наздар». Гаскәрләрне, безне ашаталар. Поезд тиз китмәсә дә, һичкем ялыкмый. Сәгать уникеләрдә быргы кычкырталар, солдатларны тагы шул суык, салкын вагоннарга чакыралар. Ник? Бу безнең илемез түгелмени, әнә стансада өелеп ята торган «буш класс» вагоннары безнеке түгелмени? Әнә хәзер генә елы вагоннарга утырып киткән кешеләр кадәр, үз илемездә йылы вагонда барырлык хакымыз юкмыни? Мин монда 120 Австрия кроны һәм дә 25 франсуз[2] франкын алыштырам. 25 франкка – 127 чех кроны, 120 Австрия кронына кырык өч чех кроны аламын. Поезд китә. Һәммәсенең күңелендә зур бер эч пошу, аңламау. Ни булды? Ник туган ил – боларның тире, каны берлә истикълял[3] алган туган иле – биш ел зәхмәттән соң кайтып килгәндә, ник болай каршы алды? Суык кичне тагы вагонда үткәрәмез, поездымыз, Моравиядә, Италиядә, Австриядәге кебек, стансада озак тора, шуның өстенә андагыга караганда өч-дүрт мәртәбә акрын бара. Солдатларның йөрәкләренә суык хис тула. Бик күбесе авырый, бик күбесе гасабилана[4], бик күбесе русчалап-русчалап үзләренең идарәләрене сүгә. Моравиядә кыр күп, урман да аз түгел. Авыллар бик кечкенә, шәһәрләр дә бик җыйнак. Юлда очраган

* Моравия – Чехиянең көнчыгыш өлешендә урнашкан тарихи төбәк.
** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.
[1] Җөда булып торган – аерылган.
[2] Дөресе: француз.
[3] Истикълял – бәйсезлек.
[4] Гасабилана – нервлана, борчыла.

стансаларда[1] халык бик тук, бөтен атлар, җирләр бик көр. Чехстан хакыйкатән[2] бик таза, нык мәмләкәт икән. Зур юлдан товар, мөсафир[3] поездлары үтәргә кирәк булганга, безне вак-төяк юллардан әйләндереп йөртәләр. Беркем дә кая баруымызны белми. Бер йирдә Прагага баралар дисәләр, бер йирдә Прагадан читтә бер шәһәргә. Менә тагы кич була, тагы без[гә] шул суык вагонда кунарга кирәк. Сәгать җиделәрдә Иглава* (Иглава**) дигән зур стансага барып җитәмез. Анда безне музыка берлән каршы алалар, анда безне беренче эшалон да көтеп тора. Халык шыгрым тулган, тагы «Наздар». Монда безнең Прагага баруымыз мәгълүм була. Без, ике эшалон берләшеп, Прагага китәчәкмез. Монда солдатларны ашаталар, эчертәләр. Без дә җылы вокзалда ашыймыз. Ашлары һәйбәт, күп, тәмле. Өч төрле ашка 12 шәр крон түлимез. Төнлә берлән сәгать берләрдә Прагага таба поездымыз кузгала. Хәзер ике эшалонны да бергә җыйганнар, без алтмыш биш вагон, сузылып барамыз. Безнең вагон бүген пласкар[4], бик яхшы йоклыймыз. Менә таң ата. Без Прагадан егерме-утыз чакрымда. Юынып, киенеп өлгермимез, Праганың бер читендәге вокзалга килеп җитәмез. Сәгать тугызда безнең поездны сугыш министры каршы алачак булганга, без шунда тугыз тулганны көтеп торачакмыз. Менә безнең купега бер офицер кыяфәтендә бер чех керә, исәнләшәмез: «Сез татар мөхәррирләре буласызмы, әйе, мин дә чехословак мөхәррире». Танышамыз, сөйләшәмез. Бездән кыска гына кемлегебез хакында сорап, мәгълүмат ала. Без аңардан Прагада бик күп рус барлыгын, Учредительное собрание*** әгъзалары күплеген ишетәмез. Димәк, монда шактый гына елы урын табачакмыз. Мөхәррирләрдән кая төшү, кая тору мәсьәләсенә күчәмез. Ул безгә ярдәм итәргә була. Менә поезд да

---

[1] Дөресе: станцияләрдә.

[2] Хакыйкатән – чынлыкта.

[3] Мөсафир – юлаучы.

* Иглава – Йиглава – хәзерге Чехиянең көньяк-көнчыгышындагы шәһәр, административ үзәк.

** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

[4] Дөресе: плацкарт.

*** Учредительное собрание – 1917 елның ноябрендә сайланган һәм 1918 елның гыйнварында Россиянең дәүләт структурасын билгеләү өчен җыелган вәкилле орган.

китте, туннельне чыкты. Менә вокзал, халык шыгрым тулган, һәммәсе «Наздар!» кычкыра, төрле тарафта солдатлар сәлам торалар[1]. Музыка чех гимнын уйный. Әнә министр Клофач*, әнә башка зур түрәләр. Поезд туктады, теге мөхәрриремез безне тантананың иң уртасына алып китте. Поездның башлары күренгәч, безне Клофачка тәкъдим итте. Без аларны истикъляллары[2] берлән тәбрик иттек, Клофач: «Сезнең дә безнең берлән бергә булуыңызга бик шат», – диде. Менә солдатлар чыкты, вокзал тулды, министр Клофач каршы алу нотыгын сөйләде. Аңарга бер забит җавап бирде. «Наздар, наздар!» тагы күккә чыкты. Ул ара да булмады, теге мөхәррир безне тагы бер кеше берлән күрештерде. Хәрбия нәзарәтенең зур бер әгъзасы, аның берлән әллә ни сөйләгәннең соңында безгә номер була, диде, һәм дә безне, автомобильгә утыртып, номерга да илтеп куйды. Без хәзер Прагада. Һәм дә аның шактый һәйбәт «Империал» отель дигән номерында. Алла насыйп итсә, бераз хәл җыячакмыз, баш-күз алачакмыз. Алтмыш өч тәүлек тулганда, 4 нче декабрьдә сәгать унда без үз номерымызда.

*5 нче декабрь*

Номерга килеп төшкәч тә, беренче эш, әлбәттә, юыну, ванна алу, мунчага бару нияте булды. Ләкин монда да ташкүмер бик кадерле булганга, безнең номерда ванна атнасына ике генә икән. Бүген әле ул юк. Багаждагы әйберләремез дә әле алынмаган. Алай-болай юынып кына шәһәргә чыгамыз. Акча алыштырырга барамыз, ләкин безнең барган банкаларда иенны алмыйлар, русның керенкаларын** кабул итмиләр. Романовский янымда юк. Икенче мәртәбә барганда, инде банка ябык була. Кич берлән безгә теге мөхәррир мондагы Учредительное собрание әгъ-

---

[1] Сәлам торалар – м о н д а: «сакта торалар» мәгънәсендә.

* Клофач – монда сүз чехословак дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе Вацлав Ярослав Клофач (1868–1942) турында бара.

[2] Истикъляллары – бәйсезлекләре.

** Керенка – 1917 елның 18 сентябреннән Вакытлы хөкүмәт тарафыннан оештырылган һәм 1918–1919 елларда РСФСР Халык банкы, шулай ук законсыз рәвештә төрле җирле полиграфияләр тарафыннан бастырылган кәгазь акча.

заларының адресын бирә. Монда Комучның* могавине[1] рәисе Брушвит** һәм дә Комучта дахилия назыйре[2] Климушкин***, мәгариф назыйре Егор Егорыч Лазарев**** бар икән. Эзли-эзли, безнең юлдаш чехларның кайда туктаганнарын белеп, казарманы барып табамыз. Безнең әйберләр һәммәсе исән, ләкин алып барырга извозчик юк. Эзли торгач, үзе ат булып тартып бара торган, сугыштан соң чыккан яңа извозчик (кытайча рикшалар)ны аламыз. Шуларны китереп, кием-салым алып, мунчага китәмез. Ләкин мунча монда алтыга кадәр генә икән, инде ул ябык. Әллә кая барып адашмас өчен, үз номерымызда кичке ашны ашап йокларга ятамыз. Иртәгә иртүк рус танышларны табачакмыз.

*6 нчы декабрь*

Иртүк торып, Брушвитны эзләргә китәмез. Чөнки ул – мондагы колониянең иң зур кешесе. Урамнан урам үтеп, чехча язылган урамнарны эзли-эзли, адрес буенча барып җитәмез. Ләкин ни өчендер безнең адреста фатирның номеры юк. Сорый-сорый, бер квартирны күрсәтәләр, рус шунда тора, диләр. Керәмез, бер немец каршы ала. Ләкин рус өйдә юк. Фамилиясе кем, белми. Ахырдан, кечкенә генә хат язып, чыгып китәмез. Инде Климушкинны эзләргә кирәк. Аны табу тагы авыр була. Безнең бер тыкрыкта алтынчы номерлы йортта гына, дигән. Андый йорт ул тыкрыкта өч, һәммәсендә дә бик күп фатир. Сорый-сорый, әйләнә-әйләнә барып табамыз. Анда тагы безнең бер таныш килеп чыга, ул да – безнең берлән бергә тугыз йөз дә биштә эшләгән сәяси учитель, хәзердә Учредительное собрание әгъзасы Раков*****.

---

* Комуч – Учредительное собрание әгъзалары комитеты.

[1] Могавине – ярдәмчесе.

** Брушвит – Иван Михайлович Брушвит (1879–1946), эсер, Учредительное собрание әгъзасы, Комуч хакимиятендә финанс министры.

[2] Дахилия назыйре – эчке эшләр министры.

*** Климушкин – Прокопий Диомидович Климушкин (1886–1969), эсер, Учредительное собрание делегаты, Комуч эчке эшләр бүлеге башлыгы.

**** Лазарев – Егор Егорович Лазарев (1855–1937), революционер, уң эсер, Учредительное собрание делегаты, Комуч мәгариф министры.

***** Раков – Дмитрий Фёдорович Раков (Осецкий) (1881–1941), рус сәясәт эшлеклесе, эсерлар партиясе һәм Учредительное собрание әгъзасы, Комучның финанс бүлеге идарәчесе.

Аларда озак утырып, алар берлән банкага барып, акча алыштырамыз. Романовскийның бер сумына бер крон аламыз. Бу күп түгел, ләкин мондагы хәятның очсызлыгына караганда, аз да түгел. Крон әле монда – шактый зур нәрсә. 12–15 кронга туйганчы ашап була. Кич берлән безне Брушвит өенә чакыралар. Без анда Русия хакында доклад ясаячакмыз. Анда тагы өч яңа кешегә очрыймыз. Берсе – соңгы өч социалистический конференцияләрдә эсерлар исеменнән иштирак иткән[1] Василий Васильевич Сухомлинов*. Икенчесе – Михаил Александрович Лихач**, өченчесе – Михаил Яковлевич Гендельман***. Болар өчесе дә – эсерларның мәркәз комитет әгъзалары, монда Егор Егорыч та бар. Безнең докладтан соң озын иттереп сөйләшеп утырамыз. Сухомлинов – мондагы иптәшләренә хәзерге әхваль хакында, хосусан социалистический конференцияләрдә барасы кеше (14) хакында доклад ясар өчен махсус килгән кеше. Аның сүзенә караганда, Парижда Азәрбайҗаннан Тупчыбашев**** һәм Чермоев***** бар. Дагстанлылардан ике кеше бар, фәкать аларның исемнәрен белмим, алар анда маташып яталар һәм дә, грузиннар берлән берләшеп, «Шәркый Европа» дигән бер журнал чыгаралар, бу безгә яңа бер хәбәр булып чыга. Иртәгә сәгать дүрттә Сухомлинов докладын тыңларга безне дә чакыралар. Кичне Брушвит берлән бергә үткәрәмез. Миңа ул бик самими кеше

[1] Иштирак иткән – катнашкан.

* Сухомлинов – Василий Васильевич Сухомлин (1885–1963), рус һәм француз язучысы, тәрҗемәче. Учредительное собрание делегаты, эсер.

** Лихач – Михаил Александрович Лихач (1887–1931), эсер, Учредительное собрание әгъзасы, 1918 елның 2 нче августыннан 27 нче сентябрьгә кадәр Архангельскида, Төньяк югары хакимиятенең хезмәт һәм мәгариф бүлекләре идарәчесе.

*** Гендельман – Михаил Яковлевич Гендельман (Грабовский, кушаматы Якоби) (1881–1938), эсерлар партиясенең Үзәк комитеты әгъзасы, Учредительное собрание һәм Комуч әгъзасы.

**** Тупчыбашев – Галимәрдан Галиәкбәр улы Тупчыбашев (1863–1932), Азәрбайҗан иҗтимагый һәм дәүләт эшлеклесе, юрист һәм журналист, Беренче Дәүләт думасы депутаты (1906), Азәрбайҗан Демократик Республикасы парламенты рәисе (1918–1920).

***** Чермоев – Тапа (Габделмәҗид) Арцуевич Чермоев (1882–1936/1937), 1917–1919 елларда Төньяк Кавказдагы сәясәт эшлекләренең берсе, нефть сәнәгатьчесе.

хисен калдыра. Үзе латыш булса да, тәрбия ягыннан тәмамән рус һәм дә киң табигатьле, зур колачлы рус. Ул безгә яшел акчаларымызны алыштырышырга ярдәм итмәкче була. Аның монда таныш-белеше күп булганга, безгә зур ярдәм итүе ихтимал. Бүген без мунчага барамыз, ләкин номер булмаганга, гомуммунча бүлмәсенә керәмез. Мунчалары зур. Тишенер өчен[1] аерым бүлмәләр, алар бикләнеп, ачкычны үзең берлән аласың, аннан бер йылы бүлмәгә керәсең, анда урындыклар бик күп, кешеләр тирләп утыралар, ләкин бу бик эссе түгел, аның күршесендә юыну бүлмәсе, ләкин ул кечкенә, анда берничә кеше генә юына ала. Һәм дә мунчадагы юындыручылар гына юалар. Башкаларга юынырга таз да юк, кран да юк, урын да юк. Аннан өченче бүлмәгә керәсең, ул тәмамән пар буы берлән тулган, һичбер кешене күрә алмыйсың. Тирә-юнендә урындыклар, ләүкә кебек нәрсәсе дә бар. Аннан дүртенчегә чыгасың, анда берничә душ, һәм дә ике кечкенә-кечкенә генә хәвызлар[2], шунда душ астында юынып маташалар. Утырырга да урын юк, сабын куярга да йир юк. Без бик керләнгән булганга, бу безгә кяфи[3] түгел, ләкин нишлисең. Бераз юынып, бишенче бүлмәгә чыгам, анда зур хәвыз. Сингапурдагы җамигъ янындагы җиз вә тимер хәвыздан зур. Шунда бик күп кеше коенып, йөзеп ята. Аннан алтынчыга чыгасың. Ул инде – чыгу юлы, хәзер синең тәнеңне пакь япма берлән сөртәләр һәм дә ак бер җилән кебек нәрсәне җилкәңә салалар. Шуларны киеп, бүлмәгә кереп китәсең, теләсәң, шунда буфет бар. Каһвә, сыра, шәраб эчеп утырасың. Бу Рим мунчаларыннан алынып эшләнгән булырга кирәк. Безгә бигүк ошамады.

Минем бүлмәм, бик матур булса да, бик суык. Пар берлән йылынырга тиеш, ләкин пар «теш сызлаганда»[4] гына бирелгәнгә, бик суык һәм юеш. Мин юешне бер дә яратмыйм. Ятак такымында юрган юк, өсткә мамык түшәк ябынып ятасың, ләкин ул безнең түшәккә караганда сыеграк, ясаган юрган урынына суык йирләрдә бик мәслихәт нәрсә икән. Чөнки ул, бердән, бик җиңел, икенчедән, бик йылы, өченчедән, арка-фәлән ачылып калмый,

---

[1] Тишенер өчен – чишенер өчен.

[2] Хәвызлар – бассейннар.

[3] Кяфи – җитәрлек.

[4] «Теш сызлаганда» – м о н д а: «әллә нигә бер» мәгънәсендә.

суык керми. Ләкин артык йылы булып, бик тирләтә икән. Мин бүген иртә берлән шыбыр су эчендә идем.

*7 нче декабрь*

Бүген сәгать дүрттә Сухомлиновның докладын тыңларга барамыз, ләкин ул килә алмаганга, сәгать җиделәрдә мондагы рус-чех түгәрәге ясый торган рус әдәбият кичәсенә китәмез. Кечкенә генә залда халык шыгрым тулы. Бик күп рус бар, ләкин иң зур кыйсеме – русча аңлый торган, аңламаса, русны сөя торган чехлар. Хосусан[1] чех хатыннары. Кичәнең программасы бигүк шәп түгел. Ләкин чехлар, чех хатыннары, кызлары бик зур ихлас берлән русның төрле-төрле көйләрен йырлыйлар. Шунысы гаҗәп: болар үзләре славян булсалар да, бу йыр-көй өчен әллә ни тел белү лязим булмаса да, тавышлары шактый эшләтелгән булса да, йырлары әллә нинди җылы, хисле була. Әллә нәрсәсе җитми. Бәлки, моның сәбәбе русның музыкасына, көенә, хосусан халык моңына безнең бик зур тәэсиремез булганга, анда славянлык хисе бик аз калгандыр. Ул, бәлки, татар-фин моңына, чех моңына караганда якынрактыр. Монда Кавказның бер егете берлән танышамыз, ул бик яхшы азәрбайҗанча сөйли. Үзенең яртысы осетин, яртысы грузин булса да, чех-рус якынлашуына хезмәт итеп ята. Һәм дә мондагы мәктәпләрдә рус теле, рус әдәбияты мөгаллиме Морковин дигән бер кеше берлән танышамыз. Ул тәмам рус, монда күптән торганга, бөтен чехны белә, аны да бөтен Прага таный. Монда ике төрле русча газета чыга икән, ләкин икесе дә – карагруһ газеталары. Бүген икемезгә пальтолар тегәргә бирдек, меңәр сумнан. Кием-салым безнең әле бер дә мондагы төсле булмаган, бик уңайсыз, хосусан пальтоның юклыгы бик авыр, бик суык, тагы минем ягмур пальтом бик былчыранган.

*8 нче декабрь*

Бүген монда зур бәйрәм, магазиннар, банкалар[2] ябык. Без[нең] көн буе вакытымыз Сухомлиновның докладын тыңларга үтә. Аның докладына караганда, бәйнәлмиләл[3] социализм

---

[1] Хосусан – бигрәк тә.
[2] Дөресе: банклар.
[3] Бәйнәлмиләл – милләтара.

җәмгыяте тәмамән черегән икән, социалистларның иң зур кыйсеме – «ватанчылар», калганнарны хариҗ өчен[1] большевиклар, ягъни үз мәмләкәтләренә большевиклык керүенә разый булмаенча, Русиядә большевизмның дәвам итүен теләүчеләр. Конференцияләрдә иң зур мәсьәлә өчесендә дә: Бернда*, Амстердамда, Люцернда** – миллият мәсьәләсе. Русиянең, Австриянең, Төркиянең вак милләтләре һәммәсе дә үзләренең истикъляллларын социализм noktai назарыннан[2] химая[3] берлән мәшгульләр. Монда безнең Русиядән украиналылар, эстоннар, латышлар, финнар, грузиннар, әрмәннәр, белоруслар иштирак итәләр[4]. Безнең төрек әквамыннан[5] беркем дә юк. Люцерн конференциясендә бер төрек социалисты гына була, ләкин аны да Интернационалга кабул итмиләр. Өчесендә дә французлар, немецлар арасында низаг бара. Большевиклык мәсьәләсе һәммәсендә дә мөзакәрә ителә. Русиягә хосусый комиссия җибәргә карар бирелә. Ләкин эшләнелми. Конференция солых мөзакәрәләренә тәзйикъ ясар өчен[6] эшләтелгән булса да, үзара кырылышу, кычкырышуга бик күп вакыт киткәнгә, һичбер төрле тәэсир итә алмыйлар. Беренче конференциядә сайланган вәкилләрне Клемансо*** кыска гына кабул итә, икенчесеннән барганнарны кабул да итми. Кич бүген шуның берлә үтә. Сухомлинов артыннан мин Тупчыбашевка**** мәктүб язам, ләкин ул аның Галимәрдан бәк булуын белми, дагстанлылар тәмамән белми. Берсе – доктор, имеш, берсе Мәскәү съездындагы Хәйдәр бәк булырга кирәк иде. Бүген шул арада

[1] Хариҗ өчен – читтәгеләр өчен.

* Берн – Швейцариядәге шәһәр.

** Люцерн – Швейцариядәге шәһәр.

[2] Ноктаи назарыннан – карашыннан.

[3] Химая – саклау.

[4] Иштирак итәләр – катнашалар.

[5] Әквамыннан – кавемнәреннән.

[6] Тәзйикъ ясар өчен – кысыр өчен.

*** Клемансо – Жорж Банжамен Клемансо (1841–1929), француз сәясәтчесе һәм дәүләт эшлеклесе, журналист, 1917–1920 елларда Франциянең премьер-министры, 1919–1920 елларда Париж тынычлык конференциясе җитәкчесе.

**** Тупчыбашев – Галимәрдан Галиәкбәр улы Тупчыбашев (1863–1932) – Азәрбайҗан иҗтимагый һәм дәүләт эшлеклесе, юрист һәм журналист, Беренче Дәүләт думасы депутаты (1906), Азәрбайҗан Демократик Республикасы парламенты рәисе (1918–1920).

өч кешенең Русиягә кайтып китәргә йөрүләре мәгълүм була. Бер мин алар артыннан мәктүб язмакчы булам. Әле Садрига* телеграмма биргән юк.

*9 нчы декабрь*

Безне бүген мондагы чех мәктәпләрендә мөгаллимлек итә торган, мондагы рус-чех мөнәсәбәтенең демократ канатына юлбашчылык итә торган Борис Владимирович Морковин** дигән кеше чәйгә чакырды. Мондагы рус-чех мөнәсәбәте мөзакәрәгә куелды. Монда руслар ике төрле кыйсемгә, иң дөресте, өч төрлегә бүленә икән. Берсе – монархистлар. Алар искедән монда эшлиләр, аларның «Русский клуб» дигән җәмгыятьләре бар, элгәре Иске идарә вакытында Русиядән ярдәм алып торганнар. Хәзер Одессадан хәзинә акчасын урлап килгән кешеләр ярдәм итәләр. Болар – чехлар, монархистлык фикере тараталар. Икенчеләре – монда сугыштан калган офицерлар, болар арасында төрле фикердәге кешеләр булса да, алар хәзер Колчак тарафдарларыннан акча алып торганга, алар да демокартиягә хилаф. Үзләреннән «Русское дело***»**** дигән газета дә чыгаралар. Бу газетага элгәре Борщов акча биргән. Болар чех хөкүмәте берлән шактый яхшы мөнәсәбәттә, өченчеләре – демократлар. Боларның мәркәзе Учредительное собрание әгъзаларыннан. Боларның «Едното*****» дигән җәмгыятьләренә башка нәрсәләре дә юк. Чех халкының демократ-социалист кыйсеме болар тарафында булса да, газеталары, фәләннәре юк. Күпләре зәгыйфь, шуңарга Морковин аерым бер газета чыгаруны мәслихәт күрә.

---

* Садри – Садретдин Низаметдин улы Максудов (1878–1957), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, юрист, Казан өлкәсеннән икенче һәм өченче чакырылыш Дәүләт Думасы әгъзасы.

** Морковин – Борис Владимирович Морковин (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы), рус нашире. 1904 елны Чехословакиягә күченеп китә, биредә рус-чех берлеге җәмгыяте сәркатибе булып тора, Прага университетында рус теле һәм әдәбияты буенча лекцияләр укый. 1919 елны Прагада оешкан «Наша речь» исемле рус эмигрант нәшриятын җитәкли.

*** Чыганакта кириллицада язылган.

**** «Русское дело» – 1919–1920 елларда Прагада атнасына 3 тапкыр рус телендә нәшер ителгән газета.

***** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

Без, ике татар, бер латыш, бер яһүд, бер хохол, өч рус, чех-рус мөнәсәбәте өчен шундый бер газетаны лязим табып, сметасын төзергә тапшырамыз. Сүз арасында руслар берлән чехлар арасындагы мөнәсәбәт безнең төрекләр берлән булган мөнәсәбәтемезгә караганда бик күп мәртәбә түбән икәнлеге, аларны берсенә берсен баглый торган һичбер рәтле мөәссәсәнең[1] юклыгы мәгълүм була. Шулай булса да, чехлар Русия өчен никадәр зур адымнар ясадылар, без төрекләр өчен бер эш эшли алмадык. Кичен без шул җәмгыятьнең ясаган концертына, рус музыкасына барамыз. Чехларның мәшһүр артисткалары берлән вә мәшһүр арфада уйнаучы хатын рус көйләрен уйный. Артисткада да әүвәлге кичәдәге ноксан[2] сизелеп тора. Арфада уйнаучы бик шәп. Кич берлән без мондагы рус колониясенең башларына һәм дә чехлардан безгә ярдәм иткән һәм итәчәк булганнарына бер мәҗлес ясадык. Мәҗлес бик күңелле үтте, һәммәсенең телләрен тиште, бик күбесенең эчендә безнең татарга каршы булган, мәхәббәт димим, ихтирам хисе дулап чыкты. Бүген Тупчыбашевка барырга мәктүб язган идек, ләкин рус китмәгәнгә җибәрелмәде әле.

## 15 нче дәфтәр

*20 нче декабрь*

Үткән ун көн эчендә һичбер төрле кулга тотарлык бер вакыйга булмады. Фәкать минем бүлмәм фәүкыльгадә[3] суык булганга, һичбер эш эшләп булмады. Франсәгә китү юлына күптән керештек, ләкин әле мәгънә бер тиенчә чыкканы юк, моннан Франсәгә китәр өчен, ике төрле юл бар. Берсе – Русия гражданы булу, ул вакытта мондагы Франсә консулы тагы үзеннән-үзе виза бирмәенчә, Парижга мөрәҗәгать итә. Аннан изен[4] килсә, рөхсәт бирә, килмәсә – юк. Бу юлны ныгытыр өчен, без Василий Васильевичтан безнең өчен кәфаләт[5] бирә торган берничә кешенең

---

[1] Мөәссәсәнең – оешманың.

[2] Ноксан – җитешсезлек.

[3] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[4] Изен – рөхсәт.

[5] Кәфаләт – поручительство.

адресын алып калдык. Боларның берсе – социалист министр Тома*. Икенче юл – рус гражданы булмаенча, үземезнең милли мөәссәсәмезнең вәкиле булып кына күренү. Моның өчен безнең шәһадәтнамә бик начар. Минекенең татарчасына, мәсәлән, Милләт Мәҗлесенең сәркатибемез мөһер басарга да онытkан. Тагы алар французча язылмаганга, тәрҗемәгә мохтаҗ. Икенчедән, минем шәһадәтнамәләрем Милләт Мәҗлесенең карары буенча бирелгән, ул вакытта немецлар берлә солых мәсьәләсе мөзакәрә кылынып ятканга, французлар Брест-Литовск мөзакәрәсенә** барырга җибәрелгән кеше дип уйлау ихтималлары бар. Фуадның шәһадәтнамәсе эшкә ярарлык. Ул үзе шуны тырыштырып, үзенә кирәгенчә иттереп язып алган. Моны һичбер лөзүме булмаган официальный представитель*** дигән сүзне дә керттергән. Бу безнең теге вакыттагы Фуад берлә Солтанбәкнең**** үзләрен рәсми иттереп, безне читтә калдырып китәргә теләмиләрме дигән шөбһәмезне тагы куәтли. Менә шул кәгазьләрдән бернәрсә оештырып, бер рәсми кәгазь чыгарырга үтенеп, чехларның хариҗия нәзарәтләренә[1] мөрәҗәгать иттек. Вәгъдәне бик тулы бирсәләр дә, әле бер эш тә эшли алганнары юк. Бер мәгънә чыгармы-юкмы, мәгълүм түгел. Икенче эш дигән нәрсә – рус акчаларын алыштырырга йөримез, монысы хакында да чехларның Кызыл салиб җәмгыятьләре ярдәм итәргә булсалар да, инде ике атна йөреп, фәкать өч мең сум алыштыра алдык. Вәгъдәләре алтмыш мең сумга иде. Егерменче декабрьдә мин бүлмәгә күчтем. Бүлмәм матур гына, җыйнак кына. Миче дә бар, яккач, йылы гына була. Монда эшләр бик озакка сузылса, бер эшкә керешергә кирәк.

---

* Тома – Альбер Тома (1878–1932), француз министр-социалисты, Халыкара хезмәт оешмасына нигез салучы һәм аның рәисе, тарихчы.

** 1918 елның 2 нче мартында Брест-Литовск шәһәрендә Советлар Россиясе һәм Үзәк державалар вәкилләре тарафыннан имзаланган һәм РСФСРның Беренче бөтендөнья сугышыннан чыгарылуын тәэмин иткән килешү.

*** Чыганакта кириллицада язылган.

**** Монда сүз Солтанбәк Мәмлиев турында бара булса кирәк. С. Мәмлиев Г. Шәрәф, Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар берлән берлектә 1915–1917 елларда Петроградтагы «Татар учагы» исемле студентлар җәмгыятен оештыручыларның берсе.

[1] Хариҗия нәзарәтләренә – эчке эшләр министрлыгына.

*21 нче декабрь*

Бүген мин беренче мәртәбә үз бүлмәмдә кундым, бүлмәм йылы булды. Җиһазлары пөхтә, пакь, бераз тынычланып, йылынып киттем. Кич берлә, Садри әфәндене эзләп, Финляндиягә срочный телеграмма бирдем. Бер мәгънә чыгармы-юкмы, Алла белә.

*22 нче декабрь*

Бүген безнең паспортларны чехлар бертөрле юлга куеп бирмәкчеләр иде, булдыра алмадылар. Бәйрәм кергәнгә, бөтен халык бәйрәм берлә мәшгуль. Боларның әле нәзарәтләре корылып бетмәгән, эшләре бик чуалчык кебек күренә. Пароходта боларның, забитларның[1], организовать итә белмәүләре никадәр күзгә ташланса, монда хөкүмәт әрбабының[2] аппарат корырга оста түгеллеге күренеп тора, шуның өчен боларның хөкүмәт аппаратлары халыкның фәүкыльгадә хәйранлыгы, үзенең дәүләтен ясар өчен һәртөрле корбанга разыйлыгы аркасында гына бара. Әгәр алай-болай һөҗүмнәр булса, үзләренең хәзерге хәлләрен саклар өчен, тартышырга тугры килсә, хөкүмәт аппаратларының эшкә яравы бик шөбһәле. Бүген Русиягә китүче инженер берлән мин Милли Идарәгә һәм дә Латыйф Яушевка, Гомәргә мәктүбләр яздым. Фуад Әмруллага, Исхакка язды. Иртәгә тагы бер тырыштырып, нәзарәтләренә җибәреп карыймыз да, булмаса, теләр-теләмәс, бәйрәм үткәнен көтәргә мәҗбүр буламыз. Безгә бу эштә Иван Михайлович Брушвит зур ярдәм итә.

*23 нче декабрь*

Кичәге «Право лиду»* («Pravalidu**») дигән мондагы социал-демократларның газеталарында инглизләрнең дә «Дейли Хроникал»*** дигән газеталарыннан күчергән бер Һарольд

---

[1] Забитларның – офицерларның.

[2] Әрбабының – әһелләренең.

* «Право лиду» – 1893–1948 елларда нәшер ителгән чех социал-демократик газетасы.

** Чыганакта сүз латин хәрефләре белән язылган.

*** «Дейли хроникал» – 1872–1930 елларда нәшер ителгән британ газетасы.

Вильямсның* мәкаләсен нәшер итте. Мәкалә безнең Идел буе татарлары хакында. Вильямс татарлар, большевиклар берлә Шәрык халкы арасындагы мөнәсәбәттә, славян милләте берлә ислам галәмен берләштерә торган, бергә баглый торган җеп ролен уйнаячагын һәм дә уеннарда большевиклар, татарларга таянып, Төркестан, Иран аша Һиндкә ихтилал[1] кертмәкче булалар. Һәм дә муаффәкъ булу[2] ихтималлары юк түгел, чөнки татарлар – төрек кавеменең иң алдагы кабиләсе, аларның зыялылары күп, аларда миллият фикере нык урынлашкан. Большевик аларның бөтен теләкләрен булдырырга вәгъдә биреп, үзләрен куллана, ди. Шуның берлән инглиз әфкяре гомумиясен[3] Һинд хакында, гомумән, Шәрык хакында, сак булырга чакыра. Бу мәкаләнең уе бик тугры, ләкин монда бик күп сүзләр әйтеп бетерелмәгән. Безнең большевикка каршы булган хәрәкәтемез бөтенләй томанда калдырылган, шуның өчен без шуны ачып, бер мәкалә язмакчы буламыз. Мәкаләмез[не] чехчадан русчага тәрҗемәгә куштык.

*24 нче декабрь*

Бүген Рождество бәйрәменең гарәфәсе[4] булганга, безнең паспорт мәсьәләмезне тагы бернәрсә дә эшләп булмады. Бүгенге газеталарның зур вакыйгасы – чехларның Париждан кайткан хариҗия назыйрлары[5] Бенешның** газетачылар берлән сөйләве.

---

* Монда сүз Британия лингвисты, журналист, разведка хезмәткәре, танылган полиглот (58 телдә сөйләшкән) Гарольд Вильямс (1876–1928) турында бара. Вильямс Россиядә «The Times», «Manchester Guardian», «The Morning Post», «Chronicle», «New York Times» газеталары корреспонденты булып эшли. Россиядә 14 ел яшәү дәверендә Вильямс бик күп сәяхәт кыла һәм фин, эстон, латыш, грузин һәм татар телләрен өйрәнә. 1914 елда Вильямс «Russia of the Russians» дигән китап нәшер итә.

[1] Ихтилал – бәйсезлек.

[2] Муаффәкъ булу – уңышка ирешү.

[3] Әфкяре гомумиясен – җәмәгатьчелек фикерен.

[4] Гарәфәсе – бәйрәм алды көне.

[5] Хариҗия назыйрлары – тышкы эшләр министрлары.

** Бенеш – Эдвард Бенеш (1884–1948), Чехословакиянең дәүләт һәм сәяси эшлеклесе. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Чехословакия бәйсезлеге өчен хәрәкәт лидерларының берсе, 1918–1935 елларда тышкы эшләр министры.

Ул ачыктан-ачык: «Антанта*, иттифакчылар иттифакы хәзер юк, ул бетте. Сәясәт идарә итә торган бәйнәлмиләл[1] һичбер куәт юк. Һәр мәмләкәт, һәр дәүләт үз ихтыярына тапшырылган, үз көченә генә куелган», – ди. Бенеш – чехларның үз сәясиләре: ул шулкадәр ачык сөйләргә батырчылык иткәч, хакыйкатән[2], иттифакчыларның көче беткән булырга кирәк. Төркия өчен, безнең өчен бу, – әлбәттә, шатлыклы бер хәбәр. Бу арада большевиклар, Балтик хөкүмәтләре берлән солых ясамакчы булып, берничә айлар мөзакәрәдә[3] булындылар, ләкин зур нәтиҗә тумады булырга кирәк. Җиденче Советлар съезды** иттифакчылар берлән дә солых ясарга карар биргәнгә, большевиклар, иттифакчыларга да солых ясыйк, дип мөрәҗәгать иттеләр. Ләкин иттифакчылар мөрәҗәгатьләрен кабул итмәделәр. Бүген кичен руслар берлән бергә үткәрдек, алар да бераз туйдырды инде.

*25 нче декабрь*

Бүген – Рождество бәйрәменең беренче көне. Урам тулы халык. Һәммәсе үзенчә яңа киемне кигән. Урамда галәбәлек[4]. Чиркәүләрдән халык актарыла. Ләкин бездәге кебек туктамый торган чиркәү кагуы бөтенләй юк, урамда исерек һич юк. Бөтен магазиннар, мөәссәсәләр[5] – бар да ябык, ләкин ашханәләр, гостинныйлар, каварный (каһвәханә)ләр вә бәнарныйлар (шәрабханәләр) – һәммәсе ачык. Урамдагы халык көне буе, төне буе көтү кебек. Театрлар, киноларда билет юк. Ләкин һичбер йирдә тәртипсезлек күренми. Болар шул бәйрәмнәрен дә тәртипле

---

* Антанта – Россия Империясе, Бөекбритания һәм Франция арасындагы хәрби блок, икенче исеме – «Тройственная Антанта». Германия, Австро-Венгрия һәм Италия дәүләтләрен бәйләгән «Тройственный союз»га каршы берлек буларак оеша.

[1] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[2] Хакыйкатән – чыннан да.

[3] Мөзакәрәдә – фикер алышуда.

** Җиденче Советлар съезды – 1919 елның 5–9 нчы декабрендә Мәскәү шәһәрендә уздырыла. Совет хакимиятенең беренче ел нәтиҗәләренә йомгак ясала. Съездда сугыш хәрәкәте, азык-төлек торышы, ягулык мәсьәләләре карала. «Тынычлык турында» резолюция кабул ителә. Съезд эшенә беренче тапкыр милли республикалардан вәкилләр катнаша.

[4] Галәбәлек – ыгы-зыгы, шау-шу.

[5] Мөәссәсәләр – оешмалар.

генә, тыныч кына, шау-шусыз гына үткәрәләр икән. Бәйрәмендә дә тормыш үзенең агышыннан чыкмый, үзе алган юлдан бара да бара икән. Боларда өйләргә барып, бәйрәм тәбрикләү юкка, чехлардан танышлар булса да, беркемгә дә бармадык. Көн буе урамда, каһвәханәдә, халыкның җыелган урыннарында үткәрдем. Кич берлән русско-чешский [...] кичәсенә бардым. Кичә бик начар булды, номерлары бик кыска. Бер Кырым татары егетенең русча биюе генә һәркемнең дикъкатен җәлеп итте. Мескен татар егете, үзенең халкы арасында хезмәт иткән кебек, үзенең биюе берлән рус-чех кабиләләрен берләштерергә хезмәт итә. Аны да, ни өчендер, үзе исеменнән түгел, рус исеменнән эшли. Үзенә Володя дигән исемен тагып, сәхнәгә чыга.

*26 нчы декабрь*

Бәйрәм дәвам итә. Шәһәр карап йөргәндә, иттифакый[1] тугры килгән бер таныш берлән чех театрына кердем. Уеннары – коруне вөста ахырларыннан бер манзара. Рухани хәят берлән дөньяви тормышның чарпышуы[2]. Пьеса шәп түгел, уйнаулары аннан да начар. Артистларда уйнап, бернинди җанландыру фикере һич юк, фәкать караучыны көлдерергә генә маташалар, шуның өчен һич лөзүме булмаган кыланулар берлән уенны бозалар, балаган характерын бирәләр. Мәсәлән, бер поп кирәкле-кирәксез чиркәү суын манулыклар вакытында сибә дә бөтен залны шаркылдатып көлдерә. Берсе, бик гырылдап йоклап, бөтен тыңлаучының рәхәтен китерә. Һичберсенең уенында табигыйлек юк. Кичкә таба «Германиядән бер рус инженеры килгән» дигәч, үземнең таныш-белештән берәр мәгълүмат чыгармаммы дип барган идем, бернәрсә белмәде. Кич берлән Фуад берлән каһвәханә[гә] чыгып киттек. Каһвәханәгә дигәнемез бер концертный зал булып чыкты. Бездән кергән өчен берәр крон алып, кешеләрне тыгызлап, безне сыйдырдылар. Зал шыгрым тулы. Ләкин һәммәсе дә кабаредагы кебек өстәл башында сыра, шәраб, каһвә, квас эчеп утыралар. Үзенең сәхнәсе, оркестры бар, сәхнәсендә артистлар чыгып төрлечә кыланалар. Халыкны бик көлдерәләр. Хосусан, хатын-кыз булып чыккан бер ямьсез ирнең,

[1] Иттифакый – очраклы.
[2] Чарпышуы – бәрелеше.

бик ябык булырга тиеш булган ирнең ачыклыгы[1] хушларына бик китте. Бөтен зал шаркылдады. Кунаклар гаилә-гаилә берлән, атасы-анасы, кызы-углы, балаларына кадәр килгәннәр. Илле биш, алтмыш яшьлек хатыннар, карт хатыннар, карт ирләр булган кебек, алты-җиде яшьлек балалар да бар. Барысы да өстәл янына тезелеп утырган, барысы да сыра, шәраб эчә, барысы да сәхнәдәге шаяру, уйнаудан[2] бик җентекләп карый. Оркестрының көенә җырлап, уенга катыша. Безгә, килеп кергәч тә, бертөрле уңайсызрак булды, үземезне ят итеп хис иттек, бара-тора күршеләремез берлән танышып китеп, бергә булдык, бергә көлдек. Халыкның бик күбесе эшчеләр: эшче хатыннары, эшче кызлары, эшче егетләре икән. Болар һәммәсе дә, бәйрәм итәр өчен, монда җыелганнар, шунда музыка тыңлыйлар, шунда сыра, шәраб эчәләр, шунда йырлыйлар, бииләр. Аларында шактый күп эчкәннәр булса да, әрсезлек юк. Хатын-кыз берлән мөгамаләләрендә һич киртәдән чыкмыйлар. Фәкать бер хатын гына күбрәк эчеп җибәреп, бик күп сөйләде, йырлады, биеде. Ләкин анықы да тәртәсеннән чыкмады. Чех хәятының бу почмагын рәхәтләнеп карап утырдык. Боларда тормыш авыр булгангамы, әллә тәрбияләреннәнме, бәйрәм каһвәханәгә чыккан. Өйдә кунакка барып, кунак чакырып, чәердәшеп[3] утыру урынына, каһвәханә хәяты урынлашкан. Гаилә хәяты кечкенә генә бер урын алган: кешенең өе, йорты, үзенең йоклый торган бүлмәсе генә булып калган. Гаилә хәятының эченнән адәм баласының тормышында бик зур роль уйный торган дуслык мәҗлесләрен, кардәш-кабилә берлән күрешү, утырышуларын, үзенең эшенә гаид[4] мәсьәләләрдәге мөзакәрәләр, киңәшләрен каһвәгә[5] чыгарып җибәрү – гаиләнең дәвамына, тәрбиясенә ничек тәэсир итә торгандыр, белеп булмый. Аннан гаилә файда эшлиме, зарар итәме, әлбәттә, тиздән генә әйтеп булмый, ләкин бу, бер яктан, шөбһәсез, гаиләне киң хәятта төрле таныш, таныш түгел халык арасында йөртеп, бер төрле тәрбиягә өйрәтә. Шуннан,

[1] Ачыклыгы – м о н д а: ачыклануы.
[2] Уйнаудан – уйнауны.
[3] Чәердәшеп – м о н д а: гәпләшеп, сөйләшеп.
[4] Гаид – караган.
[5] Каһвәгә – каһвәханәгә.

күп халыклы йирләрдә үзен үзе тота белергә ярдәм итә. Гаилә хәятының sleepingkar[1] булып калуы, шөбһәсез, гаиләнең элеккеге вакытлардагы милләт тәшкил итү, дәүләт идарә итүдә уйнаган рольләрен зәгыйфьләндерә. Гаиләнең матур якларын алып ташлап, аны сихриятеннән, елылыгыннан аны аерып алып, аның тәмен, татын бетерә. Капитализм дәверендә гаилә хәятының шул дәвергә керүе, бәлки, табигыйдер, мәҗбүридер, бу юлдан, бәлки, безнең гаилә дә читкә китә алмый торгандыр, ләкин безгә бу хәзер бик күңелсез булыр кебек күренәдер. Рождество булса [да], көннәр суык түгел. Һаман әле градус нольдән югары, кичә дүрт градус йылы бар [иде], бүген ике берлән өч арасында булды. Бездә инде бу вакытларда бик каты суыклар.

*27 нче декабрь*

Прага иртүк ап-ак кар эчендә. Һавада коры гына суык. Тәмам кыш булды, кар төште. Кары бездәге кебек шыгырдап тормаса да, аклыгы берлән күзнең нурын алмаса да, кар. Ул әллә ничек рухка тәэсир итә. Күңелне ача, дәртне арттыра. Мин көн буе карлы урамда йөрим. Көн буе үземне-үзем Мәскәүдә, Казанда, Идел буенда кебек хис итәм. Ләкин бу күңелдән өйгә кайту бик озакка бармый. Минем бәхетне көнләгән кебек, табигать карны да бик тиз ала. Кичкә таба саф, пакь ак кар төссез, сынсыз былчыракка әйләнә. Бәйрәм бүген дә дәвам иткәнгә, бер эш эшләп булмый. Мин бер-ике көннән бирле авырыйм. Тамакка суык тигән. Тамак кычынып тора, йөткертә. Мондагы юеш һава начар тәэсир итә булырга кирәк. 24 ендә мунчада үлчәндем. Киемсез-салымсыз җитмеш өч кило килдем. Унынчы апрельдә туксан кило идем. Костюмга ике кило ташлаганда да, унбиш кило кимегән булдым, ягъни утыз җиде кадак дигән сүз. Әгәр үлчәве алдамаса, бик ябыккан булдым. Мәшәкатьтән, климат үзгәрүдән генә килсә, зарар юк. Үзем дә белми торган берәр хасталыгым булмасын, дип шөбһәләндем. Яхшы бер доктор булса, күренеп карарга кирәк. Шул арада Русиягә ике кеше китә, шулар артыннан берничә мәктүб җибәрәм.

[1] Sleepingkar – монда: йокыда.

*28 нче декабрь*

Минем тамак авыртуым һаман дәвам итә. Кәефне бик ала. Бүген чехларның милли театрларына* (narodni divaido**) опера карарга барамыз. Бу чехларның, халыкның ярдәме берлән акча җыеп, үзләренең мөһәндисләре[1], рәссамнары, осталарының ярдәме берлән эшләгән беренче театрлары. Бинасы бик пөхтә, матур, биш яруслы иттереп эшләтелгән. Александринкадан*** кечкенә булса да, бик җыйнак иттереп, күп кеше сыя торган иттереп эшләтелгән. Пәрдәнең өстенә «Милләт үзенә» дигән сүз алтын берлән язылган. Көндезге театр, халык шыгрым тула. Операсы шәп түгел, исеме [...], оркестр бик зур, бик һәйбәт. Куелуы бик бай. Декорациясе, кием-салымы бик тулы. Ләкин артистлар котлылар түгел, араларында менә тавышы бар икән диярлек бер артист, бер артистка юк. Уеннары начар түгел, балетлары шактый һәйбәт, халык үзен бик тәрбияле тота. Һичбер төрле тавышкычкырыш юк, хәтта сөйләү дә ишетелми. Караучыларның иң зур бүлеге – хатыннар, ирләр күбрәк каһвәләрдә көнен үткәрәләр булырга кирәк. Бу театрны күргәч, безнең театрымыз юклыгы тагы хәтеремә төшә. Казанда «Ирек йорты» дигән өй мәйданга куелса да, шуннан билфигыль[2] бер эш эшләтелмәде. Никадәр тырыштырып карасак та, башлап эшләп китүче булмады. Аннан большевик, килеп, һәммәсен җимерде. Хәзер ни бардыр, ни юктыр – бер Алла гына белә. Безнең дә Казанда шунда бер театр эшләргә лязим иде. Исән-сау булсак, Русия[дә] мәдәни хәят берлән торырга имкян[3] туса, Иншалла, эшләрмез әле. Кич берлән безне мондагы эсерлар группасы кунакка чакырды. Бик күңелле үтте. Матур бер кич булды. Ләкин минем тамагым һаман эчне пошыра.

---

* Милли театр – Прагадагы опера һәм драма театры.

** Narodni divaido – латин хәрефләре белән язылган. Дөресе: Narodni divadlo v Praze.

[1] Мөһәндисләре – инженерлары.

*** Александринка – Александринский театр – Петербург шәһәрендәге Россиянең милли драматик театры.

[2] Билфигыль – чынлыкта.

[3] Имкян – мөмкинлек.

*29 [нчы] декабрь*

Бүген мин көн буе авырыйм, бик каты суык тигән. Кич берлән бөтен Европада шөһрәт тоткан чешский квартетның концертына барамыз. Дүрт мәшһүр музыкант егерме елдан бирле бергә концерт биреп йөриләр икән. Бүген рус музыкасыннан концерт бирәләр. Уйнаячак уеннарын[нан]: Чайковский*, Бородин**, Танеев***. Искиткеч оста уйныйлар. Танеев, Тамбов губернасы Әҗе татары булса да (хәзер дә Тамбов губернасында чукынмаган әллә никадәр мөселман Танеевлар булса да), әлбәттә, ул монда рус булып, аның тудырган музыка көйләре, дәртләре руснықы булып, чех-рус милләтләрен якынлаштырырга хезмәт итә. Никадәр безнең милли малымыз әрәм киткән, никадәресе әле дә әрәм булып ята. Кич берлән бик начар хис итеп, иртүк ятам. Фатирында үземезнең татар солдатларын очратып, алар берлән күрешергә вәгъдәләнәм.

*30 нчы декабрь*

Бүген иртүк бик авырып калынам. Күкрәк бөтенләй тоташтан каткан, тын алыр да хәл юк. Тамак өзелеп әрни. Баш авырта. Йокының рәте-чираты булмады. Тышка чыгарга да хәл дә юк, тагы өстәлүдән куркам да көн буе өйдә үткәрәм. Бер ятып, бер торып, көчкә көнне уздырам. Һичбер йирдән хат-хәбәр юк.

*31 нче декабрь*

Төн буе йоклый алмаенча борчылып чыктым. Кичтән, тир чыгарыр өчен, кайнар чәй эчеп яткан булсам да, иртәгә кадәр тир чыгара алмадым. Таң аткач кына, бераз йоклап киткәнмен. Уянганда, шыбыр су эчендә идем. Һәм дә баш бераз җиңеләй-

---

* Чайковский – Петр Ильич Чайковский (1840–1893), танылган рус композиторы, педагог, дирижер һәм музыка тәнкыйтьчесе.

** Бородин – Александр Порфирьевич Бородин (1833–1887), рус композиторы, химик-органик, җәмәгать эшлеклесе, медик. 1850 еллар ахыры – 1860 еллар башында Санкт-Петербург шәһәрендә рус композиторларының иҗади берлеге буларак оешкан «Могучая кучка» вәкиле.

*** Танеев – Сергей Иванович Танеев (1856–1915), рус композиторы, пианист, педагог, музыка теоретигы. П.И. Чайковскийның шәкерте.

гән иде. Көн буе томавы, йөткертүе кимемәсә дә, күкрәк катуы бетте. Тышка чыгарлык көч тә хис итмәгәнгә, курыкканга да бүген дә көнне-төнне өйдә үткәрдем. Бүген сәгать 12 ләрдә Яңа ел каршы алалар. Мин авырып ятам, хәерле булсын. Бүген безнең документлар хакында тагы хариҗия нәзарәтенә бардылар. Ләкин тагы бер мәгънәле җавап булмаган, чехлар эшләмимез, дип әйтергә оялалар булырга кирәк, яисә боларда алай тугры әйтмәенчә, кешене йөртеп-йөртеп, күңелне кайтарып, үзен биздерәләр булырга кирәк. Безнең өчен чехларның болай маташулары бик күңелсез. Безнең Парижга баруны тагы бик чуалта. Үзе тагы кулны бәйләп тота. Французлар, инглизләр русларга шөбһәле күз берлән караганга, болар да, үзләрен алар берлән бер дәрәҗәгә куяр өчен, шулай шөбһәләнгән булып маташалар. Вак халыкның яхшылыгы да вак, начарлыгы да вак. Эше дә кнедлики төсле чиле-пешле. Бераз терелсәм, Иван Михалычка ышанып йитмәенчә, үземез ныграк тотынырга кирәк. Сәгать уннарда мине Яңа ел каршы алырга чакырырга киләләр. Элгәре бармаска уйласам да, бик йөдәшкәч, төренеп-бөркәнеп китәм. Безнең руслар зур бер каһвәханәдә бер өстәл алганнар. Кысыла-посыла, шунда барып керәмез, каһвәдә халык шыгрым. Энә төшәргә урын юк. Һәммә өстәлдә – берничә гаилә, әллә никадәр хатын-кыз. Ләкин һәммәсе гаилә: хатыны, ире, агасы, энесе, кардәш-кабиләсе берлән бергә. Бар да шәраб эчә, бар да көлә, уйный. Музыка уйный башлагач, халыкның яртысы кушылып йырлый, хатыннар да бергә йырлаша. Уен, көлү – һәммәсе тәрбия даирәсендә, әдәпсезлек һич юк. Хатыннар арасында җилбәзәклек бер дә сизелми. Хатыннарның өс-башлары пөхтә генә булса да, өч-дүрт йөз хатын арасында бер генә дә шәп иттереп, безнең Русиядәге кебек киенгән туалет юк, һәммәсе уртача. Унике җитә, утларны сүндерәләр. Бөтен халык күршеләрендәге хатыннар берлән үбешәләр, кычкырышалар, көлешәләр, чыр киләләр. Менә ут тагы ягыла. Бер өстәлдәге ирләр үзләренең дамаларын, үзләренең иптәшләренең хатыннарын, кардәшләрен, көчләп-көчләп үбеп йөриләр, дамалар каршы килгән булып маташалар да, үзләре бик ихластан үбешә бирәләр. Халык шактый исерә. Йырлау, көйләү күбәя. Безнең өстәлдә бер хатын да булмаганга, безнең күршеләр безгә дикъкать итәләр. Сөйләшәмез, безне кызганалар, без – руслар дигәч, тагы дуслык

күрсәтәләр. Сәгать икеләрдә торып чыгамыз. Каһвәханәнең ишек төбе пар-пар егетләр, кызлар берлән тулы. Күбесе ачыктан-ачык үбешә. Үтеп бара торган егетләр, кызлар, хатыннарны тоталар, Яңа ел [берлән] котлап үбә бирәләр. Тегеләр чыр килә, көлә, сөенә. Урамда да халык шыгрым тулы. Анда да үбешү, көлешү, хатын-кыз черләве. Мин бөркәнеп, өртенеп кайтып китәм. Тамак һаман авырта. Ютәл һаман ашый. Быел Яңа елны Прагада үткәрдем, киләсе елга үз илемдә үткәрергә язгандырмы, юктырмы – бер Алла белә. 19 нчы ел минем өчен мәхәббәтсез ел булды. 20 нчесе инде бәхетле булсын иде. Эшләр юлга китеп, өсткә алган милли вазифаны үтәп, үз хәятымызга кайтып, эшкә тотынасы иде инде.

## 1920 ел

*Беренче гыйнвар*

Суык тиюем һаман кимеми. Йөткерү бетми, тавыш юк, күкрәк авырта. Тышта фәүкыльгадә юешлек булганга, миңа һич чыгарга ярамый. Чыктым исә, буылып-буылып йөткерергә тотынам. Бронхит алдыммы? Һичбер төрле эш эшләп булмый. Рух та бик төшенке. Максатка таба бер генә адым да атлый алганымыз юк. Чехларның хариҗия нәзарәтләре, көн дә бер нәрсә табып, безне алдаштырып йөртә. Яңа ел көне ничек үткәнен күрми калдым, чөнки урамда йөрергә миңа бик читен, һава җитми, буылам. Бүген мондагы татар солдатлары берлән күрешергә булган идек, мин бара алмадым. Фуад барып килде: «Бик аңсыз, мәктәп күрмәгән солдатлар, – ди. – Үзләре монда торып, бертөрле азрак шомарганнар, – ди. – Русиянең хәлен бик сораштылар», – ди. Күңелле бернәрсә дә булмаган. Көндез «Сатылган бикәч» дигән операга бардык. Бик матур опера, халык тормышыннан бик матур күренешләр бар, музыкалы нәрсә. Простой киемдәге балетлары да бик һәйбәт, артист-артисткаларның тавышларны гына начар. Гомумән, бик матур хис калдырды. Шул паспорт мәсьәләмез юлга куелманганга, без матбугат галәме берлән дә танышып, белешеп йөри алмыймыз. Үземезнең фикеремезне сөйләү, ачу тагы паспортымызга зарар итәр дип куркып торамыз. Бу халәт бик арыта, эчне пошыра. Бераз терелсәм, башка-

чарак юлга керешергә торам. Париждан хат булмады. Берлин да безнең мәктүбләргә җавап бирмәде. Берлинга китүче юк, почта берлән хат язарга цензурыннан бераз шөбһәләндем. Боларга бер дә ышанырга ярамый.

2 нче, 3 нче гыйнварларда минем авыруым һаман дәвам итә. Өйдә утырам, тышка чыгарга куркам.

*3 нче гыйнвар*

Бүген безнең паспортларыбыз хакында бертөрле күңеллерәк хәбәр бар. Хәрбия нәзарәтенең бер даирәсе шуларны бертөрле рәтләп бирмәкче була. Шуның өчен документларның франсача тәрҗемәсен әзерләп бирдек. Акча мәсьәләсе хәл ителә алмады. Хәзер рус акчасының курсы бераз менә башлаган, имеш, шуңарга алыштырмый торырга кушалар. Ләкин безгә акча кирәк. Париждан хәбәр юк. Үзем почта берлән генә Берлинга мәктүб яздым. Мин терелеп киләм, ютәл бетмәде әле.

*4 нче гыйнвар*

Бүгенге шатлыклы хәбәрләргә караганда, Иркутскины эсерлар забыт иткәннәр[1]. Колчак*, галәйһил-ләгънә, җәһәннәмгә киткән, бөтенләй югалган. Чехлар Колчакның поездын туктатып, аның янында бергә бара торган алтынны үзләренә алганнар. Бу алтын – безнең Казаннан алынып чыккан алтын. Максудлары үз илләренә китерүме-түгелме, киләчәк күрсәтер. Икенче хәбәр, Троцкийны**, имеш, Нарва фронтында атып үтергәннәр. Монысы ялган булу ихтималы да бар. Мин терелеп киләм, ләкин әле суык тию чыкмый. Без килгәнгә тәмам бер ай булды. Бер эш эшли алмадык.

---

[1] Забыт иткәннәр – басып алганнар.

* Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус дәүләт, сәясәт һәм хәрби эшлеклесе, адмирал, галим-океанограф. Тарихка Аклар хәрәкәтенең җитәкчесе буларак кереп калган.

** Троцкий – Лев Давидович Троцкий (Бронштейн) (1879–1940), рус революционеры, совет дәүләт, сәяси-хәрби эшлеклесе, троцкизм идеологиясенә нигез салучы.

*5 нче гыйнвар*

Һичбер язарлык нәрсә булмады. Эч поша, Франсәгә барып җитә аламызмы, җитсәк, бер эш эшли аламызмы-юкмы, Алла белә.

*10 нчы гыйнвар*

Бүгенгә кадәр һичбер төрле язарлык эш булмады. Тик көттек тә тордык. Бүген безнең кәгазьләремезне Чех җөмһүриятенең хәрбия нәзарәте Франсәгә, тәрҗемә итеп вә шул тәрҗемәне тасдыйк итеп[1] йибәрде. Димәк, кәгазьләремез бертөрле юлга керде. Инде французлардан виза сорарга калды. Әүвәлесе хакында да бертөрле ярдәм итәргә булалар, бәлки бер мәгънә чыгар, ничек булса да, берәр айсыз моннан китеп булмый. Париждан да, Берлиннан да, Истанбулдан да һичбер төрле хәбәр юк. Большевиклар һаман җиңеп киләләр. Бүгенге хәбәргә караганда, Одессаны алганнар. Деникин да бетә, димәк. Инглиз газеталарының язуына караганда, Йосыф Акчура, Әхмәд Агаев Мәскәүдә большевиклар берлән эшлиләр. Большевикларның фикерен Шәрыкка таратырга хезмәт итәләр, имеш. Бәлки, хезмәтләре дөрестер, ләкин большевик фикерен тарату өчен түгел, бәлки төреклеккә хезмәт өчен, төрек галәме өчен. Бу бәхетсез дәвердә төрек хезмәтчеләре төрлесе-төрле тарафта таралып беттеләр. Үзләренең байракларын мөхафәзә итә алмагач[2], төрле агымнар берлән бергә барып, аларга таянып, үз максатларына бармакчы булалар. Учредительное собрание янына җыелып, шуның байрагы астында хезмәт итмәкче булдык. Ләкин рус халкының патшасына халкыннан бер мәгънә дә чыкмады. Ул үзенең ике йөз ел гыйбадәт иткән Учредительное собраниесен сакларлык дәрәҗәдә көчле булмады, аның хулиганы аны җимерде. Хәзер болар большевик берлән бергә барып, төреклеккә хезмәт итмәкче булалар. Боларны тагы ни һәлак итәчәк – Алла белә. Фәкать үз көчең булмагач, кеше көче берлән бер кая барып булмый. Үз халкының оешкан көче булмаса, оешырлык куәте булмаса, әрәм-шәрәм, төрле дошман агымнарга хезмәттән уза алмыйсың. Алла аларга да ярдәм бирсен, безгә дә. Һәр ни исә алар большевик берлән хезмәт ит-

[1] Тасдыйк итеп – раслап.
[2] Мөхафәзә итә алмагач – саклый алмагач.

сәләр дә, шөбһәсез, безнең татар хулиганнары кебек үземезнең барлы-юклы милли барлыгымызны бетерергә көчләрен сарыф итмәячәкләрдер.

*11 нче гыйнвар*

Бүгенге вакыйгалар тагы зуррак. Большевиклар Таганрогны һәм дә Ростовны алганнар. Деникин тәмам бетте дияргә кирәк. Себердә, Иркутскида эсерлар инкыйлаб ясап, Колчак вә аның яраннарын һәммәсен тәүкыйф иткәннәр[1]. Үзләре аерым бер Себер хөкүмәте төзегәннәр. Максатлары – большевиклар берлән аңлашып, реакциягә каршы бер социалист сафы ныгыту, имеш. Ни генә булса да, большевизмның җиңүе, Колчак, Дутовның эштән чыгуы безгә, милли ноктаи назардан караганда, әлбәттә, файдалы. Ләкин большевикның шулкадәр куәтләнүе, хосусан, эченә шулкадәр күп рус генералы тутырган большевизм эченә рус империализмасын яшергән агымның куәтләнүе, шөбһәсез, безгә зарарлы. Бу большевизм бара-бара ачыктан-ачык Петр Великийның* руслыгына барып чыгу ихтималы бик якын, ул вакытта бөтен кечкенә милләтләрнең хәле бәрбад булган[2] кебек, без тагы изелеп калачакмыз. Көннәр һаман елы, градус һаман сыйфырдан[3] югары. Минем ютәл бетмәсә дә азайды. Бүген-иртәгә Русиягә китә торган русларның хәлләре мәгълүм булачак иде. Бакалым[4], ни булыр. Газеталар һаман Шәрыкта большевизмны бик куерталар. Инглиз газеталарының язуына караганда, Әнвәр** Иранда, имеш. Большевиклар Бохара берлән мөнәсәбәткә кереп, алар берлән мөгаһадә[5] ясашканнар булырга кирәк. Төркестанда йирле гаскәр инглизләрне һаман куалар; «Таймс»ның язуына караганда, татар җөмһүрияте большевиклар

---

[1] Тәүкыйф иткәннәр – кулга алганнар.

* Петр Великий – Петр I (1672–1725), 1682–1721 елларда Россия патшасы, 1721–1725 елларда Россия патшасы булып торган атаклы хөкемдар.

[2] Бәрбад булган – җимерелгән.

[3] Сыйфырдан – м о н д а : нольдән.

[4] Бакалым – карарбыз.

** Әнвәр – монда Төркиянең сәяси һәм хәрби эшлеклесе, «Яшь төрекләр» хәрәкәтенең актив көрәшчесе, хөррият каһарманы Әнвәр бәк (1881–1922) турында сүз бара.

[5] Мөгаһадә – килешү.

тарафына чыккан, имеш. Бу, әлбәттә, безнең Татар-Башкорт җөмһүрияте хакындагы сүздер инде. Безнең Милли Идарә кайда калды икән? Аның да хәле шәп түгелдер.

*12 нче гыйнвар*

Бүген әхваль тәмам башкарды[1], мин Париждан мәктүб алдым. Ни күзең берлән күрәсең, мәктүб Садри Максудидан. Бу безнең өчен фәүкыльгадә бер табыш булды. Бердән, тәмамән югалган бер кешемез табылды, икенчедән, безнең солых һәйәтенә бик зур кыйммәт бирә тора торган, милли хәрәкәтнең башындагы милли идарәнең рәисе һәм дә Европа галәмендә танылган Садри Максуди көтмәгән йирдән килеп чыкты. Бу хәбәр шулкадәр рухка яхшы тәэсир итте, солых сәфәре башланганнан бирле инде унбер ай ярым эчендә мондый көнне хәтерләмим. Моңганчы безнең солых сәфәремез һаман әллә нинди мәгънәсез, кирәкмәгән киртәләргә төртелә иде. Бөтен адымнарымыздан бер мәгънә чыкмый, мәктүбемез, телеграммамыз буш, җавапсыз кала иде. Бу беренче мәгънәле көн булды, Иншалла, моннан соң шул рәтле юлга кереп китмәсме? Мин Садрины инде бит бер елдан бирле эзлим. Истанбулга Токиодан телеграмма берлән сорадык. Истанбулга, Кырымга әллә ничә телеграмма бирдек, мәктүбләр яздык. Финляндиягә телеграмма бирдек, һич берсеннән бер мәгънә чыкмады, менә хәзер көтмәгәндә, үзеннән-үзе Садри килде дә чыкты. Мәктүб ашыгып язылган, алай да шактый күп мәгълүмат бар. Берсе, Садри үзе Финляндиядә озак кына торып, Франсәгә зур мәшәкать берлән виза алып, 1918 елның ноябрендә тырыша башлап, фәкать май башында гына рөхсәт алып, Парижга килеп чыккан. Шуннан бирле Парижда безнең Токиодан Чайковскийга (Николай Васильевич) биргән телеграммамызны белеп, Гомәр берлән бергә виза хакында тырышып, өченче августта, Токиодагы Франсә сәфарәтенә виза бирү хакында телеграмма җибәрткән, ләкин безне ул вакытта ахмак телеграмма берлән Харбинга чакырган булганга, без аннан файдалана алмаганмыз. Киткәнчегә кадәр шуннан берни белешә дә алмадык. Габидуллага шул хакта Япониядә белешергә кушкан идем, җавап кил-

[1] Башкарды – башкача, үзгәрде.

мәде. Йосыфны* Садри май башларында Швециядә күргән, аннан соң мәгълүм түгел. Димәк, Йосыф Русиядә дә дигән хәбәр бигүк дөрес түгел булу ихтималы бар. Садри солых конференциясенә безнең милли теләкләремез хакында меморандум язып биргән. Үзе Финляндиядән алган акча берлән яши икән. Димәк, акча мәсьәләмез ул кадәр мөшкел булачак түгел. Виза алырга берничә юл күрсәтә. Монда бернәрсә дә чыкмаса, аның юлын тотармыз. Теге Русиягә китүчеләрнең хәлләре тагы чуалды. Поляклар аларга виза бирмиләр. Безнең кәгазьләрне тагы бер мәртәбә күчереп язарга булдылар. Берәр көннән Франсә сәфарәтенә күтәреп барачакмыз.

*15 нче гыйнвар*

Бүген безнең Русиягә китүче танышлар кайтып киттеләр. Алар артыннан мәктүб язып булмады, чөнки алырга курыктылар. Берничә адрес бирдем. Үземезнең хәлне андагы дус-ишкә сөйләргә куштым. Икенчедән, андагы әхваль хакында мәктүб язуларын үтендем. Мин инде Советский Русиядән киткәнгә ел ярым булды. Шул мөддәттә[2] һичбер кемнән, һичбер хәбәр ала алмадым. Мәскәү ни хәлдәдер? Мәскәүдәге безнең «Ил» матбагасы ни хәлдәдер? Безнең милли даирәләр нишләп тора торгандыр, үземнең гаиләм ничектер? Әниләр исәнме, кызым исәнме, сеңелләр, борадәрләр[3] исәнме? Һичнәрсә мәгълүм түгел, шуларны, мөмкин булса, белешеп, хат язарга үтендем. Һәм дә андагы дус-ишкә безнең адресларны биреп, мотлакан[4] безгә мәгълүмат бирергә лязимлыкны аңлатырга куштым. Кайтып җитсәләр, безнең хакында, февраль ахырларында, Мәскәүдә мәгълүмат булырга тиеш. Бәлки, шуннан тизлек берлән җавап та бирсәләр, бирә алсалар, язга таба, җәй башларына берәр хәбәр дә алырмыз, бәлки, җәй көне кайтып китәргә дә мөмкин булыр. Инде өйгә кайтасы да бик килде. Франсәгә китү мәсьәләмез әле бертөрле дә хәрәкәткә кермәде.

---

* Йосыфны – монда Йосыф Акчура (1876–1935) күздә тотыла.

[2] Мөддәттә – вакыт аралыгында.

[3] Борадәрләр – ир туганнар.

[4] Мотлакан – һичшиксез.

*16 нчы гыйнвар*

Бүген озын иттереп Садрига хат язып җибәрдем*, әхваль берлән таныштырдым. Аның Финляндия берлән, бәлки, мөнәсәбәте бардыр, бәлки, аның гаиләсе хакында, эчке Русиядәге эшләр хакында мәгълүматы да бардыр. Ләкин Себер хакында, шөбһәсез, бер мәгълүматы юктыр, шуңарга күрә ул хат аңарга да күңелле һәм дә файдалы бер нәрсә булып чыгар.

*17 нче гыйнвар*

Бүгеннең иң күңелсез бер эше мине полициягә чакыру булды. Кичә бик мәхәббәтсез ике полис[2] кереп, миңа повестка биреп чыктылар, иртәгә сәгать унда полициягә барырга тиешмен. Мәсьәләнең нидән гыйбарәт икәнлеген филҗөмлә беләм, мондагы Комучның дахилия назыйре булып торган Климушкин дигән бер ахмак рус төрмәләр карарга гадлия нәзарәтеннән рөхсәт алган. Үзенә генә күңелсез булыр дип, мине дә кушкан. Мин сау түгелгә бардым. Ләкин, шулай да, шул кәгазь бөтен полиция даирәләрен астын-өскә китергән. Эшсезлектән эче поша торган полициягә яңа бер эш табылган: шул төрмә карарга баруны чехларның төрмәдә ята торган большевиклары менә дигән бер ахмакны чыгарырга план корыла дип тәфсир иткәннәр. Без, имеш, үземездәге большевикка бер дә туймаган да, боларның әер-чөер большевикларын чыгармакчы булып йөримез, имеш. Полиция бөтен дөньяда да үзенең шундый ихтирагатын[3] наданлык, ахмаклыкка бина итә бит. Мондый чех кебек кечкенә милләтнең полициясе үзенең зур иптәшләреннән артта калмас өчен, ахмаклыкның очына кадәр бара, имеш. Большевик берлән ачыктан-ачык хөкүмәт ясап, гаскәр ясап сугышкан кешеләр мәмләкәтеннән качып килеп, монда зәгыйфатның соңында чехларның большевикларын коткарып йөрсеннәр, имеш – мантыйк, диген. Ләкин никадәр мозаффар[4] булса да, шулкадәр күңелсез. Иртә берлән Иван Михайлович берлә бардык вә безгә тиз кар-

---

* Садрига хат язып җибәрдем – Әлеге хат белән Г. Исхакый «Әсәрләр»енең (2013) 14 нче томыннан танышырга мөмкин (Б. 20).

[2] Дөресе: полицейский.

[3] Ихтирагатын – уйлап чыгаруларын.

[4] Мозаффар – өстен калган.

точкаларны биргәч, бик тиз полицмейстерлар кабул итте һәм дә әллә нинди мәгънәсез сөальләр бирергә тотынды. Ләкин минем карточкадагы татар-төрек милләтенең вәкиле дигән сүз үзенә дә уңайсыз тоела. Паспорт язмаганга чакырдым, диде. Ул да язылган булып чыкты. Ниһаять, бер төрле гафу үтенгән тарызда эшне бетерде. Ахыры килеп чыкмаса ярый инде.

## 16 нчы дәфтәр

*20 нче гыйнвар*

Һаман яңалык юк. Безнең паспортларымызга чехлар дипломатический виза куярга булганнар иде. Ни булгандыр, белешә алмадык. Безнең эшне йөртә торган кешене күрә алмадык. Прага да туйдырды инде. Тизрәк Франсәгә барасы иде. Анда хәзер Төркия һәм дә Русия мәсьәләләре каралырга тора. Бәлки, берәр эш эшләп булыр иде. Бу карарсыз йөрүдән бик туйдым инде.

*21 нче гыйнвар*

Бүген безнең паспортларымызга дипломатический виза куйганнар. Димәк, Франсәгә китүнең зур бер адымы эшләнгән. Иртәгә, насыйп булса, француз консулханәсенә барып, виза сорыймыз. Вә визаны шул көнне үк алырга өмидемез бик зур. Бүген безгә, консулханәнең кешеләренә, төрле мәктүбләр китерәләр. Бакалым, ни булыр.

Акча мәсьәләмез бик начар. Иван Михайлович* безнең акчаларны алыштырырга һаман вәгъдә кылса да, бер эш тә эшли алмады. Үзе шактый күп бурычка алды. Без аларны да шул алыштыруы өчен, комиссионный кебегрәк итеп бирә килгән идек. Инде ул акчаларны нишләрмез, Алла белә.

Үземнең кәефем яхшы. Мигъдәм тынычрак юлга керде. Көннәр бу арада тагы юеш. Без килгәннән бирле, әле градус сыйфырдан[1] түбән төшкәне юк. Кыш инде үтеп бара.

---

* Иван Михайлович – Иван Михайлович Брушвит (1879–1946), эсер, Учредительное собрание әгъзасы, Комуч хакимиятендә финанс министры.

[1] Сыйфырдан – м о н д а : нольдән.

*22 нче гыйнвар*

Безгә бүген француз консулында мөрәҗәгать ителәчәк кешеләрне кич берлән генә китерделәр. Һәм дә харижия нәзарәтендә[1] иртәгә иртә берлән генә телефон берлән сөйләштерергә булганнар. Шуның өчен бүген консулханәгә бара алмадык. Иртәгә сәгать 11 дә барырга вәгъдә иттек. Тәрҗеман[2] иттереп, Франсәдә унсигез ел торган Белин исемле бер кешене алып барамыз. Ләкин йомшаграк кеше, очлап чыга алса ярый. Безнең максат бит – үземезнең руслыгымызны күрсәтмәенчә, төрек-татар милләтенең вәкилләре сыйфаты берлән виза алу. Чехлар шул мәсьәләдә шактый зур ярдәм иттеләр. Безгә милли паспорт ясатып бирделәр. Шуңарга дипломатический виза куйдылар. Инде французлар нәрсә эшләрләр? Садри* анда булганга баруымыз тәэмин ителгән кебек булса да, консул үзе виза куймаенча, Парижга мөрәҗәгать итәчәк булса, тагы сузылачак.

*23 нче гыйнвар*

Бүген иртүк торып, юынып, киенеп, Фуадны** алырга киттем. Аның шундый вакытта соңга кала торган гадәте бар. Кызуландырып китереп, вәгъдә ителгән каһвәханәгә китәмез. Анда безне Белин көтеп тора. Тугры ук Франсә консулханәсенә китәмез. Безгә бирелгән кешеләрне сорыймыз. Ул – бер чех, аз русча да белә, французча да сөйли дигәннәр иде. Ул русча бер дә белми, французча бик начар сөйләүче булып чыга. Аңарга телефон кагарга[3] булган түрә телефонда какмаган. Без эшемезне аңлатамыз да, ул безне консулга алып китә. Анда консул янына кереп, бераз торып чыккач, шунда көтеңез дип, чыгып китә. Безгә бу мөгамәлә кызыграк тоела. Мин консулга карточкаларымызны кертергә тәкъдим итәм. Безнең тылмач, сез, ди, юк, хәзер барыбер кабул итәчәк, ди. Ун-унбиш минут үткәч, безне консул аягүрә генә кабул итә. Керү берлән, һичбер безнең сөйләгәнне көтмәенчә, виза соравыңызны кәгазьгә язып кереңез, ди. Шу-

[1] Харижия нәзарәтендә – тышкы эшләр министрлыгында.
[2] Тәрҗеман – тәрҗемәче.
* Садри – Садри Максуди (1878–1957), дәүләт эшлеклесе, сәясәтче.
** Фуад – Фуад Туктаров.
[3] Кагарга – шалтыратырга.

ның берлән сүзне бетерә. Безнең тәрҗеман уйларга да өлгерми, каушап кала. Без дә аптырап каламыз. Бердән, бу кадәр суык мөгамәләне көтмәгән идек. Икенчедән, сүз әйтергә бирмәс кадәр тупас булмавын көтәргә хакым бар иде[ме]? Мин паспортны чыгарып күрсәтә башлыйм. Тәрҗеман, «Юк, юк, кирәкми» дип, безне ашыктырып алып чыга. Чыккач кына, безгә консулның сүзләрен аңлата. Без тагы катып каламыз. Ай ярым үземезнең паспорттан рус исемен бетерергә маташтык, шуңарга муафикъ та булдык. Шул рәсми кәгазьләремездән файдаланырга вакыт җиткәч кенә, тәрҗеманның ахмаклыгы хакында тагы рус булып чыктык. Андый булгач, безгә нигә ул кәгазьләр берлән маташырга иде? Нигә ул кадәр вакыт әрәм итәргә иде? Париж аша безнең бит виза ала алмаячагымызга хәзер иманымыз камил. Бу ахмаклык безнең кәефне фәүкыльгадә җибәрә. Яңадан кереп, тагы сөйләшергә тәкъдим итәм. Ул кабул итми. Көчкә генә тиремә сыеп, өйгә кайтам. Бу ни булды дип, төрле моталәгаларга[1] төшәмез. Берсе, теге хариҗия нәзарәтенең телефон кагам дигән кешесе телефон какмаган. Икенчесе, теге француз консулының чех түрәсе, безнең сүзне аңлап бетермәенчә, әллә ниләр бутаган. Өченче, тәрҗеман безне, каушап, руслар дип куйды. Шуны төзәтергә төрле-төрле планнар корамыз. Берсе, Франсәнең лигансионының рәисе барып, үзе сорарга, ахырдан, тагы берничә кеше берлән киңәш итешеп, иртәгә бер кешене хариҗия нәзарәтенә барып, теге чиновниктан тагы телефон кактырырга карар итәмез. Үземез теге консулның сораган кәгазен язып барырга, бу юлы чынлабрак сөйләшергә буламыз. Иртәгә шуның өчен берничә кеше берлән берничә йирдә күрешергә вәгъдәләшәмез. Ни булып чыгар?

*24 нче гыйнвар*

Бүген иртүк без үз эшемездә. Сәгать 10 да бер каһвәханәдә хариҗия нәзарәте берлән сөйләшә торган кешене көтәмез. Ул нәзарәттә беркемне очрата алмаган. Каһвәханәдән телефон кагарга тотына. Тугры китерә алмый. Ун берлән унбер арасында үзенең эше бар. Ул тагы телефон кагарга булып, аерыламыз. Сәгать 11 дә тәрҗеманга башка бер каһвәханәдә вәгъдәләшкәнмез.

[1] Моталәгаларга – эшне төрле яклап тикшерүләргә.

Аны көтәргә китәмез. Тәрҗеман да, теге кешемез дә килә. Телефон берлән, харижиянең түрәсе берлән сөйләшкән. Ул кичә вәгъдәсенә вафа итмәгән[1], үзе сүз биргән консулның түрәләренә телефон какмаган. Киңәшләшеп, Франсәнең лигансионының башына[2] китәмез. Ләкин без барганда шәйх (рәисе) өйдә булмый. Безне сәркатип кенә кабул итә. Мөгамәләсе нәзакәтле. Утырта, сөйләнә, аңлый. Безнең кәгазьләремезне карый. Рәисе өйдә булмаганга, иртәгә якшәмбе булганга, безне дүшәмбе көн сәгать 2 ½ ләргә чакыра. Күрешеп чыгып китәмез. Мин, өйгә кайтып, Садрига мәктүб язам. Безнең тәрҗеман булган кеше иртәгә Парижга китәчәк. Әгәр виза алган булсак, аны берәр атнага калдырырга ниятләнгән идек. Инде тагы эш сузылганга, әлбәттә, аны алып кала алмыймыз.

Бүген – 24 нче гыйнвар. Мин үткән елны шул көнне солых сәфәренә чыгып киткән идем. Инде ел тулды. Әле һаман барам. Кайчан барып җитәрмез? Бер Аллага гына мәгълүм. Бүген иртә берлән һава салкынча булды. Градус сыйфырдан түбән иде. Аяк асты көн буе коры булып үтте.

*25 нче гыйнвар*

Бүген дә һава салкынча. Иртә берлән ике градус суык бар. Иртүк мин бер таныш чех берлән шәһәрне карарга чыгып китәм. Иң әүвәл боларның hrad* (град** кальга) дигән тау башына салынган иске калаларына барамыз. Монда – иске чех падишаһларының сарайлары. Монда – бик матур иттереп челтәрләп, 14 нче гасырда салынган Святой Вита чиркәве***. Хәзерге көндә чехларның иң күп нәзарәтләре шул иске сарайларда. Рәисе җөмһүр Масарик**** та шунда тора. Чиркәү бик зур тәэсир калдыра. Манараларның эшләнүе гаҗәп матур. Чехларда күптән үк ма-

---

[1] Вәгъдәсенә вафа итмәгән – вәгъдәсендә тормаган.

[2] Лигансионының башына – лига җитәкчесенә.

* Чыганакта бу сүз латин хәрефләре белән язылган.

** Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

*** Святой Вита чиркәве – Прагадагы Рим-католик соборы, готик архитектура үрнәге, Чехиянең иң зур һәм мөһим чиркәве.

**** Масарик – Томаш Гарриг Масарик (1850–1937), чех фәлсәфәчесе, Австрия-Маҗарстанның һәм Чехословакиянең дәүләт эшлеклесе, Чехословакиянең беренче президенты (1918–1935).

турлык хисе тирән булган, күрәсең. Эчендә бик күп тәреләр, бик күп чех әүлияларының, чех падишаһларының каберләре. Болары миңа, әлбәттә, зур тәэсир калдырмый. Аннан чыгып, технический музейга керәмез. Монысы – гади музей. Ләкин бер бүлмә әллә никадәр чех асаре кадимәсенең[1] модельләре берлән тулы. Монда чех театрының моделе дә бар, сарай моделе дә бар, чиркәүләр моделе дә бар. Бик матур иттереп эшләтелгән. Чехстанның суларының агу юллары да бар. Музейда бик күп бала-чага. Рәхәтләнеп карап, үзләренең мәмләкәтләренең хәзерге хәле, элеккеге хәле берлән танышып йөриләр. Аннан чыгып китеп, матур юллардан үтеп, тау башына эшләтелгән башнядан Праганы карарга барамыз. Монда юллар матур, бер буйдан парк, бакча, җәй көне бу йирләр бик матур булырга тиеш. Башняга машина берлән менәмез. Машина ике минут ярым менә икән. Аннан бөтен Прага уч астында кебек күренергә тиеш. Ләкин Прага ягында томан булганга, суның бу ягы гына күренә. Манзара бик матур. Прага – табигать ягыннан бик матур шәһәр. Аннан төшеп, тагы бормалы-бормалы юлларыннан түбән таба китеп, шәһәрнең Насмеховка дигән ягына барамыз. Анда начар гына бер ашханәдә икмәксез генә аш ашап, елганың теге ягындагы Высший градны (бөек кальга) карарга китәмез. Трамвайдан трамвайга төшеп, менеп, шәһәрнең кырыена килеп чыгамыз. Югарыда, иске бер кальга, аның уртасында – бер чиркәү. Кальганың капкасыннан үтеп, борылып-борылып менәмез. Тау өстендә – ташландык кальга. Ләкин манзара әйтеп бетерерлек түгел. Бер яктан, Ока* кебек сузылып, Влтава суы ага. Аның теге ягында кызыл урманнар кояшка каршы көлеп ята. Бер якта зур Прага сузылып яткан. Ул үзенең бөек чиркәү манаралары берлән күккә таба сузылган. Үзенең эчендәге гөнаһысын яшерер өчен кебек, бөтен авызларыннан, тишекләреннән чыгарган төтен берлән, өстен кечкенә генә бер флер[2] берлән каплаган. Флер астында аның челтәрләгән башнялары, манаралары тагы челтәрлерәк күренә. Аның бөек зур өйләре тагы олуграк, мәһабәтрәк күренә. Төтен астында

---

[1] Асаре кадимәсенең – археологик истәлекләренең.

* Ока – Россиянең Европа өлешендә, Идел елгасының иң зур кушылдыгы булган елга.

[2] Флер – сөрем, томан.

аның иске сарайлары тагы картрак, тагы искерәк күренә. Томан астында шәһәрнең кырые чит йирнең кырыена кадәр сузылган кебек. Күкнең очына кадәр тигән кебек хис ителә. Иске кальганың өстендә бик озак йөреп, тәмам арып, бер каһвәханәгә керәмез. Күп нәрсә күрү, күп йиргә менеп төшүдән тән дә арыган, баш та арыган. Начар каһвә дә аруны киметә алмый, кәефне китерә алмый. Аерылышып, өйләргә кайтып китәмез.

Кич берлән бүген мин Праганың Мещанский урамы тарафында бирелә торган зыяфәткә[1] чакырылган. Сәгать җиде ярымда шунда китәргә кирәк. Әллә нинди бер урамнан табып, чакырылган йиргә барам. Сәгать 7 ½ генә булса да, зал шыгрым тулган. Безне шәһәрнең гласныйлары каршы ала. Бер урын күрсәтәләр, утырамыз. Халык килгәннән-килә. Бүген русларның [...] һәм дә Праганың бөтен аристократы чакырылган икән. Залда меңнән артык кеше бар. Зыяфәттә элгәре – концерт, аннан соң – чәй зыяфәте. Концерт һаман башланмый. Әллә кемне көтәләр. Ахырдан доктор Крамаржны* көтү мәгълүм була. Бер сәгатьләр кичегеп, Крамарж килә. Бөтен халык, аягүрә торып, кул чабып каршы ала. Концерт башлана. Гади начар концерт. Тирә-ягымдагы халыкка карыйм, һәммәсе пөхтә генә киенгән, ләкин хатыннардан һичбер матур иттереп киенгән бер ханым юк. Петроград, Мәскәү, хәтта Казандагы кадәр туалет[2] юк. Дүрт-биш йөз хатын эчендә күзгә ташланырлык матур бер хатын да юк. Бар да – таза гына, нык кына хатыннар. Бар да ямьсез түгел, бар да матур түгел. Барысы да үзләренең кнедликилары кебек чиле-пешле. Концерттан соң Крамарж чехча һәм дә русча нотык сөйли. Бу кеше мәшһүр панславян булганга, һәм дә күптән түгел генә баш министр булып торганга, бүгенге көннәрдә генә Деникинга** барып кайтканга, моның сүзләре әһәмияттән хали[3] түгел. Нотыгы гади.

---

[1] Зыяфәткә – кунакка.

* Доктор Крамарж – Карел Крамарж (1860–1937), сәясәт эшлеклесе, бәйсез Чехословакиянең беренче премьер-министры.

[2] Туалет – м о н д а: «бизәнү» мәгънәсендә.

** Деникин – Антон Иванович Деникин (1872–1947), генерал-лейтенант, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, Гражданнар сугышында Аклар хәрәкәте лидерларыннан берсе.

[3] Хали – буш.

Русияне сөю, Русиядән славян дәүләте ясап чыгару өмид итүдән гыйбарәт. Аңарга каршы монда Колчакның вәкиле булып тора торган Рафальский дигән поляк җавап бирә. Бик начар сөйли. Мәгънәсез тәмамлый. Чәй бүлмәсендә мине Крамаржга тәкъдим итәләр. Сөйләшеп китәмез. Мин: «Без, Русияне ныгыту ягында булсак та, сезнең берлән бер фикердә түгел. Без Русияне үзенең халкының мәнфәгатен саклаучы бер мәмләкәт итәргә телимез. Шуның өчен, әгәр сез Русиянең славян дәүләте булуны мәркәзе сикъләт[1] итсәңез, безнең берлән рус халкы арасындагы дустлыкка зарбә[2] сугасыз», – дидем. Шул мәсьәләне мөзакәрә иткәндә[3] Фуад килеп катышты. Крамаржны бераз кыздырды. Боларда мәкъбүл булмаган[4] тондарак моназарә тарызына[5] керде. Шуның өчен мин сүзне кыскартырга муафикъ күрдем. Күрешеп, киттем. Мәҗлес шактый күңелле үтте. Ләкин мин, бүген бик арыганга, начар йокладым. Иртәгә, насыйп булса, француз сәфарәтенә барамыз. Безнең Садрига дигән мәктүб бүген киткән.

*26 нчы гыйнвар*

Бүген без Франсә сәфарәтенең вәгъдәсе буенча сәгать өчтә сәфарәтханәгә барамыз. Анда безгә виза бирү-бирмәүләрен аерым әйтәчәкләр иде. Ләкин без барганда сәркатип килмәгән. Ул берәр ярты сәгатьтән килә, диделәр. Бер каһвәдә көтеп, тагы керәмез. Сәркатип һаман юк. Аның могавине[6] берлән сөйлимез. Ләкин ул безгә катгый бер сүз дә әйтә алмый. Сәркатип берлән сөйләшергә кирәк иде, ди. Кайчан киләчәк, дигән сөалемезгә каршы, берәр сәгатьтән булса кирәк, ди. Иртә кайвакыт була дигән сөалемезгә, иртә берлән сәгать 9 ½ дән 12 ½ кадәр, дип җавап бирә. Без иртәгә иртә берлән сәгать уннарда килергә булып китәмез.

Бүген төнлә берлән минем икенче мәртәбә Петроградта тәүкыйф ителүемә[7] сигез ел тулды. Шул тәүкыйфтән соң икенче мәртәбә Архангельга сөргенгә җибәрелгән идем.

---

[1] Мәркәзе сикъләт – төп авырлык.
[2] Зарбә – зыян.
[3] Мөзакәрә иткәндә – фикер алышканда.
[4] Мәкъбүл булмаган – кабул ителмәгән.
[5] Моназарә тарызына – бәхәс стиленә.
[6] Могавине – ярдәмчесе.
[7] Тәүкыйф ителүемә – кулга алынуыма.

*27 нче гыйнвар*

Иртүк торып, Франсә сәфарәтханәсенә барамыз. Сәркатип һаман юк. Кайчан килүе дә мәгълүм түгел. Тагы могавин берлән сөйләшәмез. Ул, безнең хакта мәгълүматы бик аз булганга, бер дә ачык җавап бирә алмый. Ләкин сүзләреннән үзләренең, виза бирмәенчә, Парижга мөрәҗәгать итүләре аңлашыла. Димәк, безгә чехларның һичбер ярдәмнәре тимәде. Никадәр руслыкны яшерергә теләсәк тә, һаман мөгамәлә руска булганча булды.

Парижга мөрәҗәгать ителсә, ичмасам, телеграф берлән мөрәҗәгать ителсен иде, дип сорыймыз. Могавин кичкә таба бөтен мәгълүматны җыеп, безгә телефон кагарга вәгъдә бирә. Шул телефонны көтәмез. Тагы бернәрсә мәгълүм түгел, фәкать сәркатип безне иртәгә сәгать унбергә үзенә чакыра. Ярый, хәерле булсын. Тагы барыйк. Сугышка кадәр бер минутта эшләнеп бетә торган эшне никадәр мөшкелләткәннәр. Франсәгә керү оҗмахка керүмени? Без чыдарга тиеш. Милләтнең балалары булганга чыдармыз инде. Көн шулай бушка үтә. Иртәгә бераз ачылыр инде. Ләкин инде монда виза алуга өмидемез бетте.

Көн бик пычрак. Тагы карлы ягмур ява. Бер-ике көн аяк асты азрак коры булып торган иде. Русиягә киткән егетләрдән һаман хәбәр юк. Әллә инде барып чыга алмадылар?

*28 нче гыйнвар*

Иртүк торып, тагы Франсә сәфарәтенә киттек. Безне сәркатип тиз үк кабул итте. Утыртты, сөйләште. Виза монда бирә алмыйлар, имеш. Шуның өчен Парижга мөрәҗәгать итәләр. Фәкать безгә җиңеллек ясар өчен, үзләре телеграф берлән мөрәҗәгать итәчәкләр. Шуның өчен бераз мәгълүмат кирәк, имеш. Бездән кайда тууымыз, яшемез күпмелекне сорап ала да бүген телеграмма бирергә вәгъдә итә. Җавап килгәч тә безгә хәбәр бирер өчен, адресларымызны алып кала. Сәркатипнең сүзенә караганда, берәр атнадан җавап булырга тиеш, имеш. Без Садрига да бүген үк шуны аңлатып, телеграмма бирдек. Белмим инде, ни булып калыр. Ләкин бу арада Төркия – Русия мәсьәләсе мәйданда булганга, безнең анда булуымыз бик лязим иде инде.

Көн бик пычрак. Бүген мин үземә җәйлек бер пальто тегәргә бирдем. Акча мәсьәләмез һаман шулай тора. Ләкин бу арада, имеш, рус акчасының курсы күтәрелгән. Садрига да шул акчалар хакында мәгълүмат сорап язган идек. Бакалым, инде ни булыр. Эшсез тик тору бик туйдырды. Көн дә көтеп, көн дә көтеп, эшкә керешү мөмкин түгел.

*29 нчы гыйнвар*

Бүген акча мәсьәләмез бераз хәл ителергә тиеш иде. Безгә актык мәгълүматны китерергә кирәкләр иде. Ләкин вәгъдә биргән кешемез тагы вәгъдәсендә тормады. Өйдә булмады. Ни булганын белми калдык.

*30 нчы гыйнвар*

Акча мәсьәләмез ачылды кебек булды. Иртәгә акчаларны күтәреп барырга да эшне рәсмиләштерергә, безнең акчаларның яртысына хәзердән крон бирәләр, яртысына ике айдан бирәчәк булалар. Бу да үзенчә бертөрле эшне юлга сала. Без калган акчага үземезнең адресны биреп китәмез була. Иртәгә сәгать унбердә Фуад акчаны күтәреп барырга була. Бакалым, тагы ни чыгар. Кырык төрле вәгъдәдән әле бер нәтиҗә чыкмаганга, минем инде мондагы сүзләргә ышанычым бик кичте.

*31 нче гыйнвар*

Русиягә китүче бер чех артыннан мин Харбин Гыйнаять муллага озын бер мәктүб язам. Үземезнең әхваль берлән таныштырам. Фуад Востокның Исхак Әхсановка яза. Аларга бер айлык «Голос России»* дигән газетаны җибәрәмез, мондагы әхваль берлән бераз танышсыннар. Милли Идарәгә бернәрсә дә язмыйм. Чөнки аларның кайдалыгы мәгълүм түгел. Гыйнаять муллага шул мәктүбне Милли Идарәгә, дуст-ишкә дә белдерергә үтенәм.

Акча мәсьәләмез тагы шулайрак булып чыкты. Теге кеше тагы бүген вәгъдәсендә тора алмады. Барырга тиеш урынга бара алмады. Шуңарга эше иртәгә калды. Ләкин иртәгә якшәмбе,

---

* «Голос России» – 1919–1922 елларда Берлинда чыккан рус эмигрант газетасы.

банклар, мөәссәсәләр[1] ябык, шуңарга иртәгә эшләп булмый. Дүшәмбе тагы әллә нинди бер католик монахы йә торган, йә үлгән? Тагы банклар ябык. Ул көн дә булмый. Тагы кичик.

Миңа бик каты суык тиде. Ютәл төште. Мондагы юеш һава бик начар тәэсир итә.

*1 нче февраль*

Бәйрәм булганга, иртүк торып, шәһәр карарга китәмез. Праганың элгәреге заманда яһүд каласы булган урынын карыймыз. Коруне вөстада[2] ул яһүд кальгасы булса да, хәзер тәмам шәһәр берлән кушылган һәм дә шәһәрнең иң бай йире булып калган. Элеккеге яһүдлектән калма монда шәһәр уртасында бер зиярәт бар. Иске берничә синагог бар. Иске синагоглар кечкенәләр, ярлылар. Хәзер күбе ташландык. Шуларның берсендә коруне вөстада мондагы бөтен яһүдне җыеп кискәннәр. Ләкин хәзер яһүдиләр бөтен хокуктан файдалана. Бер урамда «Жидовский музеюм»[3] дип язып куелган. Ләкин музей ни өчендер бүген ябык. Шуңарга эченә керә алмыймыз. Урамнарны карап йөреп, немецлардан калган музейларның бер бүлегенә керәмез. Бу – санагать[4] музәсе. Бу – мондагы Рудольфинумның* бер кыйсеме генә. Зур бүлеге ябык була. Санагать музейсы һәр йирдә инде бертөрлерәк. Махсус булмаган кешегә әллә ни кызыгы юк. Дикъкатьне җәлеп итә торган нәрсә булса, ул да музәханәдәге костел (чиркәү) бүлмәсе. Бер бүлмәне тәмамән чиркәү иттереп җыйнаганнар. Алтарьлар, тәреләре, камкалары, лампалары, кыңгыраулары, төрле төстәге чүпрәкләре, попларның гыйбадәт киемнәре, савытлары – һәммәсе үз урынында. Эченә кергәч, тәмамән чиркәүгә кергән кебек буласың. Ләкин үзе чиркәү түгел. Үзе – чехның сәнгать әсәре, үзе – чехның дин хәятының асаре гатикасы[5].

---

[1] Мөәссәсәләр – оешмалар.

[2] Коруне вөстада – Урта гасырда.

[3] «Жидовский музеюм» – «Яһүдиләр музее».

* Рудольфинум – Прага шәһәренең үзәгендә урнашкан концерт һәм күргәзмә залы (галерея), хәзерге вакытта Ян Палач исемен йөртә торган мәйданда. 1885 елның 7 нче февралендә ачылган. Австро-Венгрия империясе принцы хөрмәтенә Рудольф исеме белән аталган.

[4] Санагать – сәнгать.

[5] Асаре гатикасы – археологик истәлек.

Чиркәүдә мөкаддәс[1] иттереп хисапланган бу тәреләрне болай санагать музейга кую караучыларда дингә дә адәм баласының ясаган бер нәрсәсе, адәм баласының һөнәрләреннән булган бер һөнәре дигән хисне калдырып, дине тәүсыяны[2] бетерүгә хезмәт итә булырга кирәк.

Икенче дикъкать ителә торган нәрсә – чехларның өй тормышларының корылышын күрсәткән бүлмә. Чехларда кунак бүлмәсе искедә тәмамән төрек ысулында булган икән. Шулай ук төрек бүлмәсенең зиннәтләре: бәлки, боларда кунак бүлмәсе дигән нәрсә үзләрендә һич булмаенча, төрекләрнең галәбәсе[3] вакытында төрекләр аша славяннарның аристократия[се] генә кергәндер.

Бу бүлмәдә күзгә төрекчә язулы бер тарелка чагыла. Укып карыйм. Матур иттереп тәгъликъ* берлән язылган зиннәтле тарелка. Язулары бу рәвешчә: «Ләһ кырале кәмале мәхәббәтлә вә изһары сәдакатьлә иһда идептер. Але Госман падишаһына»**. Урта бер йирдә «Мәкамы Варшава» диелгән[4]. Бу тарелка – Польша корольләренең берсе тарафыннан төрек солтаннарының берсенә бирелгән һәдия[5], күрәсең. Төркиянең сарайларыннан урланган да, кулдан кулга йөри-йөри, Праганың музәсенә килеп кергән. Музейда халык күп түгел. Караучыларның күбе балачага. Музейда хезмәтче һич күренми. Әйбер урлатудан бер дә курыкмыйлармы, әллә монда урларга кыйммәтле нәрсәләр юкмы? Кайбер кадерлерәк нәрсәләр шкаф эченә куелган булса да, бик күбе ачык шүрлек, киштәдә булганга, урларга теләгән кешегә урлау бик җиңел булырга кирәк. Безнең Русиядә бу хәлдә булса, ике-өч атнада яртысы урланып беткән булыр иде.

Көн бик юеш, ягмур явып тора. Без ашарга кергәндә, бераз ачылып китә дә, шуннан файдаланып, суның теге ягындагы тауга менеп китәмез. Анда үзенә тагы бер шәһәр бар икән. Бу

---

[1] Мөкаддәс – изге.

[2] Дине тәүсыяны – динне киләсе буынга тапшыруны.

[3] Галәбәсе – җиңүе.

* Тәгъликъ – гарәп хәрефләре белән языла торган язу төрләреннән берсенең исеме.

** Польша короле камил мәхәббәт белән тугрылыгын күрсәтеп бүләк иткән Госманлы патшасына.

[4] Урта бер җирдә «Варшавада» диелгән.

[5] Һәдия – бүләк.

Летняя дигән йирләре (җәйлек), элгәре җәйлек булган, хәзер шәһәргә әверелгән иде. Зур бер парк бар. Эчендә – элгәреге Австрия наместнигының сарае. Хәзер ул рәисе җөмһүрнең сарае булган. Көн ачык булганга, югартын шәһәр бик матур күренә. Бу Прага җәй көне бик матур манзара булырга кирәк. Көндез юештә йөрүдән мин тагы авырыйм. Ютәлем куәтләнә. Бәйрәм булганга, әлбәттә, бер эш тә эшләнелми.

*2 нче февраль*

Әллә нинди бәйрәм булганга, акча мәсьәләсе бүген дә юлга куелмый. Иртәгә инде, катгый иттереп, шул эшне бетерергә вәгъдә итәләр. Көн бик юеш, минем ютәлем һаман бетми. Садридан мәктүб килергә кирәк иде инде. Һаман бернәрсә дә юк. Тагы эш бик сузыла инде, ахрысы.

*3 нче февраль*

Акча мәсьәләсе һаман рәткә куелмады. Расходлык кына өчдүрт мең сум алыштырып бирергә булдылар. Калганын тагы көтәргә тугры килә. Садридан хәбәр юк. Виза хакында бер мәгълүмат та юк. Һичбер яңалык юк.

*4 нче февраль*

Прагага килүемезгә ике ай вакыт үтте. Бер эш эшләп булмады. Бүген китәмез, иртәгә китәмез, дип, эшкә керешеп булмады. Вакыт бик әрәм булды. Һәр көн, сәгать көтәргә китте. Бу ел – бөтен елым әрәм үтте. Бернәрсә яза алмадым, бернәрсә укый алмадым. Хәерле булсын. Иншалла, казасын кылырмыз әле.

*5 нче февраль*

Бүген әллә нинди начар төшләр күреп беттем. Берсе, үзем большевикларга качкан, имеш тә, аларның лагерьларында торам, имеш. Лагерьлары төрле яктан камап алынганнар. Менәменә большевик дошманнары җиңә, дип, көтеп торамыз икән. Мин дә шулар арасында, ни дип соң большевик беткәндә генә кайттым икән, дип, кайгырып торам икән. Икенчесе, этине* күр-

---

* Әти – Г. Исхакыйның этисе имам Гыйлаҗетдин Исхаков (1838–1919).

дем. Мәсҗедкә бара икән. Мине Хәлим озатсын, ди. Әллә эти үлде микән? Үлгән булса – Хәлим дә үләргә хәзерләнә микән? Шулар көн буе рухны басып торды.

Красный Кресттан* гына өч мең сум акча алмаштырып алдык. Бүген бөтен банкларны йөреп чыктым. Рус акчасын – һичбер төрлесен – һичбер йирдә алмыйлар. Бүген Русиягә киткән кешеләрдән хәбәр алынды. Варшавадан Русиягә таба сау-сәламәт үткәннәр. Хат булыр, дигәннәр. Димәк, бер-ике атнадан минем хәбәр Мәскәүгә барып җитә. Аннан да, бәлки, берәр җавап алып булыр.

*6 нчы февраль*

Бүгеннең иң зур мәсьәләсе Садри әфәндедән алынган телеграмма булды. Безгә Франсәгә керергә виза биргәннәр. Димәк, багышлап чыккан йиргә барырга рөхсәт унөченче айда алынды. Эшнең никадәр авыр эшләнүен шуннан уйлап бел инде. Хәзер мондагы консулханәгә киләчәк кәгазьне генә көтәргә калды. Ихтимал, ул да бер-ике көндә килеп җитәр. Шулай без уйлаганча чыкса, насыйп булса, егерменче февральдә Парижда булсак кирәк. Бәлки, мин үземнең туган көнемне, ягъни 42 яшь тулган көнне, Парижда каршы алырмын. Инде эшләр шулай уңга китеп, милли вазифаны юллый алсак иде. Аллага тапшырдык инде.

Себердән шул арада берәр мәктүб кирәк иде дә, юк. Бу арада берничә мәртәбә төштә Гомәрне** һәм дә Габдулла Кариевны*** күрдем. Һәрберсендә икесен дә бергәрәк күрәм. Икесе дә әллә нишләп, эварә булып йөрмәсәләр ярый инде. Икесе дә бик куркаклар, икесе дә – бик кирәк кешеләр.

*7 нче февраль*

Ялгыз бернәрсә дә юк. Безгә бүген тагы бер өч мең сум акча алыштырып бирәчәкләр иделәр, булдыра алмаганнар. Иртәгә

---

* Красный Крест – Кызыл Хач, гаделлек принципларына нигезләнеп, бөтен дөнья буенча эшчәнлек алып барган гуманитар оешма. Ул кораллы конфликтлар һәм эчке тәртипсезлекләр корбаннарына яклау һәм ярдәм күрсәтә.

** Гомәр – Гомәр Терегулов булса кирәк.

*** Габдулла Кариев – Миңлебай Хәйруллин (1886–1920), беренче татар профессиональ театр труппасына нигез салучыларның берсе. Габдулла Кариев 1920 елның 28 нче гыйнварында үлгән.

инде якшәмбе, бәйрәм, тагы берни булмый. Көтик инде, безгә бит көтәргә язылган инде.

Бүген музаханәгә бардык. Бер дә искитәрлек нәрсә юк, гади.

*8 нче февраль*

Виноградыы дигән йирдәге театрга бардык. Театры кечкенә генә, ләхчә генә. «Яшьләргә гыйбрәт» дигән бер пьеса куйдылар. Чехларның истикъляльы өчен тартышу дәвереннән алып язылган. Ләкин пьеса сәнгать җәһәтеннән караганда бик ибтидаи. Темасы нинди бай булса да, шуны матур мантыйкый иттереп чыгара алмаган. Пьесада һичбер мәләкә[1] юк. Керәләр дә, сөйлиләр дә чыгалар, керәләр дә, сөйлиләр дә, чыгалар да, һичбер действия бармый. Ахырдан гына пьесаның җилеге булачак действие килеп чыга. Ул да әхвальдән табигый булып тумый, күктән төшә. Милли рухны кыздырыр өчен, озын-озын монологлар сөйлиләр. Чехларга тәэсир итә, ләкин әҗнәби[2] кешегә, театрдан сәнгать көткән караучыларга хисе нәфасәтене мыскыл итүдән башка бернәрсә булмый. Болар, милли рухны үстерер өчен, санагате нәфасәтне[3], фәне тарихын – һәммәсен фида иткәннәр икән. Менә шул җәгъли[4] тәрбия берлән хакыйкатән милли гаяләренә ирешкәннәр. Үзләренең аерым дәүләтләрен ясаганнар. Инде алларында икенче мәсьәлә туган – шул дәүләтне алып бару. Аны алып барыр өчен, әлбәттә, ялган тәрбия бирү фәнне хакыйкатән инкяр итеп, чехның һәрнәрсәсе шәптер, немецның һәрнәрсәсе начар дигән кыскартма фикерләре эшкә яраячак түгелдер. Аның өчен бөтен мохиткә, бөтен әхвальгә аек күз берлән карап, шуннан чыккан нәтиҗәләр берлән гамәлләр итәргә тиештер. Ләкин иске тәрбияләре шул нәтиҗәләрнең тәмам тискәресенә булганга, чех халкында, бер яктан, иске тәрбиядән алдану фикере туачактыр, икенчедән, милләтнең эчендә иске агым берлән яңа агым арасында зур тартышу китәчәктер. Шунда чех милләте милләт уларак кала беләчәкме, юкмы? Киләчәк күрсәтер.

---

[1] Мәләкә – осталык.

[2] Әҗнәби – чит ил кешесенә.

[3] Санагате нәфасәтне – нәфис сәнгатьне.

[4] Җәгъли – ясалма.

*9 нчы февраль*

Бүген безгә Франсә консулханәсеннән телефон кагарга тиешләр иде. Булмады. Үземез барып чыгуны муафикъ күрмәдек. Акчаны бүген дә алыштыра алмаган. Бик уңмаган кешегә грифтар булдык[1].

*10 нчы февраль*

Бүген Франсә консулханәсеннән телефон булмады. Җавап почта берлән килмәсә ярар иде. Акчаны бүген дә алыштыра алмаган. Иртә[гә] инде эшлим дип, бик катгый вәгъдә бирде. Ләкин бу вәгъдәсе кырыгынчы булганга, алдавы кырык беренче булганга, һич ышанып булмый.

*11 нче февраль*

Бүген кич берлән безгә француз консулханәсеннән телефон кагуы мәгълүм булды. Иртәгә виза бирергә чакырганнар. Иртәгә сәгать унда барырга вәгъдәләштек. Алла хәерлегә итсен. Ютәлем һаман бетми.

*12 нче февраль*

Бүген безгә француз консулханәсендә виза бирделәр. Виза, Франсәнең хариҗия нәзарәтенең рөхсәте берлән, диелгән. Һәм дә өстенә, дипломатический виза, дип язылган. Димәк, без хәзер рәсман дипломат булып киттек. Бүген Садридан мәктүб алдым. Озын мәктүб, үзенең әхваленнән язган. Мескин, өч ай большевиктан качып йөреп эштән чыккан икән. Сәламәт калуы да бер мәхәббәттән кенә килгән. Аннан соң ул, музыйкый халыкчы[2] булып, Финляндиягә чыккан. Аннан инде Европага үткән. Май башында Франсәгә килгән. Хәзер шактый күп эшләп ята. Төркия мәсьәләсе хакында бик тугры адымнар эшләгән. Шуңарга бик сөендем. Мәктүбне тәфсыйлләп язмыйм. Бәлки, бер вакыт матбугатка чыгарырга кирәк булыр. Акча мәсьәләмез һаман хатасыз: руза кебек, йир берлән күк арасында селкенеп тора. Ютәлем куәтләнә генә бара.

[1] Грифтар булдык – дучар булдык.

[2] Музыйкый халыкчы – музыкачы.

*13 нче февраль*

Иртүк акча мәсьәләсе берлән төрле йирләргә, күрсәтелгән күрешү урыннарына киттем. Күрешәсе кеше берлән күрештем. Акча мәсьәләсе тәмам хәл ителгән, имеш. Аннан һич куркасы юк, имеш. Ләкин гамәли яктан һаман акча юк. Бүген кичкә ашка җитәрлек акчам юк. Кичке сәгать биштә кайчанга акча алуны әйтәчәк иде. Ләкин вәгъдә куйган йиренә килмәде. Бу сузулар руслыктан гына киләме, әллә эшнең эчендә без аңламаган бер-бер нәрсә бармы? Акча бик кирәк. Бердән, китәргә булганга, аласы әйберләр бар. Икенчедән, тегүчедә киемнәремез бар. Шуларга бирергә кирәк. Өченчедән, шул акчаларны франкка алыштырырга кирәк. Болар һәммәсе дә вакыт сорый. Халәнки без 21 нче февральдә, якшәмбе көн китәргә булып куйдык. Белмим, ни булыр?

Бүген мин кайтуга, бер конверт калдырып киткәннәр. Конвертына «Лигансион де рус» дигән печать басылган. Эчендә мондагы Колчакның консулы мине үзенә чакыра. Һәм дә «үзеңезгә шәхсан гаид[1] мәсьәлә хакында» дип тәэкид итә[2]. Ул нинди мәсьәләдер? Шактый уйга калдырды. Әллә Ибнеяминнәр, Колчактан тасдыйк иттерәмез[3], дип, безнең хакта алар безнең вәкилләр түгел, дип, мөрәҗәгать иттеләрме икән дә шул хакта, үләр алдыннан, Колчак хөкүмәте үзенең кешеләренә хәбәр бирдеме икән? Бәлки, французлар һаман шул иске гадәт буенча безнең хакта шул Колчак кешесе Рафальский дигән поляктан мәгълүмат сорадылармы икән? Һәр нә исә – кызык бер нәрсә. Фуадка да шул мәктүб булырга кирәк. Уйлап-уйлап, шул хакта бер карарга килә алмадык. Фуад бармау ягында булды, мин барып чыгу һәм дә мәсьәләнең әсасен[4] аңлау ягында булдым.

*14 [нче] февраль*

Акча бүген бертөрле хәл кылынырга кирәк иде. Тагы бернәрсә булмады. Әллә кем тугры килмәде, әллә кем өйдә булмады. Әллә кеме җавап алмаган. Шәркый сәясәт кебек бернәрсә. Киткән руслардан озын мәктүб алынды. Варшауга бик сау-сәламәт

[1] Гаид – караган, бәйле.
[2] Тәэкид итә – басым ясый.
[3] Тасдыйк иттерәмез – раслатабыз.
[4] Әсасен – асылын.

барып җиткәннәр. Һәм дә чыгып китәргә рөхсәт тә алганнар. Варшауда хәят юлындарак, һәрнәрсә бар. Валютага тормыш очсыз, диелгән. Монда сөйләнелгән куркынулар дөрест булмаган, күрәсең. Бүген төштә Заһидны күрдем. Ихтимал, теге руслар, Мәскәүгә барып җитеп, Заһидны күреп сөйләшкәннәрдер. Китәсе бик килә иде дә, белмим, ни чыгар. Рафальскийның мәктүбенә җавап та бирмәдек, язмадык та. Ютәлем һич бетми.

*15 нче февраль*

Якшәмбе булганга, шәһәр карап йөрдек. Пароход берлән Дачный урамга бардык. Праганың бер тарафы ялангачрак булганга, бик матур түгел икән. Иртәгә акча хакында катгый җавап булачак кебек иде. Әлбәттә, булмас.

*16 нчы февраль*

Акча хакында берни эшләп булмый дигән җавап алдык. Ике ай буе алдап йөрттеләр-йөрттеләр дә, инде булмый, дип җавап кайтардылар. Шуңарга аптырап калдым. Китәргә дә акчамыз юк. Иеннарны алыштырсак, аның курсы монда бик очсыз. Америка доллары йөз дә өч крон булганда, иенга 25 крон гына бирәләр. Халәнки бер долларга бер иен да туксан ике цент кына бирәләр. Шуңарга аңардан да зарар итәчәкмез. Алтынны сатарга имкян бер дә күренми. Инде нишләргә дә аптырап калдык. Якшәмбе көнгә китәрмез дип уйлаган идек. Булдыра алмамыз, ахрысы. Тегүчедә киемнәремез ята, түләп алырга акча юк. Хәерлегә булсын.

*17 нче февраль*

Бүген төшемдә тагы большевик мәмләкәтенә кайтып, качып йөреп, йөдәп чыктым. Төштә Шәмголовны күрдем. Эшче булып йорт сөрә. Без бит инде шулай эшче булдык, ди. Ихтимал, безнең рус егетләре, кайтып, безнең хакта берәр хәбәр сөйләгәннәрдер. Бүген акча хакында тагы яңа бер йиргә барырга булдылар. Аннан ни чыга, Алла белә.

*18 нче февраль*

Красный Крест безнең акчаны алыштырырга разый булган, имеш. Иртәгә, акчаны күтәреп, шунда барамыз. Бакалым, ни чыгар? Якшәмбе китә алмамыз, ахрысы.

# 17 нче дәфтәр

*19 нчы февраль*

Красный Крест акчамызны алыштырырга разый булды. Ләкин берничә көнсез эш бетәчәк түгел. Якшәмбе китә алмаячакмыз.

Бүген чехларның парламентларына бардым. Бу – чехословак җөмһүренең беренче Милләт Мәҗлесе, ләкин бу халыктан сайлау ысулы берлән җыелмаган, бәлки төрле партияләрдән вәкил күндерү исәбенә корылган. Шул ук Милләт Мәҗлесе төп кануннарда эшли. Шуңарга күрә бу Учредительное собраниедә (Мәҗлесе мөәссәсан) дә, бинасы зур түгел. Тыштан һичбер төрле парламент бинасына охшамаган. Эчтән дә бик үгрәк шәп түгел. Бик күп ишекле, караңгы-караңгы коридорлы бер өй. Вәкилләренең саны ике йөз алтмыш чамасында икән. Араларында биш хатын да күрдек. Парламентның эчке тормышы һичбер төрле мин күргән парламентлар хәятына охшамый. Рәисе Мәҗлесне ачты да әллә нәрсәләр укырга тотынды. Депутатлар урындык араларында рәискә якын бер йирдә җыелдылар да тордылар. Бер почмакта биш-алты кеше җыелган. Бер почмакта – җиде-сигез, бер почмакта – ун-унбиш. Һәммәсе үзенә аерым мәсьәләләр берлән мәшгуль, рәисне тыңламый да, илтифат та итми. Бик күбе бер груһка да катышмаенча йөреп тора. Рәис һаман укый, әллә нидә бер кыңгырау шылтыратып ала. Җыелган груһлар, бу нинди ят тавыш, дип, башларын күтәреп карыйлар да тагы сөйләшергә тотыналар. Рәис, укуын бетереп, бер мәсьәлә хакында доклад ясаучыны чакыра. Анысы бик озын иттереп язган бер нәрсәне укый. Мәҗлес һаман үзенең мохтар[1] хәяты берлән яши бирә. Менә рәис кыңгырау кага, тавышка куям, утырышыңыз, ди. Зиярәт өстендә үлекне күмеп бетергәч, фатихага[2] утырган кебек, һәммәсе дөр итеп утыралар. Рәис аякка калку ысулы берлән тавышка куя. Депутатлар, тәмле сүзләрен бүлдергән шул уенны уйнап бетереп, тагы торып, тагы әкияткә керешәләр, тагы йөрер-

---

[1] Мохтар – ирекле, бәйсез.

[2] Фатихага – кул күтәреп дога кылуга.

гә тотыналар. Бер аксак вәкил таякка таянган да, бакчада йөргән кебек, залда ары барып, бире килеп, йөри дә тора. Тагы бер кеше чыгып, үзенең нотыгын укый. Тагы әллә нәрсә тәкъдим итә. Тагы тавышка куялар. Тагы дөр итеп утыралар. Аллага шөкер, тәравих* тәмам дигән кебек, дөбердәшеп торып, тагы сөйләшергә тотыналар. Шул комедия өч-дүрт мәртәбә кабатлангач, секретарь бер истифсар укый. Истифсар (запрос) Мажарстанның Словакиядәге хәрәкәте хакында, шуңарга харидҗия назыйре[1] Бенеш**, торып, хәзер җавап бирәчәк. Харидҗия назыйре – яшь кенә бер егет. Моннан элгәреге нотыкларны укыганда, шактый гакыллы бер егет хисен калдырган булса да, бу нотыкны сөйләгәнме, язганны укыганмы дигән бер сөаль дә күңелгә килә иде. Шуңарга күрә мин моны дикъкать берлә тыңларга тотындым. Тырышып тыңлаганда, бер сүзен дә ычкындырмаганда, мин хәзер чехча аңлыйм. Җавап башлана. Бенеш бик күп кәгазь күтәреп чыга да машинада язылган шул кәгазьләрне бит артыннан бит укый бара. Депутатлар кафедраның янын сырып алалар да укучы егетнең авызына карап торалар. Бер ярты сәгать укый да министр төшә. Шуның берлән Мәҗлес тәмам. Депутатларның күпмесе утырып торганын берничә мәртәбә санадым. Йөз иллеләп вәкил арасында һичбер вакытта да утыручыларның саны утыздан артмады, егермедән кимемәде. Шунысы гаҗәп: һәр мәртәбәсендә биш хатыннан дүрт хатын утыру хәлендә булды. Хатыннарда утырырга ихтыяҗ күбрәк, күрәсең. Бу Милләт Мәҗлесе үзенең базар хәле берлән бик начар хис калдыра. Чехларның парламент хәятларына иманын бик киметә. Моңынчага кадәр күргән минем дүрт милләтнең дүрт парламентыннан бу парламент иң мәгънәсезе, иң парламентка охшамаганы. Безнең Милләт Мәҗлесендәге эшләр, андагы тәртип моңарга караганда йөз мәртәбә артык иде.

---

* Тәравих – уразада кич белән укыла торган намаз.

[1] Харидҗия назыйре – тышкы эшләр министры.

** Бенеш – Эдвард Бенеш (1884–1948), Чехословакиянең дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Чехословакия бәйсезлеге өчен хәрәкәт лидерларының берсе, 1918–1935 елларда тышкы эшләр министры.

*20 нче февраль*

Красный Крест бүген рус акчасын алып килергә чакырды. Бүген акча мәсьәләсе хәл ителәчәк. Безгә, йөзенә туксан геллердан* хисаплап, чех кроны бирәчәкләр. Хәзер франкның курсы чех кронына җиде кроннар булганга, безгә бер франкка яшел сигез сумнарга килгән була. Акча бөтенләй әрәм булуга караганда, бу да ярый инде. Фуад акчаларны күтәреп китте. Мәсьәлә хәл ителде дигәч кенә, тагы эш чуалды. Иван Михайлович** безнең акчаның думскийлар икәнен әйтмәгән икән. Чехлар аны царский дип белгәннәр. Шуңарга эшне тәмам яңадан башларга кирәк булды. Ике [ай] ярым шул акчалар артыннан йөреп, шуның иң әһәмиятле булган ноктасын, думскийлыкны аерып әйтә алмаслык дәрәҗәдә ахмак булырга инде, чынлап та, шул рус әсире булырга кирәк. Моңынча көн дә лыгырдап йөреп, бу кеше ни сөйләгән? Моңарга ни әйтә аласың инде? Мөкәлләф[1] түгел шул. Соң шундый ике бозауга кибәк аерып бирә алмый торган кешеләргә, мәмләкәт башында торганда, ул мәмләкәттә ни булсын инде? Шул ахмакның ахмаклыгы хакында безнең исем тагы чуалды, тагы акчасыз калдык. Хәзер Садрига*** телеграмма бирергә дә акчамыз юк. Иеннар сатып була, ләкин аларны сатасы килми. Царскийларны да сатып була, ләкин алар монда бик очсыз. Швейцариядә боларның кроннары берлән царский бер сумга бер крон да сиксән геллер биргәндә, монда фәкать сиксән геллер генә бирәләр. Хәерле булсын. Тагы китә алмыймыз, күрәсең. Инде тагы бер мәртәбә бер кеше эшләргә вәгъдә бирде, ни булыр.

*21 нче февраль*

Бернәрсә булмады. Үземезгә ашар-эчәр өчен генә, меңәр сум легионерлар кассасыннан алыштырып алмакчы идек, аны да

---

* Геллер – Урта гасыр Европа акча берәмлеге. Башта немец пфеннигының бер төре булган, аннары – Австро-Венгрия һәм чех кронының йөздән бер өлешенә тигез. 2009 елдан чыгарудан туктатыла.

** Иван Михайлович – Иван Михайлович Брушвит (1879–1946), эсер, Учредительное собрание әгъзасы, Комуч хакимиятендә финанс министры.

[1] Мөкәлләф – җаваплы.

*** Садри – Садри Максуди турында сүз бара.

булдыра алмадык. Аннан-моннан бурычка алып йөримез. Хәерле булсын. Дүшәмбе көнгә берәр җавап алырмыз, дип торамыз. Теге Русия миссиясе дип чакырган кешегә бармадык та, җавап та бирмәдек. Берәр зарары тимәсә ярый инде.

*22 нче февраль*

Иртүк рәсемнәр музәханәсенә[1] бардым. Бина бик зур булса да, өч кенә бүлмәсе ачык. Болар да тулган. Шул Гайсә берлән Мәрьям, Мәрьям берлән Гайсә, тәредән гыйбарәт. Башка бүлмәләрендә рәсемнәр күп, имеш. Аннан бер рәсемнәр выставкасына кердек. Футуристлар выставкасы. Боларның футуристлары да русларныкы кебек: үзе ахмак, үзе мәгънәсез, үзе талантсыз икән. Бөтен осталыклары кәкре-бөкре иттереп, ялангач хатынның гаурәтен күрсәтүдән гыйбарәт. Аннан чехларның элгәре үзләре ясаган музәләренә бардык. Анысында чех хәятына гаид[2] бик күп нәрсә бар. Безгә дә шундый музей ясарга кирәк. Насыйп булса, исән-сау булсак, эшләрмез әле.

Иртәгә тагы акча мәсьәләмез хакында җавап бирергә булдылар. Бакалым, ни булыр?

*23 нче февраль (искечә 10 нчы февраль)*

Минем туган көнем. Мин бу көнне, гадәттә, бәйрәм итә идем. Берничә елдан бирле төрле йирдә читтә тугры килеп, бәйрәмсез үтте. Үткән ел солых һәйәте[3] өчен акча җыю сәфәрендә Иркутскида идем. Бу ел һаман очы чыкмаган Солых сәфәрендә, Прагада. Киләсе елга кайда булырмын? Ләүхел мәхфуздә[4] генә языла. Үткән елгы 23 нче февральдән 20 нче елның 23 нче февраленә кадәр ни эшләдем дигән сөальгә хәзер ни җавап бирәсең?

Иң кыска, иң тугры җавап: «Көттем».

Мин элгәре акча җыелуны көттем. Аннан Милли Идарәдән җавап көттем. Аннан Фуадлар* килгәнне көттем. Аннан Франциядән җавап көттем. Аннан тагы Милли Идарәдән җавап

---

[1] Музәханәсенә – музеена.
[2] Гаид – караган.
[3] Һәйәте – комиссиясе.
[4] Ләүхел мәхфуздә – язмыш китабында.
* Фуадлар – Фуад Туктаров турында сүз бара.

көттем. Аннан акча алыштыруны көттем. Аннан тагы Фуадны көттем. Аннан Читага киткән Гомәрне* көттем. Аннан пароход көттем. Прагада чехларның документларны юлга куюларын көттем. Аннан Франсәнең рөхсәт бирүен көттем. Аннан акча алыштыруны көттем. Хәзер дә шуны көтәм. Бу көтү инде актык көтү булып, икенче елга да мирас тарикы[1] берлән чыкмасын иде. Кулда бер тиен дә акча булмаганга, ел буе көтү бик туйдырганга, әхвале рухиям[2] бәйрәмчә булмады. Һичбер төсле чәй мәҗлесе, фәлән дә ясамадым. Вазифаны үтәгәч тә, мәҗлесләр ясарга өлгерермез әле.

Акча хакында бүген җавап булачак иде. Тагы бер хәбәр дә булмады. Тагы көттек.

*24 нче февраль*

Фуад теге акча эшендә ярдәм итәчәк чехны күрергә киткән иде. Таба алмаган. Бүген ун иен алыштырып, бераз ашарлык акча алдык. Бер иенга 25 крон гына бирделәр. Садрига** 29 нчы февральдә чыгамыз дип, телеграмма бирдек. Ул да инде көтәкөтә көт булгандыр. Акча алыштыра алсак, бәлки, китә алырмыз.

*25 нче февраль*

Бүген безнең акчаларга каршы сумына 37 геллер, ихтимал, бирәмез дигән җавап алдык. Иртәгә шул сумма тирәсендә катгый җавап бирмәкче булалар. Халәнки[3], безгә беренче вәгъдәләре 90 геллер берлән алыштыру иде. Парижда, шөбһәсез, бу акчалар мондагы бәһадән күтәренке. Ләкин безнең кулда башка акча юкка, шуны алырга мәҗбүрмез. Фәкать шуны залог тарызында[4] салып, безнең акчаларны Парижга җибәртеп, анда түләп алырга мөмкин булса иде дигән бер үтенеч ясадык. Кабул итәрләрме, юкмы – мәгълүм түгел. Чехларның сүзләренә һич ышаныр хәл юк. Минемчә, болай булачагын белсәк, әлбәттә, башкачарак акча табу юлына кергән булыр идек. Иң әүвәл Брушвит алдап йөртте,

* Гомәр – Гомәр Терегулов турында сүз бара.
[1] Тарикы – ысулы.
[2] Әхвале рухиям – рухи халәтем.
** Садри – Садри Максуди турында сүз бара.
[3] Халәнки – чынлыкта.
[4] Тарызында – ысулында.

аннан ары болары. Бөтен руслар туксаншарга алыштырганда, без фәкать кырыкка алыштырамыз.

*26 нчы февраль*

Бүген безгә телефон берлә, акчаларымызны залогка алып, сумына 37 геллер бирергә вәгъдә бирделәр. Иртәгә акчаларны алып килергә куштылар. Без, үземездән бөтен безнең рус акчаларымызны Париждагы чехларның сәфарәтханәләренә җибәртеп, анда түләп алырга ясарга үтендек. Әгәр шулай итсәләр, яхшы була. Башка кешеләр 90 шар геллерга алыштырганда, без шулай өч ай көтеп, рәзаләт[1] чигәргә мәҗбүр булдык. Безнең татарлыкның җәзасы – чех татардан никадәр ярдәм күргәне хәлдә, безгә, шул милләтнең вәкилләренә, шундый кечкенә генә ярдәм дә булмады. Халәнки, рус акчасының монда йөрмәве чех хөкүмәтенең чит сәүдәне үз кулына әгъзар[2] итеп ясаган сыйнфый сәясәттән генә килә. Швейцариядә рус акчасы боларның кронынnan бәһале. Һәм дә рус акчасы боларга – Сибириядә 40 мең гаскәре булган ханга кирәктән. Шул җитмеш-сиксән мең татар милләтенең акчасын үз бәһасенә алганда, әлбәттә, чех дәүләте җимерелмәс иде. Халкымызны шулкадәр талаган чех милләте алдында безгә аз булса да, кечкенә булса, бер түләү булыр иде. Болар әле шулай файдаларын гына белеп, башкалар берлән һич хисаплашмаенча дөнья кормакчы булалар. Бөтен милләтне һәлакәткә этеп чыгарган шул сәясәт чех милләтенә нигә мал булыр? Аны кая этеп терәячәк? Чәһәршәнбе[3] көн китәр өчен язылырга булдык. Акча алсак, киемнәремезне алачакмыз. Юлга хәзерләнәчәкмез.

*27 нче февраль*

Кулдагы акчаны биреп, 15 мең крон алдык. Банкага залог салганнарымызны биреп, тагы 15 мең алачакмыз. Шуңарга китәргә юл ачылды. Ләкин якшәмбе өлгерә алмыймыз. Аннан соңгы поездда китәргә кирәк була. Беренче марттан Париж берлән Прага арасында йөри торган поездларның маршруты үзгәрәчәк.

---

[1] Рәзаләт – хурлык, түбәнлек.
[2] Әгъзар – әгъзалар.
[3] Чәһәршәнбе – чәршәмбе.

Моңынчага кадәр поездлар Швейцария аша йөри иде. Март башыннан Германия аша китәчәк. Бу, бердән, безнең юлны кыскартачак, икенчедән, бераз очсызланачак. Фәкать яңа юлның әле көннәре мәгълүм түгел. Бүген кич берлән Фуад белешеп язылырга булды. Нә исә, чәршәмбесез китә алмыймыз. Садрига, язылгач та, ачык телеграмма бирәчәкмез. Кичә акча булып, киемнәрне алдым.

*28 [нче] февраль*

Поездга язылырга мөмкин булмаган. Шул язылу эше бер мөәссәсәдән икенчегә бирелү дәверендә булганга, берсендә эш беткән, икенчесе әле дүшәмбесез башламаячак. Акча берлән тагы чуалчык туды. Теге ахмак рус безнең акчаны сиксән дип яздырган. Безнеке җитмеш алты гына. Шуңарга тагы дүрт мең яшел табарга кирәк. Инде үземез сатып алырга буламыз.

*29 нчы февраль*

Якшәмбе булды. Бер эш тә эшләп булмады. Вакыты мәгълүм булмаганга, Садрига телеграмма бирә алмадык. Төрле музейлар карап йөрдем. Бүген төштә Нияз Максудины* күрдем. Мескен әллә нишләп, мәшәкатькә эләкмәсә ярый инде.

*1 нче март*

Фуад бүген поездга язылырга барды. Гадәт буенча соңга калган. Чәршәмбе, җомга китә торган поездларга урынны аңардан иртә торган кешеләр алып бетергәннәр. Алай да, урын калса, җомгага бирергә булганнар. Ләкин Фуад эшне якшәмбе[гә] калдырырга маташа кебек күренә. Бүген мин көн буе, теге сумманы тутырыр өчен, дүрт мең яшел акча эзләдем. Һич табып булмый. Тапсак, бик кыйммәт. Җитмеш-сиксәнне сорыйлар. Акча берлән эш итә торган мөәссәсәләр[1] унике ярымда ябылганга, бер эш эшләп булмый. Ул тагы чүп өстенә чүмәлә булды. Имеш, 37 гә үзең сат та, шуны тутырыр өчен, алтмыш-җитмешкә алып түлә.

* Нияз Максуди – Троицк каласында мәдрәсә мөдире. 1914 елда Нью-Йорк университетының тәгълим-тәрбия факультетында укыган.

[1] Мөәссәсәләр – оешмалар.

Бүген мондагы Немец театрына* бардым. Монда театрның иң искесе. Бер-ике йөз ел элек салынганы. Бик зур. Биш яруслы иттереп эшләнгән. Бинасы матур җиһазлы булса да, иске стильдә. Бик яхшы уйнадылар. Бик һәйбәт тавышлар бар. Һәм дә бик оста уйныйлар. Телен аңламасам да, музыкасы һәм дә нәфасәте[1] берлән бик зур күңел азыгы бирде. Күптән мондый уен, мондый оста театр күрмәгән идем. Чехларның театрына караганда, кеше йөри. Кул сузымы югары. Ләкин бина бик суык. Халык киемнән утыра. Һәм дә бакчага нык бер төрле пернү исе чыккан. Утлар бик аз. Чехлар якмыйлар, яктыртыр өчен күмер дә бирмиләр, электричество да бирмиләр икән. Шул суыклык һәм дә ут юклыктан немецларның бик күп мәктәпләрендә сабак та укылмый икән. Менә сиңа тагы бер гадаләт[2].

*2 нче март*

Көн тагы дүрт меңне эзләргә үтте. Табып булмады. Иртәгә бары берлән китәргә булдык. Бүген тагы берничә банкадан сораштым. Яшелләрне күпмегә аласыз дип сорагач, утыз һалиш, диләр. Күпмегә сатасыз, дигәч, туксан һалиш, диләр. Бу бер йирдә генә түгел, берничә йирдә шулай булды. Димәк, болар берлән сату-алу ахмак өчен генә мөмкин. Мондый кечкенә халык шул үзен генә бик гакыллы дип утыртканга, һәм дә сәүдәнең мөштәрәк[3] мәнфәгатьләр әсасына корылганын аңламаганга, әлбәттә, алуда да, сатуда да бер эш эшли алмаячаклар. Сату-алуга хөррият булды исә, үзләренең урыннарын башкаларга – яһүдләр, немецларга бирергә мәҗбүр булачаклар.

Иртәгә Фуад, иртүк барып, җомгага билет булу-булмауны белешергә булды. Садрига һаман телеграмма бирә алмадык. Мең ярым кронга сатып алырга рөхсәт алдык. Ләкин крон

---

* Немец театры – бүгенге көндә Прага дәүләт операсы дип аталган Чехия опера театры 1888 елда Яңа немец театры буларак ачылган. 1949–1989 елларда ул Сметана театры дип аталган. 1883 елда ук Прага немец җәмгыятендә үзләренең немец телендәге опера театрын булдыру теләге туган була. Ул вакытта Чехия җирләре Австрия-Венгрия империясенең өлеше саналганлыктан, Прагада немецлар күп булган.

[1] Нәфасәте – гүзәллеге.

[2] Гадаләт – гаделлек.

[3] Мөштәрәк – уртак.

һаман менә бара. Бер көнне алты крон 44 кә төшкән иде. Бүген тагы җиде булды. Прага бик туйдырды инде. Китәсе, Аллага тапшырып.

*3 нче март*

Тагы яңа хәбәр: Франсәдә тимер юл эшчеләре эш ташлаганга, җомга көн поездның китү-китмәве мәгълүм түгел. Иртәгә эш мәгълүм булачак. Акча эшен һаман бетерә алмадык. Дүрт мең сум яшел һаман таба алмадык. Бер чех банкасы 42 гә алып бирергә вәгъдә иткән иде, ул да булдыра алмады. Иртәгә ни булыр инде. Кичкә таба тимер юл забастовкасы беткән дигән хәбәр чыкты. 2 нче мартта килгән чех эшелоны берлән бер татар офицеры килгән, имеш. Ул кемдер инде? Әллә инде Солтанбәк лыгырдап килеп чыктымы? Иртәгә мәгълүм булачак.

*4 нче март*

Бүген безнең Прагага килеп җитүемезгә тәмам өч ай тулды. Атна-ун көннән китәчәк кешеләр – һаман әле монда ятамыз. Дүрт меңне таба алмаганга, акча эшемезне шулай 76 меңгә 27 мең крон алып кына тәмамладык. Акчаны Франсәгә җибәрергә вәгъдә алдык. Франсәдә тимер юл забастовкасы тәмам булса да, әле монда бер поезд да килмәгәнгә, Прагадан поездның кайвакыт китәчәге мәгълүм түгел. Тагы иртәгә килергә куштылар. Чехның да «иртәгәсе» русның «завтрасы»ннан* ким түгел икән. Акчамыз азлык итәр төсле күренә. Тимер юл бәһасе бик кыйммәт. Мәсәлән, ике көн өчен ятак кына 154 кронга чыкты. Мең дә бер йөз крон, ягъни өч мең дә дүрт йөз сум. Ник улкадәр кыйммәтле ятак кирәк? Ике көн генә йокламаенча чыдап булмыймыни дигән сөаль килә түгелме? Бик була. Мин һәрвакыт 154 кронга ике көнне төнли алдым. Ләкин ятаксыз билет сатмыйлар. Билет кыйммәтме булачак? Тагы мәгълүм түгел. Акчамыз җитсә ярый инде.

*5 нче март*

Бүген Франсәдән поездның чыгуы һәм дә Прагага килеп җитүе мәгълүм булды. Шул ук поезд җидесендә, якшәмбе көн

---

* Чыганакта бу сүз кириллицада язылган.

Прагадан китәчәк, ди. Ләкин атна эчендә бер поезд да китмәгәнгә, безгә поездга билет булмас, диделәр. Ачулангач, кәефсезләнгәч, тагы сәгать дүрткә килегез, диделәр.

Бүген мең дә ике йөз франк алдык. Бәһасе җидешәр кроннан. Мондагы курс яшелгә егерме бер сумнан. Көннәр бик йылы. Агачлар яфрак ярырга тора. Һәммә кеше җәйге пальтодан йөри. Садрига һаман телеграмма бирә алмадык. Теге килгән татар офицерының кемлеген белә алмадык.

*6 нчы март*

Бүген сәгать дүрттә безгә билет саттылар. Димәк, иртәгә, насыйп булса, сәгать 4 тә китәмез. Иртәгә чех җөмһүриятенең рәисе Масарикның туган көне* һәм дә җитмеш яшь тулган көне. Чехлар бик зур бәйрәм ясарга хәзерләнәләр. Рәтләп күрә алмыймыз. Бүген таныш-белеш руслар, чехлар берлән күрешеп йөрдем. Иеннар җыештырдым. Акчамыз җитмәве мәгълүм булды. Шуңарга күрә иртәгә банкалар да ябык булганга, дуст-ишләрдән генә бераз иен алыштырамыз инде. Алла хәерле юл бирсен инде.

Үзем рухан вә хисмән чехлыкка сәламәт килеп, сәламәт китәм.

*7 нче март*

Иртүк көн ачык. Ун дәрәҗә йылы бар. Масарикның туган көне булганга, урам тулы халык. Минем урамда карап йөрергә вакытым юк. Сәгать өчтә вокзалга төшәмез. Без монда Чех-Австрия хөдүденә[1] кадәр билет алдык. Әйберләремезне багажга алалар. Бер чемоданымның багажга бирелүенә минем бераз кәефем китә. Үзем юкта бер озатучы биреп өлгергән. Вагонга йирләшәмез. Бик һәйбәт урын. Сәгать 4 тә 12 минутта поездымыз кузгалып китте. Тугыз ярымда Чех хөдүденнән узып, Австриягә кердек. Хөдүдтә чех түрәләре әйберләремезне карамакчы булдылар. Ләкин карточкаларымызны күрсәткәч, карамаенча киттеләр. Австриядә яңадан Австрия таможыннан үтәр өчен,

---

* Масарикның туган көне – Томаш Гарриг Масарик (7 март, 1850–1937), чех фәлсәфәчесе, Австрия-Мажарстанның һәм Чехословакиянең дәүләт эшлеклесе, Чехословакиянең беренче президенты (1918–1935).

[1] Хөдүденә – чигенә.

билетлар алдык. Икемезгә йөз кырык биш франк түләдек. Монда берничә чех берлән танышып алдык. Иншалла, исән-сау барып җитәчәкмез. Инде безгә Швейцариядә бер мәртәбә, Франсәгә тагы бер мәртәбә билетлар алырга калды. Иншалла, акчамыз җитәр. Безнең поезд фәкать өч кенә вагоннан гыйбарәт. Аның да берсе багаж өчен. Бик пөхтә иттереп урын җәеп бирделәр. Бүген коры-сары гына ашап ятарга булдык.

*8 нче март*

Иртә торганда без Тирольда*, Альп таулары эчендә. Тышта бер туктамаенча карлы ягмур явып тора. Сәгать уннарда безнең поезд Иннсбрук дигән Австрия шәһәрендә озак торды. Швейцария аша бара торган юлда тимер юл ватылганга, безне Италия аша җибәрәчәкләр. Шуңарга күрә, шуңарга безнең Швейцария читенә кадәр алган билетларымыз җитми, тагы билет аламыз. Багажларымыз өчен дә тагы түлимез. Италиянең шималеннән буйлап чыгарга булганга, безнең юл тагы бер тәүлеккә озая, ягъни без Италиянең Милан, Турин дигән шәһәрләрен үтеп китәчәкмез дә Франсәнең читеннән килеп керәчәкмез. Бу, бердән, юлны суза, икенчедән, кырык хөдүддән үтәргә кирәк булганга, бик күп мәшәкатьләр тудырачак. Чөнки һәрбер хөдүдтә кереп, тикшереп, йөдәтеп бетерәләр. Өченчедән, безнең акчамыз бик кысынкы булганга, акчасызлыкка эләгүемез ихтималымыз бар. Хәерле булсын инде.

Әле сәгать берләрдә дә һаман карлы буран эченнән Альпның астыннан чыккан туннельдән туннельгә кереп, Италиягә таба, җәнүбкә[1] таба хәрәкәт итәмез. Прагада кояшлы йылы яздан – карлы-сазлы пычрак язга, сәгать икедә Италия чигенә килеп җиттек. Юеш буран дәвам итә. Безнең әйберләрне тагы бер мәртәбә карарга маташып, эштән чыктылар. Әллә нинди рәсмиләр булырга кирәк, поездымыз мондагы хөдүд стансасында тора да тора. Мондагы буран безнең Себер бураны кебек икән. Аерма шунда гына, анда буран коры була, монда юеш. Көн буе бүген һаман ап-ачык кар өстеннән барамыз. Сәгать囲 бишт sure поездымыз кузгалып китә. Әллә никадәр туннельләр кереп-чыгып,

* Тироль – Альп тауларының көнчыгыш өлешендәге тарихи төбәк.
[1] Җәнүбкә – көньякка.

Альптан төшә бара. Сигезләрдә кар бетә, һава йылына төшә. Без төнлә берлән Миланда булырга тиеш. Кич берлән аш ашадык. 17 шәр франк алдылар. Биниһая[1] кыйммәт. Прагада 17 франкка бик шәп ашап була иде. Без өченче көнгә барып җитсәк кирәк. Бик күп кешеләр берлән таныштык. Бик күбе русча белә. Әлегә әле мәшәкатькә очраганымыз юк. Акчамыз җитсә ярый инде.

*9 нчы март*

Расписание буенча без бүген сәгать сигез дә егерме минутта Парижга барып җитәргә кирәк иде. Безне сәгать җидедә, билетка түләргә дип, Италиянең кечкенә бер шәһәрендә уяттылар. Без монда багаж өчен 166 лира түләдек. Италиядән үткән өчен 280 лира түләдек. Тагы да хөдүдкә кадәр барып җитәр өчен, утызышар лира түләдек. Кулымызда Италия лирасы булмаганга, шуларны франк берлән түләргә тугры килде. Франкны бик озак алыштыра алмаенча, эштән чыктык.

Без әле һаман Альп таулары эчендә. Җидедә килеп туктаган кешеләр, сәгать унбердә генә кузгалып киттек. Ләкин Франсәгә таба түгел, тагы Швейцариягә таба. Анда тагы түләячәкмез. Күпме алачаклар, бер Аллага гына мәгълүм. Мәсәлән, ярты сәгатьлек юл – хөдүдкә кадәр булган юлга Италия 35 шәр лира алды. Бу ел бездә сугышка кадәр беренче класста бер сум, бер сум ун тиеннәр булырга тиеш иде. Уникенче яртыга кадәр берничә зур туннельләрне үтеп, Швейцария хөдүденә килеп җиттек. Анда тагы безне туктаттылар. Тагы паспортларны алып киттеләр. Күпмегә кадәр торырмыз, мәгълүм түгел. Хәзер безнең акчамызның җитмәве мәгълүм булды. Бәлки, берәр йирдән иеннар алыштырып булыр. Бәлки, мондагы бер таныш чехтан алып булыр. Альп монда фәүкыльгадә мәһабәт. Ләкин кәеф булмаганга, аларга карап булмый. Юкны да ашап барырга акча җитмәгәнгә, без икмәк берлән Садри әфәндегә бүләккә дигән конфетны ашап барамыз. Сау-сәламәт барып җитәмезме – Аллага мәгълүм. Италия чигендә ике сәгать туктап торганның соңында, 1 ½ сәгатьтә Италия берлән Швейцария арасындагы Альп таулары астыннан үткән зур туннельгә кереп китәмез. Туннельне 34 минут кичәмез. 4 минут туктап торганны чыгарганда да утыз

[1] Биниһая – бик.

минут була. Туннельнең озынлыгы күпмелеген белә алмадым. 14 километр икән. Исеме Симплонски (Simplon*) икән. Аннан без туп-тугры Швейцариягә килеп чыгамыз. Монда тагы никадәр тотарлар? Анысы, әлбәттә, мәгълүм түгел. Аннан Швейцарияне аркылы кисеп, Франсәгә чыгамыз. Швейцариядә күп[ме] алдыклар әлегә мәгълүм түгел. Тәмам ике сәгатьтә Швейцариядә. Ике ярымнарда Швейцариядән поездымыз кузгала. Безнең поезд электрический. Бик кызу бара. Без әйләнеп-әйләнеп туннельләр кичеп, Альпны үтәмез. Сәгать 4 ½ дә без [...]. Әле [...] кар берлән капланган. Табигать Финляндияне хәтерләтә. Бездән билет өчен әллә нинди стансага кадәр иллешәр франк алдылар. Тагы әле алачаклар. Бүген кич берлән Франсә чигенә җитсәк кирәк. Бүген аш ашамадык. Икмәк берлән конфет бергә бутап, бик тәмле иттереп сугындык.

Сәгать җиделәрдә Швейцариянең Франсәгә якын бер стансасында яңадан Швейцария өчен билетлар алдырдылар. Икемезгә йөз кырык дүрт франк алдылар. Бу әле Франсә чигенә кадәр генә. Аннан соң тагы билет алачакмыз. Бу – безнең җиденче мәртәбә билет алуымыз. Монда безнең акчамызның җитмәве катгый мәгълүм булганга, без бер чех таныштан йөз франк бурычка алдык. Дүрт франкка мин колбаса һәм дә шоколад алып кердем. Бик тәмле иттереп кечке ашны ашадык. Сәгать уннарда Франсә чигенә килеп җиттек. Анда безнең әйберләремез[не] тамож[ня]дан үткәрделәр. Бернәрсәмезгә дә бәйләнмәделәр. Ләкин ачтырып, көттереп бик арыттылар. Аннан Парижга кадәр билет алдык. Бусы – сигезенче мәртәбә билет алуымыз. Икемезгә йөз туксан алты франк түләдек. Кесәдә биш франкымыз калды да әле. Поездымыз уникеләрдә китәчәк, имеш. Паспортларымызга печатьләр суктылар. Иртәгә, насыйп булса, Парижга иртән барып керәмез.

*10 нчы март*

Иртә уянганда, поездымыз куян куган кебек чаба. Ике якта да бик күп фермалар, урманнар. Тирәсенә агач утыртылган таш юллар кала. Поездымыз, әллә нигә өлгерергә тырышкан кебек, ашыкканнан ашыга бара. Менә сәгать тугыз. Әнә Париж күренә.

* Бу сүз латин хәрефләре белән язылган.

Ләкин әле бу – Парижның морҗалары гына. Менә тагы берничә минут кичте. Менә заводлар, менә фабрикалар, менә Парижның яңа бистәсе. Тагы берничә минут безнең поезд кечкенә бер вокзалда. Без әле монда туктамыймыз. Тагы китәмез. Менә тагы вокзал. Бөтен халык актарыла. Без дә чыгамыз. Ләкин, никтер, Садри әфәнде безне көтми. Хәер, беркемне дә монда беркем дә көтми. Бәлки, мондагы гадәт буенча платформага чыгару юктыр. Вокзалның бер йирендә көтә торгандыр. Менә безнең әйберләрне бер арбага төяп алып киттеләр. Борылып-борылып, вокзалның бүлмәләрен үтәмез. Бер бүлмәдә безне туктаталар, тагы караячаклар. Тагы әллә нәрсәләр эзләячәкләр. Монысы инде Парижның бәләдиясе[1] карый. Без рөхсәтсез йомыркамы, йаймы[2], күмерме алып килмимезме? Виза дипломатик дип җавап бирәмез. Һәм дә күрсәтмәенчә керәмез. Менә монда инде Садри әфәнде безне көтәчәк. Каранамыз, эзләнәмез – анда да юк. Таксомотор алып, Садри әфәнде торган номерга таба китәмез. Ләкин бәласе шул: безнең калган акчамыз таксомоторга түләргә җитмәү ихтималы бар. Садри әфәнде өйдә булмаса – нишлимез, ул бөтенләй Парижда булмаса – нинди хәрәкәттә буламыз. Менә без хәзер Париж урамында. Парижның урамнарының беренче тәэсире берлән һичбер төрле безнең чиккән мәшәкатьләргә мөнәсәбәт күренми. Урам – бер урам, Истанбул урамнарыннан бер урам. Аннан яңа да түгел, шәп тә түгел. Ни өчен соң бу шәһәргә килүне оҗмахка керү берлән бер дәрәҗәдәге авырлыкларга баглаганнар? Менә Сена нәһере, менә аның күпере. Елгасы Дим киңлеге. Бер елга күпере, Прагадагы кебек бер күпер. Тагы тар урам. Тагы киң урам. Ләкин хәйран калырлык һичбер нәрсә юк. Менә Садри әфәнде тора торган «Виктория палас» отеле. Керәмез. Мусьё Максудов... Капычы телефон кага. Садри өйдә икән, хәзер төшәчәк. Садри әфәнде сау-сәламәт. Бераз яшәргән дә. Таксомоторга ун франк түләп җибәрәмез. Аллага шөкер, инде без Парижда. 14 айдан бирле омтылган Парижда. Инде килдек. Эшне иңләткән бер урамга аяк бастык. Ләкин безгә бу номерда бүлмә юк. Бәлки, кичкә булыр, диләр. Әйберләрне

[1] Бәләдиясе – шәһәр идарәсе.
[2] Йаймы – маймы.

калдырып, бер каһвәгә барып, иртә[н]ге каһвәне эчәмез. Өйлә ашын Садри әфәндедә ашыймыз. Кичкә, бәлки, номер булачак. Бакалым. Көтик, без көтәргә өйрәнгән. Өйләдән соң Галимәрдан бәк* берлән күрешергә китәмез. Ул бу тарафта түгел. Бөтенләй башка якта. Парижның уртасында, Парижның беренче дәрәҗә номерында. Коточкыч зур караван сарай, коточкыч кыйммәт бәһа. Иң кечкенә номер – ашау-эчүсез 75 франк. Галимәрдан бәк Лондонга киткән икән. Әле кайтып җитә алмаган. Карточкаларымызны калдырып, өйгә кайтамыз. Номер бүген безгә юк. Иртәгә булачак. Бүген тактадан ясалган Мәкәрҗә номеры** кебек бер суык, юеш номерга гына кереп кунамыз. Шуңарга да 12 шәр франк түлимез. Париж беренче көнне бик сөеп каршы алмады. Һава суыкча гына, пычрак кына.

* Галимәрдан бәк – Галимәрдан Галиәкбәр улы Тупчыбашев (1863–1932), Азәрбайҗан иҗтимагый һәм дәүләт эшлеклесе, юрист һәм журналист, Беренче Дәүләт думасы депутаты (1906), Азәрбайҗан Демократик Республикасы парламенты рәисе (1918–1920).

** Мәкәрҗә номеры – Мәкәрҗә ярминкәсенә килгән кешеләргә кунар өчен әзерләнгән бүлмәләр күздә тотылган.

# Кушымта



Гаяз Исхакый (1878–1954)



Гаяз Исхакый япон тюркологы
Кочи Окубо белән. Токио




Г. Исхакый көндәлегенең тышлыгы.
1919 ел, 13 нче дәфтәр



Г. Исхакый көндәлегенең
кулъязмасы. 1919 ел, 12 нче дәфтәр



Гаяз Исхакый *(беренче рәттә, уртада)* һәм Гомәр Терегулов (1883–1938) *(беренче рәттә, уңнан беренче)* татар эмигрантлары белән. Токио. 1919 ел



Татар милли хәрәкәте лидерлары: Гаяз Исхакый *(сулдан беренче)*, Садри Максуди (1878–1957) *(уртада)*, Фуад Туктаров (1880–1938)



Азәрбайҗан иҗтимагый һәм дәүләт эшлеклесе Галимәрдан Тупчыбашев (1863–1934)



Сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе Латыйф Яушев (? – 1922) хатыны Камилә белән



Иркутск сәүдәгәре Шәйхулла Шәфигуллин



Француз сәясәтчесе һәм дәүләт эшлеклесе, журналист Жорж Клемансо (1841–1929)



Журналист, тел белгече Гарольд Вильямс (1876–1928)



Бәйсез Чехословакиянең беренче премьер-министры Карел Крамарж (1860–1937)



Чехословак дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе Вацлав Клофач (1868–1942)



Җәмәгать эшлеклесе, Комучның мәгариф министры, мөхәррир Егор Лазарев (1855–1937)



Япония дәүләт эшлеклесе Окума Сигэнобу (1838–1922)



Чехословакия дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе Эдвард Бенеш (1884–1948)



Сәясәт эшлеклесе Николай Чайковский (1851–1926)

## Китапта файдаланылган фоторәсемнәр түбәндәге чыганаклардан алынды:

- *ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге (135 нче фонд);*
- *Лена Гайнанованың шәхси архивы;*
- *Надир Дәүләт. «Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды» (Казан, 2005);*
- *интернет ресурлар:*

https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%A2%D0%BE%D0%BF%D1%87%D0%B8%D0%B1%D0%B0%D1%88%D0%B5%D0%B2,_%D0%90%D0%BB%D0%B8%D0%BC%D0%B0%D1%80%D0%B4%D0%B0%D0%BD-%D0%B1%D0%B5%D0%BA. – 7.04.2023;

https://arhistrazh.livejournal.com/268267.html. – 7.04.2023;

https://decabristka003.livejournal.com/4564.html. – 7.04.2023;

https://ru.citaty.net/avtory/zhorzh-klemanso/. – 7.04.2023;

https://ru.wikisource.org/wiki/%D0%93%D0%B0%D1%80%D0%BE%D0%BB%D1%8C%D0%B4_%D0%92%D0%B8%D0%BB%D1%8C%D1%8F%D0%BC%D1%81. – 7.04.2023;

https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%9A%D1%80%D0%B0%D0%BC%D0%B0%D1%80%D0%B6,_%D0%9A%D0%B0%D1%80%D0%B5%D0%BB. – 7.04.2023;

https://pardubice.rozhlas.cz/politici-regionu-8367734/3. – 7.04.2023;

https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%9B%D0%B0%D0%B7%D0%B0%D1%80%D0%B5%D0%B2,_%D0%95%D0%B3%D0%BE%D1%80_%D0%95%D0%B3%D0%BE%D1%80%D0%BE%D0%B2%D0%B8%D1%87. – 7.04.2023;

https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%9E%D0%BA%D1%83%D0%BC%D0%B0_%D0%A1%D0%B8%D0%B3%D1%8D%D0%BD%D0%BE%D0%B1%D1%83. – 7.04.2023;

https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%91%D0%B5%D0%BD%D0%B5%D1%88,_%D0%AD%D0%B4%D0%B2%D0%B0%D1%80%D0%B4. – 7.04.2023;

https://arhlib.ru/2021/08/nikolaj-chajkovskij-istoricheskij-portret/. – 7.04.2023.

# ЭЧТӘЛЕК


Төзүчеләрдән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
«Шул өмидсез истикъбаль алдында рухымыздагы пакьлекне саклый алырмызмы?» *Д.Ф. Заһидуллина* . . . . . 7
2 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
3 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
4 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
5 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
6 нчы дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
7 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
8 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
9 нчы дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
10 нчы дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
11 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
12 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
13 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
14 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
15 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
16 нчы дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
17 нче дәфтәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Кушымта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293

Научно-популярное издание

**Гаяз Исхаки**

**ДНЕВНИКИ**

**Книга 1**

(на татарском языке)

Редактор *А.А. Давлетова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать: 24.03.2023 г.
Формат 60×84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Times New Roman».
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 14,1. Тираж 500 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20